# казан утлары

2
ФЕВРАЛЬ · 1974

# Таныш булыйк

*Казан якларыннан килеп Пермь губернасының Көңгер шәһәрендә төпләнеп калган Габдрахман агай семьясында 1908 елны бер малай дөньяга килә. Аңар Фәйзерахман дип исем бирәләр.*

*Башка малайлардан бер ягы белән аерыла Фәйзерахман: рәсем ясарга ярата. 3—4 яшендә үк инде ул таныш-белешләренең портретларын шактый охшашлы итеп ясый торган була.*

*Җиденче классны тәмамлагач, сәнгать техникумына укырга керә. 1931 еллардан Пермь опера һәм балет театрында художник-декоратор булып эшли. Яшь егеттә белем алу дәрте көчле була. Ләкин бу хыялына ул сугыштан соң гына ирешә ала. Фәйзерахман Әминев 1948 елда Ленинградта И. Е. Репин исемендәге сәнгать институтын тәмамлый.*

*Художник Әминев картиналарының тематикасы асылда татар халкына, аның фольклор иҗатына һәм күренекле кешеләренең портрет-образларына нык бәйләнештә үсә. Аның диплом эше дә «Сабан туе» дип атала. Бу картина күп кенә күргәзмәләрдә куела, үз вакытында матбугатта басыла, аерым открытка, эстамп булып та халыкка тарала.*

*Үткән ел Казанның сәнгать музеенда Фәйзерахман Әминевнең әсәрләреннән төзелгән аерым (шәхси) күргәзмәсе булып узды. Тамашачылар күргәзмәне зур кызыксыну һәм күңел канәгатьлеге белән ай буе карадылар һәм рәссам исеменә бик күп мактау сүзләре, рәхмәтләр әйттеләр.*

*Бу күргәзмәдә бигрәк тә Габдулла Тукай иҗатына багышланган әсәрләр, татар көйләренә карата эшләнгән «Кара урман», «Салкын чишмә», «Тукай үзенең образлары арасында», «Тукай — Кырлай урманнарында» дигән картиналары, халкыбызның күренекле кешеләре — физика-математика фәннәре докторы Шәфика Шәрәф, профессор Фәттах, сәнгать фәннәре кандидаты Энҗе Сәгыйтова, I ранг капитаны Янбулат Төхфәтуллиннарның портретлары уңышлы эшләнгәннәр, алар тамашачыларда зур канәгатьләнү хисе калдырдылар.*

*Журналыбызның шушы саныннан башлап татар совет язучыларының Фәйзерахман ага Әминев ясаган портретларын укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итә барачакбыз.*

*Тышлыкның 3 битендә Хәсән Туфанның Фәйзерахман Әминев тарафыннан эшләнгән портретын урнаштырабыз.*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

2

ФЕВРАЛЬ
1974

## Бу санда

В. НУРУЛЛИН. Әгәр син булмасаң... Повесть . . 3
Д. СИРАЙ. Авыл поэмасы . . . . . . . . . 37
Г. АХУНОВ. Ардуан батыр. Повесть . . . . . 43
Р. ГӘРӘЙ. Җайлашмыйбыз. Шигырьләр . . . . 84
Р. ВӘЛИЕВ. Туган як. Шигырьләр . . . . . . 86

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 88
Ә. ГАЙНУЛЛИН. Ашкынулы булсаң... . . . . . 90

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

Г. РАМАЗАНОВ. Үкендермәс мине үткән гомерем. 102

ЛЕНИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦ-ФАШИСТ ИЛБАСАРЛАРЫН ТАР-МАР ИТҮГӘ 30 ЕЛ

Ленинград өчен сугышларда . . . . . . . . 107

ЯЗУЧЫНЫҢ ИҖАТ ЛАБОРАТОРИЯСЕННӘН

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Кояш тотылганда табылган хәзинә . . . . . . . . . . . . . . . . 117

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Х. САРЬЯН. «Алай да була!» — булмасын . . . 128

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ү. ГЫЙМАДИЕВ. «Чикерткә» — татар телендә беренче сатирик журнал . . . . . . . . . 140
Ф. МАХИЯНОВ. Колхозчы шагыйрь Г. Насыйров . 144

МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Я. АБДУЛЛИН. Дини тәгълиматка һәм суфичылыкка каршы . . . . . . . . . . . . . 149

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

А. АЙНЕТДИНОВ. Батырлар эзеннән . . . . . 160
В. ГОНЧАРОВ. Фронтташ дустым . . . . . . . 165

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ХАТИПОВ. Көрәшче геройны яклап . . . . 168

БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Р. МОСТАФИН. Былбыл Хәбир чишмәсе . . . . 173
Н. МӘҖИТОВА. Шәрыкны өйрәнү буенча яңа хезмәт . . . . . . . . . . . . . . . . 174

ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Г. КАШШАФ. Иҗат портретына штрихлар . . . 176
Юбилярны котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . 181

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Х. ХАЛИКОВ. Җәйге яңгыр. Шигырьләр . . . . 183

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 185

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 19/IX-1973 ел. Басарга кул куелды 9/I-1974 ел. ПФ 04001, Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 88.000 экз. Заказ Л-206. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казань, Декабристлар ур., 12.

© «Казан утлары» 1974 г.

## Вакыйф Нуруллин

# ӘГӘР СИН БУЛМАСАҢ...

ПОВЕСТЬ



Илебездәге меңнәрчә яшь галимнәр кебек, гап-гади бер фәнни хезмәткәр иде ул. Туган-тумачаларыннан, дус-ишләреннән һәм үзе белән бер институтта эшләүче танышларыннан башка, физика-математика фәннәре кандидаты Равил Нәҗметдиновның исеме юньләп беркемгә дә билгеле түгел иде. Һәм моңа гаҗәпләнергә урын да юк. Галәмне айкап төшкән космонавтларга да артык исе китми башлаган безнең заман халкын фән кандидаты булу белән генә шаккатырып булмый да булмый инде. Аннары килеп, холкы-фигыле, бите-йөзе, буесыны белән дә бер дә алай күзгә бәрелеп тормый безнең Равил. Калын кара каш. Коңгырт үткен күзләр. Маңгаена ук төшеп үскән бөдрә кара чәч. Ач яңак, чыгынкы ияк. Чандыр озын буй... Күрәсез, һич тә алай гайре табигый җире юк. Барысы да гадәти, барысы да кешеләрнекечә. Йөргән чагында бераз аксый аксавын, ләкин анысы да алай зыянлы түгел.

Бу моннан ун көн элек шулай иде. Ә бүген аның исеме бөтен илгә билгеле. Ничек шулай булды дисезме? Нәкъ ун көн элек СССР Дәүләт премияләре комитетының чираттагы карары чыкты һәм шунда, физика фәне өлкәсендәге уңышлары өчен, бер төркем галимгә, шулар арасында Равил Нәҗметдиновка да, Дәүләт премиясе бирелде.

Башта Равилне котлап телефоннан шалтыраттылар, аннары телеграммалар килде, аннары илнең төрле якларыннан хатлар ява башлады.

Бер хат аны сискәнергә мәҗбүр итте.

Илле икенче елдан бирле күрешкәннәре булмаса да, гел Равилнең күңелендә йөргән Рухия хаты иде бу!

Равил, бар дөньясын онытып, шул хатны укырга тотынды:

«Равил абый! Иң элек сиңа бик күп кайнар сәлам озатып калам. Аннары үзеңне чорыбызның иң акыллы, иң башлы кешеләренә генә бирелә торган зур бүләккә — Дәүләт премиясенә лаек булуың белән котлыйм! Молодец, классташ! Әлбәттә, сине миннән башка кешеләр дә

котлар. Котлаганнардыр да инде. Лəкин мин сине чын күңелемнəн, синең иң якын кешең буларак котлыйм! Синең бу зур бүлəккə лаек булуыңа миннəн дə ныграк куанган кеше юктыр. Чөнки синең менə шушындый зур галим булып китүеңдə минем дə өлешем бар бит, Равил абый. Бар бит, əйеме? Хəтереңдə микəн, бервакыт син миңа: «Əгəр син булмасаң, мин, мөгаен, Чүкəйдə укып та йөрмəс идем»,— дип əйткəн идең. Ярата идең ич син мине, əйеме? Мин дə сине ярата идем, Равил абый. Җир йотсын менə, ярата идем. Лəкин син кирəгеннəн артык тыйнак, горур егет идең. Ə мин, киресенчə, җилбəзəгрəк, шаянрак, азагы ни белəн бетəрен уйлап тормастан, күбрəк сөйлəшүчəн идем. Син хислəреңне тыя, кулга ала белəсең, ə минем эчемдəге — тышымда иде. Шуның нəтиҗəсендə гомер буе үкенеп яшəргə туры килəчəген күз алдына да китермəдем шул мин.

Ярар, шатлыклы көннəреңдə минем зарымны тыңлыйсың килеп тормый торгандыр. Мондый чакта матур хатирəлəрне генə искə алырга кирəктер. Ə андый хатирəлəр байтак булды безнең, Равил абый, шулай бит? Их, кайтарып булсын иде шул үткəн матур көннəрне! Бөтенесен дип əйтмим, һич югы, берничəсен генə кайтарып булсын иде!.. Мин сине гел тыйнак, гел əйбəт егет итеп күз алдыма китерəм. Күрəсе иде бер сине!

Өйлəнгəнсеңдер инде. Əлбəттə, бала-чагаларың да бардыр.

Нигə болай кинəт кенə минем белəн кызыксына башладың əле син, дип аптырама, Равил абый. Минем семья тормышым барып чыкмады. Шуңа, ичмаса, синең бəхетле булуыңны телим.

Җете кызыл тиз уңа дип белеп əйткəннəр икəн. Теге чакта минем өчен үлəргə җитеп йөргəн Рəмзи абыең коточкыч үзгəрде. Вак, көнчел əдəмгə əйлəнде. Шулай үзен-үзе ашап, минем дə җаныма тиеп, тəмам бабайга əйлəнеп бетте хəзер. Хəер, яше дə байтак шул: миннəн нəкъ унбер яшькə олы ич ул. Тартмый да үзе. Эчми дə. Хатын-кыз белəн дə йөрми. Эшен дə əйбəт кенə алып бара. Рус мəктəбендə директор булып эшли. Лəкин əнə шул чамасыз вакчыллыгы, бер дə урынсызга көнлəшүлəре һəм, минем белəн тамчы да исəплəшмичə, һаман үз дигəненчə генə эш итүлəре белəн пычаксыз суя инде, Равил абый! Дөресен генə əйткəндə, башта ук яратып чыкмадым бит мин аңа. Син үзең дə белəсең моны. Синең аркада шулай булды бит бу, Равил абый. Бик авырга туры килеп, елап утырган чакларымда əле дə сине каргыйм мин, Равил абый. Син, егет кеше, шул чакта бер җылы сүз генə əйткəн булсаң да, шушы хəллəргə каласы кеше түгел идем бит мин!..

Күптəн хат язмакчы идем сиңа, лəкин кайда икəнлегеңне дə, адресыңны да белмəдем моңарчы. Аннары, дөресен генə əйткəндə, мин синең үзеңнəн хəбəр булмасмы дип тə көткəн идем. Ə син, горур егет, мине бөтенлəй оныттың, ахрысы.

Хуш дип əйтмим, чөнки синнəн түземсезлек белəн җавап көтəм.

Хатыңны өй адресына яза күрмə — үтерер мине Рəмзи бабаң. До востребования яз, яме!

Сиңа бəхет телəп калучы бəхетсез Рухия».

...Гаҗəп икəн ул күңел дигəн нəрсə: үзе менə шушы Рухиядəн берəр хəбəр килмəсме дип егерме ел буена туктаусыз көтеп, өметлəнеп йөрде. Ə хəзер, инде ул хəбəр килгəч һəм анда Рухия барысын да əйтеп-аңлатып биргəч, коелды да төште Равил. Куана да алмый, кайгыра да алмый. Гомумəн берни дə уйлый алмый иде ул хəзер. Чөнки күңелендə яңарган хатирəлəр шул тикле күп, шул тикле каршылыклы һəм буталчык — аларның очына чыгу мөмкин түгел иде...

Шулай да ун-унбиш минут аптырап утырганнан соң, ниһаять, күңелендəге фикер һəм хислəр давылы басыла төште. Уйлары акылына

буйсынып агыла башлады һәм иң элек ул үз-үзенә менә шушы сорауны куйды: «Җавап язаргамы, юкмы?» Шунда ук: «Язарга!» дигән фикергә килде. Ләкин ничегрәк итеп язарга? Аны һаман да оныта алмавын туп-туры әйтепме? Әллә, юк инде, чибәр апай, мин элекке беркатлы Равил түгел хәзер, синең өчен тилереп йөрер чаклар үтте инде, элек йөргәннәремә дә үкенеп бетә алмыйм дип, кырт кисәргәме? Яки, тегесен дә, бусын да өзеп кенә әйтмичә, икеле-микеле уйларга урын калдырыбрак язаргамы икән?



I

Бүгенгедәй хәтерли әле Равил: мең тугыз йөз кырык тугызынчы елның уникенче сентябре, сизелер-сизелмәс кенә рәшә дулкынланып торган җылы, аяз көн иде. Равил Гобәй урманы буенда өч кызны куып җитте. Алар, акрын гына атлап, шаярыша-көлешә мәктәптән кайтып баралар иде. Тукталып тормыйча, выжт иттереп кенә үтеп китмәкче булып, Равил велосипедының кыңгыравын чылтыратты. Кызлар сискәнешеп читкә тайпылдылар. Ләкин араларыннан берсе, кинәт кенә кире борылды да, колачын җәеп, Равилнең юлына аркылы төште:

— Тукта әле, абый җаным, бер генә минутка! — диде ул, көмеш кыңгыраудай саф, нәфис тавышы белән.— Кайларда булдың, ниләр күрдең — безгә дә әйтеп кит әле?

Өстенә кара юбка, изүе чигелгән ак кофта кигән, иптәшләре белән уйнап-шаярып килгәнлектән бит алмалары алсуланып киткән, кап-кара күзләре очкынланып торган бу кызның үтенечен кире кагу мөмкин түгел иде. Равил шатырдатып тормоз салды да, ялт итеп сикереп төшеп, кыз каршына басты. Ләкин авыз ачып сүз әйтә алмады. Кызның калын һәм озын чәч толымнарына карап шаккатып калды. Аның шаккатып торганын кыз үзе дә сизенде булса кирәк:

— Әй, абый, нигә карга күк авызыңны ачып калдың? Әллә чәч күргәнең юкмы? дип, ниһаять, телгә килеп, түбыгына тикле төшеп торган толымнарын күкрәгеннән аркасына алып салды.

Унҗиде яшенә җитеп, кызлар белән танышып караган кеше түгел иде Равил. Кызның чаялыгы алдында ул гел дә менә каушап калды.

— Әллә бөтенләй телсез инде бу абый! — диде кыз иптәшләренә карап. Тегеләре пырхылдап көлеп җибәрделәр.

Әле һаман чая кызның толымнарына һушы китеп, Равил кызлар шактый ерагайганчы карап торды. Велосипедына атланып, ул аларны эһ дигәнче куып җитә ала иде, сүз куша ала иде, ләкин тагын хур булудан куркып, сабыр итәргә булды. Янында гына күренеп торган урман буена килеп, велосипедын җиргә аударды да чикләвек куагы төбенә чалкан ятты.

Күк йөзе зәп-зәңгәр иде. Уктай сузылып киткән самолет эзеннән башка, тырнак очы кадәр дә болыт әсәре күренми. Тирә-як тып-тын. Бары Равилнең йөрәге генә күкрәк читлегеннән атылып чыгарга теләгәндәй ашкынып тибә. Их, буласы иде аңа хәзер әнә шул эзен калдырып үткән самолетның очучысы! Күрәсе иде җирне шул биеклектән! Анннары кинәт, яшен ташыдай, түбәнгә ыргыласы иде дә әнә теге «телсез» дип көлеп киткән озын толымлы кызыйның баш түбәсеннән генә кул болгап үтеп китәсе иде! Янсын иде йөрәге...

Равил шулай хыялга чумып ятканда, тып итеп, маңгаена нидер килеп төште. Сискәнеп китеп торып караса — чикләвек икән. Сап-сары. Тукта, бу чикләвекнең иптәшләре дә юкмы икән монда?.. Равил, эзли торгач, унбиш чикләвек табып алды. Боларны бит теге кызларга бүләк итәргә була, сүз башларга җай да табыла. Хәзер тиз генә артларыннан

куып җитеп, озын толымның кайсы авыл чибәре икәнен генә булса да белеп калырга кирәктер бит инде...

Равил куып җиткәндә, кызлар, аның туган авылы Ташый елгага борыла торган юлны үтеп, шактый җир киткәннәр иде. Равил бер генә мизгел икеләнеп торды да, тәвәккәлләп, кызларны куып житте һәм, баягы шикелле куркытмас өчен, сигнал бирмичә генә:

— Әй, алыгыз сыерларыгызны — ат килә! — дип кычкырды. Велосипедын шып туктатып, җиргә сикереп төште.

Әмма кызлар барыбер куркышып-чырылдашып читкә сибелделәр. Тик куркулары озакка бармады: Равилне танып алуга тагын көлешә башладылар. Озын толымлысы бик нык гаҗәпләнгән сыман итеп:

— Бәй, теле бар икән ич, кызлар, бу абыйның! — дигәч, тагын да кычкырыбрак көлешергә тотындылар.

Ташый елга кызлары шушылай итеп үзеннән көлеп торса, җен ачулары чыккан булыр иде Равилнең. Ләкин боларга тамчы да хәтере калмады. Киресенчә, гомерендә беркайчан да болай булмаганча кызык иде аңа. Ул үзе дә аларга кушылып рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аннары:

— Теле генә түгел, чикләвеге дә бар әле абзагызның!— дип, чалбар кесәсенә каккалап, теге куак төбеннән җыеп алган чикләвекләрен шылтыратып куйды.

— Чынлап әйтәсеңме, абый җаным? Кая, чын булса, берәрне генә бирче, зинһар? — диешеп, кызлар Равилне шундук урап алдылар.

— Бик ашыйсыгыз киләмени соң? — дигән булды Равил.

— Бик ашыйсыбыз килә шул, абый җаным! — диде әлеге озын толымлысы.

— Алайса, башта барыгыз да исемнәрегезне әйтегез!

— Мин Рухия булам! — диде Озын толым.— Чүкәй мәктәбендә укыйм, сигезенчедә. «Өчле»ләрне исәпләмәгәндә, билгеләрем «дүрт» тә «биш». Комсомолга керергә әзерләнәм. Әтием дә, әнием дә, туган-тумачаларыбыз да чит илдә булмаган, хөкемгә тартылмаган. Кая, абый җаным, тизрәк бир инде чикләвегеңне?

Һәркайсына аерым-аерым бирсә, чикләвекнең бик аз булуыннан курыкты Равил. Шуңа күрә үзенчә хәйлә корды: кесәсендәге чикләвекне кепкасына салды да юл читендәге чирәмгә куйды. Ашагыз дип әйткәнне дә көтеп тормастан, кызлар, чыр-чу килеп, кепка тирәсенә утырыштылар һәм Равилгә рәхмәт укый-укый «эшкә» керештеләр.

Өч кешегә унбиш чикләвек — малмыни ул? Равил әле Озын толымга туйганчы карап калырга да өлгермәде, ә кепкадагы чикләвектән инде җилләр искән иде. Дөрес, кызларның исемнәрен дә, кайсы авылдан икәнлекләрен дә белде ул белүен. Ләкин аның өчен хәзер бу мәгълүматлар гына аз иде шул. Тагын нәрсә кирәген ул үзе дә ачык кына белми, әмма һич кенә дә бу кызлардан аерылып каласы килми иде аның. Тик ничек итеп аларны тагын бераз тоткарлау чарасын табарга соң?..

— Кызлар, тагын ашыйсыгыз киләме чикләвек?

Ни әйтүен үзе дә бик үк белештермичә, Равил әнә шулай дигәч, Рухиянең болай да очкынланып торган үткен күзләре тагын да ныграк ялтырап китте һәм ул:

— Булса, тагын икешәрне генә бирче, абый җаным? Бигрәк тәмле икән чикләвекләрең, телләреңне йотарлык! — дип, сикереп торып, Равилнең каршына үк килеп басты.

Равил бүген көн буе урманда йөреп җыйган һәм, ак киндер капчыкка төреп, велосипедының багажнигына бәйләп куйган алты-җиде стакан чикләвеген чишеп алды да кепкасы янына барып утырды.

— Әйдәгез, бергәләп ашыйк әле, кызлар!

Вәсимә белән Таня, ышанырга ярый микән бу кешегә, дивана түгел микән бу адәм дигән сыман, аптырашыбрак калдылар. Ләкин бу хәл озакка бармады. Рухия капчык янына чүгәләп:

— Әйдәгез, нигә шаккатып торасыз, күрсәтергә түгел, ашарга дип куйды бит ул бу чикләвекне! Шулай ич, абый? — дигәч һәм Равил тагын бер тапкыр шулай икәнлеген әйткәч, янә «эшкә» керештеләр.

Чикләвек ашаганда ниләр сөйләшенүе Равилнең хәтерендә бик ачык сакланмаган. Әмма ашап бетергәннән соң Рухиянең әйткән сүзләре хәзер дә ишетелеп тора әле.

— Бәй, сыптырып та куйдык ич без моны! — диде ул, кинәт куркып киткән сыман итеп.— Ничә стакан иде, абый, чикләвегең?

— Бездә чикләвекне санап җыймыйлар! — диде Равил, бер дә исе китмәгән атлы булып.

Алдагы атнада Равилнең әнисе Казанга йомырка сатарга барырга җыена иде. Казанда чикләвекнең стаканы өч сум тора дип сөйлиләр. Ун гына стакан чикләвек алып кайтсам да, утыз сум акчасы булыр. Шул акчага бераз йомырка саткан акчаны да өстәп, әни аякка ботинка алып кайтыр дип өметләнгән иде Равил. Ботинка очты болай булгач.

— Әй, абый җаным, булмаса булган икән, тагын бер изгелек эшлә инде. Велосипедыңа утыртып Укмаска илтеп куй инде мине.

Укмаста берниндн дә йомышы юк иде Равилнең. Шушындый чибәр кыз аның иске велосипедына утырып барырга бик куанып риза булыр дип уена да китермәгән иде. Ул арада Рухия:

— Кая утырыйм, абый җаным, багажнигынамы, әллә алга утыртасыңмы? — дип, балаларча түземсезләнеп, велосипедның руленә үк тотынды. Бу көтелмәгән бәхеттән әле һаман айнып җитә алмыйча, Равил багажнигына ымлады. Кыз:

— Мәгез әле, дуслар, зинһар, чиратлашып алып кайтыгыз әле шушы имгәкне! Капка төбенә ташлап китәрсез шунда! — дип, сумкасын тиз генә Вәсимәгә тоттырды. Аннары ялт итеп багажникка менеп кунаклады һәм, егылып төшмәс өчен, Равилне кочаклап:

— Әйдә, абый җаным, элдерт! — диде.

Кызның җылы кулын, сикәлтәле урыннарда аркасына кагылып-кагылып киткән күкрәкләрен тоеп бара торгач, Равил Укмаска килеп җиткәнен дә сизми калды. Тик авылларына кайтып, велосипедны тапшырырга баргач һәм Йосыф абыйсы, иртән сөйләшенгәнчә, велосипед хакына чикләвек сорагач кына аңына килде.

Чикләвек очрамады дисә, Йосыф абыйсы барыбер ышанмаячак иде. Шуңа күрә Равил алдашырга мәҗбүр булды:

— Теләсәң ни эшләт, Йосыф абый, ләкин мин сиңа чикләвек алып кайта алмадым. Биш-алты стакан җыеп, капчыкка салып, багажникка бәйләп куйган идем, капчык тишек булган да юлда бөтен чикләвегем коелып беткән! — диде.

Йосыф абый алай зурдан кубып тавышланмады. Әмма әйтте:

— Ярый, энекәш, син бу әкиятеңне тавыкларга сөйлә, яме. И булше биләсәпит дип минем янымa киләсе булма! — диде.

## 2

Иртәгесен Равил ат көтүеннән кайтканда, Мәсрүрә түти кәҗә савып керер килә иде.

— Гомерең озын булыр әле, улым,— диде ана, улын күргәч чын күңеленнән куанып.— Җылы сөт эчәргә кайтып керсә әйбәт булырые дип, сине уйлап кына керер киләдерием әле. Хәзер сөзеп кенә бирим дә җылысы белән эчеп куярсың.

Лэкин энисе бер-ике атлау белэн шып тукталып, кинэт кире борылды да, Равилгэ текэлеп һэм хэвефлэнеп:— Эллэ төнлэ берэр хэл булдымы, улым? Бөтенлэй ябыгып, суырылып киткэнсең лэбаса! — диде.

Ярты көн эчендэ күңеле дэ, уйлары да бик нык үзгэргэнен үзе дэ сизенгэн иде Равил. Лэкин ул үзгэрешлэр йөзенэ үк бэреп чыккандыр дип, башына да китермэгэн иде. Э менэ хэзер, энисе дэ аның хэлен чамалап алгач, аңа бик кыен, оят булып китте. Бит алмалары, колаклары ут кебек кызышып чыкты. Мөгаен, бик зур хэзинэ чэлдереп кайтып кергэннэн соң, артыннан килеп тотып алгач, угры да менэ шушылай Равил кебек аптырап-югалып кала торгандыр: хэзинэ урлавын да эйтергэ телэми, минем эш түгел дип танудан да мэгънэ чыкмаячак. Эйе, Равил дэ нэкъ угры хэлендэ калган иде: аңа да гашыйк булганлыгын эйтергэ ярамый, асарга дип муенына элмэк салсалар да алай дип эйтергэ йөрэге җитмэячэк иде аның. Шул ук вакытта бөтенлэй үк дэшми калу да мөмкин түгел. Ничек тэ бер җаен табып, үзендэге үзгэрешнең сэбэбен аңлатырга — мэсьэлэне укуга китереп терэргэ кирэк иде. Шунлыктан Равил энисенең борчылып соравын бөтенлэй ишетмэгэнгэ салышты һэм, тэвэккэллэп:

— Телэсэң ни эшлэт, эни, мин иртэгэ сигезенче класска укырга барам! — диде.

Энисе, шаккатып, беркавым сүзсез-өнсез булып торды. Аннары, барысын да аңлап алгандай итеп:

— Эһэ-э! Менэ ни өчен төсең-битең качкан икэн синең! — диде.— Инде онытты, инде тынычланды дип куанып кына йөри башлаганыем, тагын шул уку җенең кузгалган икэн алай булгач! Мине тагын кыш буена япа-ялгыз калдырып китэргэмени исэбең! Өч кыш бер ялгызы яшэп чилэнүе җитмэгэн, тагын чилэнсен эле бу эни дисеңмени? Эй, бала-бала, бүтэн ягың ярый, ну шушы укуың белэн чэчлэремне агартасың инде, биллэһи! Син укый башласаң, кем кышлык утын хэзерлэшер соң инде миңа? Кем, хезмэт көне эшлэп, түлэүлэрне түлэргэ ярдэм итэр?

Эйе, энисенэ дэ кыен Равилнең. Ул да дөрес эйтэ. Аның шушы сүзлэренэ каршы куярлык бер генэ дэ ныклы дэлиле юк Равилнең. Ул тик бер генэ нэрсэне аермачык белэ: ничек тэ укый башларга кирэк аңа. Рухия укый торган мэктэптэ укый башларга кирэк!

— Утын өчен кайгырма, эни! — диде ул, мөмкин кадэр ипле һэм сабыр булырга тырышып.— Утынсыз калмассың. Мин ул эшне үз өстемэ алам. Ял көннэрендэ, айлы төннэрдэ булса да утын эзерлэп, үзем алып кайтып бирермен мин сиңа, эни. Аннары мин бит хезмэт көне эшлэүне дэ ташламыйм. Чүкэйдэ торып укымыйм мин, көн саен кайтакилэ йөрмэкче булам. Кар төшкэнче ат көтэрмен, э кышын фермага каравылчы булып керермен. Эле шушы көннэрдэ генэ Хэбир бабай белэн сөйлэшеп утырган идек. Ул эйтэ, картаям инде, тагын берэр ай гына мэтэшэм дэ ташлыйм бу каравыл эшен. Кыш көне мэшэкате бик күп була: сыерлар бозаулый, сарыклар бэрэнли, бөтенесен вакытында күреп, җылы урынга алып керергэ кирэк — түзэ алмам мин аңа, ди. Рөхсэт ит инде, эни бэгырем? Бер генэ ел булса да укыйм инде!

Энэ шулай инэлеп ялынгач та, укырга рөхсэт бирергэ ашыкмады энисе.

Равил аны һич тэ ризалаштыра алмагач, кызып китеп:

— Эгэр яхшылык белэн ризалык бирмисең икэн, тотам да авылдан чыгам да китэм һэм бүтэн беркайчан да эйлэнеп кайтмыйм! — дип ычкындырды.

Шуннан соң энисенең дэ түземе төкэнде булса кирэк:

— Эй, балакай-балакай! — дип, елап ук җибэрде.— Болай ук үзсүзле буласыңны белсэм, валлаһи дип эйтэм, теге чакта сиңа карап

тормаган булырыем. Шул синең арканда, сине борлыктырмыйм дип кенә Шәлегә китмичә калдым-лабаса...

Равил дүртенчене тәмамлап йөргән елны аның әнисен кияүгә сорап килгәннәр иде.

Мартның ахыргы числолары, көннәр озая, дөньяга яз исе керә башлаган чак иде. Равил карыны бик ачып мәктәптән кайтып кергәндә, өйләрендә аңа таныш булмаган, әмма күрер күзгә ягымлы гына бер ир кеше утыра иде. Ә әнисе күренми, кече яктан аның тавышы гына ишетелә:

— Анысы синең сүзең дә дөрес инде, авылдаш: ирсез-атсыз тормыш итүләре җиңел түгел инде түгелен. Шулай да бик каты куырма әле син мине, уйлап-үлчәп, киңәш-табыш итеп карарга кирәк бит миңа да. Уен эш түгел ич, бик зур эш ләбаса.

Әнисенең шул сүзләрен ишеткәч, Равил, исе китеп, ишек төбендә катып калган иде. Һәм ул әле тагын бераз тыңлап тормакчы иде. Ләкин шунда аны теге ят агай күреп алды да:

— Эһем, Мәгъсүмә, чык әле бу якка. Бер чибәр егет килеп керде әле монда. Синең малаең шушы буламы әллә инде? — дип эшне бозды.

Әнисе тиз генә түр якка чыкты. Равилне күреп, кинәт әллә нишләп каушап, кызарып калды. Аннары, әйе, минем улым шушы була инде, дип елмайгандай итте. Ләкин бу Равилгә таныш елмаю түгел, ничектер, читрәк, оялчанрак, гаепле кеше сыманрак елмаю иде. Хәтта көн дә әйтә торган:

— Нихәл, улым, кайттыңмы? — дигән сүзләрен дә әнисе бүген каушабрак, калтыранган тавыш беләнрәк әйтте.

Әнисенең аш өлгертеп йөргән чагы булган икән. Равил букчасын чөйгә элеп куеп, бит-кулларын юган арада ул табын әзерләде. Аннары өчәүләп ашарга утырдылар. Аш янында алай телгә алып әйтерлек сүз булмады. Теге агайның кем булуын һәм нишләп йөрүен тагаенләргә бик теләсә дә, Равил барыбер иң кирәклесен ишетә алмаган иде әле. Шулай да, утыра торгач, кайбер нәрсәләрне ачыклады: агай сугышның беренче айларында ук яраланып кайткан. Шуннан бирле үз колхозларында хисапчы булып эшли икән. Узган кыш хатыны үлеп киткән һәм ул ике бала белән торып калган.

Агай, сүз уңаенда, Равилнең ничек укуы турында да сораштырды. Равил аңа бер «өчле» дә алганы булмавын, гел «дүрт» белән «биш»кә укуын әйткәч, маладис, маладис, энекәш, дип мактап куйган булды. Әйтерсең Равил аның мактавына исе китә инде!

Аш яныннан купкач та кайтып китәргә ашыкмады ул агай, һаман шулай Равилне сөйләштерергә тырышып, авылыгыз кечкенә булгач, кинолар да бик сирәк килә торгандыр инде сезгә, театрлар да куючы юктыр, бик күңелсездер сиңа монда, дип төче телләнеп утырды. Вәт бездә рәхәт ул, ичмаса: көн аралаш кино, ай саен театры килеп тора! Әйдә, мин сине үзебезгә кунакка алып китәм дип, гомер булмастай нәрсәләргә Равилне үгетләп маташты. Ул әле тагын шулай сөйләнгән булыр иде, ләкин Равилнең артык түзеп торыр чарасы калмады һәм ул, кырт кистереп:

— Кыстамасана, я күндереп куярсың! Тинтәкмени мин синә ияреп йөрергә? — диде.

Агай капкаларыннан чыгып, өй турларыннан үтеп киткәнне генә көтеп торды да Равил әнисен «дупруслый» башлады:

— Әни, ник килгән ул кеше?

Әнисе тагын каушап-оялып китте. Бите чия төсле кызарып чыкты. Ни дип тә әйтә алмагач:

— Улым, ошыймы ул абзый сиңа? — диде.

— Юк, әни, ошамый ул миңа! — диде Равил, юри каты итеп.

— Кай җире ошамый, улым?

— Муены да, башы да, колаклары да, күзләре дә — бер җире дә ошамый!

— Әйт әле, Равил, син ул абыйга «әти» дип әйтә алырсыңмы?

— Тилерденме әллә син бүген, әни? Нигә мин шул зур колак, ямьшек борынга әти дип йөрергә тиеш ди әле?

Хәзер дә күз алдында бик ачык тора Равилнең: теге агайның колаклары да бик таман, борыны да бик килешле, күзләре дә ягымлы иде. Равил аның йомшак итеп дәшүен дә ошатып калган иде. Ләкин менә шул кеше белән инде әнисе дә шактый нык кызыксына башлагач, агай минуты белән Равилнең явыз дошманына әйләнде һәм ул аны юри әнә шулай яманлап ташлады.

Равил бу хакта сүз шуның белән бетәр дип уйлаган иде. Әмма алай булып чыкмады. Әнисе аның янына килеп, башыннан сыйпады да:

— Туктале, улым, алай ямьсез сөйләшмә әле,— диде.— Син хәзер дәү бит инде. Әйдә, ашыкмыйча гына, икәүләп киңәшеп алыйк әле, балам. Тыңлыйсыңмы син мине?

— Сөйләп кара инде алай булгач,— диде Равил. Аны әнисенең үзе белән зурларча сөйләшә башлавы кызыксындырды.

— Менә хәзер генә бездән чыгып киткән абыең Зиннәт исемле ул, улым. Минем туган авылым Шәленеке. Без аның белән бала чакта бергә уйнап үскән кешеләр. Менә шул Зиннәт абыең синең белән мине Шәлегә чакыра, улым. Икегез дә безгә килеп тора башлагыз, ди. Аларның да синең шикелле бер малайлары, синнән өч яшькә кечерәк бер кызлары бар икән. Ә әниләре узган кыш авырып үлеп киткән. Шуңа күрә Зиннәт абыеңа да, балаларына да аш пешереп ашатучы да, кием-салымнарын юучы да юк икән. Шуларга барып тора башласак, ничек булыр икән, балам? Зиннәт абыең әйтә, Равилгә мәктәпкә йөрү өчен дә бик җайлы булыры, өебез мәктәп янында гына, ди. Мин аңа өс-башына яңа киемнәр, китапларын тутырып йөрергә яңа сумка да алып кайтып бирерием, ди. Барыйк микән, улым, шул Зиннәт абыйларыңа?

Равил бер мәл икеләнеп калды. Шул арада аның күз алдына өр-яңа бишмәт белән өр-яңа бүрек, яңа чалбар белән яңа ботинкалар, йозагын чырт иттереп кенә ябып куя торган өр-яңа сумка килеп басты. Шул киемнәрне киеп, шул яңа сумканы кулына тотып, ул очып кына мәктәпкә дә барып кайтты. Кием-салымын алгач, чанасыннан гына тормас инде ул абзый, бәлки алып куйган чанасы ук бардыр әле дип, аның чанасын күз алдына китереп, һәм шул чананы сөйрәп, бөтен авыл малайларын шаккатырып, тау шуарга да барып килде. Хәтта, секундның меңнән бер өлешендә генә булса да, мин риза, әни, дип әйтмәкче дә булды Равил. Әмма, ризалык бирсә, әнисе шул бөтенләй чит-ят булган кеше белән яши башлаячагы күз алдына килеп басу белән ул теләген куып җибәрде дә, һич икеләнеп тормыйча, хәтта ачулы итеп:

— Бик барасың килсә, үзең генә бар, әни. Ә мин беркая да китмим! Кечерәк чакта, син урман кисәргә барган вакытта да түздем бит әле, хәзер, зурайгач, ничек тә чыдармын. Үзем генә яши алмасам, авыл Советына Сажидә апа янына барырмын да, ул берәр җиргә балалар йортына җибәртер мине. Ә синең ул Зиннәтең янына үтерсәләр дә барачак түгел мин. Киеме дә, сумкасы да үзенә булсын. Әгәр мине ташлап китәсең икән, мин сиңа бүтән әни дип тә әйтмим! — диде һәм йөгереп урамга ук чыгып китте...

Ничек булса булган, үткәнне кайтару мөмкин түгел. Шулай да әнисе кызганыч Равилнең. Зиннәт абзыйга бары тик Равилнең каршы килүе аркасында гына, аның хәтерен саклап кына кияүгә чыкмыйча калган бит ул. Димәк, әнисе аның өчен яшьлеген корбан иткән булып чыга. Әйе, яшьлеген, чөнки ул чакта аның әнисе әле нибары утыз

икедә генә булган. Ә менә Равил бүген шул түзем әнисенә, бердәнбер әнисенә, бөтен тормышын улына багышлаган әнисенә каршы барып, сүзен сүз итәргә тиеш. Шунсыз ул дөньяда иң чибәр, иң акыллы Рухияне көн дә күреп тора алмаячак. Шунсыз аның колакка җыр булып ишетелә торган көмеш тавышын көн саен ишетмәячәк.

— Әнием, җан кисәгем, тыңла инде сүземне! — диде Равил, һаман үҗәтләнә биреп.— Бер генә ай булса да укып карыйм инде, әни бәгырем? Сиңа читенгә туры килә башлау белән ташлармын мин аны. Менә күрерсең, утын да әзерләп бирәм, төнге ат көтүен дә кар яуганчыга тикле ташламыйм. Көндезге эшләргә үк йөри алмам инде алуын, ну ат көтүен ташламыйм. Ә кар явып, көтүләр кергәч, Хәбир бабай урынына каравылчы булып урнашам. Сигез чакрым ара әллә ни ерак түгел бит ул. Мин көн дә кайтып йөрермен, әни. Баруын-кайтуын бергә кушканда да нибары уналты чакрым гына була ич. Бер дә авырсынмам, тик синең ризалыгың гына булсын. Риза бул инде, әни бәгырем?! Укып карыйм инде азрак. Әгәр әйбәт кенә башта унны, аннары берәр төрле зуррак уку йортын тәмамлап чыгып эшли башласам, мин сине түр башында гына утыртырмын.

— Ә укып кем булмакчы буласың соң син, бала?

Равилнең ул турыда уйлаганы юк иде әле.

— Син кем булуымны телисең соң?

— Әнә, Мәдинә апаң шикелле, укытучы була алсаң ярый да бит...

— Укытсаң — булырмын, әни. Укыйм инде, яме?

Бары шуннан соң гына, ниһаять, әйтте әнисе:

— Аяк итеңне ашап, көн саен уналты чакрым җир җөрергә бик атлыгып торасың икән, ярар, укып кара, алай булгач,— диде.— Түлке кара аны: авыр дип, арыйм дип, зарланасы булма миңа!

Кая инде ул зарлану! Рухияне бер күрер өчен көненә уналты километр гына түгел, көненә кырык алты километр йөрергә дә әзер иде Равил. Һәм ул, тиз-тиз генә юынып, арурак күлмәк-чалбарын киде дә, җидене тәмамлау турындагы таныклыгын кесәсенә салып, Чүкәйгә китте.

## 3

Равил барып кергәндә, мәктәп умарта күче кебек гөжли, әмма коридорда да, залда да җан иясе юк — дәрес вакыты иде. Димәк, ул соңгарак калган. Хәер, шулай булуы гаҗәп тә түгел: әнисен ризалату өчен никадәр вакыт кирәк булды бит. Әгәр бүген укырга алсалар, бүтән көннәрдә атларны да көтүдән иртәрәк алып кайта башлар, мәктәпкә дә иртәрәк кузгала торган булыр иде...

Әнә шуларны уйлап, Равил акрын гына мәктәп директоры кабинетының ишеге төбенә килеп басты. Ләкин ишек ачар вакыт җиткәч, ул каушап, икеләнебрәк калды.

Әнә шулай әүле-тәүле булып торганда кинәт ишек үзе ачылып китте һәм мәктәп директоры Хәнифә Вәлиулловна килеп чыкты. Килеп чыкты да, Равилгә бәрелә язып, туктап калды. Бер үк вакытта гаҗәпсенеп тә, куанган сыман да итеп:

— Чү! Син түгелме соң бу, Нәҗметдинов? — диде.

— Мин идем шул, Хәнифә Вәлиулловна,— диде Равил. Директор һаман әле аның фамилиясен хәтерендә тотканга сөенеп куйды.

— Күр инде син аны, ә! — диде директор, Равилне баштанаяк күздән кичергәннән соң.— Бер җәй эчендә тәмам үсеп, егет булып җиткәнең ләбаса — танырлык та түгел!

Ул тагын нидер әйтергә ымсынган иде, ләкин артыкка китә башлар дип булса кирәк, шунда тыелып калды да:

— Ә синең нишләп йөрүең иде соң? — дип сорады.

— Сезнең янга килгән идем, Хәнифә Вәлиулловна.

— Шулаймы? Әйдәле, алайса, кереп сөйләшик! — дип, директор Равилне үз кабинетына алып керде. Өстәле янына барып тормады. Стена буйлап тезеп куелган урындыкларның берсенә үзе утырды, икенчесенә Равилне утыртты.

— Я, Равил, тыңлыйм!

— Сигезенчегә укырга алмассызмы дип килгән идем, Хәнифә Вәлиулловна.

— Андый исәбең булгач, нигә алданрак килмәдең соң, энем? Укулар башланганга өченче атна китте бит. Классларны комплектовать итеп, ронога тиешле мәгълүматларны бирдек шул инде без.

— Шулайдыр инде анысы, Хәнифә Вәлиулловна, тик мин вакытында килә алмадым шул.

— Әниең риза булмагандыр инде.

— Әйе.

— Ә хәзер ничек рөхсәт итте соң?

— Мин кайта-килә укырга булдым. Көндез укыйм, ә төнлә көтүләр кырдан кергәнче ат көтәрмен, аннары фермада төнге каравылчы булып урнашырга исәп. Эшләп укыйсы булгач, ризалашты.

— Алай икән,— диде директор. Каршы як стенага эленгән Ленин рәсеменә карап, аның белән киңәшләшкәндәй, берничә минут уйланып утырды.

Ә Равил Хәнифә Вәлиулловнага карап, аның һаман бер дә үзгәрмәвенә, гел шулай элеккечә мөлаем, акыллы һәм матур булуына хәйран калып, сокланып торды. Директорның өстендәге куе зәңгәр костюмы да, аякларындагы ялтыравыклы кара туфлиләре дә, чал керә башлаган чәчләре дә үзенә бик килешеп, мәһабәтлек биреп тора иде. «Юк, мондый кеше кире борып җибәрергә тиеш түгел!» — дип уйлады Равил.

— Карале, энем,— диде директор, Равилгә таба борылып.— Эшләп тә, кайта-килә йөреп тә укуы авыр булмасмы соң сиңа? Түзәрсеңме?

— Мин ныклап уйладым инде, Хәнифә Вәлиулловна. Түзәрмен. Сез мине кире какмагыз гына. Алыгыз мине укырга? Ышаныгыз, йөзегезгә кызыллык китермәм!

Хәнифә Вәлиулловна тагын беркавым уйланып торды. Аннары әйтте:

— Ярый, без сине укырга алыйк та, ди. Син укый да башладың, ди. Ләкин укыган өчен түләргә хәле бармы соң әниеңнең? Анысын беләме ул?

Менә сиңа мә! Барысын да хәл иткән шикелле булган иде ләбаса Равил. Ә монда мәсьәләнең иң четереклесе, иң авыры онытылып калган икән. Сигезенче, тугызынчы һәм унынчы классларда укучыларның этиләре сугышта үлмәгәннәре укыган өчен акча түләргә тиеш икәнлекләрен белә иде бит Равил, бик яхшы белә иде. Ә менә кичә, Рухияне күргәч, онытып җибәргән шул ул аны. Дөрес, Равилнең дә этисе инде күптән, утыз бишенче елдан бирле, җир куенында ята. Ләкин сугышта үлмәгән шул ул, тыныч чакта, өйләрендә авырып үлгән. Равил тагын — үз гомерендә инде ничәнче кат! — үлгәч үлгәч сугыш кырына барып үлмәгәне өчен этисенә үпкәләп куйды һәм күңеле тулып, елар дәрәҗәгә җитеп:

— Мин ул турыда онытканмын икән, Хәнифә Вәлиулловна. Акча түләргә кирәген белсә, әни мәңге риза булмаячак — аңа хәле җитмәячәк аның. Гафу итегез, юкка борчып йөргәнмен икән мин сезне,— диде дә, өметен өзеп, ишеккә юнәлде.

— Туктап тор әле,— диде шул чак Хәнифә Вәлиулловна. Ул Равил

янына килеп, кулын аның иңбашына куйды. Костюмы төсле үк күк зәңгәр күзләрен тутырып карады да:

— Бик укыйсың киләме, энем? Укый башлагач гайрәтең чикмәсме? — диде.

— Чигүен чикмәс иде дә, Хәнифә Вәлиулловна, тик болай булгач барып чыкмый инде.

— Китап-дәфтәрләр алып килгән идеңме соң?

— Укырга алмасагыз, акча әрәм итү генә булыр дип, китап-дәфтәрсез генә килгән идем бүген.

Директор сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Аннары:

— Алайса, менә болай итик без, энем,— дип, ишек катында торган пыяла ишекле шкафыннан дүрт дәфтәр алып Равилгә бирде дә:— Хәзер звонок булырга тиеш. Тәнәфестән соң сигезенче «б» классына кер дә бүгеннән үк укый башларсың, ярыймы! — диде.

Үле дә, тере дә түгел дигәндәй, бер яктан, Хәнифә Вәлиулловна укый башларга рөхсәт иткәнгә чамасыз нык куанып, икенче яктан, укыган өчен түләргә акча каян алырмын, әниең юк, булса да бер тиен дә бирмәячәк, чөнки башка түләүләребез дә бетәсе түгел дип куркып, Равил каккан казыктай катты да калды. Күз аллары әлҗе-мөлҗе килеп, башлары әйләнеп китте. Аның нигә шулай өннән чыгып торуын Хәнифә Вәлиулловна сорап тормыйча да аңлап алды булса кирәк, аркасыннан кагып:

— Ә түләү өчен кайгырма, Равил. Анысын җайларбыз.— диде.

## 4

Равил белән бергә Качкалак мәктәбен тәмамлаган малайларның да кайберләре сигезенчегә килгән икән. Директор кабинетыннан килеп чыгу белән Равилне шулар урап алды. «Нишләп йөрисең? Укырга килдеңме әллә? Нишләп моңарчы килми тордың, авырдыңмы әллә?» — дип, төрлесе төрле яктан сорау яудырырга тотындылар. Равил аларга җавап биреп барса да, күңелендә гел Рухия иде. Мәктәп залында тыз да быз килеп кайнашып торган йөзләрчә укучы арасыннан ул һаман шул Озын толымны эзләде. Аның да сигезенче класста укыганын белә, ләкин кайсы сигезенчедә икәнлеге мәгълүм түгел иде әле. «Кичә велосипедка утыртып авылларына илткәндә никадәр сүз сөйләштек, ә менә иң кирәклесен сорарга онытканмын бит, юләр баш!» — дип, үзен-үзе орышып та куйды ул. Эзли торгач, Васимәне дә күрде, Таня да күзенә чалынып үтте, ләкин Рухияне таба алмады. Йөз төрле сорау биреп, күктән иңгән чит-ят затка карагандай кызыксынып, менә шушы янында басып торган малайлардан сораса, әйтеп бирерләр иде дә, аларга серне ачарга ярыймы соң?..

Дәресләр башланырга тиешлеген белдереп, звонок та бирелде, әмма Рухияне тәки күрә алмады Равил. Узган елгы классташ дуслары, Равилнең быел бүтән класста — сигезенче «б»да укыячагын белгәч, ничектер кинәт суынышып-читләшебрәк киткән сыман булдылар һәм тиз генә таралышып та беттеләр. Равил бер ялгызы торып калды. Тәнәфес вакытында ул сигезенче «б»ның класс җитәкчесен күрергә һәм кайсы партада утыру мәсьәләсен ачыклап калырга тиеш иде. Ләкин һаман шул Рухияне уйлап башы катканлыктан, аны да онытып җибәргән булып чыкты. Ә класска тиктомалга барып керү ничектер уңайсыз да, килешми дә шикелле тоелды. Кулына теге дүрт дәфтәрен тоткан килеш, ул сигезенче «б» ишегe төбенә килде дә дәрескә керергә тиешле укытучыны көтә башлады. Укучылар классларга кереп бетүгә, укытучылар бүлмәсеннән укытучылар чыга башлады. Ләкин алар да үз уйлары белән мәшгуль иделәр булса кирәк — аңа игътибар да

итмичә узып киттеләр. Тик директор бүлмәсеннән килеп чыккан бер укытучы хатын гына, чыгу белән, Равилне күреп алды, елмаеп аның янына килде:

— Нәҗметдинов Равил син буласыңмы, энем?

— Мин.

— Әйдә, алай булгач, танышыйк инде: мин сигезенче «б»ның класс житәкчесе Суфия апаң булам. Фамилиям Хәсәнова,— диде дә:— Ә хәзер, әйдә, дәрескә керик! — дип, Равилне класска ияртеп керде.

Класстагылар, дәррәү кубып, башта укытучы белән исәнләштеләр, аннары барысы да Равилгә текәлде. Кемнәрдер үзара пышылдаша башлады, кайсыларыдыр пырхылдап көлеп җибәрде. Равил бик нык уңайсызланып, күтәрелеп карарга да кыймыйча торды. Шул арада класс җитәкчесе түргә үтеп, дәрес барышында кирәк булачак әсбапларын өстәлгә куйды да, әле һаман тынычлана алмаган класска мөрәҗәгать итеп:

— Я, җитәр, укучылар! Калганын киләсе тәнәфестә сөйләшеп һәм көлешеп бетерерсез! — диде. Ишек төбендә аптырап басып торган Равилне үзе янына чакырып китерде дә әйтте: — Менә, укучылар, безнең класска тагын бер укучы өстәлде. Бүгеннән алып ул сезнең белән бергә укыр. Исеме — Равил, фамилиясе — Нәҗметдинов. Ә бүтән яклары белән уку барышында үзегез танышырсыз,— диде. Аннары арткы рәттәге бер буш партаны күрсәтеп, Равилгә шунда барып утырырга кушты.

Суфия апа рус теле һәм әдәбияты укыта икән. Ул алдагы дәрестә үтелгән материалны сорый башлагач, класс тып-тын булып калды. Бары шуннан соң гына Равил азрак җиңеләеп, иркенрәк сулап куйды. Һәм ул таныш булмаган класс алдында басып торганда нибары бер-ике минутка гына онытылып киткән Рухиясен яңадан исенә төшереп, күзләре белән аны эзли башлады. Бик үткен һәм күп сөйләшүчән булгач, Равил аны алдагы рәтләрнең берсендә утыра булырга тиеш дип уйлаган иде: чаярак укучыларны гадәттә укытучы күз алдына утыртучан булалар. Ләкин бу очракта Равил уйлаганның киресе булып чыкты: Рухия, Равил кебек үк, иң арткы партада, тик өченче рәттә генә утыра икән ләбаса!

Рухия аны инде байтактан күзәтеп-көтеп торган, ахры: Равилнең күзе үзенә төшү белән, башта хәйләкәр генә елмайды, аннары кинәт прых итеп көлеп җибәрде. Равилнең тәне эсселе-суыклы булып китте. Бер Рухия генә түгел, бәлки класстагы барлык укучылар да аны юләргә санап, эчләреннән генә көлеп утыралар шикелле тоелды. Шунда ул үзен дөньядагы иң бәхетсез кеше итеп тойды һәм үзен-үзе орышырга тотынды. Хәтта ул, әле соң түгел, әллә шыпырт кына чыгып сызыйм микән, дип урыныннан куба да башлаган иде. Ләкин шул чак яңа дәрес аңлатырга тотынган Суфия апа аның борсалануын күреп:

— Мин синең белән өчен дә сөйлим, Нәҗметдинов! — дип искәртеп куйгач, тынып калырга мәҗбүр булды. Тора-бара укытучының дәрес аңлатуы белән чын-чынлап мавыгып китте. Ә теге хыянәтче кыз — Рухия турында бүтән беркайчан да уйламаска, аны күңеленнән бөтенләй чыгарып ташларга, хәтта ул үзе килеп сүз катса да, аның белән сөйләшмәскә карар кылды.

## 5

Ләкин Рухия Равил уйлаганча хыянәтче түгел икән: тәнәфескә звонок булып, укытучы класстан чыгып китәргә дә өлгермәде, күбәләктәй җиңел генә очынып, Равил янына килде дә, бөтен классны балкытып елмаеп:

— Молодец, Равил абый! Килеп яхшы иттең. Беренче уку көнең белән котлыйм үзеңне! — дип искиткеч йомшак һәм кайнар кулын сузды.

Рухия бүген кичәгедән дә чибәррәк иде. Димәк, бая дәрес вакытында да ул мыскыллап түгел, бәлки якын итеп, үз итеп көлеп җибәргән, дип уйлап алды Равил. Башка вакытта алай ашыгып нәтиҗә ясарга ярамас, дип күңеленә беркетеп куйды.

— Велосипед белән килдеңме, Равил абый? — диде Рухия, Равил әле һаман сүз әйтергә кыймыйча торгач.— Бүген тагы утыртып алып кайтасыңмы мине?

— Минме! Мин...

Велосипедым юк минем, кешедән алып торган велосипед кына иде ул, дияр иде — болай да кылтаерга гына торган иркә кызның кәефе кырылып, бөтенләй читләшеп китүе мөмкин.

— Җәяү генә килдем шул бүген. Урман буена җиткәч камерасы ярылды да кире кайтарып куйдым,— диде Равил. «Бер алдашкач, тагын бер алдашудан гына әллә ни зур гөнаһ булмас», дип уйлап алды да:— Шуның белән мәшәкатьләнеп йөреп, беренче дәрескә дә соңга калынды,— дип өстәде.

— Шулаймыни-и-и! — дип сузып куйды Рухия.— Ә иртәгә төзәтеп килә алырсыңмы икән, Равил абый?

— Иртәгәме?.. Юк, иртәгә үк булмас әле, Рухия. Камерасы бик иске инде аның — ябыштырып кына игә китерә торган түгел.

— Ә нигә яңаны алмыйсың?

— Каян аласың аны? — диде Равил, кыюланып. Кыюлануының хикмәте шунда, ул әле моннан берничә көн элек кенә Йосыф абыйның, велосипед камерасы өчен Казанга махсус барып та таба алмыйча кайтуы турында бик каты сүгенеп, колхоз идарәсе алдына җыелган ирләргә сөйләп торуын ишеткән иде.

— Сиңа ничә камера кирәк, Равил абый? — диде Рухия.

— Икәү кирәк,— диде Равил. Берне генә сорасам, тәки табып бирер дип шикләнде.

Әмма кыз бу юлы да аптырап калмады гына түгел, хәтта аеруча бер эчке куаныч белән:

— Булды, Равил абый! — диде.— Бүген дәресләр беткәч икебез бергә безнең авылга кайтабыз да мин сиңа ике камера биреп җибәрәм. Син аларны өегезгә алып кайтып, велосипедыңны бүген үк төзәтеп куясың. Ә иртәгә иртән, безнең авылга килеп, мине утыртып мәктәпкә алып барасың! Ризамы?

— Ә син ул камераларны кайдан аласың? — диде Равил. Ул кызның мондый тәвәккәл тәкъдименә шаккатып калды.

— Әнием кибетче дип кичә әйткән идем бит инде!

— Ә сатуда бармы икән соң?

— Сатуда юк, ләкин кибеттә бар! Әле шушы араларда гына «бик кирәкле кешегә» дип, эти үзе әнидән бер камера сорап алды. Тагын биш камера калганын шунда үз күзләрем белән күрдем. Хәер, сиңа каян алсам да барыбер түгелмени, Равил абый,— диде Рухия. Егет кеше шулай вакланып торамыни дигән сыманрак итеп, чак кына турсаеп та куйды.

Шулай итеп сүйде да салды ул Равилне. Булмаган велосипедына ни пычагыма кирәк ди аңа камера? Бала түгел ләбаса инде ул: белә иде, ишеткәне бар иде бит ялган белән ерак китеп булмаганын!.. Нишләргә соң менә хәзер? Бу коточкыч авыр хәлдән ничек чыгарга? Шушы хәтле алдашып та хәзер дөресен әйтсә — кыз алдында ахмакның да ахмагы булып кала бит инде ул! Әһә, беткән баш беткән, муен калса җиткән: алдагысын алла белгән, ә бүген, форсаттан файдаланып, бу

кызый белән бергә кайтырга кирәк. Югыйсә, мондый бәхетнең бүтән тәтемәве дә бик ихтимал...

Башына шушы әйбәт фикер килгәнгә куанып, рухланып китте дә, эченнән бик нык борчылса да, тыштан шат күренергә тырышып:

— Син әйткәнгә мин риза, Рухия! — диде.

— Ләкин бер шарт белән,— диде кыз,— икебез дә физкультурадан сорап, бер сәгать алдан китәбез, яме!

Һәм ул, Равилнең «я» дип әйтүен дә көтеп тормастан, ялт итеп класска кереп тә китте.

## 6

Ул көннән соң инде егерме елдан артык гомер узды. Равил башыннан йөзләрчә, меңнәрчә хәлләр үтте инде. Тик аларның берсе дә шул көнне мәктәптән кайтышлый кичергән хисләр, сөйләшенгән сүзләргә торырлык түгел. Барысы да менә әле хәзер генә булгандай хәтерендә Равилнең. Рус теле дәресеннән соң тагын дүрт сәгать укырга тиеш иде алар. Нинди дәресләр булганлыгы да онытылмаган: тарих, инглиз теле, тригонометрия һәм физкультура сәгатьләре иде. Рухия ул көнне тәки бер сәгать алдан кайтып китте. Физкультура укытучысы Валентин Иванович класска кереп, укучыларны барлагач:

— Димәк ки болай: бүген малайлар футбол уйный, кызлар волейбол,— дигән иде. Рухия тиз генә кулын күтәрде дә, йөзенә бик кызганыч кыяфәт чыгарып, русчалатып:

— Валентин Иваныч, мине, пожалуйста, занятиедән азат итегез. Башым әйләнә бүген. Үзегез беләсез, мин волейболны начар уйнамыйм бит,— дигән булып, укытучының ризалыгын тиз генә алып, кайтып китәр өчен, китап-дәфтәрләрен җыештырырга тотынды.

Узган тәнәфестә Рухия Равилне дә физкультура сәгатеннән китәргә өйрәтеп куйган иде:

— Класс журналында әлегә синең исем-фамилияң юк, ә Валентин Иванович сиңа игътибар итмәячәк. Менә күрерсең, үзең дәшмәсәң, сине күрмәячәк,— дигән иде ул.— Ә син дәшмичә утыр да, класс спорт мәйданчыгына чыга башлагач, шыпырт кына таю ягын кара. Синең сумкаң да юк бит әле бүген, берәү дә сизми калачак. Әгәр дә инде алай-болай Валентин Иванович сине күреп алып, класс журналына теркәп куя икән — ул чакта шулай ук каушап калма. Иплэп кенә янына бар да, шушы алыпныкы хәтле резин итекләреңне күрсәтеп, әйт: Валентин Иваныч, диген, бу итекләр белән футбол уйнап булмас бит, диген. Аннары минем сигез километр җир кайтасым да бар бит әле, диген. Шулай диген дә, әллә кайтарып кына җибәрәсезме, барыбер җәяү атлыйсы ич ул сигез километрны — футбол уйнаганнан бер дә ким булмас, хәтта артык та булыр әле, диген. Безнең Валентин абый искиткеч әйбәт кеше ул. Менә шушылай мин өйрәткәнчә матур итеп сорасаң, сине дә һичсүзсез җибәрер.

Рухия — хәйләкәр кыз! — хаклы булып чыкты: Валентин Иванович класста яңа укучы барын бөтенләй сизмәде. Хәер, Равил үзе дә сизделергә бик тырышмады, хәтта посыбрак та утырды әле. Хәзер аңа шыпырт кына чыгып китәргә дә була иде. Ләкин... бер көн эчендә күпме алдашырга мөмкин соң инде?

Әнә шул турыда уйлап алды да:

— Валентин Иванович, ә мин! — дип кычкырып җибәрүен сизми дә калды.

— Что за «аминь» там? — дип, Валентин Иванович шактый кырыс кыяфәт белән әйләнеп караган иде, Равилне күреп, гаҗәпсенеп, сирәк сары кашларын сикертеп куйды да, кинәт йомшап-яктырып китеп:—

Ах, да, мин сине оныткanмын да, гафу ит, пожалуйста. Миңа бит Суфия Гайнутдиновна әйткән иде,— дип сөйләнә-сөйләнә, Равилне класс исемлегенә теркәргә кереште.

Ә шул арада Рухия Равилгә, эх, син, нигә куштанланып утырасың, дигән сыман итеп, канәгатьсезлек белдереп, зур кара күзләрен тутырып бер карады да, горур гына атлап, ишекне юри шапылдатып ябып, чыгып китте.

Яздан бирле уйнамый торгангадыр, күрәсең, сагынылган икән футбол. Итекләре авыр дип тормады Равил, үзәк һөҗүмче булып уйнады. Онытылып, рәхәтләнеп уйнады. Хәтта каршы яклар капкасына туп та кертә язды әле. Әгәр Әнәс дигән, башы-күзе акайган дуамал малай аяк чалып екмаган булса, туп, һичшиксез, тегеләр капкасына барып керәчәк иде...

Физкультура сәгате бетеп, Равил кайтырга чыкканда, көн инде кичкә авышкан иде. Җилнең әсәре дә юк, кояш, җәй көнендәгечә үк булмаса да, хәйран нык кыздыра. Офыклар киң, һава биек һәм суларга рәхәт иде. Иртәдән бирле ашаганы булмаса да, сәгатькә якын туп артыннан чабып йөрү үзенекен иткән икән: авылны чыгып, күпер төбенә барып җитү белән авызлары кипшеп, эчәсе килгәнен тойды Равил. Иөгереп төшеп, күпер буенда гына челтерәп агып яткан салкын чишмә суын чөмерә башлаган иде:

— Эй, дяденька, бу чишмәнең суын бушка эчәргә ярамый, иң элек түләргә кирәк! — дигән тавыш ишетеп, тукталып калды. Аңа бик таныш тавыш — Рухия тавышы иде бу. «Ах, чукынган кыз, тәки бер сәгать буена көтеп утырган бит!» Бер үк вакытта сөенеп тә һәм аптырап әнә шулай дип уйлап алды Равил. Аннары, кызга күтәрелеп карамыйча гына:

— Курыкма, кызыкай, бурычлы булып калмам, мин андый егет түгел,— диде дә юри озаклап, тешләре туңып чатный башлаганчы су эчте. Һәм шуның бик зур файдасы булды: Рухия тавышын ишеткәч читлегеннән чыгардай булып тырпылдый башлаган йөрәге шактый тынычланып калды, фикерләре яктырып китте. Югыйсә, хәрти иде егетнең хәлләре.

Равил чишмә яныннан купканда Рухия елганың аргы ягында бер кулына сумкасын, икенчесенә тал ботагы тотып басып тора, ләкин йөзендә гадәттәге сихри елмаю юк иде. Киресенчә, үпкәләп, турсаебрак тора иде ул.

— Шушыңарчы мине көтеп утырдыңмы, Рухия? — диде Равил, аның янына барып җиткәч.

Кыз горур гына итеп башын чөеп куйды:

— Ә кем әйтте әле сиңа, мин сине көтеп утырган дип? Бәлки мин монда су сатып тора торганмын! Ягез әле, әфәндем, түләгез әле рәхим итеп!

Шунда ялт кына, йомшак кына итеп кочып кына аласы да, менә сиңа, менә сиңа! дип, ике битеннән суырып үбеп кенә куясы бит инде Равилгә. Кыз сизми дә калган булыр иде. Сизсә дә, бер үпкәләгән булыр иде дә шуның белән үтеп китәр иде әле. Хәзерге кырык яшьлек акылы булган булса, Равил, әлбәттә, нәкъ менә шулай иткән булыр иде. Ике генә тапкыр белән дә чикләнмәс, дүрт, биш, ун тапкыр үбәр иде. Ләкин Равил ул чакта кыз-кыркын белән юньләп сөйләшеп карамаган һәм аларны бөтенләй җене сөйми торган, ә Рухияне алла урынына күреп йөргән саф, риясыз яшь егет иде. Шунлыктан ул кызның шаяртуын аңламады һәм ни әйтүен үзе дә белештермичә:

— Кем әйтте дип, белмәмешкә салышып торма инде син, Рухия. Бая мәктәптә үзең бергә кайтырбыз дип әйттең ич,— дип ычкындырды.

Тупасрак килеп чыкканын үзе дә шундук сизенеп алды алуын, әмма эш узган иде инде. Рухия, үз колакларына үзе ышанмагандай, берничә

секунд шаккатып, авызын ачып Равилгә карап торды. Аннары үтергеч итеп елмайды һәм:

— Шулай дип әйткән идеммени?! Рәхмәт инде искә төшерүең өчен! Эх, син...— диде дә, кырт борылып, Чүкәйгә таба китеп тә барды.

Хәзерге акылы ул чакта булган булса, кыз әнә шулай үпкәләп китеп барганда да югалып калмас иде Равил. Тиз генә куып җитәр иде дә, юләрләнмә, Рухия, мин ялгыш кына әйттем бит, әйдә, матур гына сөйләшеп кайтыйк әле бергәләп, югыйсә, без бер-беребезне рәтләп белмибез дә ич, дип иплән кенә култыклап алып, кайтыр юлга борыр иде. Ләкин ул вакытта хәзерге шикелле сабыр һәм салкын канлы түгел иде шул әле Равил. Дорфарак иде, тәҗрибәсез иде. Башы-аягы белән гашыйк иде. Ә гашыйк кеше барысын да уйлап-үлчәп эш итә алмый икән шул. Аннары аны велосипед мәсьәләсе дә бик нык борчып тора иде. Шуңа ул Рухия артыннан бара алмыйча, аның нигә кинәт үзгәреп китүен дә аңлый алмыйча, кадаклап куйгандай, баскан урынында катты да калды.

Үпкәләгән килеш, җилт-җилт атлап китеп барган килеш тагын да матуррак иде Озын толым. Бер дә килмәгән җире юк иде аның! Нәфис аяклары белән җиргә түгел, йомшак кына итеп, Равилнең йөрәгенә басып бара төсле иде. Равил аны авылга кереп китеп күздән югалганчы карап тормакчы иде. Болай булгач моның артыннан йөрүдән мәгънә юк, минем белән барыбер сөйләшергә теләмәс, дип уйлап тора иде ул. Бәхетенә каршы, бу юлы да Равил уйлаганча килеп чыкмады.

Күперне үткәч, күп тә бармады, кыз башта адымнарын акрынайтты, аннары бөтенләй туктап калды. Туфли башы белән юл тузанына нидер сызгалап, бер-ике минут уйланып торды. Аннары гәүдәсен бормыйча гына артына әйләнеп карады. Әле һаман бер урында басып торган Равилне күреп, авыз чите белән генә, әмма тирә-якны барыбер балкытып, елмаеп куйды һәм ялт итеп борылды да, тагын шулай йомшак кына Равилнең йөрәгенә басып, кире килә башлады. Равил, коты алынып, тагын нинди хикмәт китереп чыгарыр икән инде бу кызый, дип уйлап алган арада Рухия килеп тә җитте һәм зур, дымсу кара күзләрен тутырып карап:

— Нәрсә, Равил абый, китте инде бу, котылдым бу бәйләнчектән, дип сөенгән идеңме әллә? Ә мин, юри үч итеп, сиңа ияреп кайтам бүген! Әйдә, киттек! — дип, култыклап ук алды.

Кызның кул җылысын тоюы булды — күз аллары караңгыланып китте, башлары әйләнә башлады Равилнең. Шул минуттан тулысынча Рухия ихтыярына буйсынды: ул ни сөйләсә, шуны тыңлап, ул нәрсә сораса, шуңа җавап биреп барды. Үзлегеннән фикер йөртер хәлдә түгел иде ул. Һәм шулай булуы аңа әйтеп бетергесез рәхәт иде!

Ә кыз сөйләде дә сөйләде.

— Бигрәк тә томана инде бу авыл халкы,— диде ул, ничектер сүз арасында җаен табып,— бигрәк артка калганнар инде культурадан: иртән торалар да эшкә чабалар, кич кайталар да ятып йоклыйлар. Бүтән бер нәрсә белән кызыксынмыйлар да, кызыксынырга теләмиләр дә! Ә иң яманы шул: үз хәлләрен үзләре белеп, тик кенә тормыйлар, кешедән гаеп итеп, көлеп яткан булалар. Егетләрен әйтер идем! Китап укыганыңны күрсәләр, җинаятьчегә карагандай, «интеллигент» дип мыскыллап китәләр, кичләрен клубка перчатка киеп чыксаң, «хан кызы» дип авыз ерган булалар. Әйтерсең авылда тумаганыма мин үзем гаепле!..

Авыл мәсьәләсен хәл иткәч, шулай ук җентекле итеп, шәһәр тормышын мактады:

— Менә шәһәрдә тормыш дисәң дә ярый, ичмаса! Бер-берсеннән гаеп тә итешмиләр, кая телиләр — шунда баралар, нәрсә телиләр — шуны эшлиләр, ничек телиләр — шулай яшиләр. Беркемдә беркемнең

эше юк. Перчатка гына түгел, җәй көне тун киеп чыксаң да, һичкем синнән көләчәк түгел. Ә егетләре турында әйткән дә юк инде: шундый культурный, шундый вежливыйлар! Кызларның өйләренә килеп, әти-әниләренең рөхсәте белән генә кинога алып баралар, кинодан соң бас-кыч төпләренә тикле китереп куялар. Аннары, хәерле төн, тыныч йокы теләп, матур гына кайтып китәләр. Ә кайбер кызларны хәтта җәяү дә йөртмиләр, машина белән генә килеп алалар да машина белән генә китереп куялар!

Ул чакта әле үзләренең район үзәгеннән арыга киткәне булмаган һәм дөньяда Казан дигән зур шәһәр бар икәнлеген кешеләрдән ишетеп кенә белгән Равил өчен болар искиткеч зур яңалык иде, әлбәттә. Шуңа ул Рухиянең һәр сүзен йотлыгып тыңлап барды. Ләкин, шул ук вакыт-та, бу Озын толымның гел шәһәрне генә мактап, авылны бөтенләй юкка чыгарып калдыруы белән бик үк килешә дә алмады ул.

— Алай бик тә әйбәт, бик тә рәхәт булгач, нигә Казанда гына яшәмисең соң син? Нигә монда — бөтен яктан артта калган авыл җи-рендә чиләнәсең? — диде.

Бу сорауга җавап бирү кыен иде булса кирәк — Рухия башта бер сүз дә әйтмичә, тын гына уйланып барды. Аннары күтәрелеп карамый-ча гына әйтте:

— Соравыңны җавапсыз калдырсам, үпкәләмәссеңме, Равил абый?

Әллә нигә бер сүз кушып, анда да кызның авырткан җиренә кагы-луы өчен Равил күңеленнән тагын үзен нык кына битәрләп алды да:

— Ә мин гомумән үпкәли белмим! — дигән булды.— Шулай да син минем икенче бер бәләкәй генә соравыма җавап бир әле, Рухия?

Кыз, ризалыгын белдереп, керфек какты.

— Әйт әле, Рухия, синең үзеңне шәһәр егетләре ничек килеп алалар һәм ничек озатып куялар иде? Җәяү генәме, әллә машина беләнме?

— Минеме?..— Секунд эчендә кызның бите мәк чәчәгедәй кызарып чыкты. Озын керфекләре тагын аска сирпелде. Тик ул үзен тиз арада кулга алды һәм Равилнең күзләренә туп-туры карап:— Минем моңарчы китереп куйдыртканым да, килеп алдыртканым юк иде әле,— диде.— Яшь бит әле мин, уналты да тулмаган бит әле миңа, Равил абый! Әгәр эти шул эшендә эшләп, без киләчәктә дә Казанда яшәгән булсак, әлбәттә, машина белән йөртәчәкләр иде. Бер завод директорының малае һәр көн телефоннан шалтырата иде. Машина белән капка төбенә үк килеп алам, шәһәр күрсәтәм, шәһәр читенә һава суларга алып чыгам дип кыстый башлаган иде. Тик ул чакта миндә андый кайгы түгел иде әле. Ә мена хәзер каршы килмәс идем. Эш узды шул инде... Аңа да үкенмим. Югыйсә, авыл тормышын кайда күрер идем дә, кайчан синең белән сөйләшеп йөрер идем? Ә кеше үз гомерендә күпне күрергә, үзе хис итеп, татып карарга тиеш.— Кыз үзалдына елмайды. Аннары тирән итеп көрсенде дә әйтте:— Шулай да мин кичергәннәрнең кайбер-ләрен бүтән кешеләрнең, хәтта дошманым да, кичерүен теләмәс идем, Равил абый.

Бүтән ул хакта сорамаска әле генә сүз биргән булуына да карамас-тан, Равил тыелып кала алмады:

— Син сөйлисең дә сөйлисең, ә мин һаман берни дә аңлый алмыйм, Рухия: шушылай яшь кенә башыңнан ул тикле күрсенерлек нәрсәләр үргәнең бар соң әле синең? Яшермичә генә әйт әле, зинһар, нигә Казан тикле Казанны ташлап, авыл җиренә киләсе иттегез соң сез?

— Сер саклый беләсеңме син, Равил абый?

— Саклап карарга туры килгәне юк югын. Шулай да, туры килсә, сынатмам дип уйлыйм.

— Әгәр без иртәгә үк бер-беребезгә үпкәләшеп, яки бөтенләй дошманлашып китсәк тә — тьфү, тьфү, алай булырга язмасын, әйттем исә кайттым! — шулай да, иртәгә яки башка берәр вакытта ачуланы-

шып китәргә туры килсә дә, минем серемне саклый алырсыңмы, Равил абый?

— Хатын-кыз түгел ич инде мин сиңа, әйттем бит инде саклыйм дип!

— Ярый, ышанам мин сиңа, Равил абый. Мин аны беркемгә дә сөйләргә тиеш түгеллегемне дә бик яхшы белеп торам үзем, ләкин нигәдер сиңа сөйлисем килә. Тукта, кайдан башларга соң әле? Әһә, мәле, джентельмен булып, минем сумканы тот әле башта!

«Миннән дә юләр кеше юктыр бу дөньяда! Чүкәй күпере буеннан кузгалып киткән чакта ук үзем сорап алып тотып кайтырга тиеш идем ләбаса мин аның сумкасын!» — дип, оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булды Равил. Шулай да, соңлап булса да, гомер эчендә бер егетлек күрсәтергә башы житте үзенең:

— Әйдә, без аны менә болай гына итик, Рухия! — диде дә, җиңел генә итеп, кызны сумкасы-ние белән күтәреп алып та китте.

Рухия башта бик нык курыккан булды, тыпырчынган булды, җибәр яхшы чакта, җибәрмәсәң кычкырам, Равил абый, дип куркыткан булды. Ләкин Равил аларның берсенә дә игътибар итмәде. Дөресрәге, игътибар итәрлек хәлдә түгел иде. Чукрак иде, куанычыннан телсез-өнсез калган иде ул бу минутларда. Кызның ай-ваена исе дә китмичә, күтәреп баруын гына белде. Хәер, кыз үзе дә алай озак карышып азапланмады. Җәяү баруга караганда, Равил абыйсының көчле кулларында тирбәлеп баруның күп мәртәбәләр кызыграк та, рәхәтрәк тә икәнлеген сизенеп алды булса кирәк:

— Әһә, мин әйткәндә төшермәдеңме? Менә хәзер үзеңә үпкәлә инде, алайса: Укмаска житкәнче күтәреп алып кайт мине! — диде дә, егылып төшеп китмәс өчен, Равилнең муенын уттай кайнар кулы белән кочаклап, йокыга киткәнгә салышып, күзләрен үк йомды...

Я, хода! Бар иде бит, булды бит Равилнең бәхетле минутлары! Шул озын толымлы кызның толымнарын, җиргә тиеп сөйрәлеп бармасын өчен, үз иңенә салып күтәреп алып барган чакта кичергән рәхәтлекләрне, шул чакта татыган ләззәтне һәм шул чакта күңелендә булган горурлык хисен тагын бер мизгелгә генә яңадан кайтарып алып булса икән! Әгәр яңадан кайтарырга мөмкин булса һәм Равилгә әйтсәләр: икесенең берсен сайла — бөтен белемең, дәрәҗәләрең белән хәзерге хәлеңдә каласыңмы, әллә шуларның барысыннан да ваз кичеп, озын толымлы кыз белән Чүкәйдән Укмаска бергә кайтасыңмы, дисәләр, ул, һичшиксез, соңгысын сайлар иде. Ләкин бу мөмкин түгел шул инде!

Ә ул көнне... Рухиянең юри генә йоклаганга салышуын бик яхшы белеп торса да, Равил, аны «уятудан» куркып, шактый араны бер сүз дә әйтмичә, тыныч кына атлады. Кызның озын керфекләренә, нәфис ак маңгаена бик тә килешле итеп урнаштырылган карлыгач канатлары — кашларына, алсу алмадай алсу битләренә, чиядәй кызыл иреннәренә карап һәм сокланып бару бик тә, бик тә рәхәт иде аңа. Шуннан башка берни дә кирәк түгел иде. Әгәр кыз шулай йокымсырап кына барган булса, Равил аны Укмаска илтеп житкергәнче бер сүз дә дәшмәячәк — борчырга кыймаячак иде. Ләкин, гадәтенчә, бу юлы да Рухия тынлыкны үзе бозды. Башта ул күзләрен ачты. Күзләре кояшта чагылганга, озын керфекләрен каккалап, иркә генә елмаеп куйды. Аннары сорады:

— Я, булдымы инде, Равил абый, арыдыңмы? Төшер инде мине!

— Арысам, ат яллармын, Рухия,— диде Равил, кызны өркетмәс өчен мөмкин кадәр йомшак һәм якын итеп,— ләкин хәзергә бер тамчы да арымадым әле. Бигрәк җиңел икәнсең син — мамык кебек кенә. Теге сереңне сөйләмичә һич тә ычкындырачак түгел мин сине. Әйдә, сөйлә, Рухия!

Бик үк уңышлы чыкмаса да, Равилнең бу шаяртуын ошатты булса кирәк — Рухия көмеш тавышы белән рәхәтләнеп көлеп куйды һәм шундук җитдиләнеп китте дә әйтте:

— Ой, әйе, мин бит сиңа ни өчен бу якларга килеп чыгуыбызны сөйләмәкче идем! Тик син мине иң элек җиргә бастырырга тиеш! — дип, каршы килергә һич урын калдырмыйча, ялт кына Равил кулыннан сикереп төште һәм иплэп кенә сөйләргә керешге.— Мин әниемне күбрәк яратам, шуңа аннан башлыйм әле. Унөч ел балалар укыткан һәм Казанда әйбәт педагоглар исәбендә йөргән кеше ул минем әнкәй. Ләкин хәзер Укмаста кибетче булып эшли. Үз предметы — татар теле һәм әдәбияты буенча Укмас мәктәбендә сәгатьләр булмады, ә башка фәнне әни үзе укытырга теләмәде. «Белер-белмәс укыту — акча алыр өчен генә укыту булыр иде, ә мин алай теләмим, балаларга тиешле белемне бирә алмыйча, гөнаһлы булып калыр хәлем юк», дип, сату эшен яратмаса да, кибеткә керде. Ә менә эти...— Кызның кинәт күңеле сүрелеп, йөзендәге матурлык балкышы тоныкланып китте, дымсу кара күзләре дә уйчанланып калды:— Сугышка кадәр, мотор төзү заводында мастер булып эшләгән чагында, безнең эти дә бик әйбәт кеше булган. Вакытында киткән эшенә, вакытында кайткан. Өйдә дә бик иплe, бик йорт җанлы булган. Әниемне дә раткан, ә мине бөтенләй кулыннан да төшермәгән инде — шул тикле сөйгән. Мине түшәмгә тикле чөя-чөя уйнатуларын, эшеннән кайтышлый көн саен конфет-шоколад алып кайтуларын үзем дә яхшы хәтерлим әле... Аннары ул сугышка китте. Фронттан килгән хатлары да искиткеч әйбәт иде. Ә менә сугыштан кайтып, яңадан шул заводта цех начальнигы урынбасары булып эшли башлагач, әллә нишләп бик нык үзгәреп, усалланып китте ул. Әнием белән дә бер дә юктан талашып китә, минем белән дә салкын гына сөйләшә торган булды. Ә инде моннан өч ел элек шул үзләренең заводында тагын да югарырак урынга — цех начальнигы булып күтәрелгәч, бөтенләй бозылды: эштән соңга калып кайта, эчә. Кайта да бер сәбәпсез әниемә җикеренергә тотына. Миңа да юньле сүз юк. Тора-бара кайдадыр кунгалап та кала торган булып китте. Командировкага дип чыгып киткән була да Казанда яшеренеп ята икән. Әни никадәр генә белгертмәскә тырышса да, аның хикмәтләрен күрше-күләннәр дә чамалый башлады. Барысын да эчеңә генә җыеп ятма, Мәрьям, завод директорына бар да бөтенесен сөйләп бир, аңа гына көчләре җитәр, бик тиз авызлыкларлар аны анда, дип, әнине үгетләп тә караганнар иде. Тик әни, белмим, кызгангандырмы, әллә курыккандырмы — беркая да бармады.

Әни ябыкты, сүзсез калды. Миңа да иптәшләрем арасында бик уңайсыз, ата-аналар җыелышына бүтәннәрнең этиләре килә, минекенең бер тапкыр да килеп караганы юк. Менә шул хәлләрдән соң минем түзәр чамам калмады: быел кыш тоттым да, этинең үземә мәгълүм булган бөтен-бөтен кыланышларын әйтеп, әгәр тиз арада аңа чара күрелмәсә, мин артык түзеп тора алмыйм — үземә бер-бер хәл эшләргә мәҗбүр булачакмын дип, бер үк төрле итеп, берьюлы өч хат яздым. Шуларның берсен обкомга, берсен «Комсомольская правда» газетасына, берсен эти эшли торган завод директорына адреслап җибәрдем.

Кайсылары алдан тикшерә башлагандыр, белмим, әмма мин хат язып җибәргәнгә ике ай да үтмәде — этине эшеннән бушаттылар. Әнине чакыртып сораштырганнардырмы, юкмы, анысын әйтә алмыйм, минем белән сөйләшмәделәр. Күрәсең, кирәк дип тапмаганнардыр. Этинең эшендә дә гөнаһлары җитәрлек булган, ахрысы, судка барып җитсә, эш зурга китә дип, директоры йолып калган, диделәр.

— Әйдә, бераз авыл җирендә эшләп гыйбрәт алып кайтсын. Шуннан соң бәлки белер дөньяның кадерен! — дип, Авыл хуҗалыгы министры

белән сөйләшеп, шушы Укмас МТСына баш механик итеп җибәрткән ул аны.

Менә шулай итеп сезнең якларга килеп чыктык инде без, Равил абый. Күрәсең, минем аркада эшләнгән эш бу.

«Кара син аны, яшь кенә булса да, әллә никадәр борчу кичергән икән ләбаса бу кыз! Шуңа шушылай барысын да бик белеп, олы кешеләрчә сөйләшә торгандыр инде»,— дип уйлап алды Равил. Аннары кызны кызганып:

— Ничек соң, Рухия, файдасы булыр тәсләме этиеңә? Гыйбрәт алыр чамасы күренәме? — дип сорады.

— Гыйбрәт алырмы-алмасмы, белмим,— диде кыз.— Ләкин кикриге шиңде. Хәйран яхшырып китте хәзер. Әнигә дә «әнкәсе» дип, миңа да «кызым» дип кенә тора башлады.

— Ә хатны син язганны беләме атаң?

— Юк, Равил абый, сизмәде бугай ул аны. Тикшерүчеләргә рәхмәт инде, алар минем хәлне аңлаганнар — сиздермәгәннәр булса кирәк.

— Ай-яй, батыр йөрәкле кыз икәнсең син! — диде Равил.— Минем егет башым белән дә шул эшкә тәвәккәллегем җитмәс иде.

— Комплиментың өчен рәхмәт, Равил абый. Ләкин минем бүтән чарам юк иде ул чакта.

— Ә хәзер шул кызулыгыңа үкенәсең, ахры, шулаймы?

— Каян чыгып әйтәсең әле син моны?

— Әле яңа гына авылны яманлап, шәһәрне мактап килдең түгелме соң?

Кыз рәхәтләнеп көлеп алды.

— Ә-ә-ә, син әнә нәрсәне әйтәсең икән! Чынлап әйтелгән сүзләр түгел лә ул. Просто шаярып, син ни дияр икән дип кенә шулай сөйләдем мин, Равил абый. Ә авыл миңа ошый.— Ул әсәрләнеп китеп, очарга талпынган аккош шикелле кулларын җәеп җибәрде:— Карагыз әле бу иркенлекне! Күрегез әле бу кырларның матурлыгын! Ә һавасы, ә һавасы — сулап туймаслык бит! Юк, үкенмим мин монда кайтканыбызга!

Алар Укмасның басу капкасы төбенә кайтып җиткәннәр иде. Велосипед камералары биреп җибәрәм дип, Рухия Равилне өйләренә үк алып бармакчы иде. Ләкин Равил якын да килмәде. Басу капкасын керү белән тукталды да:

— Юк, Рухия, мин сезгә бара алмыйм: оялам, йөрәгем җитми,— дип терәлде дә катты. Ә тегесе гел кыставын белде. Инде бик аптырата башлагач, Равил серне ачып:— Дөресен генә әйткәндә, миңа бернинди камера да кирәк түгел, чөнки минем велосипедым юк! — дип әйтеп тә караган иде. Ләкин Рухия аны ишетергә дә теләмәде.

— Димәк, син мине иртәгә утыртып алып барырга теләмисең? Эх, син, классташ дип, мин сиңа ышанып кайткан булдым тагы! — дип үпкәли үк башлады.

Эшләр болайга ук килеп җиткәч, Равил авыл уртасындагы күпер төбенә тикле барырга мәҗбүр булды һәм кызны шунда көтеп утырды.

— Сорап алдыңмы боларны? — диде Равил, Рухия бик тиз әйләнеп килгәнгә гаҗәпләнеп.

— Курыкма инде, зинһар! — диде кыз, һич тә шик калдырмаслык итеп.— Әлбәттә, сорап алдым. Әни минем математикадан йомшак икәнне белә, шуңа күрә, математика укытучысына кирәк дип сорасаң — җанын да бирергә әзер! Бар, Равил абый, кайт та бүген үк велосипедыңны көйләп куй. Кара аны, иртән мине килеп алырга онытма! Сәгать җиде туларга егерме минутта мин басу капкасы төбенә барып көтеп торырмын, яме!

— Тырышып карармын, Рухия.

## 7

Әй, егетләр, бар бит дөньяда вакчыл бәндәләр! Равил ялынып-ялварып Иосыф абыйга велосипед сорап керде, ә теге нәрсә ди? Камераны ярып кайткансың, имеш! Якасыннан каптырып кына аласы иде дә хәзер, теге көнне үзең тикшереп алдың бит, нигә шунда күрмәдең, күзең чыккан идемени дип, акылына утыртасы иде азрак!.. Ләкин юк, ярамый. Иосыф абый ни генә әйтсә дә, тешен кысып түзәргә мәҗбүр иде ул көнне Равил. Чөнки аның бөтен киләчәге, бөтен өмете менә шушы камера игәүләп утыручы дәү башлы, нечкә муенлы, кашларына ук диярлек тоташып үскән куе кара чәчле һәм киң танаулы адәмгә бәйләнгән. Равилне кыен хәлдән коткарса, ул гына коткара ала иде. Шуңа ул аңа сукыр бер тиенлек тә үпкәләмәде. Киресенчә, аның хәлен аңлап алып, әһә, бу агай «ашыгыч ярдәм» күрсәтергә ашыккан булган икән дә, эше барып чыкмаган икән, дип кызганып та куйды әле. Ә «ашыгыч ярдәм»нең хикмәте менә болайрак иде: кечкенә авыл булганлыктан, файдасы юк дип, райпо Ташый елгада кибет ачмаган һәм ачарга җыенмый да иде әле. Ләкин, кечкенә авыл булса да, Ташый елгада да теге «шайтан суы»ның хаҗәте гел чыгып тора. Кемдер мич чыгаручы белән мич чыгартырга килешә; я берәрсе ат белән (әлбәттә, колхоз аты белән инде) берәрсенә печәнен алып кайтып бирә; кемдер, дус-ише белән бергәләп, каравылчы сизмәгәндә генә урманнан ике-өч бүрәнә чәлдереп кайткан була; кемдер мунча бурата башларга мөгәрич сөйләшә; кайсы каралты-курасын сипләткән була; ә кайберсенең башы бик каты авырткан чагы туры килә дә... Кыскасы, көн саен диярлек сәбәбе чыгып, кирәге табылып кына тора шул бәдбәхетнең. Ә ул әйберне, кибет булмагач, Ташый елгада табам дип уйлама да. Аның өчен Качкалакка — алты километрга барырга туры килә. Барып та һәркем ансат кына юллап кайта алмый әле аны, чөнки кибеттә дә алай тулып ятмый ул нәрсәкәй.

Менә шундый чакларда бик интеккән кешеләрнең барысы да Иосыф абый катына килә. Бүтән мәсьәләләр буенча килүчеләр белән бик коры сөйләшсә дә, мондый вакытта, ходаның хикмәте белән, искиткеч йомшак күңелле, кешелекле кешегә әверелә ул. «Ничә бүтилкә кирәк?» дип кенә сорый да велосипедына атланып, Качкалакка элдерә. Беркайчан да, берәүнең дә үтенечен кире какмый. Ихтимал, өенең бер почмагына ут кабып, өе яна башласа да исе китмәс: башта, Качкалакка барып кайтып, кешенең үтенечен җиренә житкерер, тик шуннан соң гына өен кайгырта башлар иде ул. Аннары Иосыф абыйның тагын шул яклары яхшы: бердән, бик тиз әйләнеп кайта, икенчедән, беркайчан да буш кул белән кайтмый, өченчедән, көндезме, төнләме, кичме, иртәме — теләсә кайчан алып кайта. Хәтта кибеттә күрсәтеп сатуда булмаганда, Качкалак ир-атлары үзләре дә тилмереп йөргән чакларда да буш кул белән кайтмый, дип сөйлиләр аның турында. Әнә шул бик тә кадерле, Ташый елгада бүтән беркемдә дә булмаган «маһирлыгы» өчен аны борынгырак кешеләр «лухки избуччик» дип, яшьрәкләр исә «ашыгыч ярдәм» дип йөриләр. Дөрес, Иосыф абый ул «ашыгыч ярдәм»не коры рәхмәт өчен генә күрсәтми, әлбәттә. Бәясе билгеле аның: бер шешә алып кайтартучыдан — йөз грамм, бердән артык булса (кирәк ун булсын шунда, анысы барыбер) 150 граммы анык булырга тиеш. Шунысы кызык тагын: акчалата беркемнән дә бер тиен дә алмый икән үзе. Шулай ук калган акчасын да хуҗасына кайтарып бирми — анысын Качкалакта ук «салып» кайта дип сөйлиләр.

Менә бүген дә, ишегалдында бик ачуланып камера ямап яткач, мөгаен, «ашыгыч ярдәм»гә дип чыккан булгандыр да шушы бәлага таргандыр дип, Иосыф абыйны кызганып куйды Равил. Һәм ул, шул форсаттан файдаланып, аңа ярдәм итеп калырга, ә аннары сүзне үзенә

кирәк якка борып җибәрергә ниятләп, сумкасыннан камерасын алды да:

— Каяле, үлчәп карыйк әле менә бу нәрсәне, синең велосипедыңның көпчәгенә ярыймы икән? — дигән булып, аны Иосыф абыйга сузды.

Әй күрсәгез иде сез ул минутта Иосыф абыйның кыяфәтләрен! Ул башта, өнемме бу, төшемме бу, дигәндәй аптырап, Равилгә карап торды. Аннары ялт итеп аның кулыннан камераны тартып алды да бик җентекләп тикшереп чыкты. Камераның, чыннан да, чын камера, яңа камера икәнлегенә, ниһаять, тәмам ышангач кына, телгә килеп:

— Әйт, энекәш, күпме сорыйсың шушы камераң өчен? — диде.

«Каба бит бу, болай булгач! — дип куанып уйлап куйды Равил.— Каптыргач-каптыргач, яхшырак каптырырга кирәк иде үзен».

— Бер тиен дә кирәкми миңа, Иосыф абый! Бүгеннән алып мин Чүкәйдә сигезенче класста укый башладым. Велосипедыңны бер атна шунда барып-кайтып йөрергә биреп торсаң — бик җиткән!

Иосыф абыйның әле яңа гына яктырган чырае шундук сытылып китте.

— Юк,— диде ул, кырт кисеп,— бер атнага булмый! Ә өч көнгә риза булсаң — мә!

Шулай диде дә, шап иттереп, Равилнең кулына сукмакчы булган иде, ләкин Равил кулын бирмәде. Аның әле тагын бер камерасы бар иде бит. Аны ипигә ягып ашап булмый ич, Равилгә бер тиенгә дә кирәге юк лабаса ул камераның. Шул ук вакыттан өч көнгә ике камера бирү дә артыгын очсызга килешү булыр иде. Шуңа ул кул сугышырга ашыкмады һәм, ни булса — шул дип, тәвәккәлләп әйтте тегеңә:

— Алайса, болай итәбез, Иосыф абый: мин сиңа аның менә монысын да бирәм, ә син велосипедыңны миңа шушы атна ахырына тикле биреп торасың, булдымы?

Иосыф абыйның күзләре тагын очкынланып китте.

— Монысы да яңамы? Каян чәлдердең син боларны, малай актыгы?

— Монысы да заводтан әле яңа гына чыккан, суынып та җитмәгән хәтта! Ә каян алганымны син сорама, Иосыф абый, мин әйтмим!

— Чукын инде алайса, әйдә, синеңчә булсын! — диде Иосыф абый, тагын бераз икеләнеп торгач.— Түлке менә болай килешәбез, яме: биләсәпитне иртән минем ишегалдыннан алып китәсең, кайткач шунда китереп куясың штубы! Ишеттеңме?

— Ишеттем, Иосыф абый, нәкъ синеңчә булыр!

— Ярый, күп сайрама! Ә хәзер, давай, шушы яңа кәмирәләрне кигереп куйыйк та тиз генә барып кайтыйм әле мин барасы җиремә.

— Качкалакка барышың идеме әллә, Иосыф абый?

— Сыер икәнсең, сабакы малай, өстенә генә бастың. Шунда дип чыкканыем шул. Чулак Саматның хәле бик мөшкел икән анда: башны төзәтмәсәм — үләм, ди. Күрә торып үтермик инде адәм баласын. Ул үлсә, сиңа да кыенга туры килер — ат көтүе үзеңә генә калуы бар.

Иосыф абый әнә шулай үзалдына гына сөйләнгәндәй мыгырданган арада икәүләп яңа камераларны көпчәк тугымнарына кидереп, аларга һава тутырдылар. Аннары Иосыф абый, артыннан кугандай ашыгып, Качкалакка элдертте.

Равилне инде кайчаннан бирле бик каты борчып торган һәм бөтенләй хәл итеп булмастай тоелган четерекле мәсьәлә һич тә уйламаганча әнә шулай аңсат кына хәл ителде дә куйды.

Их, тагын бер генә атнага булса да велосипед табып торасы иде дөньяда! Нинди рәхәт булган иде бит узган атнада! Ул көннәрдә җир йөзендә Равилдән дә бәхетлерәк кеше, мөгаен, булмагандыр да. Хәер, бер Равил генә түгел, Рухия үзе дә бик канәгать, бик шат йөрде. Иртән Равил аларның басу капкасы төбенә килгәндә, бөтен дөньяны балкытып, көлеп каршы ала, кичен шунда китереп куйгач, кул болгап озатып кала иде. Һәр көнне укудан кайтышлый, урман буена туктап, китапларын үлән өстенә, дәфтәрләрен кәүсәләре кисеп алынган куш имән төбенә куеп, алар биш көн рәттән дәрес хәзерләделәр: алгебрадан, физикадан, тригонометриядән өйгә биреп җибәрелгән мәсьәләләрне чиштеләр, мисалларны эшләделәр. Рухия уйлап чыгарган иде моны. Математика белән физиканы бик үк өнәп бетерми икән ул кыз. Артык тырышмый да, тырышканда да физика законнарының, тригонометрик теоремаларның серенә төшенә алмый интегә икән. Ә болар — Равилнең иң яраткан фәннәре. Менә шуңа күрә дә Рухия дәресләргә аның белән бергәләп хәзерләнергә тырыша иде. Әй, рәхәт тә иде соң шул кызыйның кайнар сулышын һәм чигә чәчләренең биткә кагылып-кагылып китүләрен тоеп утырулары! Алар утыра торган куш имән төбе колач җитмәслек юан һәм өстәл шикелле тигез иде. Их, тагын ике генә, һич югы, бер генә көн икәү шул имән «өстәл» артында утырып дәрес хәзерлисе иде дөньяда!..

Ләкин, юк, тәтемәс шул инде ана андый бәхет. Велосипедка утырып йөрисе булмагач, Рухия кайта-килә йөрүдән туктар да, иптәш кызлары кебек, мәктәп интернатында торып кына укый башлар. Ә иң куркынычы шул: велосипедның Равилнеке булмаганын белгәч, ялганчы кеше икәнсең син дип, Равил белән бөтенләй сөйләшмәс булыр. Иртәгә иртән Рухия басу капкалары төбендә көтеп торачак бит аны... Йосыф абыйга барса да файдасы булмас шул. Кичә дә, велосипедын илтә баргач:

— Ике кулсыз иттең син мине, сабакы малай! Биш көн генә түгел, биш ел йөрткән шикелле булдың,— дип мыгырданып калды.

Кая барып бәрелергә соң инде хәзер?..

Уйлады-уйлады да, ниһаять, аккордеонын Йосыф абыйның велосипеды белән алыштыру турында сөйләшеп карарга булды Равил. Әйе, аккордеоны бар иде Равилнең. Кырык өченче елны сугыштан кунакка кайтып киткән чагында Искәндәр абыйсы калдырып киткән иде аны. Бик шәп булып чыкты ул нәрсә: күрер күзгә дә искиткеч матур — гел пыяладан гына эшләнгән төсле ялтырап тора. Тавышы да бик чиста һәм моңлы иде аның. Искәндәр абыйсының кулы җиңел булды: ул китүгә өч-дүрт ай да үтмәгәндер — хәйран гына уйный да башлады Равил. Ул чакта Равил бәләкәй, алдына алып утыргач, аккордеон артыннан башы гына күренеп тора торган иде. Еллар үткән саен Равил үзе дә үсте, аккордеонда да яхшырак уйный башлады. Инде менә ике-өч ел рәттән Октябрь һәм Май бәйрәмнәрендә колхоз хисабына үткәрелә торган һәм, әйтергә кирәк, гаҗәеп күнелле үтә торган мәҗлесләргә гармунчы итеп авыл ир-атлары гел Равилне дәшәләр иде. Әнә шул мәҗлес кичләренең берсендә бераз кызып алганнан соң, әлеге дә баягы, Йосыф абый әсәрләнеп киткән иде дә:

— Их, энекәш, уйныйсың да соң! Ятим бала моңлы була диләр иде, тәки хак икән. Ну, әйттерәсең дә инде, сабакы малай: прәме йөрәкнең әллә кай җирләрен умырып алган шикелле итәсең! Әгәр теге патифун пластинкасында уйный торган Мохтар Әхмәдиев белән ярышып карарга туры килсә, иманым кяфер китсен дип әйтәм, җиңә үк алмасаң да, аннан бер тамчы да калышмас идең! — дип кычкырып әйтеп куйган иде.

Аның шул сүзләреннән соң авыл халкы да, үз итеп, яратып, Равилгә Мохтар Әхмәдиев дип йөри башлаган иде инде.

Хәер, бер ул гына кызыкмый, башкаларның да күзе төшә иде аның аккордеонына. Әле узган көз көне генә Качкалакның армия хезмәтеннән кайткан бер гармунчы егете килеп, сат-сат дип канын корткан иде Равилнең. Нинди генә зур бәя тәкъдим итеп тә Равилнең акчага кызыкмавын белгәч, бер сарык белән җәй йөргән бер бозауга алышырга да бик тырышып караган иде. Бозауның киләчәктә сыер буласын күз алдына китереп, башта Равил үзе дә ымсынып куйды ул чакта. Әмма аккордеонының гади аккордеон гына булмавын, Искәндәр абыйсына фронтташ дусты васыять итеп калдырган, димәк, күз карасыдай сакланырга тиеш әйбер икәнлеген хәтеренә алу белән ул ымсындыргыч фикереннән кире кайтты һәм:

— Юк, агайне, булмый! Йөге белән алтын китерсәләр дә, беркемгә дә бирмәячәкмен мин моны! — дип, теге егетне борып җибәргән иде.

Ә менә бүген... Искәндәр абыйсының аманәтен бозу булса да, аннары килеп үзенә дә бик кызганыч тоелса да, Равил аккордеонын Йосыф абый белән велосипедка алыштыру хакында сөйләшеп карарга булды.

Равил килгәндә велосипед хуҗасы капка буендагы эскәмияләрендә тәмләп кенә тәмәке тартып утыра иде. Берәрсенә «ашыгыч ярдәм» күрсәтеп кайткан иде булса кирәк: эчкә батып торган яшькелт күзләре ялтырый, йөзе бөтен шарты килеп пешкән бәрәңге пәрәмәченеке шикелле кызарып киткән, чигә тамырлары зәңгәрләнеп бүртеп чыккан иде. Йосыф абыйсын беренче тапкыр гына күрүе түгел, белә Равил: салмыш чакта кыяфәте гел менә шушылай була аның. Аннары тагын шунысы да мәгълүм Равилгә: мондый вакытта кәефе әйбәт була Йосыф абыйның. «Капмаган» чагында гына бик кырыс ул. Мондый чагында сөйләшеп була аның белән.

— Нихәл, Йосыф абый? — диде Равил, тегенең янына ук килеп утырып.— Көтү кайтканын көтеп утырабызмы?

«Капмаган» чагы булса, синең ни эшең бар минем нишләп утыруда, дип кенә җибәрер иде ул. Ә хәзер кәефләнеп, бер тирән итеп тәмәкесен суырды да:

— Хәлләр изге, энекәш, тик менә Һадия апаң гына бизде! — диде. Үз сүзеннән үзе тәм табып, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Көләсе килмәсә дә, тегенең күңеле булсын өчен, Равил дә кушылып көлгән булды. Һәм шунда, форсаттан файдаланып, әйтә куйды:

— Һадия апа музыка ярата бит ул, ә соңгы вакытларда сезнең өйдә гармун тавышы бөтенләй ишетелми башлады: шуңа бизмәде микән аның күңеле, Йосыф абый?

— Белеп сукалыйсың бит син, сабакы малай! — диде теге, Равилгә гаҗәпләнеп карап.— Тучны, Һадия апаң әле кичә генә, нигә бер дә уйнап карамыйсың ул гармуныңны, телләре күгәреп бетә бит инде аның, дип мыгырданып утырганые чәй эчкәндә.

— Шулай булгач, нигә азрак уйнап күрсәтмисең соң үзенә?

— Һей, уйнарлыгы калганмыни соң минем ул гармунның — тәмам кибеп-коргаксып беткән бит инде ул, чыгарып ташлыйсы гына калган аны! — диде Йосыф абый, кулын селкеп. Һәм шундук әсәрләнеп китте дә:— Синеке шикелле әкәрдиун булсыные ул! Вәт уйнап карарга булыры ул чакта! — дип телләрен шартлатып куйды.

— Ә нигә әйтми утырасың аны? — диде Равил, җай чыкканга сөенеп.— Әйдә, син миңа велосипедыңны бирәсең, ә мин сиңа аккордеонны китереп бирәм дә — эше бетте!

— Мә бишне дә, бар, йөгер әкәрдиуныңны алып килергә! — дип кулын күтәргәч, Йосыф абый нигәдер кинәт туктап калды да, барма-

гын Равилнең борын төбендә үк селкеп:— Юк, малай, булмас, барып чыкмас синең бу махинатсияң,— диде.— Биләсәпитсез калдырып, син мине ике кулсыз итмәк буласың бит. Әкәрдиунсыз тора алам мин, ну, биләсәпитсез — булмый, агайне, извини пужалысты! Көненә икешәр-өчәр рәт барып кайтырга туры килә бит миңа Качкалакка.

— Соң, алла бәндәсе, тиздән барыбер җәяүгә каласың лабаса, пычрак башлана, кар ява бит озакламыйча! — дип тә әйтеп караган иде Равил. Ләкин Иосыф абый ишетергә дә теләмәде.

— Әйттем — бетте! Бүлше ул турыда авыз да ачасы булма! — диде дә, тәмәкесен тиз генә таптап сүндереп, өйләренә үк кереп китте.

Равилнең соңгы өмете дә өзелде һәм ул, шуңа бик нык кайгырып, гадәттә берәр солы яки бодай кибәне буена ятып йоклап ала торган өч-дүрт сәгать йокысын да йоклый алмады ул төнне. Иртән атларны көтүлектән җыеп алып кайткан чагында да Рухиягә бирәчәк җавабы әзер түгел иде әле аның. Дөресен әйтеп бирергәме яки тагын берәр сәбәп тапкан булып алдашыргамы икәнен тәки хәл итә алмаган иде. Шулай да бөтенләй үк бәхетсез җан түгел иде, ахрысы, ул. Бу юлы да мәсьәлә һич тә көтмәгәнчә ансат хәл ителде: Равил кәнүшнидән кайтып килгәндә Иосыф абый аның каршына үзе килеп чыкты да:

— Кичә теге син әйткән сүзне Һәдия апаңа әйткәнием, тач сагыз урынына ябышты бит, наный: көннән-көн картаюга барасың, кеше йомышын йомышлап йөрер чакларың узып бара, алыш биләсәпитеңне әкәрдиунга, ди. Аннары кичә үзең дә бик борлыгып кайтып киткәниең бит, сине дә җәлләп куйдым да, үзең туганрак та тиешле кеше булгач, аллага тапшырып, тәвәккәлләргә булдым. Бар, наный, алып кил әкәрдиунныңны да алкитәрсең минем биләсәпитне! — диде.

«Монысы шәп булды бит әле моның! Тик менә әни ни дияр икән соң?» дип хәвефләнебрәк кайткан иде Равил. Гаҗәпкә каршы, әнисе — изге җан — бу юлы бөтенләй сүз көрәштереп тә тормады.

— Искәндәр абыең сиңа бүләк иткән әйбер бит. Шулай булгач, үзең чамала инде, улым. Алай-болай абыең кайтып төшеп, кая куйдың мин калдырган әкәрдиунны, дип сораганда аның хәтерен калдырмаслык җавабың әзер булса, алыштыр,— диде дә чишмәгә суга төшеп китте. Ә Равил: «Ярар, Искәндәр абый кайтсын гына иде әле, ничек-ничек булганын сөйләп биргәч, ачуланмас, хәлемне аңлар иде»,— дип, тәвәккәлләп, күңел юаткычы булып хезмәт итеп килгән иң якын дусты — аккордеонын шул сәгатендә үк Иосыф абыйның иске велосипедына алмаштырып кайтты.

Равилнең бәхетенә каршы, ул елны көз коры килде. Әле дә хәтерендә Равилнең, алар октябрьның җидесенә кадәр кайта-кила йөрделәр. Дәресләрен дә, гадәттәгечә, әлеге куш имән төбендә хәзерләп кайталар иде. Тагын шунысы бик яхшы хәтерендә калган: Рухия әдәбият белән тарихны бик ярата иде. Кечерәк кенә тарихи вакыйганың да кайда, кайчан һәм ни сәбәптән булганлыгын сора — шундук әйтә дә бирә. Әдәбиятны аеруча ярата иде ул кыз. Мәүлә Колый, Габделҗаббар Кандалый, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Һади Такташлар кебек әдәбият дәреслекләренә кертелгән язучыларны әйткән дә юк инде, хәтта Равилнең ишеткәне дә булмаган бик күп әдипләрнең биографияләрен, язган китапларының исемнәрен, ул китапларның эчтәлекләрен дә бик яхшы белә иде Рухия. Рус әдәбияты хакында сүз чыкса, шулай ук судагы балык иде инде. Әле дә хәтерендә, бер көнне шулай, сүз җаен туры китереп, Равил аңа:

— Әгәр син укыган китапларның яртысын гына укып чыккан булсам да, мин үземне бик бәхетле санар идем, Рухия! Ләкин авылда китапханә булмагач, миңа бөтенләй диярлек укырга туры килмәде шул,— дип офтанып әйтеп куйды.

Рухия кинәт кенә моңсуланып китте.

— Әй, кызыкмасана миңа, Равил абый! Шул китап укый-укый шушы көнгә калдым инде мин: күреп торасың ич, математикага бөтенләй тешем үтми хәзер.

Куыш имән төбендә дәрес хәзерләп утырган чакларында сөйләшкән сүзләреннән Равилнең хәтерендә тагын шунысы ачык сакланып калган. Инде өч-дүрт көн бергә кайта-килә йөргәннән соң да, Рухия үзенә әле һаман таныш түгел кешегә эндәшкәндәй «абый» дип йөргәнгә сәерсенеп, Равил аңа:

— Нигә син миңа абый дип әйтәсең, кызый? Минем синнән бер генә яшькә олырак икәнлегемне беләсең бит инде. Аннары классташлар да ич без. Ә классташлар бер-берсенә абый-апа дияргә тиеш түгел! — дигән иде.

Кыз чиядәй алсу иреннәрен искиткеч матур итеп бөрештерде дә, берәр шаянлык эшләгәннән соң әтисеннән гафу үтенгән иркә бала сыман:

— Ачуланма инде, Равил абый! — диде.— Беләм, барысын да бик яхшы беләм. Ләкин барыбер сиңа «абый» дип йөрисем килә. Минем кече-кечкенәдән абыйлы буласым, кемне булса да абый дип йөрисем килде. Тик андый кешенең очраганы юк иде әле. Ә син миңа нәкъ менә үз абыем шикелле тоеласың, Равил абый! Ачуланма инде син миңа, икебез генә булган чакларда гел «абый» дип йөрергә рөхсәт ит инде, яме. Ә класста мин сине просто Нәҗметдинов дип кенә йөрермен, ярыймы, Равил абый?

— Ярый, тик шуны исеңдә тот: сеңелләр абыйларының сүзен тыңларга тиеш!

— Бүтән теләсә нәрсәгә риза, әмма монысын үти алырмын дип вәгъдә бирә алмыйм, Равил абый.

— Нигә, син шулай тыңлаусызмыни?

— Юк, алай бер сүз белән генә әйтеп биреп булмый аны, Равил абый. Хикмәт тыңлаусызлыкта гына түгел монда. Ничектер даимилек җитми миңа. Кайчакта үзем дә сизмәстән һич уйламаган юләрлекләрне эшләп ташлыйм да ахырдан айлар буе үкенеп йөрергә туры килә. Хисләнеп, әсәрләнебрәк китүчән мин. Менә шундый чакта эшләргә тиешле нәрсәләрнең нәкъ киресен эшләп ташлаган чакларым да була.

— Анысыннан гына зыян юк, Рухия. Анысын гына аңларга тырышырбыз. Авылда туып үссәк тә, бөтенләй үк юләр егет түгел ич без.

## 9

Бәхетле, иксез-чиксез бәхетле иде ул көннәрдә Равил. Бәхете бер дә өзелмәс, гел шулай дәвам итәр төсле иде. Ләкин материя мәңгелек булса да, бәхет дигән нәрсә мәңгелек түгел икән. Октябрьнең уннарында яңгырлар башланып, юллар пычрангач, Рухия иптәш кызлары Таня белән Вәсимә янында — мәктәп интернатында торып укый башлады. Ә Укмаска атнага бер тапкыр, анда да иптәш кызлары белән бергәләп кенә кайта. Шимбә көнне яңгырлап торса — бөтенләй кайтмый калган чаклары да булгалый.

Ә менә Равилгә алай йөрүне уйларга да ярамый. Яңгыр түгел, таш яуса да, иртән сәгать сигезгә мәктәпкә барып җиткән булырга тиеш ул. Мәктәп директорына дәрес калдырмыйм дип кем сүз бирде? Ә егет сүзе бер булырга тиеш!

Шулай үк таш яуса да, Равил кичкә үзләренең Ташый елгасына кайтып җитеп, атларны төнге көтүгә алып чыгарга тиеш. Алып чыкмый

кара, колхоз председателе Фәйрүзә апа иманыңны укытыр. Дөрес, ул ат көтүен Равил үзе генә түгел, Самат абый белән бергә көтә. Ләкин аңысы да ышанычлы кеше түгел. Я ярты төн үткәннән соң гына килә көтүлеккә, я берәр ышык урынга башын төртеп йоклап китә...

Менә хәзер шул заманнарны күз алдына китергәч, үзе дә аптырап китте: ничек түзелде икән шул тамашага? Салкын җилле, яңгырлы октябрь таңы. Хәер, таң диярлеге дә юк әле аның. Чөнки караңгы әле, сәгать дүртләр чамасы гына. Халыкның иң тәмле йокы вакыты. Мондый яңгырлы иртәләрдә авыл халкы яктырып беткәч тә җылы урыннан кубарга ашыкмый: колхоз эшенә барасы түгел, көтүчеләр көтүне алып чыгып китәргә шулай ук атлыгып тормый. Кыскасы, сәгать җиделәрсез авылга җан керәчәк түгел. Ә хәзер бик иртә әле. Хәтта яктыра да башламаган. Янына ук килеп төртелмәсәң, салам эскертен дә күреп булырлык түгел. Яңгыр шыбырдавыннан һәм кисәк-кисәк аеруча нык котырып исеп куя торган ачы җилдән башка, дөньяда бернинди тавыш, бернинди хәрәкәт юк. Барча җан иясе үлеп беткәндәр төсле...

Менә шул шомлы, шул чирканыч чакта, кулына йөгән тотып, лачлоч пычрак ерып, Равил атлар эзләп йөри. Салам эскертенә яки башка берәр җиргә ышыкланып бер генә минут та торырга ярамый аңа. Кичтән үзе кырга алып чыгып, үзе тышаулап җибәргән кырык сигез баш атны җыеп, иртәнге сәгать алтыга алып кайтып җиткерергә тиеш ул. Шулай булмаса, мәктәпкә соңга калачак. Ул алып кайткан атларны бәлки бүген бөтенләй җикмәсләр дә — бу пычракта эш эшләп буламыни?.. Ләкин аңысы инде икенче мәсьәлә, аңысы аның Равилгә кагылмый.

Ул — төнге көтүче.

Ул иртәнге алтыга атларны алып кайтып җиткерергә тиеш!

Ә атлар, уч иткәндәй, әллә кайларга таралышып беткәннәр. Бу җилгә, бу салкынга ул бичаралар да түзә алмаган, күрәсең. Кичке уңберләрдән сибәли башлаган иде, шуннан бирле яңгыр көчәйгәннәнкөчәя бара.

Ичмаса, берәр атны тотып алып, бүтәннәрен шуңа атланып кына эзлисе иде дә бит, ни хәл итмәк кирәк, тоттырырга һич кенә дә теләмиләр шул. Тышаулы булсалар да, яннарына килә башлау белән кушаяклап сикереп, дөп-дөп чабып китәләр. Чөнки белә алар: әле кайтырга иртәрәк, вакыты җитмәгән әле. Тагын берәр сәгатьтән, яктыру белән, шул атларның теләсә кайсысы янына кил — берсе дә өрекмәячәк. Тышауларын чишкәндә дә рәхәтләнеп торачаклар. Хайван-хайван дибез дә, әмма алар да ахмак түгел шул. Кайчан үзләрен ничегрәк тотарга икәнлеген чамалый алар, бик яхшы чамалый...

Ә Равилнең яктырганчы ук көтеп торырга чамасы юк. Атларны хәзердән үк бер тирәгәрәк җыйнап куярга кирәк аңа.

Яңгырның туктар исәбе сизелми әле. Һаман шул бер килеш коя да коя. Ичмаса, Самат абый да килмәде. Аның белән икәүләп йөрсәләр дә, азрак күңеллерәк булыр иде. Тагын шул кичтән салгандыр да көтүгә чыгар рәте булмагандыр инде. Хәер, мондый ямьсез төннәрдә аек булса да бик ашыгып йөрми ул. Равил атларны мең бәла белән җыйнап, конюшняга алып кайтып килгәндә каршы очрады:

— Теләсәң ни әйт, наным Равил, тотып яңакласаң да бер сүзем юк! Тик бу эшне прсидәтел Фәйрүзәгә генә җиткерә күрмә, ямә?

— Син бит инде моны миңа бер әйткән идең.

— Монысы, билләһи дип әйтәм, соңгысы, наный. Кичтән, әз генә ятып торыйм дип, хатыннан качыбрак кына чоланга кереп, башны төрткән булганыем — эрегәнмен дә киткәнмен бит, тинтәк баш! Менә күрерсең, бүтән чакта үлсәм үләрмен, ну, бер минут та соңга калмам.

Дөресен генә әйткәндә, яңгырлы төннәрдә генә түгел, яңгырсыз әйбәт төннәрдә дә әллә ни эш майтара торган бәндә түгел ул. Кая инде аңа, иллегә житеп килгән чулак кешегә, Равил белән рәттән ат эзләп йөрү. Шуның өстенә көн аралаш диярлек көтүгә бөтенләй чыкмый калуларын да Фәйрүзә апасына әйтсә — берсүзсез эшеннән алып атачаклар аны. Ләкин Равил алай итә алмый шул. Кызгана ул Самат абыйны. Йомарлап алсаң, учка сыярлык кына бер адәм иде ул. Ә инде дүрт ел төрмәдә утырганнан соң бөтенләй корышып, тире белән сөяккә генә калып кайтты. Житмәсә, биш баласы бар үзенең! Һәм аларның берсе дә әле кул арасына керерлек түгел — барысы да бәләкәй һәм кызлар. Әнә шул балалары хакына кызгана аны Равил, шуңа түзә. Ат көтүеннән дә куып чыгарсалар, ул чулак кулы белән бүтән беркайда да эшли алмаячагын белеп кызгана. Шуңа менә шушылай берүзе пычрак ерып йөрергә мәжбүр.

Әнә шундый яңгырлы, жилле, салкын һәм караңгы чакларда ялгызлыктан аптыраган чакларда Равил Рухияне искә төшерә. Рухия Равилгә әйтеп бетергесез көч-куәт, түзем-сабырлык биреп тора. Сукаланган кырлар, сазлыклы болыннар буйлап йөрүдән туктап, нииндидер бер күзгә күренми торган илаһи көч ярдәмендә жилне дә, яңгырны да сизмичә, канатланып йөри башлый. Ә инде берәр атны ничек кирәк алай тотып, бүтәннәрен шуңа атланып эзләргә керешкәч исә, күңеле тагын да күтәрелебрәк китә дә, хисләре эченә генә сыешып тора алмыйча, тышка бәреп чыга — Равил бөтен тирә-якны яңгыратып, кычкырып жырлап жибәрә:

Сөям сине, сө-ям си-не,
Сө-ө-өям сине чә-чә-гем шул!
Соңгы су-лы-шы-ма-а ка-дәр
Гел си-и-и-не сө-ө-өя-чәгем!

## 10

Ә аннары Равил ике күзен дүрт итеп көткән чираттагы шимбә көн килеп житә. Ул көнне алар икесе бергә кайталар. Рухия — хәйләкәр кыз — тәки жаен таба: кайтырга я Таня белән Вәсимәдән алданрак кузгала, яки нинди дә булса «бик мөһим эш»е килеп чыга да, арткарак кала. Рухия соңрак кузгаласы көнне Равил аны әлеге Чүкәй күпере тирәсендәге әрәмәлектә көтеп тора. Башта Таня белән Вәсимә үтеп китәләр. Ә кайтыр юллары нәкъ әрәмәлек буеннан гына уза. Һәм менә шул чакта, теләсә-теләмәсә дә, Равилгә ул ике кызның үзара сөйләшеп барган сүзләрен ишетеп калырга туры килә.

Башка кызлар да шушылар кебек була микән, ләкин Таня белән Вәсимә әрәмәлек турыннан үткәндә гел малайлар турында сөйләшеп үтәләр. Әле менә шушы узган атнада гына кайсы малай кайсы кызга ни дип әйткән; кайсы малай кайсы кызга дәрестә хат язып биргән; кайсы малайның күзе кайсы кызга төшкән — сүз һәр вакыт шул тирәдәрәк бара.

Бу ике кызның үзенә карата нинди мөнәсәбәттә булуларын да белде инде Равил.

— Син шул Ташый елга Равилен ярата алыр идеңме? — диде бер көнне Танясы, нәкъ Равил торган әрәмәлек турыннан үтеп барышлый.

— Юк! — диде Вәсимәсе, кырт кистереп.— Ярата алмас идем мин аны. Йомыкый бит ул.

— Мин аны беренче очраган көннән бирле яратып йөрим инде, беләсең килсә! — диде Танясы.— Ә ул мине бар дип тә белми. Рухиядән башка берәүне дә күрми ул.

— Әйе шул, нәрсәсенә шаккаткандыр инде шул җилбәзәкнең? Аннары...

Тагын нәрсә әйткәндер, анысын Равил ишетә алмады — кызлар шактый ераклашып өлгергәннәр иде. Кызык: ә Равил үзе бу кызларның кайсысын ярата алыр иде икән соң? Юк, Рухиядән башка берсен дә ярата алмас иде ул! Һәркемнең өзелеп сөйгәне бер генә булырга тиеш!..

Әһә, әнә Рухия үзе дә килеп житә! Атлап килүләрен генә күрегез әле сез аның! Юк, җир йөзендә шушы кыздан да сылу гәүдәле, моннан да чибәррәк кызның булганы да юк, булачак та түгел. Рухия әле Равилне күрми. Күрсә, елмаеп куйса — болытлы көннәр кояшлыга әйләнеп киткәндәй була инде. Тукта, сиздерми генә каршына килеп чыгып, куркытып алган булсын әле бер...

Әмма Равил куркытырга өлгермәде. Кыз аны үзе күреп алды да, шып тукталып:

— Кәк-кү, Равил абый! Әйдә, чык! — дип, көмеш тавышы белән көлеп җибәрде. Аннары:— Уф, арыдым! Әйдә, азрак ял итеп алыйк әле,— дип, бөтенләй хәлсезләнгән атлы булып, юл читендәге чирәмгә утырды.

— Нинди ару ди әле ул — юлга чыгып кына киләбез бит, Рухия.

— Андый физик ару түгел, Равил абый. Рухи ару белән арыдым мин бүген. Бигрәк тә соңгы физика сәгатендә, Габдуллыч миннән сорамаса гына ярар иде дип, котым алынып утырдым. Сораса — беткән иде баш!

— Дәресеңне әзерләмичә, кино карап йөрсәң шулай була ул!

Равил моны белеп түгел, просто сүз кушып җибәрү өчен генә әйткән иде. Ләкин кыек атып та туры тидергән булып чыкты. Рухия бер мизгел гаҗәпсенеп Равилгә карап торды. Аннары бармагын селкеп көлеп җибәрде дә әйтте:

— Син әле шулай минем арттан шымчылык та итеп йөрисеңмени?

— Шул гына калганые!

— Ә мин тагы кызыксынасың дип сөенеп киткән идем!

Рухия үпкәләде.

Кайтырга кузгалгач, рюкзагын да Равилгә теләр-теләмәсрәк кенә бирде. Башка вакытта Равилгә авыз ачарга да ара калдырмый — юл буе гел үзе сөйләп-сорашып кайта торган иде ул. Бүген никтер сөйләргә дә ашкынып тормый, хәтта Равил сүз кушканда да кыска гына җавап бирү белән чикләнеп кала. Ә Равил аның гадәттәгечә туктаусыз сөйләшеп баруын, ачык йөзле, шат күңелле булуын тели иде.

— Син ничек уйлыйсың, Рухия? — диде ул, кыз күңелен күтәрердәй сүз таба алмый аптырагач.— Минем кебек юләр, беркатлы тагын берәр кеше бар микән дөньяда?

Ниһаять, Рухия пырхылдап көлеп җибәрде.

— Ә син ничек уйлыйсың?

— Мин үземме?..— «Барын бардыр инде ул анысы. Бар дисәм тагын килешмәс бит бу көйсез фәрештәгә».— Мин үзем менә болай уйлыйм: минем кебек юк юләр кеше бүтән юктыр!

Кыз бу юлы кычкырып ук көлеп куйды.

— Нигә кимсетәсең үзеңне?

— Юньләп сөйләшә белмәгән өчен! Алдын-артын чамаламыйча, нәрсә уйласам — шуны туп-туры әйтеп биргәнем өчен. Менә шуның өчен юләр дип саныйм мин үземне. Бая син, шымчылык итәсеңмени, дип сорагач, «әйе, шымчылык итәм» дип әйткән булсам, яки «ә син ничек теләр идең соң?» дигән булсам, син миңа үпкәләми идең бит!

Ә мин менә үземнең беркатлылыгым аркасында синең хәтереңне калдырдым. Шуңа күңелсезләндең бит син, әйеме?

— Карале, әүлиямы әллә син, Равил абый? — диде кыз, кинәт ачылып китеп.— Ничек белдең син минем уйларымны?

— Эш узгач белүдән ни мәгънә? Алданрак чамаларга кирәк иде миңа моны. Хәзер син миңа барыбер үпкәләдең ич инде!

— Әйе, уйларымны укып әйтеп биргәнче, мин сине, чыннан да, гамьсез һәм хиссез кешегә санаган идем. Ә хәзер аңладым: ялгышканмын икән. Бүтән беркайчан да үпкәләмәм мин сиңа, яме, Равил абый!

Равил, ни эшләвен белештермәстән, кызны күтәреп алды да зыр-зыр әйләндерергә тотынды. Кыз: «Үләм, Равил абый, башым әйләнә, җитәр»,— дигәч кенә тукталды.

— Менә хәзер шушылай сине күтәргән килеш очып кына китимме?

— Кирәкми, Равил абый. Очасың икән — үзең генә оч, ә минем егылып төшеп үләсем килми.

— Ә минем үлгәндә дә синең белән бергә үләсем килә!

— Мин әле озак, бик озак яшәргә тиеш. Дөньяның бөтен рәхәтлекләрен күреп калырга телим мин, Равил абый!

— Мин дә гел михнәт чигеп кенә яшәү ягында түгел анысы. Минем дә үләсем килеп тормый. Ләкин син булганда гына яшәү кызык минем өчен.

Кыз көлүеннән туктады.

— Әй, ул кадәр төче телләнмәсәнә, Равил абый! Тагын үпкәләтәсең, югыйсә.

«Я, әйт инде син мине юләр түгел дип! Хәйран гына җайланып, ипле генә сөйләшә башлаган кызның кәефен тагын кырдым бит. Их, Равил, Равил! Кайчан кеше төсле итеп, һәр сүзеңне уйлап-үлчәп сөйләшергә өйрәнерсең икән соң син? Хәзер аны ничек көлдерергә инде менә?»..

Равилнең каушабрак калуын сизенде, ахрысы, кыз аңа карап хәйләкәр генә елмайды да үзе сүз башлады:

— Әйдә, азрак хыялланып алыйк әле! — диде ул, кинәт әсәрләнеп китеп.— Әйт әле, Равил абый, унынчыны бетергәч кем булырга, нинди югары уку йортын тәмамларга телисең син?

— Минме? — диде Равил һәм тотлыгып калды. Чөнки аның бу турыда бөтенләй уйланганы юк иде. Дөресрәге, андый зур эшләр хакында уйларга ук курка иде. «Хыялланганда да чама беләнрәк кенә хыялланырга кирәк бит инде!» — дип, үзен мәҗбүри рәвештә тыя килә иде ул.

— Я? — диде Рухия түземсезләнеп.— Көтәм мин, Равил абый?

— Минем алда торган иң зур хыялым — ничек тә сигезенчене өзмичә тәмам итү!

Рухия, шаккатканын белдереп, күзләрен зур ачып Равилгә карап алды.

— Бары шул гынамы хыялың?

— Ә бу минем өчен кечкенә мәсьәлә түгел, Рухия. Әни алай-болай авырып китсә яки кышкы бураннарда кайта-килә йөрүләр мөмкин булмый башласа, синең өчен бик бәләкәй тоелган шушы хыялымның да тормышка ашмыйча калуы бик ихтимал әле!

— Юк, син укуыңны ташларга тиеш түгел, Равил абый! Син булмасаң — бетәм ич мин. Ә мин, беләсеңме, сине кем итеп күрергә телим? Мин сине Казан университетының хөрмәтле укытучысы, физика-математика фәннәре кандидаты, доцент итеп күрергә хыялланам. Математиканы су урынына эчәсең бит син...

Карале син аны, дөрес чамалаган бит. Ә ул чакта, «факультет», «кафедра», «доцент» дигән сүзләрне газеталарда очратканы булса да, Равил аларның мәгънәләрен бөтенләй белми иде әле. Университетны да дәреслекләрдә басылган рәсеме буенча гына күз алдына китерә иде. Шуңа ул, артык тирәнгә кереп, сүз озайтып тормыйча гына:

— Математиканы ярату белән генә эш бетми торгандыр шул анда. Белгәнеңне менә синең шикелле итеп, чатнатып русча сөйли белергә дә кирәктер. Ә минем русча белүем ипилек-тозлык кына бит,— диде.

Рухия бу юлы да сүзсез калмады.

— Анысы өчен кайгырма, Равил абый! Иң мөһиме — башың эшләсен дә белемең булсын. Булган белемне аңлату берни түгел аны. Әнә, атаклы химик, профессор Нурый Садыйковның да русчасы әллә ни түгел. Ә студентлар шуның лекцияләренә атлыгып торалар ди.

«Бу шәһәр кызлары барысы да шушылай күп белә микән? Барысы да бәйләнчек була микән?»

Равил, Рухиянең әлеге фикерен хупларга да, кире кагарга да белмичәрәк, беркавым уйланып барды. Дөрес, Нурый Садыйков дигән исем колагына кергәне бар иде барын. Ә менә шул кеше нинди профессор, кайда һәм нинди фәнне укыта — Равил аларыннан һич тә хәбәрдар түгел иде. Ә сораштырып үзенең наданлыгын күрсәтәсе килмәде. Шуңа ул бу юлы да бәхәскә кермичә, уенын-чынын бергә кушып:

— Булды, кызый, ышандырдың. Ә синең хыялларың кай тирәдә соң? — диде.

— Минем хыял зурдан, Равил абый. Ничек кирәк алай унынчыны тәмамлап, шул җенем сөйми торган физикалардан, математикалардан котылсам, университетның филология факультетында укып чыгар идем дә, я, әнием кебек, укытучы яки журналист булыр идем мин!

— Минемчә, тормышка ашмас хыял түгел бу, Рухия.

— Амин, Равил абый, амин!..

Кырык тугызынчы елның октябрь азакларында әнә шундый матур-матур теләкләр теләшкән иде алар. Әйе, Рухия Равилгә теләгән теләкләренең күбесе кабул булды. Рәхмәт аңа! Ләкин үзенең хыялларын тормышка ашыра алды микән ул? Илле икенче елда ук Үзбәкстанга китеп барган бит алар. Анда кайда укый алсын икән? Хәер, нигә укый алмасын әле? Үзбәкстан вузларында укып чыгып, үзбәк галиме булып киткән әллә ничә татар егетен белә бит Равил. Кем белә, бәлки Рухия дә хыялына ирешкәндер, бәлки ул да Ташкент университетын тәмамлап, берәр газетада яки журналда эшлидер. Сүзгә бик тапкыр, телгә бик оста, дөнья хәлләре белән бик нык кызыксынып бара торган тынгысыз кыз иде бит ул. Шулар өстенә тагын кыюлыгы да житеп ашкан иде. Журналист булу өчен тагы ни кирәк инде?.. Яки әнисе шикелле укытучы булып киткәндер.

## 11

Равилнең уйлары күңелендә мәңгегә уелып калган мәктәп елларына янә әйләнеп кайтты.

Классларында Әнәс исемле бер малай бар иде. Тик торганда теләсә кемнең эченә китереп төртә торган гадәте булганга, Тәкә Әнәс дип йөртәләр иде аны. Равилнең үзенә кагылмый кагылуын. Әмма бүтән малайларга, бигрәк тә кечерәкләренә, бер дә көн күрсәтми иде инде. Ә кызлар турында әйткән дә юк: яннарыннан үткәндә ялгыш та орынмыйча яки чеметмичә үтми. Менә шул Әнәс Рухиягә аеруча хөсет-

ләнә: юл өстендә туры килмәсә дә, үзе эзләп табып, аның Равилне һушсыз иткән озын толымнарыннан тартып китә. Шуңа бик ачуы килә Равилнең. Ботарлап ташлардай булып карап тора. Ләкин шул карап торудан ары китә алмый, чөнки Әнәстән шикләнә иде ул. Шуңа шикләнә, Әнәс бишенче классны тәмамлаганчы район үзәгендә яшәгән малай. Ә район һәм шәһәр малайлары сугышка да, телгә дә бик маһир була. Шуның өстенә буйга Равилдән кайтышрак булса да, тәнгә бик таза иде ул Әнәс. Бөтен мускуллары уйнаклап, хәрәкәтләнеп тора. Көч тә бик күп: мәктәп ишегалдында ята торган ике потлы герне унар тапкыр рәттән күтәрә.

Әй кыланып та карый торган иде соң үзе дә! Бүтәннәрне этеп-төртеп кимсетүе генә җитми, русча белүен дә атлаган саен күрсәтергә тырышып, бер сүзен татарча әйтсә, бишне русчалатып кына җибәрә. Русча белүе әйбәт, әлбәттә. Ләкин, беләм дигәч тә, ул тикле үк йөгәнсезләнергә ярамый бит инде.

Рухияне аеруча нык кимсетә торган иде ул.

Шулай бер көнне Тәкә Әнәс оятсыз рәвештә Рухиянең күкрәгенә орынып киткәч, һәм толымыннан тартып, кызны тәмам интектерә башлагач, Равил бу хәлгә чик куярга булды. Хәбир бабайдан ике потлы гер алып кайтып, бик тырышып, күнегүләр ясый башлады. Беренче көнне нибары бер генә тапкыр күтәрә алды ул аны. Анда да шактый озак азапланганнан соң гына күтәрде. Әмма хикмәт көче җитмәүдә булмаган икән. Рәтен генә белмәгән икән аның Равил. Бер җаена төшенгәч, эше яхшы ук алга китте аның. Герне алып кайтканга дүрт көн дигәндә рәттән биш ярым тапкыр күтәрде. Тагын атна-ун көн шулай тырышса, мөгаен, Әнәсне куып та җитәр — унар тапкыр күтәрә башлар иде. Ләкин...

Герне алып кайтканга алтынчы көнне, тәнәфес вакытында Рухия иптәш кызлары белән тыныч кына сөйләшеп торганда, Әнәс сиздермичә генә аның артына барды да, ике куллап нечкә биленнән тотып:

— Һоп-ля! — дип кычкырып куйды.

Бу көтелмәгән вәхшилектән коты алынып, Рухия чырылдап кычкырып җибәрде. Ә Әнәс, авызын ерып, бик зур эш башкарган кешедәй тантаналы елмаеп, акрын гына китеп барды. Менә шунда Равилнең түземе төкәнде инде. Уктай атылып, тегенең каршына килеп басты да, изүеннән эләктереп алып:

— Җиттеме сиңа, тәкә тәре, юкмы? — диде.

Әнәс башта бик азга гына аптырап-югалып калды. Аннары шундук күкрәеп китте дә, кулыннан килсә кабып йотар дәрәҗәдә мыскыллы елмаеп:

— А тебе чего надо, петух галанский? — диде. Шул уңайдан, дыңк иттереп, Равилнең ияк астына китереп тә сылады.

Йодрыгы нык икән каһәрнең — шәп эләктерде. Чак кына авып китмичә калды Равил. Бүтән урында Әнәс шушылай суккан булса, ихтимал, егылып та киткән булыр иде. Әмма монда, бөтен мәктәп укучылары күз алдында, һич тә сер бирергә ярамый иде аңа. Чөнки монда Рухия бар һәм ул барысын да күреп тора иде. Шуңа Равил аягында басып калды һәм үзе дә тегенең ияк астына берне ямап алды. Йөрәге җитеп, Равил аңа каршы кул күтәрер дип уйламаган идеме, әллә җан ачыйгысы белән Равил үзе бик нык тондырдымы, ни булса да булды, кисеп аударган агачтай ауды да китте Әнәс.

Шуннан ары ниләр булганын Равил күрмәде. Әнәскә бер-бер хәл ясамадым микән дип, коты алынып класска кереп китте ул. Икенче тәнәфестә дә класстан чыкмады. Менә-менә директорга — Хәнифә Вәлиулловна янына алып керерләр дә башта тәмам тирләткәнче тир-

гәрләр, аннары, безгә мондый сугыш чукмарлары кирәкми дип, мәктәптән куып чыгарырлар дип, башын иеп, ут йотып утыра иде ул. Менә шул чакта, һич тә көтмәгәндә, кинәт могҗиза булып алды: башта Равилнең уң күзеннән йодрык хәтле ут чәчрәп чыкты һәм колагы чынлап куйды. Аннары бөтен дөнья караңгыланып китте. Ни булганын да аңлый алмыйча, Равил берничә секунд өнсезләнеп торды.

Ул аңына килгәндә, итәгенә ут капкандай өтәләнеп, Энәс класстан йөгереп чыгып бара иде. Равил аның артыннан куып җитәргә ниятләп ыргылган иде дә — барып чыкмады: башы әйләнеп китеп, хәлсезләнеп, урынына сыерылып төште. Хәтәр элэктергэн иде аңа Энәс. Коры кул белән генә сукмаган иде бугай ул. Коры кул белән генә суккан булса, Равилнең колаклары алай ук чынлап тормас иде. Колаклары чыңласа да, теше исән калган булыр иде. Ә аның уң як өске казнасындагы бер теше дә сынган иде ул чакта.

Бер теш сынганга карап кына дөнья харап булмый, анысы чүп тә түгел иде Равил өчен. Хәнифә Вәлиулловна янына алып кермәсәләр генә ярар иде, дип коты алынган иде аның ул минутларда. Энәс кебек калай әтәчләр үзләре башкаларны кыерсытканда гына бик батыр булып кылана бит алар, ә үзләренә кыенга туры килә башласа, хәзер дөньяны сасытып кычкырырга, мескенләнергә тотыналар дип уйлаган иде. Дөрес хәвефләнгән икән. Шул тәнәфестә үк Равилне Хәнифә Вәлиулловна янына чакырттылар.

Энәс, үлем хәлендәге кешедәй куырылып-бетәшеп, директор кабинетында утыра иде инде. Равил килеп кергәч, бөтенләй елар дәрәҗәгә үк җитеп, Хәнифә Вәлиулловнага әләкләргә тотынды. Аның сөйләвенә караганда, үзендә берниндидә гаеп юк, ә Равил аңа тик торганда бөтен укучылар алдында китереп суккан икән. «Теләсә кайсы укучыны чакырып сорасагыз да әйтерләр: мин аңа тырнак белән дә чиртмәдем»,— диде ул.

Энәс бөтен зарын сөйләп бетергәннән соң Хәнифә Вәлиулловна, әй, малай-малай, мин сине шуның өчен дип укырга алдыммыни, шулмыни синең миңа рәхмәтең, дигән сыман үпкәле итеп, Равилгә карады да:

— Моны ничек аңларга инде, Нәҗметдинов? — диде.— Бүтән теләсә кайсы укучы шушы эшне эшләгән булса да, бу тикле гаҗәпләнмәс идем. Ләкин синең, җиткән егетнең, бала-чага шикелле сугышып йөрүең сәер, бик сәер миңа! Я, ничек дип аңларга кушасың бу кыланышларыңның сәбәбен?

Равилнең шаһите юк иде. Чөнки аңа Энәс сукканны бәрәү дә расламаячак — аннан куркалар. Килдеков Рухияне кимсетте, шуңа суктым мин аңа, дип әйтү шулай ук егетлек булмас иде. Шунда аңа, бәхетенә каршы, бая Энәс сугып сындырган теше ярдәмгә килде. Равил аны, истәлек булыр дип, кәгазьгә төреп кесәсенә салып куйган иде. Равил Хәнифә Вәлиулловнага башта шул тешен, аннары авызын ачып ул тешнең сынган урынын күрсәтте:

— Менә, миңа «тырнак белән дә чиртмәгән» шушы Килдеков эше бу, Хәнифә Вәлиулловна!

— Нәрсә син выдумываешь? — диде Энәс, тешне күргәч, елак тавыш белән чәрелди башлап.— Ялган сүли ул, Хәнифә Вәлиулловна, мин аңа даже тырнак белән дә тимәдем.

Шунысы гаҗәп: ул бу сүзләрне әйткәндә аз гына да кызармады.

Равил, хәзер нәрсә булыр икән инде дип, коты алынып утырганда Хәнифә Вәлиулловна иплән кенә:

— Ярый, булды, аңлашылды, Килдеков. Сиңа чыгарга мөмкин. Ләкин кара аны, бүтән вакытта алдашма, ярыймы? — диде.

— Ә кем монда алдашкан әле? — дип, Әнәс яңадан чәрелди башлаган иде дә, Хәнифә Вәлиулловна:

— Бар, бар, Килдеков! — дип, эшне бик коры тотты.

Ул чыгып киткәч, Хәнифә Вәлиулловна Равилгә карап, башын чайкап куйды:

— Ай-яй, Нәҗметдинов! Килешә торган эшме соң инде шушылай итеп ямьсезләнешеп йөрү. Я, әйт әле?

— Бик туйдырган иде бит, Хәнифә Вәлиулловна. Бөтен мәктәп баласын кимсетеп, җәберләп йөри иде бит ул. Кичерегез инде, Хәнифә Вәлиулловна, кызыбрак киткәнмен. Ләкин барыбер шулай бер өйрәтеп алу кирәк иде аны. Шунсыз тыначак түгел иде ул.

— Мин сине аңлыйм, Нәҗметдинов. Ләкин кабатлап әйтәм: ничек кенә булмасын, бөтен мәктәп укучылары күз алдында кул күтәрергә тиеш түгел идең син аңа! Сез бит өлкән класс укучылары, түбән класслар сездән үрнәк ала бит! Син бүген нинди үрнәк күрсәттең инде аларга?..

— Әйбәт үрнәк түгел инде, Хәнифә Вәлиулловна.

Хәнифә Вәлиулловна шул сөйләшүдән соң ул мәсьәләгә бүтән әйләнеп кайтмады. Иң мөһиме шул — үпкә саклап йөрмәде, мөнәсәбәтен үзгәртмәде. Ә Әнәснең исә кикриге шиңде шуннан ары. Равилгә генә түгел, бүтәннәргә дә алай бик кагылмый башлады.

Равил үзе дә унынчыны тәмамлаганчы Хәнифә Вәлиулловнаның кәефен кырмаска, гел тәртипле генә булып йөрергә уйлаган иде. Тик ул уйлаганча барып чыкмады. Тагын бер тапкыр оялып-кызарып Хәнифә Вәлиулловна каршында басып торырга туры килде әле аңа...

*Ахыры бар*

Дифгать Сирай

# АВЫЛ ПОЭМАСЫ

## 1

Авыллар, авыллар...
Шат балкып,
Нур бөркеп утыра һәр авыл.
Әйтерсең аларга бер чак та
Орынып үтмәгән җил-давыл.

Кем уйный гармунда таң белән?
Тәрәзәләр киереп ачылган.
Әйтерсең шул көйдән пәрдәләр
Кабарып урамга тартылган.
Оча көй, күңелне җилкетеп,
Авылның башыннан башына.
Кем уйный гармунда таң белән,
Кемнең соң йөрәге ашкына?
Укучы малай ул.
«Сарман»нан
Күчә ул ярсынып «Уел»га.
Бу тормыш аңарга һәр вакыт
Тоташ җыр шикелле тоела.
Белми ул әлегә юлларның
Кемнәрне кай якка илткәнен.
Белә тик
Бу иске гармунда
Бабасы йөрәге типкәнен.
Үкереп елаган ул гармун
Хушлашу көйләрен сыкканда.
«Дәртлесен оныгым уйнасын, —
Васыятем шул — юлга чыкканда»...
Ә бүген яңадан сайрый ул.
Теләсәң, кош итеп күккә чөй.
Телләре өстеннән йөгереп
Төшә көй, шаян көй, дәртле көй.
Шул көйләр ургылып керер дә
Басар күк йөрәкнең давылын.
...һәр көнне гармунын киереп,
Йокыдан уяна авылым.

## 2

Авыллар, авыллар...
Картада
Нибары кечкенә бер нокта.
Ә афәт килгәндә һәркайсы
Әйләнде утлы бер йодрыкка.

Кем анда чаң суга таң белән?
Әйтерсең кайдадыр ут чыккан.
Куркытмый,
Авылым корычтай
Мең кызып, мең утта чыныккан...
Басылмый тик йөрәк януы,
Ялкыны яңарып киткәли...
Кем анда чаң суга таң белән
Бәгырьне теткәли-теткәли?
Чал чәчле карт икән.
Халыкны
Чакыра ул клуб каршына.
Туганнар кабере, йөзләгән
Исемнәр язылган ташына.
Йөзләгән каһарман! —
Һәркайсын
Сагынган ана бар, бала бар.
Чаң чыңы!
Әйтерсең ул чаңны
Йөрәкнең түрендә кагалар.
Каксын карт,
Бастылар уллары
Күрәшнең иң хәтәр давылын.
...Һәр көнне таң белән чаң сугып,
Йокыдан уяна авылым.

## 3

Авыллар, авыллар...
Охшашлар
Күп күбен, әмма һич юк игез.
Зурмы ул, уч төбе хәтлеме,—
Бәхете, шатлыгы бертигез.

Кем быргы кычкырта таң белән? —
Колакны кытыклый авазы:
Шуңарга ияреп килә күк
Көннәрнең яктысы, аязы.
Капкалар тар кебек,
Кәҗәләр
Коймалар аркылы элдертә.
Кем быргы кычкырта таң белән,
Шатлыгын белдертә-белдертә?
Көтүче агай ул.
Командир
Шикелле менгән дә атына.
Быргысын уйнатып, малларны
Дәшә ул карурман артына.

Карурман артында болын бар,
Үләне кумәрлек тезеңне.
Кер дә чум, дулкыннар шикелле,
Кочаклап тирбәтер үзеңне.
Янында инеше.
Кармак сал
Чабаклар сикергән урынга...
Төш җитү белән үк малларын
Китереп туктатыр «борынга».
Бәрәңге кумәр ул көлөнә,
Тергезеп җибәргәч учагын.
Орденнар тасмасын күрсәтер,
Булды дип минем дә ут чагым.
Авылда һәр кеше сугышчы,
Игенче, терлекче тумыштан.
Быргысын кычкыртып кайчандыр
Болынга кайтты ул сугыштан.
Ә быргы авазы кайчан да
Юлдашы булмады авылның.
...һәр көнне быргысын кычкыртып,
Йокыдан уяна авылым.

4

Авыллар, авыллар...
Кайсының
Бары тик көлләрен күмделәр.
Һәйкәлләр куясы бар әле:
Солдат күк сугышып үлделәр.

Кем кага таң белән кыңгырау?
Ишетелә чылтырап ерактан.
Җил чаба, итәген күтәреп,
Әйтерсең аңарга ут капкан.
Шомыртлар, кемнедер көткәндәй,
Башларын сузганнар урамга.
Кем кага таң белән кыңгырау?
Моны соң нәрсәгә юрарга?
Кыз төшә авылга.
Кыңгырау
Ерактан ук сала хәбәрен.
Сирень дә сөенеп түшенә
Кадаган чәчәкнең зәңгәрен.
Малайлар йөгерә, ялтырап
Кала тик әй табан аслары.
Акбайлар, Сарбайлар чабалар
Тоймыйча кай төшкә басканын.
Кушылган шикелле кошларның
Җыры да ул шаулы тавышка.
Кыз төшә авылга, әйтерсең
Берьюлы мең шатлык кавыша.
Әбиләр тын гына озатып
Калалар бизәлгән атларны.
Барысы да безнеңчә! — дигәндәй,
Кул изи авылның картлары.
Кыңгырау чылтырый.

Кыз төшә,
Оланнар ишәер тагын да.
...Бу юлдан без күпме ирләрне
Озаттык җәйнең бер таңында.
Кыңгырау тагылган атларда
Киттеләр,
Моң калды күңелдә.
Кыңгырау тагылган атларда
Кайтырлар шикелле бүген дә...
Кыз төшә,
«Юлыңа — ак бәхет» —
Дигәндәй, каеннар иелгән.
Назлы җил биетә гөлләрне,
Кочаклап алган да биленнән.
Чылтырый кыңгырау,
Әйтерсең
Яшьләрдән көнләшә-көнләшә,
Теле бер булса да,
Бүген ул
Йөзләгән телләрдә сөйләшә.
Мариның такмагы аңардан,
Башкортның моңнары коела.
Тел төрле булса да, уй-хисләр
Сүтелмәс йомгак күк тоела;
Бер илнең баласы барысы да, —
Удмурт та, чуваш та, татар да...
Кыз төшә,
Йоласын китереп,
Кыңгырау чылтырый атларда.
Әйтерсең мәңгегә тынмаска
Кузгаткан ул шатлык давылын.
...Һәр көнне кыңгырау чыңлатып,
Йокыдан уяна авылым.

5

Авыллар, авыллар
Әйтерсең
Һәркайсы үзе бер башкала.
Барасы юллары аларның
Игеннәр кырыннан башлана.

Кем җырлый өздереп таң белән?
Тирә-як бәхеткә туенган.
Чыга күк бүгенге һәрбер җыр
Ургылып җирнең үз куеныннан.
Йөрәкне җилкеткән аһәңен
Тоймаса тоймас тик таш кына...
Кем җырлый өздереп таң белән,
Кайгы-зар төшкәнме башына?
Җыр суза яшь егет.
Әйтерсең
Җыр урып йөри ул кашлакта.
Бөртекләр урнына җыр тулып
Өлгергән шикелле башакта.
Игеннәр сусаса, авылның
Йөрәге кысыла шикелле,

Амбарда сакланган ашлыкның
Соңгысы сосыла шикелле...
Басулар яныннан узганда
Җиңел дә, рәхәт тә сулавы,
Колакта чыңлый күк әле дә
«Мәм-мә» дип балалар елавы.
Әле дә хәтердә:
Язларда
Көз калган башакны җыйган чак.
Черегән бәрәңге җирендә
Саз ерып калды ул бала чак...
Таянып авылның иңенә,
Басты ил яңадан аякка.
Теш чыккан көннән үк авылга
Бурычлы булсак та кай якта.
Шул бурыч әйтерсең җыр булып
Ишетелә бүген дә һәр яктан.
Бәхетне басулар өстенә
Язабыз без алтын башактан.
Стена шикелле калкынып
Бүләр ул юлларын давылның.
...һәр көнне күңелле җыр сузып,
Йокыдан уяна авылым.

### 6

Авыллар, авыллар...
Берсе дә
Сайламый тормышның җайлысын.
Әзер ул үзенең иңенә
Алырга бөтен ил кайгысын.

Кем шакый тәрәзне таң белән?
Үтәме җил хәтер яңартып?
Нык безнең хәтер дә,
Йөри ул
һаман да чәчләрне агартып.
Онытылыр бары тик йөрәкләр
Сукканда иң соңгы сәгатен,
Кем шакый тәрәзне таң белән,
Җибәреп йокының ләззәтен?
Почтальон кыз икән.
Йөри ул
Әйтерсең таң нурын өләшеп.
Бу фани дөньяда кешеләр
Туймаслар, ахрысы, серләшеп.
Туганнар язалар, танышлар,
Ерактан язалар, якыннан.
Хат килә хәтта күз күрмәгән
Диңгезләр, океаннар артыннан.
Хат килә күп еллар үткәч тә,
Өзгәч тә бөтенләй өметне.
Күпме хат
Үлгән дип саналган
Меңнәрчә кешене терелтте!
Килә хат,
Сер итеп эчендә
Китерә хәбәрнең төрлесен.

Берәве яралый йөрәкне,
Берәве тазарта чирлесен,
Харьковтан язалар, Мәскәүдән,
Мишалар язалар, Павеллар...
Утларның авызыннан аларны
Каерып алдылар авыллар.
Җәяүләп,
Атларга төялеп
Килделәр кышның бер кичендә.
Украин, белорус, эстонга
Аш пеште татарның мичендә.
Татарның кунакчыл зур өе
Барысын да үзенә сыйдырды.
Бергәләп урдылар игенне,
Бергәләп саудылар сыерны.
Меңләгән йөрәкләр берьюлы
Типтеләр гүя һәр кешедә.
Бер максат күтәрде авылны
Мең төрле батырлык эшенә.
Үземә җил өрә димәде, —
«Тик фашист явы тиз кырылсын!»
Фронтка озатты авылым
Киемнең яңасын, җылысын.
Үзем ач димәде авылым, —
«Тик фашист башы тиз ватылсын!» —
Фронтка озатты авылым
Ризыкның тәмлесен, татлысын...
Хат килә элекке солдаттан:
«Хәтердә гел Мәскәү яклары.
Син бәйләп җибәргән оекбаш
Аякны өшүдән саклады».
Хат килә хәзерге солдаттан:
«Торма син борчылып, аһ орып.
Кайтырга чыгамын, әнкәем,
Постымны энемә тапшырып»...
Хат килә авылга,
Аларда
Шатлык та мең төрле, сагыш та.
Авылны әйләнеп үтми һич
Дөньяда бер генә язмыш та.
Кичерде башыннан тормышның
Ничәмә-ничә ул давылын.
...Шакып гел күңелләр тәрәзен,
Йокыдан уяна авылым.

1972

# Гариф Ахунов

# АРДУАН БАТЫР

ПОВЕСТЬ



Ун көн тула дигәндә беренче машинаны «гараждан» чыгардылар. Гараж димәсәң хәтере калыр — стругламаган тактадан җил-яңгыр тимәсенгә каккалап куйган лапас кисәге.

Чыгардылар машинаны, шофер янына ике «помошник» — Фәхриев белән Карташев чүмәште. Буранов үзе кәкре тимере белән моторны кабызды, тәбәлдерегенә басты, киттеләр, мин сиңа әйтим, әче төтен бөркеп. Менә шунда Зөлхәбирә күрсә икән... И теләп тә карады соң Сайрар кош Зөлхәбирәнең янында булуын.

«Помошниклар» машинаның йөрүенә ышандылар. Буранов ярдәмчеләрен машина йөртергә өйрәтә башлады, көне буе такта лапас-«гараж» янында йөрделәр: алга алып киттеләр, чигенделәр, борып, әйләндереп карадылар.

Беренче рейска чыгар көнне көтә башладылар. Кемгә эләгер, кем бәхете? Буранов төптән уйлап, һәммә нәрсәне бизмәнгә салып үлчи торган кеше булып чыкты. Иң беренче кем өйрәнеп җитте — Фәхриев. Көн саен кимендә ике сәгать артык кем эшләде — Фәхриев. Нәфүшнең күңел очар коштай талпына. Тәбәлдерегенә басты, ачкычын борды — ләм-мим бер сүз дәшми Роман Яковлевич; кәкре тимер белән моторны кабызды. Китте, мин сиңа әйтим, кузгалып!

Усолье станцасыннан бер йөк кирпеч төяп, механика цехы төзелешенә китерделәр. Нәфүшнең йөрәге, читлектән чыгарга теләгән коштай, ярсып тибә. Монда бит — Ардуановлар. Мирсәет абзый бригадасы котлованны бетонлый. Бригада бөтенләе белән — бер йөздән артык кеше — Фәхриев янына атылып чыкты. Егетне күтәреп алдылар да һавага чөеп җибәрделәр: кепкалары очты, кесәдән вак акчалары, ачкычлары чәчелде — чөяләр, төшермиләр.

— Ай да маладчина! Менә, ичмасам, Нәфүш! — дип, Мирсәет абзый, мактауга шактый ук саран кеше, аны күккә күтәрде.— Беренче рейска кирпеч китерден, икенчесенә цемент китер инде, яме, балакай, ату исә бригада бер сәгатьтән эшсез калачак. Тьфү, тьфү, әстәгафирулла, әйттем исә кайттым, эшсез утыру ударный бригадага килешмәс.

---

Ахыры. Башы 1 санда.

Каяндыр Борис Зуев килеп чыкты:

— Шаулама, Мирсәет Ардуанович, эшләр тәгәри, болай булгач — техника килде. Күрәсеңме, бер килүдә унбиш ат олавын алып килгән бит...

Төзелеш участогына машина юлы юк иде, калын сайгаклардан юл җәйделәр, кирпечтер, цементтыр, комдыр бушату өчен шундый ук сайгаклардан ындыр табагы чаклы мәйдан әзерләделәр, Нәфүш-Сайрар кош, машинасын үкертеп, төзелешкә материал ташый башлады.

Ул үзенең шундый зур, катлаулы эшне белүе белән горурлана, түбәсе күккә тиеп йөри, тик аның рульдә утыруын Зөлхәбирәнең генә күрмәве бу горур сөенечне киметә төшә. Кадерматова комсомол путевкасы белән Мәскәүгә алты айлык курсларга китеп барган иде.

Тагын ике атнадан Иван Карташев машинасы «гараждан» чыкты. Төзелеш житәкчеләре Роман Яковлевич Бурановны, автомашина белгече буларак, укытучы итеп билгеләделәр дә, озакламый яңа машиналар кайтачагын әйтеп, унике кешедән шоферлар курсы ачып җибәрделәр.

Төзелешкә машина килү шоферлар әзерләүдән тыш та күп кенә өстәмә мәшәкать тудырды — кирпечне, цементны, чуерташны пароходлар яки «товарняклар» китерә, машинага исәп тотып салынган юллар юк, сазламык та ком; юл төзелешенә аерым бригада төзеп, чокырчакырлы йомшак урыннарга шлак салдылар, бүрәнә түшәделәр, тоз әчесе сеңгән таштай каты балчык тутырдылар. Кайвакыт бөтенләй көтелмәгән җирдән юл җимерелә яки Зырянка елгасы аша салынган агач күпер сайгагы-сайгагы белән сынып китә иде; андый чакта бригада килгәнне көтеп торып булмый, Фәхриев белән Карташев, аларга йөкче итеп бирелгән сигез кеше, юлын да рәтләп, күперен дә төзәтеп куялар...

Менә машиналар, үкереп, ачы төтен бөркеп, Иске Чуртан, Веретья авылларыннан уза: тәрәзәләр ачыла, машина тавышына сала мужиклары төркем-төркем булып урам чатларына җыела; алар, башларыннан картузларын салып, шоферларны сәламләп калалар, су алырга туктаган чакларда машинаны сырып алып, бу әкәмәтнең атсыз ничек йөрүен сорашалар.

Нәфүш-Сайрар кош, кулларын буташтырып, бар белгән урысчасын хутка җибәрә: янәсе, менә моннан су саласың, менә моннан керәчин саласың, керәчин белән су буталып сугыша башлый да ут чыга, уттан төтен чыгып, ул киңәя, кәкре тимер белән төтенен болгатып, машинаны җилкә белән этеп тә җибәрсәң, чаптырып китә дә бара.

Мужиклар баш чайкый, сакал баскан битләренә елмаю чыга:

— Шустрый татарин, шустрый! — диләр.

Эш үз җаенда бара, Нәфүш белән Иван яңа һөнәрләренә бик һәйбәт өйрәнеп житкәннәр иде инде. Сентябрь башларында иртән эшкә килгәч, Фәхриев машинасының кузов такталары ватылган, алгы тәгәрмәченең берсе — резин көпчәк, балта белән урталай чабып чыгарылганын күрде.

Шундук башлыкларга хәбәр иттеләр. Веретьядән милиция килде, тикшерделәр, яздылар, андый хәл булганны берәүгә дә әйтмәскә куштылар. Җинаятьчене табарга кирәк иде.

Безне капчыкта яшереп тотып буламыни!

Төзелештә бит хәзер бер генә машина калды, өстәвенә, яңа кузов ясарга килгән балта осталары йөк машинасының юри, дошман кулы белән ваттырылган булуын, тагын да арттырып, үзләреннән дә өстәп, халыкка җиткерделәр. Китте вәсвәсә, китте имеш-мимеш.

Ярты ел чамасы туктап, тынып торган башбаштаклык, кыйнаш-тукмашу өянәге, элеккесеннән дә битәррәк булып тагын кабынды. Громов

бригадасыннан, Вотиновтан берничә егетне караңгыда кыйнап, имгәтеп ташладылар.

Имеш, юкка төзиләр комбинатны, ул барыбер озак тормаячак, җир астыннан өч йөз ел буена күпме тоз чыгарылган, һәммәкәй җир куыш, төзеп кенә бетерсеннәр менә, заводлары, электр станцалары — барысы бергә җир астына убылачак.

Гайбәтнең аягы озын, имеш-мимеш көннән-көн күперде, искесенә яңалары өстәлде. Юк, имеш, комбинат төзеп бетергәнне дә көтмәс, җир астында тозы алынган шахта куышлары гына түгел, нефть тә бар икән, Чусовойда бәреп чыккан нефть, шахта куышларына тула-тула, җирне ашап, Березнәккә таба килә, ди.

Шөбһәне эшче халык түгел, меңләгән кеше арасында яшеренеп йөргән акгвардиячеләр, авылларда, йорт-җире тартып алынудан куркып качып киткән кулаклар тарата — моны төзелеш җитәкчеләре яхшы аңлыйлар, дошманнарны ГПУ белән милиция өзлексез тикшерә, эзләп тора иде.

Төзелеш начальнигы Крутанов, партком секретаре Хангильдян, постройком председателе Мицкалевич өчесе бергә утырып киңәштабыш иттеләр дә бригадирларны, прорабларны, ликбезда эшләүче укытучыларны ашыгыч киңәшмәгә җыйдылар.

Хангильдян сөйләде.

Карчыга борынлы, зур күзле, кайнар табигатьле бу кеше, тыңлаучылар өстенә утлы кисәү ыргыткандай, кулы белән һаваны ярып җибәрде:

— Дошман баш күтәрә. Ни өчен? Чөнки авылда аның койрыгына басалар. Дошман кырларга азот килүне теләми. Ул аның өчен файдалы түгел. Сак булыйк, иптәшләр. Мирсәет Ардуанович, синең бригадада ничә комсомолец? Нишләп әкрен кыймылдыйбыз? Алдынгы яшьләрне комсомолга тартырга вакыт. Вотинов, Громов, сездә ни хәл? Үзегез коммунист булу гына җитми, бүтәннәргә йогынты ясарга вакыт. Машина ватучыларны да, сугыш оештыручыларны да табарбыз, Свердловскидан милиция отряды чакырттык. Ләкин берсен тапсак, икенчесе калыр. Сизгерлекне, уяулыкны барлык фронт буйлап көчәйтергә кирәк. Сүзне күп сөйләү — вакыт уздырудан бүтәнгә китермәс. Никифор Степанович! (Крутановка борылды.) Бригада саен ударный йодрык оештырырга, тәртип саклауны, сизгерлекне аларга йөкләргә кирәк булыр. (Крутанов риза икәнен белдереп баш какты.) Игорь Николаевич! (Мицкалевичка таба борылды.) Бараклардагы тәртипкә сез җаваплы. Ликбезны тикшереп бару да сезнең өстә. Социалистик ярыш оештыруны, ударниклык хәрәкәтен мин үз өстемә алам.

Беркетмә язуны постройком секретаре Сагайкинга йөкләгәннәр иде. Хангильдянның сөйләгәннәрен ул берсен дә калдырмый яза барды. Баш күтәрми язды. Язды һәм барысын үз уе аркылы үткәрде.

«Ударный йодрык. Бараклар өчен җаваплылык. Ярыш оештыру. Оештырыгыз, оештыр. Ә без конкретрак эшләрбез. Икенче машинаны сафтан чыгарырга вакыт. Моны таза хәлле мужик эшли ала. Төзелешкә ул ике ат алып килгән. Машина аңа файдалы түгел. Аңа, үз аты белән таш ташып, кесәсен калынайту файдалы. Коткы таратырга, машинаны аңардан ваттырырга кирәк».

Хангильдян сүзеннән соң ул бригадирлар сүзен яза башлады. Ардуанов сөйләгәндә кулының калтырый башлавын тойды: «О татарва, син миңа теге заманда эләксәң, гауптвахтадан, камчыдан башыңны чыгармас идем мин синең...»

Каләме икенче нәрсә язды:

«Бетончы-арматурчылар бригадиры Ардуанов. Ярыш турында сөйләде. Вотинов, Сираев бригадаларын ярышка чакыра».

Вотинов белән Громовка килеп җиткәч, ишек артында, коридорда

шаулашкан тавышлар ишетелде, ул да түгел, соры шинельле милиционер ишекне ачып җибәрде дә, кулын чигәсенә күтәреп, честь бирде:

— Иптәш Крутанов, рөхсәт итегез...

— Нәрсә бар? — диде Никифор Степанович, киңәшмә бүленгәнгә кәефе китеп.

— Контра тоттык. Рөхсәт итегез алып керергә.

— Кéрегез.

Ишектән җирән сакаллы, чикмәнле берәүне төртеп керттеләр. Аңа ияреп, Карташев, Фәхриев керде. Фәхриевнең кулында балта, Карташевта лом иде.

Милиционер ишек төбендә калды. Җирән сакалны өстәл буена ук китерделәр.

— Машина ватарга килгән,— диде Карташев.— Без менә икәү...

— Кулын чишегез,— диде Крутанов.

Чиштеләр.

— Сөйләгез.

— Балта тотып килгән, корткыч! Теге машинаны да, мөгаен, ул ваткандыр. Тоткач, ваз кичә, ялганлый, утын әзерләргә чыктым, ди.

— Дөресме? — диде Крутанов, тавышын күтәрми генә. Җирән сакал тотлыга биреп:

— Иптәш начальник, зерә рәнҗетәләр. Истинный крест менә...— мужик ашыгып кына чукынып алды.— Төн суык, учак якмакчы идем. Арба астында йоклыйбыз бит...

— Кайсы участоктан? Фамилиягез?

— Бишенчедән. Мясоедов.

— Ничек сез, Мясоедов, бишенче участоктан гараж янына тикле килеп җиттегез? Олаучыларның бит төн куну урыны Кама буенда.

— Арбаның тәртәсе сынды, гражданин начальник. Механическийга кирпеч китердем. Тәртә сынды и шабаш. Балта күтәреп тәртәлек эзләргә чыктым.

Җирән сакал, гаебе юкка рәнҗетелгән эт кебек, Крутановка тилмереп карады. Никифор Степанович икеләнә калды.

Сагайкин эшләрнең юньлелеккә илтмәячәген аңлап алды. Сорау алу озаккарак тартылса, Мясоедовның кирәкмәгәнне әйтеп, эшне бозып ташлавы бар иде. Олаучылар арасында коткы таратучы Шалага группасы бит. Әгәр бу шуны әйтеп ычкындырса? Юк, моңа юл куярга ярамый.

Сагайкин мәче житезлеге белән Мясоедов янына сикереп төште, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде:

— Җинаятеңне яшереп калмакчы буласыңмы? Ә?! Машиналарны ремонтлау файдасыз, моңарчы торганнар, моннан соң да торырлар дип коткы салып йөрисеңме? Олаучыларны кем котыртты? Имеш, бездә Мәскәү түгел, шоссе юк, машина йөри алмый. Синең фәрештә булып кылануыңа ышанырлар дип беләсеңме, сволочь?!

Өстәл янындагылар аңнарына килеп өлгергәнче, Сагайкин мужикны якасыннан әләктереп алды да унлы-суллы яңаклый башлады.

— Контра! Кулак калдыгы! Җитмәсә әле, аклана, боргалана! Күрсәтербез без сиңа социализмга аяк чалуны!

Сагайкинны көч-хәл белән аерып алдылар. Аның күзләре тонган, йөзе ярсудан көл кебек агарган иде.

## 14

Кама буенда, химкомбинат корпуслары белән бер үк вакытта, су кудыргыч станца бинасы да житешеп килә иде. Башка төзелешләрдә әле эшлисе эш күп булгангамы, газета хәбәрчеләре иң элек әнә шул станцага ташландылар.

Станцаны Николай Вотинов слесарьлары монтажлый иде. Төзелеш җитәкчеләре аңа ышаналар. Нәсел-нәсәптән үк килгән эшче улы ул. Аның әтисе Строгановларның тоз заводларында кырык җиде ел бил бөккән, ләкин семьясына бер тиен дә акча калдыра алмый үлеп киткән. Гаиләдәге кытлык аркасында Николайны унике яшеннән заводка өйрәнчек слесарь итеп биргәннәр. Аз сүзле, кулына тоткан тимер чүкечтәй нык холыклы Вотинов үзе җитәкләгән егерме алты кешелек слесарьлар бригадасы белән тәүлегенә унар сәгать цехтан чыкмый эшли ала, торакның яхшысын, киемнең затлысын бирегез дип дәгъваламый, ул кесәсендә билет йөрткәнгә түгел, күңелендә Совет властена нык ышаныч йөрткәнгә коммунист иде.

Вотинов бригадасының эшен карап киткәннән соң газета хәбәрчеләре «Социализм юлы»нда мәкалә язып чыктылар.

*«Кама химия гиганты көнләп түгел, сәгатьләп күтәрелә. Коммунист Николай Вотинов слесарьлары су кудыру станцасын монтажладылар. Станцаның никадәр зур һәм никадәр мөһим икәнен түбәндәге саннардан да күреп була: станца Мәскәүнең барлык водопроводыннан ике мәртәбә көчлерәк. Станцага унтугыз насос куелды. Алар тәүлегенә 83 миллион чиләк су кудырырга тиешләр. Әгәр шушы станца булмаса, Березники химкомбинаты үз карамагында көне-төне су ташучы 225 мең ат тотарга тиеш булыр иде».*

Март урталарында, җәяүле буран себергән кап-караңгы бер төнне, шартлау тавышы тирә-якны тетрәтте. Теткәләнгән бетон кисәкләре белән бергә, гигант фонтан булып, һавага су баганасы күтәрелде.

Тревога унбиш мең кешелек коллективны аякка бастырды. Җитәкчеләр, тау надзоры инспекторлары сәгате-минуты белән авария булган урынга килеп җиттеләр. Күрделәр: Кама басымыннан станцаны саклау өчен махсус корылган броня — бетон стена — җимерелеп төшкән, тиз арада аварияне бетермәсәң, су станца залларына үтеп кереп, чит илләрдән алтынга сатып алынган ун миллион сумлык насос һәм башка җиһазларны эштән чыгарачак иде.

Хәлне туры чыбык буенча Мәскәүгә хәбәр иттеләр дә иң алдынгы бригадаларны авария урынына китерделәр.

Тайгадан буран көчәеп килә, әйләнә-тирәдә сирәк кенә фонарьлар булып, алар кара урман эчендәге бүре утлары сыман күренәләр иде.

Вак таш белән цемент ташу эшенә ике йөздән артык олау һәм Карташев белән Фәхриев машинасын куйдылар. Кама буенда учаклар кабынды, автогенның зәңгәр тасмасы, төн карасын аралап, олаучыларга юл яктыртып торды.

Ләкин эшнең авыр башы Ардуанов бетончылары белән Вотинов слесарьлары җилкәсенә төште. Вотинов бригадасы су эчендә калган насосларны коткарырга, аннары тиздән салкын суда торып, аларны монтажларга, Ардуанов бригадасы бетон перемычканың җимерелгән урынын ялгарга тиеш иде.

Төзелеш җитәкчеләре Ардуанов белән Вотинов егетләренең искиткеч чыдамлыгын белсәләр дә, март аеның бозлы суына эшчеләрне кертергә шикләнәләр, моның азагы һәлакәт белән бетсә, алар җаннарына вөҗдан газабы алып кына калмаячаклар, Березники химкомбинатының язмышын да кыл өстенә куячаклар иде.

Ике бригадир да, эшчеләр белән сөйләшкәч, салкын суга керергә ризалыкларын белдерделәр. Ләкин эшнең һәр ягын уйлап, акыллы итеп оештырырга кирәк иде. Ардуанов бригадасы нәкъ менә шунда үзләрен төзелешкә килергә димләгән Нәриман Нурисламов белән тагын бер мәртәбә очрашты. Башына басып кигән җылы бүректән, таза күн итектән, олаучылар киеп йөри торган брезент кәҗәннән килде Нурисламов; Ардуанов егетләре белән — йөздән артык кеше белән — кул биреп күрешеп чыкты. Үзе чакырып китергән бригаданың язмышы

өчен җаваплылык тойгысы аны тәгәл хәрәкәтле, аз сүзле итә иде. Нурисламов, Ардуанов белән киңәшеп, бетончыларны өч отрядка бүлде. Сугыш командиры әмер биргән кебек, отрядларга задание биреп чыкты. Ике отряд әзер бетонны ташый; бер отряд, җилкәләреннән куллары белән тоташып, үлем эшафотына баскан коммунистлар кебек, корыч стена булып баса; салкын суга төшерелгән бетончыга көч-куәт биреп, аның рухи ныклыгын саклап тора; биш минуттан аны тартып алып, кием алыштыру, спирт белән тәнен уу өчен махсус әзерләнгән җылы бүлмәгә озата һәм чираттагы бетончыны суга төшереп җибәрә.

Болай эшләгәндә, җаваплылыкны да, авырлыкны да барысы бергә күтәрәләр, хәрби хезмәттә генә була торган корыч тәртип, бердәмлек-иптәшлек хисе кешеләрне бер максатка туплый.

Нурисламов боларны Гражданнар сугышы чорында хәрби кораб-ларны коткару тәҗрибәсеннән чыгып эшләде. Крутанов та, Хангильдян белән Мицкалевич та хәзер аңа — бары тик аның әмеренә буйсын-дылар.

Март аеның бозлы салкын суына беренче булып Мирсәет Ардуанов барып керде...

## 15

...Авария вакытында Ксенофонт Иванович Сагайкин да йокы күр-мәде. Дөресен әйткәндә, ул төзелешнең башка җитәкчеләренә караган-да да күбрәк тырышты: бетон болгатучылар, атлы олаулар һәм машина йөртүчеләр — барысы аның карамагында булды. Ул, Нурисламов әме-ре буенча, ашханәдән кайнар аш, кайнар чәй китерүне оештырды, урамга учаклар яктырды, чыланмаган яңа кием әзерләттерде һәм бу хәл салкын су белән көрәшне шактый җиңеләйтте. Төзелешнең олырак җитәкчеләре аның эшеннән канәгать булып калдылар. Үзара фикер алышканда гаҗәпләнүләрен дә белдерми булдыра алмадылар: кат-лаулы да соң кеше дигәнең, янәсе! Сагайкин җыелышта нинди буш сүз сөйләде, ә менә авырлык килгәч, кара син аны, тешен кысып эшли.

Әйе, теш кысу дигәне — дөрес.

Төнлә һавага ут-төтен, су баганалары күтәрелгәнне тәрәзәдән күр-гәч, шушы минутларны көтеп яткан Ксенофонт Ивановичның җаны канат какты.

«Тайгада социализмның көле күккә оча. Шулай була ул менә — алдан кычкырган күкенең башы ярыла. Начальство паникада калачак, аварияне хәзер җәйсез бетерү мөмкин түгел, кемнең кураләтә боздай салкын суга керәсе килсен. Менә шунда инде чит ил фирмаларыннан казна акчасына, саф алтынга сатып алынган насослар сафтан чыга. Җәйгә чаклы су эчендә утырсалар, алар чыгарып ташлаудан бүтәнгә ярамый. Ә бит ул эшче халыкның маңгай тире. Менә шунда башлана инде низаг. Станца берүзе ун миллион тора. Аны кабат салу төзүче-ләрнең эш хакын кисү исәбенә генә була ала. Болай да дәгъвачыл сезонникны Совет властена каршы аякландыру түгелмени бу?! Менә шулай, Крутанов, Хангильдян һәм башка иптәшләр, мин сезгә эш эшләп куйдым, сезнең тайгадагы социализмыгыз барлык җөйләреннән сүтелеп китте...»

Социализмның «җөйләре сүтелмәгәнне» күрү Сагайкинның тешлә-рен шыкырдата. Аның күз алдында тимер юлдан көн саен, ярсып аккан тау елгасы кебек, Березникига һәм Соликамскига йөкләр таш-кыны килеп тора. Йөге нинди, гади генә йөкме? Ул такта ящиклар өстенә кара буяу белән язылган бөтен дөнья промышленникларының фирма исемнәрен укый: Бабкон-Вилькокс. Ганномаг, Сименс-Шуккерт, Борзит, Рейн Кабель-Павер Газ... тагын әллә кемнәр, әллә кемнәр...

Ксенофонт Ивановичның үз сыйныфына — капиталистларга ачуы кабара. Ул аларның комсызлыгын, алтын дигәндә газиз аталарын да сатып җибәрергә әзер торуларын күралмый. Насос сатмый торсалар ни була? Ачлыктан, хәерчелектән, тифтан интеккән Россия куәтле насосларны каян алсын? Ничек җитештерсен? «Сәүдә кешеләре» Строгановлар Урал тайгасында өч йөз ел хакимлек иткәннәр, иге-чиге булмаган хәерче илне хәтта тозга да туйдыра алмаганнар. Яши бирсен иде әнә шул тоз заводлары...

Березники комбинаты базасының көннән-көн ныгый, куәт җыя барганын хәвефле бер курку белән күзәтә Ксенофонт Иванович. Тайгада ак балчык тапканнар — аңардан алюмин алып була. Магний табылган, фәнгә яраклы. Болар бит дөнья күләмендәге запасы булган калий ятмаларыннан тыш. Болар бит Чусовойдагы нефтьтән тыш. Каян килә бу халыкка энтузиазм? Ниндидер бер Казан татары, грамотасыз бер крестьян улы, өч-дүрт ай эчендә бетончылар бригадасы төзи, фанатикларча бирелгәнлек белән, көненә унар сәгать бетон таптый; ул гынамы — өч көн буе салкын суда торып, аварияне бетерә. Бу хәл аның һич кенә дә башына сыймый. Аның тайга төпкелендә Ардуановны очратасы килә. Үз кул астында эшләүче бандит Шалаганың аны сугып егуын, битенә менеп, борыны изелгәнче сикерә-сикерә таптавын күрәсе килә.

Булачак комбинатның механический цехына пар казаны китерделәр. Сагайкин еш кына әнә шул казанны карарга бара, ул анда инженерлар күрә — сакаллысын, сакалсызын; күзләр әлҗе-мөлҗе килердәй сары чалбарлы американны, Зырянканың чикмәнле мужигын күрә, рус һәм украинны, татар һәм башкортны күрә, монтерлар, слесарьлар, җир казучылар, бетончыларны күрә; аның әкәмәт торбалары, исәпсез күп бүлемнәре — моңа никадәр кеше хезмәте киткәнне әйтеп торалар; кешеләр гигант казанга сокланып карый һәм мәңге онытылмас минутларның бөеклеген күңелләренә сеңдереп, телсез калып тора...

Тагын күпмедер вакыттан соң, пар казанын сынау башланып, моңарчы ишетелмәгән тоташ бер гүләү әйләнә-тирәне тутыргач, Сагайкинның йокысы кача, ул үзен кая куярга белми бәргәләнә һәм аяусыз бер уй аның миен яндырып уза: «Ничәмә төрле милләт кешесе эшли монда, алар арасында дошманлык чире таратырга кирәк. Бер-берсен күралмасыннар, сугышсыннар, кан үче алсыннар...»

Ул үз карамагындагы «ышанычлы кешеләрне», моңарчы төрле җирдә чәчелеп эшләгән төркемне, бергә җыйнарга, тайга эченә, ераккарак яшерергә дигән карарга килә. Мәскәү комиссиясе пар казанын сынаганны карап китәр өчен генә килмәгән, Мәскәү комиссиясе Сагайкинның эзенә төшәргә килгән. Юкка мыни комиссиянең эшен Крутанов белән Хангильдян аңардан яшерәләр. Сакланганны алла саклармын, ди. ГПУның овчарка кебек иснәнеп йөрүче этләренә килеп капканчы «ышанычлы кешеләрне» тайгага иң беренче итеп яшерергә кирәк. Ә кайда торырлар? Көннәрнең җылы булуы аның күңеленә өмет кертә. Җир казып, вакытлыча землянкада тора алалар. Азык-төлек булдыруны бергәләп хәл итәрбез.

Пар казаны гүли; ике сменага куелган автомашиналар, тәрәзә шәүләләрен стеналар буйлап йөгертеп, бер-бер артлы узып китә. Кайдадыр гармун өзгәләнә, аңа кемдер хәсрәтен түгә, Сагайкин хәлдән таеп, арып, саташулы йокыга китә...

## 16

Урал тайгасына тагын яз килде. Кыш буе йокыда утырган карагайлы урманнар, язын кояш нуры, җир җылысы белән мавыгып, тунналарын алыштырган арада, сизмичәрәк калдылар: химия гигантының

беренче заводлары, цехлары, ярдәмче хуҗалыклары барлыкка килде, үз электр станцасы, су кудыру станцалары үсеп чыкты. Бишьеллык урамы белән янәшә Индустриализация урамы да күзгә күренеп үсә, таш пулатларын тезә башлады. Күгелҗем томанга уранып, зәңгәрсу урман ераклыклары хасил итеп, тоташ бер массив булып яшәгән тайга телгәләнде, ярты күккә чаклы менеп җиткән кирпеч морҗалар, кара тимер торбалар тайга пейзажына мәңге китмәскә дип килделәр. Төзелешкә автомобиль, бетон болгаткыч җайланма һәм тагын бүтән төрле машиналар кайту гадәти бер күренешкә әйләнде.

Болар барысы яңа, барысы мавыктыргыч иде. Әмма барыннан да битәр кешеләрдәге үзгәреш күзгә ташлана иде. Элеккерәк елларны туган якларга кайтып китү, атлы-тунлы булу, йорт җиткезергә акча туплау Ардуановларның телендә туктаусыз кабатланса, соңгы вакытларда өйләнү, төпләнеп калу, «туган җирдән торган җирнең матурлыгын» исбатларга тырышу тенденциясе көчәйде.

Әнә шуларның һәммәсенең бер төбәге, җыелу ноктасы булып татар халкының бик борынгыдан килә торган язгы хезмәт бәйрәме — сабан туй көн тәртибенә килеп басты. Ул һәммә кешедә диярлек берьюлы кабынды. Дөресрәге — ул кешеләрнең күңелендә мәңгелек юлдаш төсле аерылмый яши, тик әле аны килү, урнашу, дөнья куу кебек мәшәкатьләр генә басып киткән иде.

Эшләр аз гына җайга салыну, комбинатның беренче контурлары күренә башлау белән сабан туй өскә калыкты, күңел шуны тели, шуңа ашкына...

Бәхтияр абзый сменага чыккан саен да, баракларда җыелган саен да шуны кузгата. Мирсәет абзыйны «начальство» янына барып, тәгаенен генә ачыклап, урынын-көнен дигәндәй билгеләп кайтуны сорый.

Крутанов андый бәйрәмне белеп җиткерми, ул урта Россиядән килгән, шунлыктан ул бераз шикләнү белдерде.

— Төзелештә дүрт меңнән артык татар-башкорт эшли, иптәш Ардуанов. Һәр бәйрәмнең үз дәгъвасы, низагы була — азагы өчен кем җавап бирер?

Мирсәет абзый сүзен Хангильдян куәтләде.

— Юкка борчыласыз, Никифор Степанович. Сабан туй — хезмәт бәйрәме. Анда берәү дә эчми, сугышмый, житезлеккә, гайрәтлелеккә көч сынаша. Пермьдә ясадык без аны, барыбыз да канәгать калдык.

— Бик яхшы, ә сез, иптәш партком, шул эшне оештырырга алынасызмы?

— Берсүзсез.

— Җавап та бирәсезме?

— Әлбәттә.

Хангильдян белән Мирсәет абзый, эштән соң кичләрен ике көн утырып, сабан туйның урынын билгеләделәр.

Секретарьны куркытмас өчен Ардуанов әллә ни күп нәрсә таләп итмәде.

— Бер дистә чүлмәк. Мәйдан уртасына колга утырту. Капчык сугышына бүрәнә-брус. Ат чабышына, татарча көрәшкә приз-бүләкләр бүлеп кую. Аннары килеп болай: сабан туй авыл шартларында үткәрелми, чуптарлы сөлге белән чигүле яулык бирүче булмас бәлки. Ә бит сабан туеның бөтен матурлыгы шунда. Кызлар, яшь киленнәр яз башыннан, кар китә башлау белән үк, иң матур бүләкләрен — тегүчигүләрен сабан туена дип әзерләп куялар; аннары кем бүләге кемгә, кайсы батырга эләгер икән дип түземсезлек белән көтеп алалар. Сез менә, Хан иптәш,— дип, Мирсәет абзый партком секретарена төбәлде, Хангильдянны эшчеләр үз итеп шулай дәшәләр, күбесе аның исемфамилиясен дә белми иде.— Сез менә, Хан иптәш, үз телегез белән постройкомга әйтә алмассызмы — кырык-илле метр ак кисея, шул

чама кызыл материя, бераз гына булса да сатин белән ефәк табасы иде. Шакир Сираев бригадасы кызлары унбиш көн эчендә барлык батырыңа җитәрлек бүләк әзерләп куярлар иде.

Анысына да килештеләр.

Әмма бәйрәмнең тәртипле узуы Хангильдянны борчый иде әле.

— Ипидер-кояш, берни дә булмас! — диде Мирсәет абзый һәм ант итә-итә ышандырырга тырышуыннан көлеп куйды.

— Мин сине аңлыйм, иптәш Ардуанов. Синең бригада тиктомалдан сугышмас. Ә бит... дошман бар. Соңгы көне җиткәнне сизеп, үлем агониясендә тыпырчынучы корткычлар бар. Яшерен-батырын түгел, яңа гына бит әле дошман безне тез тиңентен бозлы суда эшләргә мәҗбүр итте. Ул бик каты ялгышты, әлбәттә. Ул безнең водонасосныйны Кама дулкыннары иркенә калдырырга исәп тоткан иде. Эшчеләрнең гайрәтен чигерә, янәсе, юкка көчәнәсез димәкче була...

— Ничек соң, очы-кырые күренмиме, Хан иптәш?

— Күренер,— диде Хангильдян, өстәлгә кара төк баскан каты йодрыгын китереп куйды.— Безгә, иптәш Ардуанов, бер генә минутка да уяулыкны югалтырга ярамый. Иң әүвәл, бәйрәм өчен җаваплылыкны тулысынча үз өстеңә аласың. Тәртибе ничек анда сезнең?

— Нинди тәртибе?

— Бәйрәмне башлау, алып бару — кемгә тапшырыла?

— Гадәттә аны аксакаллар, ил агалары эшли.

— Табыгыз шуларны, комиссия төзегез.

— Ул гына җитәрме?

— Шулар янына яшьләрне куярга, нык куллы егетләрне! Бер егерме-утызны. Беләкләренә кызыл бәйләп, бәйрәм эченә, халык арасына сибәргә. Ил сагында торган постовойлар кебек булсын.

— Булыр, Хан иптәш,— диде Ардуанов, аның күп эшләүдән арып, капчыкланган, ләкин нурын җуймаган коңгырт күзләре өметле елмайдылар.

## 17

Бар да үз тәртибендә бара иде. Мирсәет абзый, Бәхтияр абзый, алар белән бергә Исәнгол Юлдыбаев, Кинъябулат, Янбай Дәүришев, чаярак егетләрдән Шәмсетдин, Сибгат-Сибай, Нәфүш-Сайрар кош ду килеп сабан туйны әзерләп йөриләр иде, Мәскәүдән укуын тәмамлап, Зөлхәбирә Кадерматова кайтып төште.

Бу яңалык Ардуанов бригадасын дер селкетте. Мөгаллимәләрен сагынганнар, күреп туймаслык булганнар иде. Шуның өстәвенә, аның бәхете түгәрәк булуын да бик телиләр. Нәфүш-Сайрар кошка үгет-нәсихәтләрен дә бирми булдыра алмыйлар.

— Син, янәсе, авызың белән кош тотып йөрмә, Нәфүш, сайрар сандугачыңны җиде ятка ычкындырып куя күрмә. Бел аны, бригат безнең ударный, эшләгән эшебез нинди югары булса, ийе, теге ни... Күңел канатлары да каерылмаслык нык булсын! Менә син аны пырахуттан машина белән каршы аласың калган, вәт, ичмасам, булырың егет. Син соң әле аңар шофер дигән иң затлы һөнәр иясе булганыңны язганыеңмы?

Нәфүш кызара, ыкы-мыкы килә.

— Юк, син дөресен әйт, язганыеңмы, юкмы? — дип бастырып киләләр егетләр. Бигрәк тә Исәнгол тырыша, ул һич кенә дә көлми, хәтта елмаймый да:

— Һин, кустым, бәк йаваплы кара ул эшкә. Стройка тулы күзен ямьрәйтеп торган ас козгын. Һизмәй лә калырһың, бисәкәй булаһы мөгаллимә һеңлебеззе бер ас козгын эләктерер дә алыр. Һин, кустым, уны абайла.

— Чистый! — дип ду килә егетләр.

Нәфүшкә рәхәт, авыз — колак артында. Бригада егетләренең төрт-мәле шаян сүзләрен үзенә хас бер киң күңеллелек белән тыңлап утыра-утыра да ул, күкрәгеннән киереп, ашкындырып торган кайнар тойгыларын дуслары белән бүлешми булдыра алмый.

— Мин аны станцадан машина белән алып кайттым бит!

— Китсәнә!

— Кайчан?!

— Зөлхи миңа хат язды. Күбәләгем-түгәрәгем, имеш, сайрар кошым-сандугачым, янәсе, син, Нәфүш Фәхриев, кеше оясында үскән күке баласы, укуыңны онытып бетермәдеңме әле? Әгәр дә мәгәр, ди, син, ди, укуыңны онытып бетерсәң, и янә дә килеп, чи усак түмәркәсе кебек надан килеш утырып калсаң, мин, ди, укытучы Зөлхәбирә, ди, синең дөньяда бар икәнеңне дә онытам и шулай ук яшь йөрәгемнең түреннән исемеңне үк сызып ташлыйм, ди. Белдегезме, кая таба китте эшләр!

— Ә син?

— Мин нәрсә? Мин уйлыйм, тукта, мин әйтәм, абзыкаем, торып тор, Зөлхәбирә туташ, мин әйтәм, син укып кайтканчы мин... ни тукмышты яңалифны, урысча да өйрәнеп куйсам ни диярсең? Урыс үзе авыз ачып торырлык итеп, ә?! И тотындым, и тотындым, мин сиңа әйтим, билне буып, беләкләрне сызганып...

— Бик ерактан тотындың, балакаем. Әллә, мәйтәм, мәсьәләгә якынрак киләсеңме? — диде Ардуанов, мыегын учы белән сыпырып.

— Ә нигә, теләк булганда якын ук килергә була, Мирсәет абзыкаем. Үзегезгә мәгълүм, ул бит минем машина йөртергә кергәнне күреп китте, әмма дә ләкин, Бәхтияр абзый әйтмешли, булдыра алачагыма бигүк ышанып бетмәде.

— Әлбәттә! Синең булдыксызлыкны белде бит.

— Причум монда булдыксызлык? Әгәр, алайга китсә, кем беренче башлап хәреф таныды? Кем беренче булып язу язарга өйрәнде? Кем беренче булып кәчтүн сатып алды. Менә шул-шул! Кем беренче башлап әмерхәннең үзеннән тиңелтен килгән автомобиль машинасына утырды? Сөйлисез икән, белеп сөйләгез, егетләр, белеп сөйләмәсәгез, авызыгызны ачыгыз да күзегезне йомыгыз.

— Каршы алдыңмы соң? — диде Мирсәет абзый, кайнарланыбрак киткән Нәфүшне туктатып.

— Баядан бирле шуны әйтергә итенәм бит инде, Мирсәет абзыкаем. И әрсез дә халык соң бу бетончылар, фундаментны бетонга катыра-катыра күңелләре дә катып беткән. Каршы алдым мин аны. Крутановка барып машина сорадым, бирми, үземне дә җибәрми. Ул ниткән әкәмәт, пнимаешь, эш вакытында эш калдырып, техниканы производстводан аерып һәм башкалар, һәм башкалар...

— Ә син?

— Мин әйтәм, иптәш-тавариш начальник, Зөлхәбирә кайта бит, гомер эчендә бер мәртәбә каршылыйм бит...

— Ә Крутанов?

— Крутанов тагын да ярсый төште. Ах, ул әле кызлар каршыларгамыни? Ничек оят түгел! Производствода прорыв ясап, көпә-көндез, транспорт алып китеп... Ничек оят түгел! Комсомол башың белән...

— Ә син?

— Нәрсә мин? Мин авызны ачкан да күзне йомган... Баш өстенә гравий ташы кебек сибелгән ачы сүзләрне тыңлыйм: эчтән генә хәйләкәр план корам, юк, мин әйтәм, иптәш-тавариш начальство, син миңа көне буе коршау сугып тора алмассың, бер дә бер арырсың, ә мин сабыр кеше, син арып туктауга үз туксанымны тукый башлыйм: күбәләгем-түгәрәгем һәм башкалар, һәм башкалар. Үз гомеремдә беренче

тапкыр минем сөйгән ярым Мәскәүдән кайта, машина миңа шуның өчен кирәк, бүтән чакта, көчләп бирсәгез дә кирәкми...

— Җиңелдеме?

— Җиңелде, ләкин үз ихтыярыннан түгел. Булмәдә безнең сәгать буена шаулаганны ишетеп Хан килеп керде, партийный секретарь. Керде и әйтә: Иптәш Крутанов, ди, недаром сиңа крутой дигән фамилия куйганнар, түзеп-түзеп торам да, борчак куырган кебек куырасың бит, ди. Бир син, ди, Фәхриевкә машинаны, эш сәгатеннән тыш бер сәгать артыгын эшләр, ди. Эшләрсеңме?

— Какой-такой сүз булырга мөмкин, иптәш партийный секретарь, мин әйтәм, рәзе минем кайчан да булса эштән баш тартканым бар?! Боерыгыз гына, көн димим, төн димим, бер сәгать йөргәнне уны белән кайтарам!

— Ә ул?

— Нәрсә ул? Малайлар кебек авызын ерып елмаеп тора, баштан сыйпамакчы итенә дә уңайсызлана, миңа үпкәләр дип курка бугай...

— Ә Крутанов?

— Крутанов та йомшады. Партийный секретарьның миңа үтә дә үз итеп каравы йомшартты. Шулай бит ул дөнья: мир какканны ир кага дип әйтте ди бер кодагый. Рас партийный секретарь миңа якты күз белән карый икән и шулай ук минем баштан сыпырып куярга итенә икән, Крутановның, стройкада беренче кул начальство булса да, йомшамый хәле юк... Мине үз янына чакырып ала, өстәл каршысына урындыкка утырта и әйтә: яшермә, Фәхриев, кем сиңа Кадерматова, шаляй-валяймы, әллә...

Шунда минем бугазга ачу утыра, күзләр ярсудан әчетеп китә:

— Ә кем сезгә, мин әйтәм, иптәш Крутанов, права бирде минем кәләштән көләргә, җитмәсә, мыскылларга?!

— Ә ул?

— Аңа нәрсә? Минем ише Әтәч Пәхрине бер генә күргән дисеңме? Мин авыздан күбекләр чәчеп кычкырам, ә ул елмаеп тик утыра. Кычкырынып аргач сорады: «Беттеме?» — «Бетте!» — мин әйтәм. «Димәк, серьезно?» «Серьезно»,— мин әйтәм.

— Алай булгачыннан, ди, син водитель Фәхриев, ди, эшне сузма, мөгаллимә Кадерматовага матур итеп кенә, җаен җайга китереп кенә өйлән дә куй. Кара аны, матри. Сайрар кош, начальствога мәшәкать тудырырга уйлый күрмә. Пока фатир юк. Баракта бер почмак бүлеп бирербез.

— Ә туй?

— Нинди туй?

— Кызыл туй, мин әйтәм. Безнең әллә аңа правабыз юкмы?

— Анысын Мирсәет Ардуанович белән сөйләшегез. Әгәр ул сине кызыл туйга лаеклы дип саный икән, баш өсте, шаулатып кызыл туй ясыйбыз, әмма, ди, стройкада, ди, андый хәлнең әле булганы юк, ди.

Тыңлап утыручы Шамукларның, Сибайларның күзләре уйный башлады.

— Эш шуңа барып җиттемени инде?..— диде Мирсәет абзый да, башны кашып.

Исәнгол, чын мәгънәсендә көнләшеп, авызын ачып Нәфүшкә карап калган иде.

— Авыдынды... япһаң да ярай. Ату исә карга сысып китәр,— диде Янбай Дәүришев. Ул үзе дә Фәхриевнең бәхетенә кызыга, аның сөйләгән чакта тагын да чибәрләнеп киткән кара тутлы түгәрәк йөзенә, көйрәп янган шомырт кара күзләренә төбәлгән иде...

Иртәгесен сабан туй әзерлеге белән бергә туй әзерлеге дә башланды. Бригада моны инде кияү белән кыздан яшереп түгел, аларга әйтеп, аларның ризалыгын сорап эшләде.

...Ардуанов бригадасының, аларга ияреп төзелештәге барлык татар һәм башкорт эшчеләренең милли бәйрәмнәрен үткәрергә җыенуын белгәч, Сагайкин күңелендә янә бер мәртәбә өмет уты кабынды.

«Аммонал белән динамит эшли алмаганны гади бер финка эшләргә тиеш. Бәйрәмне сүтәргә һәм моны... руслар белән «нацменнар» арасында дошманлык тудырырлык итеп эшләргә кирәк».

Үз янына ул «ышанычлы кешеләре» арасында иң кансызы Тощевековны чакырды, тегенең яңа бер вакыйга буласын сизеп, дәртләнеп кабынган яшькелт күзләренә төбәлеп:

— Татарва туй үткәрергә җыена. Укытучы Кадерматова шофер Фәхриевкә кияүгә чыга,— диде.

— Соң, чыкса?

— Туй булмаска тиеш.

— Ә мин аларны ничек таныймын?

— Элемтәче Сираев. Йә, нәрсә дивана кебек миңа карап торасың, белмисеңмени? Бетончы. Кызлар белән эшли. Шакир Сираев.

— Беләм,— диде Тощевеков.

— Белсәң шул... Сираев сиңа кияү белән кызны күрсәтер. Йә, аллага тапшырдык.— Ул, кулларын хәтәр селтәнеп, чукынды һәм усал ысылдап сүзен тәмамлады:— Кара аны, тотыла-нитә калсагыз, берберегезне сатмаска! Юкса... гомер буе большевиклар төрмәсендә черербез.

## 18

Биектә-биектә, төпсез зәңгәр күктә, аккош мамыгыдай йомшак ак болытлар йөзә. Алар кояш нурыннан яктырып, балкып, үсмер кызлар кигән кисея күлмәктәй җиңел, затлы, ымсындыргыч булып күренәләр.

Тайга урманнары ямь-яшел. Болыннар хәтфә япкан төсле, шул яшеллек эченнән көмештәй ялтырап, әле гөлҗимеш куаклары арасына яшеренеп, әле күренергә чыккан яшь киленнәр төсле, кояшка битен ачып, Зырянка инеше ага.

Инеш үз гомерендә күрмәгән яңа бер күренешкә шаһит: елга тугаена кешеләр килде, баганалар какты, колгалар утыртты, каеш түбәтәйне артка чигереп, нидер сөйләште, киңәште...

Инде менә Зырянка буйлары гөр килә. Гармуннар сайраша, колга башында чүпләм сөлгеләр җилферди, урта бер җирдә түгәрәк зур мәйдан калдырып, кешеләр җыела.

Зөлхәбирә белән Нәфүш соңгарак калып килделәр. Зөлхәбирәнең сабан туй күлмәге киңрәк булып чыккан, ул аның бил турысын тарайтып, яңадан төзәтеп утыра, әллә иелеп эшләүдән, әллә бәйрәм тойгыларыннан бите алсуланган, мәк чәчәге кебек яна.

— Син, малай, Нәфүш, миңа бик карама, яме, ату мин оялам. Бармагыма инә чәнечсәм, сабан туе урынына больницага алып барырга туры килер...

Нәфүш үзе дә бәйрәмгә дип инәдән-җептән генә киенеп чыккан: ал сатин күлмәк, кара постау чалбар, Пермь толчогыннан кайтарткан сары хром итек — болар барысы өр-яңа, нәкъ менә өр-яңа булулары белән Нәфүшне оялталар, уңайсызлыйлар, ләкин ул аларны Зөлхәбирәнең күрүен, бәя бирүен тели; аның үлеп тә сөйләшәсе килә, сөйгәнен үзенә сыендырып, инде менә ничә айлар күңелендә йөрткән сагыну тойгыларын әйтеп бирәсе килә, ләкин Зөлхәбирә — үз кадерен үзе белә торган чая кыз — аны якын да китерми, сөйләштерми, бәйрәм күлмәге төзәтә.

Алар сабан туе буласы урынга килеп җиткәндә инеш буйлары инде халык белән тулган, кеше күплегеннән, кояш күплегеннән, чуарлыктан күзләр камаша иде.

Халык кинәт гөрр килеп көлде.

Зөлхәбирә, ни булганны карар өчен, Нәфүшне житәкләп, эчкәрәк алып кереп китте. Иң алгы рәттәгеләр, түгәрәкләнеп, аякларын сузып, яшел чирәм өстенә, жиргә утырганнар, авызларын ачып, мәйдан уртасында барган тамашаны күзәтәләр. Аякларына капчык кигән оп-олы кешеләр, тышаулаган ат кебек, кушаяклап сикерәләр, авып-авып китәләр, Зөлхәбирәнең моны күргәне дә юк икән, ул эчләре катып көлә, якындагылар аны туктатырга итенәләр,— кая ул! — рәхәтләнә Зөлхәбирә көлеп!

Көлеп кенә калса бер хәл иде, Зөлхәбирә утырган көйгә Нәфүшнең беләген ике куллап кысып-кысып куя, Нәфүш — ни жор егет бит инде! — шулай да уңайсызлана, күзәтеп тора торганнардыр дип ут кебек кызара, ләкин беләген тартып алмый, жан сөйгәненең янәшә булуы, чыр-чу килеп сөенүе рәхәт, бик рәхәт аңа.

Чүлмәк вату башлангач, Зөлхәбирә әсәрләнеп үк китте. Күзләре бәйләнгән түбәтәйле бер картның, зырр итеп әйләндергәннән соң, чүлмәк булмаган якка, халык өстенә таба таяк күтәреп бара башлавы аны тагын рәхәтләнеп көлдерде.

Мәйдандагылар чүлмәк ватучыларны: «Уңга бар, сулга борыл!» — дип өзлексез өйрәтеп, тамаша кылып тордылар.

Рәттән өч кеше жирнең «башын ярып» чыккач, Зөлхәбирә түзмәде, урыныннан сикереп торды да:

— Киттем мин, Нәфүш, бәхил бул! — дип, мәйдан уртасына йөгереп барып та керде.

Чүлмәк ватарга теләүче күп, араларында кызлар юк иде. Күз бәйләп торучы Исәнгол белән Сибай, бөтен сабан туеның күрке булган Зөлхәбирә уртага йөгереп кергәч, иң элек аңар ташландылар. Исәнгол алданрак житешеп, кызның күзен бәйләргә кереште, Сибайга иптәшенең бәхетеннән көнләшеп, карап торырга гына калды.

Исәнгол Юлдыбаев Зөлхәбирәнең чүлмәкне ватуын бик тә тели, шунлыктан кызның күзен ачыграк калдырырга тырыша, тик чамасыз дулкынланудан яулыкны бәйли алмый азаплана иде. Бәйләп бетердем дигәч кенә хәйләсез Зөлхәбирә эшне бозып ташлый язды.

— Күренә бит бу, Исәнгол! — дип пышылдады.

— Шаулама, һылукай, үзем ошолай бәйләнем,— диде Юлдыбаев, аның нәфис иңбашына кагылып.— Киттек, бергә атлап барабыз.

Ул Зөлхәбирәне, кулыннан житәкләп, чүлмәктән егерме адым читкә алып китәргә тиеш иде, житәкләшеп бару бәхетеннән онытылып, тиешле араны узып китә язгач, кыз өчен янып-көеп утыручы яшьләр, алар белән бергә Нәфүш тә:

— Житте!

— Булды!

— Хәрәмләшмә! — дип кычкырдылар.

Зөлхәбирә нығытып бәйләнмәгән яулык астыннан жирне шәйләп, туктый-туктый барды. Сабан туе шартын күз карасы кебек саклаучы картлар: «Күрә! Күрә!» — дип шаулашырга тотындылар.

Зөлхәбирә каушады, чүлмәкне вата алмаячагыннан, Нәфүш алдында хур булачагыннан куркып, бөтенләй туктап калды. Ул арада яулык шуып, аның күзен томалады. Мондый чакта, ни булса ул дигән тәвәккәллек белән, тиз-тиз генә тагын берничә адым атлады да, кызларча — кизәнмичә — тык иттереп кенә, жиргә сукты һәм үз колакларына үзе ышанмыйча катып калды. Мәйдан гүли, мәйдан ду куба, челпәрәмә килгән чүлмәк жирдә чәчелеп ята иде.

Ул колак төбендә генә: «Ай да маладчина! Рәхмәт, кызым!» — дигән тавыш ишетте. Тавышка борылып караганда, кара бәрхет түбәтәй кигән, беләгенә кызыл тасма таккан Мирсәет Ардуанов аңа кәгазьле исле сабын сузып тора иде.

Үз гомерендә шуннан да кадерлерәк бүләк алганы булды микән Зөлхәбирәнең! Ул, сөенечennән нишләргә белмичә, бүләкне Нәфүшкә күрсәтергә йөгерде. Үзенең битләре ут булып яна, йөрәге тасырдый иде. Менә нәрсә икән ул сабан туе!

Нәфүш янына килеп утырганнан соң да, аның мактап әйткән сүзләрен ишеткәннән соң да, ул әле һаман тынычлана алмыйча, ничек-ничек булганын, нинди хисләр кичергәнен Нәфүшкә сөйли, тегесе, авызын ерып, рәхәтләнеп аны тыңлый иде. Әнә шул бергә кичергән дулкынлану минутларында алар инде яңа төр уеннар, яңа төр мәзәкләр башланганын сизми дә калдылар. Мәйданның бер почмагында, бүрәнә өстендә капчык белән сугышалар; чалбар балакларын сызганган бер малай озын колга башындагы читлектән тере әтәч алырга менеп бара; Шакир Сираев кызлары, бизәкле көянтә-чиләкләр белән, бер генә тамчысын да чайпалдырмаска тырышып, су күтәреп йөгерәләр иде.

Нәфүш-Сайрар кош боларның барысын исе китмичәрәк карап утырды. Зөлхәбирә бераз аптырауда иде: ничек шулай тыныч кала ала ул, нигә көлми, нигә дәртсенми? И шәһәр кызы, белмисең шул әле син, сабан туенда егетләрнең йөрәген чаптар аттай җилкендергән уен — көрәш ул, батырлыкка көч сынашу, өстен чыгып, кызларның йөрәгенә ут салу.

Мәйдан уртасына төрле яктан бәләкәй малайлар йөгереп керә башлагач:

— Нәрсә бу?! Нәрсә бу?! — диде Зөлхәбирә, тагын Нәфүшнең беләгенә тотынып.

— Көрәш башлана, шаулама,— диде Нәфүш, җитди итеп. Зөлхәбирә аның кинәт дулкынлана, күзләре зурая башлаганын күрде.

Малайлар үсмерләргә, үсмерләр тап-таза егетләргә әйләнә барды. Мәйдан кинәт кысылды, тарайды. Арттагылар алга уздылар.

— Нәрсә бу?! Нәрсә бу?! — диде Зөлхәбирә, тагын аңламыйча.

— Көрәш бу, Зөлхи, көрәш.

Көрәш барган җиргә ике атлы милиция кереп, кысыла барган мәйданны әкрен-әкрен киңәйтеп йөри башладылар. Ат аягы астында калырга теләмәгәннәр чирәмгә утырган көе иләп кенә арткарак шуышты.

Зөлхәбирәгә дә ялгызы калыр, егете өчен янып-көеп утырыр чаклар җитте.

— Кайтмый калсам, бәхил бул, Зөлхи,— диде Нәфүш-Сайрар кош, кызның үзе кебек шаяртып.

Нәфүш кулына сөлге тоткан минуттан башлап Зөлхәбирәдә бәйгечеканы уянды. Нәфүшкә каршы чыккан зәңгәр майкалы егет бик таза, аның беләк мускуллары ишелеп килгән бау кебек иде. Зөлхәбирәгә ул Нәфүшне эһ тә итмичә әйләндереп салыр кебек тоелды. Нәфүш башта күлмәген салмый гына тотынган иде, тәртип саклаучы картлар аны да салдырдылар. Зөлхәбирә — беренче мәртәбә — сөйгәненең киң күкрәкле, теге егеттән бер дә ким булмаган мускуллы икәнен күрде. Бу аны тынычландырды. Ләкин егетләр сөлгене кулларына урап, гәүдәләре белән җиргә ятар дәрәҗәгә җитеп, маңгайларын терәшкәч, аны тагын курку алды. Зәңгәр майкалыны аягыннан тартып егардай булды. Көрәшчеләр таптанып йөри башладылар. Халык ризасызлык белдереп, сузмагыз, сузмагыз, дип шаулашты.

Менә бер заман Нәфүшнең аяклары әкрен генә җирдән куба башлады. Зәңгәр майка Нәфүшне күкрәгенә кысты (Зөлхәбирәнең йөрәге тамак төбенә менеп җитте!), инде сала дип кенә торганда Нәфүш тегенең кочагыннан шуып чыгып, җиргә басты да зәңгәр майкалыны ян якка аударып та җибәрде. Бу шул кадәр тиз булды, Зөлхәбирә ни булганын да аңламый калды. Нәфүш, мышкылдап, аңа ике метрлы ак бәс китереп тоттыргач кына егетенең җиңгәнен аңлады. Икенче көрәшчене Нәфүш бер күтәрүдә салды. Өченчесе көрәшә белмәүче иде

бугай, таптанып йөри-йөри Нәфүшне алҗыткач, ниндидер бүләк биреп, аны көрәштән чыгардылар.
Дүртенче кеше Нәфүшкә каршы тиз генә чыкмады. Бәхтияр абзый көрәшчеләр арасыннан кыюларны үгетләп йөрде, Ардуанов бүләкләр өеменнән чигүле ак күлмәк алды. Зөлхәбирәнең йөрәге тагын тамак төбендә үк тибә башлады — бу аның бүләге иде.
— Кем чыга? Кем чыга? — дип, күлмәкне баш өстенә күтәреп күрсәтте Ардуанов.
Нәфүшкә каршы кара сатин күлмәген чалбар өстеннән чыгарып кигән караңгы чырайлы бер кеше алпан-тилпән атлап килә башлады. Мирсәет Ардуанов аның Шакир Сираев икәнен танып, өнәми генә сөлге китереп бирде.
Нәфүш биленә сөлге килеп төшү белән үк Шакирның каты куллы икәнен сизеп алды, караңгы чырайлы, сүзсез бу кеше, сулыш алырга ирек бирмичә, билне тимер кыршау белән кыскандай кыса иде.
Шакир белән Нәфүш маңгайны маңгайга терәп йөри башлагач, Зөлхәбирә түзә алмыйча:
— Бирешмә, Нәфүш! — дип кычкырды.
Нәфүш аның тавышын ишетте, ахрысы, Шакирны үзенә таба суыра башлады, ләкин теге — җиргә берегеп үскәнме диярсең — селкенеп тә карамый. Ул арада Нәфүш үзенең күтәрелә башлавын сизде, беренче көрәшчедәге кебек, бераз ирек бирергә дә, көтмәгәндә җиргә басып, тегене янга аударып җибәрергә ниятләнде. Дошманның күкрәгенә күтәрелгәч, күңеленнән хәвефле уй узды: җиргә баса алмаячак ул. Сау бул, чигүле күлмәк! Сау бул, Зөлхәбирә бүләге!..
— Карагыз әле, кара, менә бу, ичмасам, көрәшче! — Бу сүзләрне комиссия өстәле янында утырган Никифор Крутанов әйтте.
— Әйе, белеп көрәшә, күрәсең, моңарчы да көрәшкәндер,— диде Хангильдян тыныч кына.
Өч кешене еккач, Сираевны читкәрәк утыртып, башка көрәшчеләргә ирек куйдылар. Мирсәет абзый башта көрәшергә уйламаган иде, торабара аңарда да көрәшче каны кузгалды, рәттән өч кешене егып, ул да Сираев янына барып утырды. Җиңелми калганнар сигез кешегә җыелды. Сабан туен үз гомерендә беренче мәртәбә күргән Крутанов, хисләренә төелеп, Хангильдян белән Мицкалевичка моның әйбәт бәйрәм икәнен, ел саен үткәрергә кирәк икәнен, Ардуановның эшне дөрес башлап җибәрүен кайнарланып сөйли иде.
— Чебешләрне көз көне санарбыз, Никифор Степанович, ашыкмый торыйк,— диде партком секретаре.— Ничек икән анда милиция посты? Башлыкларын чакырып, хәлне белешергә кирәк.
Отряд начальнигын чакырырга Сагайкинны җибәрделәр. Ксенофонт Иванович, картлар белән бергә, сабан туй комиссиясендә тәртип саклый иде, ул озакламый үзе белән отряд начальнигын алып килде. Гимнастерка якасына кубик таккан урта яшьләрдәге кеше төзелеш җитәкчеләренә әлегә тәртипсезлек булмавын, кызмача егетләрне берәмберәм баракларга озата торуларын хәбәр итте.
Кичке алтылар тирәсендә Зырянка буенда халык сирәгәйде. Көрәшнең азагын карамый китми торган иң һәвәскәр картлар да көрәшчеләр үзләре генә диярлек торып калды.
Батыр булып Ардуановның калуын бик теләделәр. Көчен кызганмыйча, хәрәмсез көрәшә. Бик чиста әйләндерә,— җиргә сылап кына куя. Ниһаять, сигез кешедән дүртәү калдылар. Алар арасында Ардуанов бар иде әле. Крутанов тагын түзмәде: «Ай да молодец! Ну, Мирсаид, не подкачай!» — дип аваз салды. Ләкин ул теләгәнчә барып чыкмады. Батыр даны Шакир Сираевка эләкте. Дөрес, ул Ардуановны ега алмады, әмма җитәрлек азаплады. Аның ике мәртәбә Мирсәет абзыйны күтәреп алуын истә тотып, батырга дигән патефонны аңа

тоттырдылар. Халык, дөрес түгел, көрәштереп бетермәдегез, дип дәгъвалашып та караган иде. Мирсәет абзый үзе бүтән көрәшергә теләмәгәч, теш кысып кына риза булдылар. Сираев тир түгеп алган патефонын култык астына кыстырып тизрәк таю ягын карады, чөнки сабан туеның кагыйдәсен яхшы белә иде ул, аллам сакласын, Ардуанов яклылар измәнне изеп ташларга да күп сорамаслар...

Мәүгыйзә түти Мирсәетен уртадан үзе кереп алып чыкты. Ире көрәшеп җыйган бер кочак бүләкне дә күтәреп чыкмакчы иде, анысын Мирсәет абзый хатынына тоттырмады.

— Монысы бригатныкы, без әле тагын сабан туе үткәрәбез,— диде.

Һәм чыннан да Ардуанов әллә ни арада кечерәк мәйдан оештырып, үз бригадасы егетләрен көрәштерә, йөгертә, чүлмәк ваттыра башлады. Монысы беренче зур сабан туйдан да кызыграк булып чыкты. Уенкөлкенең, кызыкның чиге-чамасы булмады. Бригада егетләре инде бүләк алудан бигрәк мәзәклеге өчен тамашага катнашып киттеләр. Ардуанов бүләкне үз кулы белән биреп торды. Йөгереш вакытында иң азаккы булып лырт-лырт йөгереп килүче Бәхтияр абзыйдан халык рәхәтләнеп көлә, төрлесе төрле яктан киңәшен биреп тора.

— Бәхтияр абзый, бирешмә! Беренче киләсең!

— Бәхтияр абзый, ник шул чаклы тырышасың? Бүләк калмады бит инде...

Гайнуллин бер дә аптырамыйча, үз җаена гына лырт-лырт юыртуын белә һәм елмаеп әйтеп бара:

— Мирсәет юмарт ул, миңа да бирәр нәрсә табар әле.

## 19

Зөлхәбирә белән Нәфүш сабан туйдан соңгы кеше булып диярлек кайттылар. Аларга бүген диңгез тубыктан! Кулларын кулга тотынып, елга тугайларында йөрделәр, яр буйларында утырып тордылар. Инде менә Әдәми таудагы баракка кайталар.

Урман сукмагы караңгы. Чәбәләнеп үскән дуләнә куаклары, баш өстенә чатыр корган имән ябалдашлары йолдызларны яшереп асрый. Төзелеш гөрелтеләре монда тонык кына ишетелә — урманның сизелерсизелмәс кыштырдаулары аларны үз эченә йота.

Кулларын кулга тотынып, алар икәү генә атлыйлар. Кыш буе бербереен сагынып үткәргән көннәр күңелләрендә кабат яңара, һәм алар әкрен генә үз уйларын уйлап баралар.

«Әгәр Березнәктә комбинат салмасалар, мин бу Сайрар кошны очрата алмас идем. Ул икенче берәүнең кулын тотып барыр иде. Хәзер ул минеке. Минем өчен утка-суга керергә, биек кыядан упкынга сикерергә әзер. Мин аның турылыклы юлдашы булырмын. Мин аңар берсеннән-берсе матур малай белән кыз бүләк итәрмен...»

«Бу нәфис гөл минем бәхеткә туган. Ул минем күзләремне ачты, сукыр тавык булып йөрүдән коткарды. Мин аның кадерен белермен: өрмәгән җиргә дә утыртмам. Ул миңа тупырдатып ун бала табып бирер. Без, урман кошлары кебек, чыр-чу килеп яшәрбез...»

Уралның мастер Кадермәт кызы белән Актанышның крестьян Фәхри малае тайга сукмагыннан атлый. Алар бүген яшьлекләре белән саубуллаша. Иртәгә туй — төзелештә беренче кызыл туй, комсомол туе!

И дөнья! Зөлхәбирә белән Нәфүшнең дә яшьлек дип аталган ашкынулы ваемсыз чагы, хәсрәт-кайгылардан ерак чагы, тайга тирәнлегеннән килгән өрфия җилдәй җинел-нәфис чагы узып китәмени?! Аларның гаилә дигән зур тормышы башланачак. Мирсәет Ардуанов кебек, аның үткен телле, нечкә күңелле хатыны Мәүгыйзә түти кебек, Нәбиулла

белән Зөлхәбирә дә ил йөкләгән һәм үзләре теләп алган йөкне ыңгырашмый-нитми тартып барырга тиеш булачаклар. Аларга социализм иленең язмышы тапшырыла.

Хәзергә әле алар ул хакта уйламый. Күңелләре тулы ашкыну аларның. Тамырларында — кайнар кан, күңелләрендә — зәңгәр болытлар, җилкәнен киергән кораблар; яратасы һәм яратыласы килүдән, теләктойгылардан башлары әйләнә.

Кечерәк бер аланга килеп чыктылар. Баш өстендә йолдызлар кабынды. Йолдызлар яктысыннан каен кәүсәләре җемелдәп китте.

Зөлхәбирә куш каенга килеп сөялде. Кулларын сөйгәненә таба сузды. Нәфүш, аның ике кулыннан берьюлы тотып алып, әкрен генә әйтте:

— Син мине яратырсыңмы?

Зөлхәбирә башын артка ташлап, күзләрен йомды, иркә балалар тавышы белән келтерәп көлде.

— Я-ра-тыр-мын! — диде. Уйнап әйтте, тылакыйланып әйтте.

— Гомер буенамы? — диде Нәфүш, кайнар пышылдап.

Зөлхәбирә кинәт тынды.

— Яратырмын. Гомер буе яратырмын. Синнән дә газиз бер генә кешем дә юк бит минем, бәгырькәем...

Нәфүш, моңарчы күңелендә тыеп асраган шашкын хисләренә баш була алмыйча, үз гомерендә беренче мәртәбә, ярсып-онытылып, аны күкрәгенә кысты һәм шул мизгелдә үк кемнендер, якасыннан умырып алып, аркасына тезен терәп, артка каеруын тойды.

Ул да түгел, очлы салкын тимер, кабыргаларын шытырдатып, йөрәгенә кадалды.

Зөлхәбирә, сискәнеп, күзләрен ачты. Ни булганын аңлап алырга да өлгермәде, күкрәк турысында пычак сабы тырпаеп калган Нәфүш — дорфа рәвештә этеп җибәрүдән,— аңа килеп бәрелде, кызның аппак күлмәгенә ургып кайнар кан ага башлады.

## 20

Төн идеме бу, әллә таң алды карасы идеме, Ардуанов дөбердәтеп бүлмә тактасы какканга уянды. Бәла килгәнне сизенеп, урыныннан сикереп торды, өстен киенергә дә онытып, эчке күлмәк-штаннан ишекне барып ачты.

Ишек төбенә бригадасы җыелган — фонарь тоткан егетләр зур бер кара төркем булып басып тора. Төркемнән Исәнгол Юлдыбаев аерылды, бригадир янына ук килеп, колагына әйтте:

— Нәбиулланы үтергәннәр.

— Кайсы Нәбиулланы?

— Сайрар кошны.

«Ә туй? Ә Зөлхәбирә?!» — Аңына барып ирешкән беренче уен Мирсәет абзый әллә күңеленнән, әллә кычкырып әйтте.

Киенергә кирәк иде — киенде. Барактан чыгышлый, төзүчеләр поселогында шаулап сөйләшкән тавышлар колакка чалынды, кемнәрнеңдер ашыгып, йөгереп узган шәүләләре күренеп калды.

Әнә шул минутлардан башлап, авыр таш булып җилкәне баскан кайгы һәм бригаданың язмышы аны нык булырга, җебеп төшмәскә өндәде.

Төзелеш җитәкчеләре дә аякка баскан иде инде. Крутанов биш минутлык киңәшмә җыеп, шундук күмү комиссиясе төзеде. Рәисе итеп партком секретаре Хангильдянны, әгъзалары итеп Нурисламовны, Ардуановны, Бәхтияр Гайнуллинны билгеләделәр, Сагайкинны

оештыру, өлкә белән элемтәгә керү эшенә билгеләмәкчеләр иде, ул өйдә түгел икән.

Беренче эш итеп мәрхүмнең гәүдәсен больницага алып кайтып урнаштырдылар, суд экспертизасы һәм оператив эш кешеләре үз эшләренә кереште.

Бригада эштән туктамаска тиеш. Төзелешне туктату яшерен эш алып барган корткычларның халык арасында төрле коткы таратуга, буталыштан файдаланып, кара эшләрен эшләүгә китерәчәген беләләр иде.

— Мирсәет Ардуанович, мин сезнең халыкның күмү йолаларын белмим, ул эш тулысынча сиңа тапшырыла,— диде Хангильдян.— Нәрсә кирәк дип табасың, барысын да эшлә. Ләкин бер нәрсәне онытма, Фәхриев комсомолец иде, без аны барлык йолаларны үтәгәннән соң, табутка салып, халыкка күрсәтеп күмәргә тиешбез. Тагын бер тапкыр иптәшләрчә сорыйм: иң вак детальләренә хәтле уйлап эшлик. Күренеп тора, егетләр ярсыган, бигрәк тә синең бригада егетләре, стихияле бунт башланып китмәгәе. Үзегезгә мәгълүм, милли хисләрне ярсытудан да хәтәр провокациянең дөньяда булганы юк.

— Егетләрне мин үзем тынычландырырмын. Алар моңарчы минем сүздән чыкмыйлар иде әле,— диде Мирсәет абзый.— Безгә бит мәрхүмнең туганнарына белдерергә, күмү өчен кирәкле материалларны табарга кирәк. Шул эшкә дип билгеләнгән Сагайкинның өйдә булмавы миндә шик уята.

— Әйе шул. Моны ачыкларга кирәк. Фәхриев йөрткән машинаны бик яхшылап юдырырга, кызыл һәм кара материя белән уратып алырга кирәк. Ул эшләрне Мицкалевич башкарыр. «Сагайкин кая киткән, менә бу проблема. Неужели, аның бу эштә катнашы бар?» — дип уйлады партком секретаре, тик әле ул күңеленә килгән шикне берәүгә дә әйтми торырга булды.

Мәрхүмнең гәүдәсен, алдан сөйләшкәнчә, татар йолалары белән кабыкка салып юдылар, бу эшне Березникида күптәннән яшәгән картлар ярдәмендә, Бәхтияр абзый эшләде, аннары яңа киемнәрен киендереп, табутка салдылар, башта алып чыгуны баракта эшләргә уйлаганнар иде, халыкның күп киләсен, баракта урын җитмәсен уйлап, клубка куярга булдылар. Саубуллашу һәм күмү вакытын Крутанов эшчеләрнең ялга туктаган сәгатьләрендә эшләргә һәм төшке ялны бер сәгатькә озайтырга, шул хакта барлык төзелешкә агитаторлар, тәрбиячеләр, бригадирлар аркылы белдерергә киңәш итте.

Көндезге сәгать уникедә борынгы сода заводы минут буе гудок биреп торды. Кешеләр эшләреннән туктап, клубка, Бишьеллык урамына таба юнәлделәр.

Мәрхүм белән саубуллашырга килүчеләр чираты бер чакрымга сузылды. Сүзсез генә керәләр, табут эчендә кыр чәчәкләренә күмелеп яткан япь-яшь егеткә соңгы ихтирамнарын белдереп, әкрен генә узып китәләр; аның баш очында өнсез утырган Зөлхәбирәне кызганып, йөрәкләренә моң төяп чыгалар, теш казналары кысыла, йодрыклары төйнәлә.

Менә табутны машинага чыгарып куйдылар. Күз күреме җирдә диңгез кебек чайкалып торган халык төркеменә карап, Хангильдян саубуллашу сүзен әйтте:

— Иптәшләр, явыз дошманның канлы пычагы безнең арабыздан комсомолец Фәхриевне алып китте. Аңа әле егерме биш кенә яшь иде. Ул тормышны ярата, иптәшләрен ярата, ул җаны-тәне белән төзелешкә гашыйк иде. Җир казучыдан ул бетончы булды, химкомбинат төзелешенә кайткан беренче машинага менеп утырды. Дошман безнең сафларыбызны бозарга, төзелештә чыныккан дуслыгыбызга кул сузарга, паника чәчәргә теләде. Барып чыкмас! Эшче иптәшебез Нәбиулла

Фәхриев җеназасында без энергиябезне икеләтә, өчләтә арттырып, социализм иленең химия гигантын нык итеп салып бетерергә ант итәбез.

Җиз тәлинкәгә җиз тәлинкә китереп бәрде — үлемнең чынлыгын халыкка җиткерде; көмеш быргылар тавышы, барабаннарның дөпелдәтеп баскан марш ритмы кешеләрне бер адымга, бер йодрыкка туплады.

Баш өстендә июнь кояшы, күктә аккош мамыгыдай ак болытлар, юлда грузовик бара, грузовикта — Нәбиулла Фәхриев, аның баш очында — канатларын салындырган кара кош төсле, Зөлхәбирә Кадерматова утыра. Янәшәдә — Мирсәет Ардуанов, эскәмияләрдә — бригада егетләре.

Җирдән кешеләр атлый, аркаларына мылтык аскан атлы милиционерлар килә, җиз тәлинкәләр, көмеш быргылар, киерелеп тартылган барабаннар кайгылы-тантаналы маршка кешеләрне туплый.

Төзелеш фронты солдатын соңгы юлга озаталар...

## 21

Ксенофонт Иванович Сагайкин беркая да китмәгән, сабан туе көнне кичтән үк кулга алынып, ялгыз камерада төн чыккан һәм менә хәзер, ГПУ диган өч кенә хәрефле, дәһшәтле сүзне күңеленнән кабатлап, сорау алырга чакыруларын көтеп утыра иде.

Кеше тормышында иң авыр нәрсә — билгесезлек. Әгәр Сагайкин менә хәзер нинди сәбәпләр аркасында бирегә килеп эләгүен белсә, допрос вакытында үзен ничек тотарга, нинди версияләр уйлап чыгарырга икәнен чамалар һәм йокысыз үткән төн эчендә ул аны инде беркем бәйләнә алмаслык итеп уйлап та чыгарган булыр иде. Ләкин ул белми. Белми, каһәр суккыры! Ышанычлы кешеләре кияү егетне үтергәннәрме-юкмы — белми, үтерсәләр, ничек үтергәннәр, судан коры чыкканнармы — белми; аның үзен болай гына, шикләнү сәбәпле генә кулга алганнармы, әллә ышанычлы кешеләренең берәрсе тотылып, допрос вакытында аны сатканмы — берсен дә белми, белмәгәнгә күрә гасабиләнә, ниндирәк карарга килергә, ничегрәк саклану чараларына керешергә аптыраудан газаплана иде.

Ул моңарчы да ГПУ кешеләренең үз эшенә тыныч карый алмауларын, аны гел күзәтеп, аның сүзенә гел колак салып йөргәннәрен тоена иде, әмма кулга алыну болай ук көтелмәгәндә булыр дип башына да китерми иде. Чөнки каршы якның бер генә төрле дә дәлиле юк, аны кулга алырдай җинаять билгесе юк иде бит. Чаларган каты мыегын чәйнәштереп, ул соңгы көннәрдә кайларда булуын, кемнәр белән сөйләшүен, ниндирәк саксыз гамәлләр кылуын күңеленнән барлап чыкты. Тайга төпкеленә яшерелгән землянкада булды, күрүче-мазар булмады. Әллә күреп тә күрмәмешкә салыштылармы? Бәлки инде аның ышанычлы кешеләре изоляторда утыра торгандыр, хөкем сәгате сукканны көтеп, газаплы уйларын күңелләреннән кичерәләрдер. Әллә водонасосныйдагы төнге шартлауның очына чыкканнармы? Алай дияр идең, аны бер Сагайкин белә дә, шартлатуны эшләгән группа белә. Аны бит Сагайкин группасы түгел, читтән килгән, башка кеше кул астында эшләгән группа башкарып чыкты, Сагайкин аларга юл гына күрсәтеп бирде. Алар инде, мөгаен, Магниткага барып чыкканнардыр, яңа шнурлар, яңа аммоналлар әзерләп, күккә ут-төтен баганалары күтәреләчәк көннәрне күз алларына китереп, хыялланып йөри торганнардыр.

Сагайкин, шуларны уйлагач, аз гына тынычлангандай булды. Кулы белән капшанып, камера стеналарына тотына-тотына, арырак китте. Ишек төбендәге парашага абынып, теш арасыннан сүгенде. Камера

карангы, тынчу иде. Чуен рәшәткәле бәләкәй тәрәзә каршысына туктады. Зырянка елгасы ягыннан, алар моннан берничә ел элек «балык тотып» утырган аулак тугайдан, күк читенә кан кызыллыгы сибеп, таң яна башлаган иде. Әнә шул кызыл шәүлә аңар большевиклар төрмәсеннән качып киткән чакларын, иректә яшерен эш алып барган эсер иптәшләрен, алар ярдәмендә поручик Софроновны Себернең Демидов заводларында эшләгән потомственный Сагайкиннар фамилиясенә алыштыруын, аннары бик озак — айлар буе — Себердән ераклаша баруын күз алдына китерде. Партиядәш иптәшләре аңар Урал үзәгенә урнашу, социализмның тамырына балта чабу бурычын йөкләделәр. Балта чаба алдымы соң ул? Водонасосный исән. Ударник Ардуанов исән. Һәм тагын кайчанга тикле Ардуановлар исән йөрер? Сагайкин теш казналары кысылып, янак сеңерләре бүртеп чыгуын тойды. Бетон басмаларга катыкаты басып йөргән Ардуановлар, Громовлар, Вотиновлар аның киләчәген тартып алдылар, аның үзен шушы ялгыз камерага ябып, үткән көннәр истәлеге белән бер ялгызын калдырдылар.

Ксенофонт Иванович чуен рәшәткәле төрмә тәрәзәсе аша кандай кызарып янган таң шәүләсенә — ирекле көннәренә — кызыгып карады. Күзләре талганчы көн яктырганны көтеп торды. Каяндыр ерактан моңсу гына булып завод кычкырткан тавыш ишетелде. Купец Любимов белән швед Солвэның Урал урманнарында адашып калган бердәнбер химия заводы икәнен белә иде ул моның, үз сыйныфының тавышын әнә шул завод гудогыннан зәгыйфь кенә итеп ишетү аның йөрәк ярасын телеп җибәрде. Завод гудогына иртәнге сменага бетон төяп килүче күкепаровоз ачы итеп җавап кайтарды. Төзелешкә соңгы айларда күпләп кайткан йөк машиналары сигнал бирешеп, бер-берсен сәламләделәр. Аннары тавышлар ишәйде, тоташ бер гөрелдегә, үз ихтыярын көчләп тага ала торган хакимдар өндәмәгә әйләнде. Шушыларның барысын чуен рәшәткә аша гына күреп, сиңа кан дошманы булган системаның йөрәгенә басып килүен белеп торудан да авыр нәрсә бармы? Сине иртәгә, юк, бүген, тагын бер-ике сәгатьтән, нинди язмыш көткәнен белми яшәүдән дә авыррак нәрсә бармы? Социализм сине ялгыз камерага бикләп үз эшен эшли. Себер чаклы Себердән — кедрлы, пихталы урманнарны, тоташ тынлыкта яткан буш өнсезлекне, урман күлләрен ташлап, туган тияген ташлап, монда — Урал үзәгенә, ут һәм төтен эченә нигә омтылды соң ул? Социализм гүләвен чуен рәшәткәләр аркылы тыңлап тору өчен омтылдымыни?

Калын тимер ишекнең аратасы шалтырап Сагайкинны сискәндереп җибәрде. Ул да түгел, шыгырдап ишек ачылды һәм шәфкатьсез калын тавыш:

— Сагайкин, к выходу! — дип боерды.

Ксенофонт Иванович кораллы конвой озатуында ярым карангы бер коридордан, алдына-артына каранмыйча, озак кына барды, һәрхәлдә, аңар озак тоелды; аннары сулдагы бер ишек ачылды һәм аның күзенә көлтәсе белән яктылык бәреп, сукырайтып җибәрде; күзен ачып карарлык хәлгә килгәндә, аның каршысында ярым хәрби гимнастеркалы, билен яссы каеш белән буган тыгыз гәүдәле, яңаклары эчкә суырылган шакмак битле берәү басып тора иде. Сагайкин аның киеме белән йөз кырыслыгы бик тә туры килүен, тик иләмсез зур башында, пеләше тирәли бөтеркәләнеп үскән сары йомшак чәченең генә тышкы кырыслыгы белән ятышмавын чамалап алды. Каршы алучының әнә шул контрастлыгы аңа ни өчендер үтә дә таныш кебек тоелды. Газапланып, күргән-белгән кешеләрен, танышларын күңеленнән барлады, әмма очрашу артык хәвефле булгангамы, ул аны бер ничек тә исенә төшерә алмады.

Кабинетта бер өстәл, ике урындык, галәмәт дәү сейф бар, соргылт төстәге шәрә стенадан Дзержинскийның күңелгә шом сала торган портреты карап тора иде. Сагайкинны таң калдырганы сейф булды. Себер-

нең Демидов заводларында эшләнгән бик зур һәм авыр бу сейфның ишегенә сәмруг кош сурәте төшерелгән иде, Россиянең капиталистлары өчен дип ясалган шул сейф хәзер большевикларга хезмәт итә, бәлки әле анда Сагайкинның язмышын кыл өстенә куярлык документлар ятадыр.

Каршы алучы Сагайкин белән исәнләшергә ашыкмады, буш урын да тәкъдим итмәде, ач яңаклы усал йөзендә балкып янган коңгырт күзләре белән корбанына төбәлеп:

— Сагайкин сезнең үз фамилиягезме? — диде.

Бу сорау башка мылтык түтәсе белән бәргәннән ким тәэсир итмәде Сагайкинга. Ул коры җиргә чыгарылган балык сыман һава йотып:

— Бу ниткән мыскыллау, гражданин следователь? — диде, тавышының көчсез һәм әкрен чыкканын тойды. — Без потомственный Сагайкиннар. Минем бабам гомер буе Демидовлар заводында бил бөккән. Аның Алтай ахагыннан ясаган йөзекләрен чит ил корольләре киеп йөрергә кимсенмәгәннәр.

— Димәк, сез Демидов заводларының атаклы мастеры Дмитрий Ксенофонтович Сагайкиннар нәселеннән?

Сагайкин, җинел сулап, уң кулының чәнти бармагына кигән ахак кашлы зур йөзекне следовательгә таба сузды:

— Менә минем Дима бабайдан калган бердәнбер байлыгым. Үлгән чакта ул аны миңа бүләк итте. Эшче намусын күз карасы кебек сакла, тап төшермә, улым, дип әйтеп калдырды.

Сорау алучы өстәленең сул тартмасыннан зурайткыч пыяла чыгарды, Сагайкинның йөзекле кулын зур һәм кытыршы учына куеп, ахакны шул пыяла аша карады һәм, йомшак көйле тавышка күчеп, сөйләнеп куйды:

— Бар да дөрес. Дмитрий Сагайкин эше бу, фальшивка түгел. Аның икенче пары менә бездә саклана,— дип, сейфтан шундый ук йөзек алып, Сагайкинга күрсәтте.

Ксенофонт Ивановичның эченә өмет уты керде. Эшне йөзектән башлап дөрес итте бит әле ул, шайтан алгырысы! Котыла ул, котыла болай булгач. Ул, нурланып киткән күзләре белән, азатлык өмет итеп, сорау алучыга карады һәм бөтен тәне өшеп китте. Следовательнең йомшак һәм бер үк вакытта таләпчән нык кыяфәтеннән кинәт чамалап алды: Морозов! Эчкә баткан ач яңак, шакмак бит, йомшак сары бөдрә чәч, кара күмер булып янган күзләр. Себердәге иптәшләре аңар шушы рәсемне күрсәттеләр бит. Морозов тырнагына эләгүдән курык, йомшак җәеп, катыга сала, диделәр. Беттең син, Ксенофонт, котылу юк сиңа!

— Я, ничек, Ксенофонт Иванович, эшче намусына тап төшермисезме сез? Бабагызның исемен — Ксенофонтны лаеклы йөртәсезме?

Сагайкин сыртына камчы төшкәндәй җыерылып:

— Моңарчы тап төшергән булмады, гражданин следователь, — диде. Тынып хәл җыйгач, өстәп әйтте: — Аңлы рәвештә тап төшергәнем юк. Ну... кеше тормышында төрле хәл булуы мөмкин. Әгәр... ялгышкан булсам, гаебемне каным белән юарга әзер.

— Да-а... Юарга туры килмәгәе, Ксенофонт Иванович,— диде Морозов, үзалдына сөйләнгәндәй, һәм шундук допрос тонына күчте: — Колчакта ничә ел хезмәт иттегез?

Аның сораулары шул кадәр дә көтелмәгәнчә иде, Сагайкин бу юлы да үзен баш түбәсенә мылтык түтәсе белән бәргәндәй хис итте.

— Хезмәт иткәнем юк.

— Беркайчан дамы?

Сагайкин, Морозовның яссы киң каешына тагылган наган кабурасына төбәлгән хәлдә, хәтеренә яшен кебек сызылып калган бер вакыйганы күңеленнән кичерде. Колчакта хезмәт иткән чагында кызыллар аның өч иптәшен аттылар. Ксенофонт Иванович әнә шул хәлне Совет властена беркайчан да гафу итми, революция аның биографиясендә өч кешенең

канлы ярасы булып ята, ул моны түләтергә дип кылыч үбеп ант иткән иде.

Коралдаш иптәшләрен — янып торган өч поручикны янә бер мәртәбә күз алдыннан үткәргәч, Сагайкинның башы әйләнеп китте. Нинди егетләр иде бит! Кызыл командирларны, авызларыннан папиросларын да алмыйча, кылыч белән буйга ярып чыгара алалар иде.

— Димәк, беркайчан да? — дип кайтарып сорады Морозов.

— Беркайчан да! — диде Сагайкин, күзен дә йоммыйча.

— Ярый, шулай дип яздык.— Морозов азакка дип саклап килгән козырен уенга кертер вакыт житте дигән фикергә килде. Әгәр комсомолец Фәхриев үлемендә бу кешенең катнашы булмаса, ул көтелмәгән хәбәрдән сискәнеп китәргә, катнашы булса, тыныч кан белән каршы алырга тиеш. Димәк, ул аны белә дигән сүз.

Морозов эшне кечерәк бер эксперименттан башлады. Урыныннан торып, өстәлнең бу ягына чыкты, Сагайкинның каршысына ук килеп, папирос кабызды, ләкин гаепләнүчегә папирос тәкъдим итмәде: затлы нәселдән булса, Сагайкин папирос сорап түбәнсенмәс. Сагайкинның котырып та тартасы килә башлады, папирос төтене аның барлык ихтыярын бары тик шул төтенгә генә юнәлтте, ләкин ул түзде, хәтта төкерек йотканын да сиздермәскә тырышты. Морозов коңгырт күзләренең балкып торган карашын бер генә минутка да аңардан алмыйча, гүя ки аның хәленә кереп, дусларча әйтте:

— Эшегез хөрти сезнең, Ксенофонт Иванович. Постройком секретаре буларак, бәйрәм сезнең җаваплылыкка тапшырылган булган. Ә сез аны... җимергәнсез. — Пауза ясап торды, Сагайкинның хәвефле елтырый башлаган күзләренә туры карап һәм аның борчыла башлаганын сизгәнен белдереп: — Менә ни өчен без сезне кулга алдык,— диде.— Сезгә эшчеләр сыйныфы алдында җавап бирергә туры киләчәк.

— Әллә... ул-бу булдымы?

— Комсомолец Фәхриевне үтерделәр. (Сагайкинның йөзендәге бер генә тамыр да селкенмәде.) Ә бу хулиганнар эше түгел. (Сагайкинның сул кашы тартылып куйды.) Без үтерүчене тоттык. (Сагайкинның битенә шаулап кан йөгерде.)

— Кайда ул? — диде Сагайкин, үзе дә сизмәстән.

— Тиешле урынында, Ксенофонт Иванович. Сез соңга калдыгыз?

— Ничек?

— Менә шулай. Эшчеләр сыйныфы сезгә моны гафу итмәс.

Сагайкин башын түбән иде.

Морозов өстәл кырыендагы кнопкага басты. Ишек төбенә кереп баскан яшь кенә чырайлы конвойга:

— Ксенофонт Иванович Сагайкин, җинаять составы булмау сәбәпле, конвойдан коткарыла. Расписка белән алынган әйберләрен кайтарып бирегез, — диде.

Гаепләнүче чыгып киткәч, Морозов телефоннан бүлек башлыгына шалтыратып, Сагайкинны иреккә чыгаруын һәм аның артыннан күзәтүчеләр куюын хәбәр итте.

Аның максаты үтәлгән иде. Сагайкинга ул аның ГПУ кулында икәнен төшенердәй ике усал сорау бирде, Фәхриевнең үлемен хәбәр итеп, бүренең сарык тиресен салдырды һәм бүген булмаса иртәгә яңадан кулга алыначагын төшендереп чыгарды. Сагайкин хәзер ничек кенә булса да иптәшләре белән бәйләнешкә керергә тырышачак, үлем агониясе аны аек акыл белән эшләүдән мәхрүм итәчәк.

Күрше камерада Петр Шалага утыра. Фәхриев үтерелгән сәгатьләрдә аны тайга сукмагыннан тотып алып кайттылар. Аңардан ике яклы финка табылды. Чагыштырып карагач белделәр: Фәхриевне үтергән пычак моның адашы, алар икесе дә тимерчелектә, бер кулдан ясалган-

иар иде. Допроста Шалага белән нәзакәтләнеп маташмады Морозов: ике пычакның икесен дә янәшә куеп, аныкымы икәнен сорады. Кеше гомере белән бик ансат уйнаса да, үз гомере дигәндә, җәза алуга Шалага шактый сыек булып чыкты. Күз яше белән елап, үзен исән калдыруларын сорады, башлыклары Сагайкин икәнен, аның кул астында унөч кеше эшләвен, аларның кайдадыр тайга эчендә яшәүләрен, тик Сагайкинның аларны бергә очраштырмавын, берәм-берәм генә чакырып задание бирүен әйтеп салды.

Морозов Сагайкин белән Шаланы икесен дә ирекккә чыгарырга карар кылды, тик, алар күрешә алмасын өчен, Шаланы бер-ике сәгатькә соңгарак калдырып чыгарды. Ирекккә чыгучыларның кайсы да булса берсе тайгадагы отрядны эзләп китәчәгенә ул шикләнми иде.

22

Көрәш ике яктан да кискенләште.

Сагайкин ирекккә чыгу белән үзе өчен бер нәтиҗә ясады. «Эзгә төште болар. Мине юри чыгарды Морозов. Группаны эзләп табып хәбәр итсен дип. Эзләми торсын, эзләгән диярләр. Үлсәм үләм, әмма үз дигәнемне итеп үләм. Ардуанов бригадасына, Фәхриевне татар булганы өчен үтерделәр, дигән коткы салырга кирәк. Руслар эше дип уйласыннар. Бригаданың иң ярсыган чагында Ардуановның үзен юлдан алып ташларга. Коткы татар-башкортларны ярсытыр, Ардуановның һәлакәте, хәбәрнең дөрес икәнен раслап, ялкынны пожарга әйләндерер. Күрербез, большевик әфәнделәр, дуслык дип мактанган ныгытмагыз нинди комнан өелгән икән!»

ГПУ тарафыннан бик азга гына бирелгән ирекнең һәр минутын дөрес файдаланырга кирәк иде. Төп эшне Сираев аркылы эшләтү хәерле булыр. Ике ел эчендә ул аның холкын бик яхшы өйрәнде, төзелешкә ник килеп чыгуының да сәбәбен ачыклады. Совет власте кулакны каты, нык**л**ы салым белән кыса башлагач, Сираев авыл Советында эшләгән баҗасыннан гади бер крестьян булуы турында белешмә алган да самосвалкага килгән. Аның Ардуановтан аласы үче бар. Ниндидер бер грузчик герой булып йөри, ә бит Сираев герой булырга тиеш иде. Культуралы, белемле завод хуҗасы булырга хыялланган бит ул. Ардуановка булган нәфрәте Сираевның күзен сукырайтачак.

Башка вакытта булса, Сираевка бик сак кына, хәйлә белән генә якынаер иде Сагайкин, хәзер вакыты ул түгел, я баш, я мал методы белән эшләргә туры килә. Шунлыктан ул Сираев белән кичен түгел, көпә-көндез, аулакта-мазарда түгел, үз кабинетында очрашуны кулай күрде һәм кеше җибәреп чакыртып алды. Сираев аның кабинетына эш киеменнән — бетонга каткан кәҗәннән, брезент бияләйләрен путасына кыстырып, дагалы күн итекләре белән каты-каты басып килеп кергәч, постройком секретаре аның белән юньле-башлы исәнләшеп тә тормастан, кычкыра башлады:

— Бу ниткән безобразие, Сираев? Сез нәрсә карап йөрисез? Нәрсә авызыгыз белән кош тотасыз? Ярышка чыккансыз икән, ярышташыгызның иминлеге өчен дә кайгыртырга кирәк түгелмени? Ниндидер бәйрәм уйлап чыгаралар. Сабан туй, имеш! Ә азагы өчен кем җавап бирә? Эшче сыйныфының нахакка аккан хәләл канын нәрсә белән түлибез?

Сираев моның театр уены икәнен, күрше кабинеттагылар ишетсен өчен эшләнгәнен белә иде. Постройком секретарен ул кашларын җимерел, каршы сүз дәшмичә, сабыр гына тыңлап торды, ләкин Сагайкинның ишекле-түрле йөреп, өстәл төя-төя җикеренүе озаккарак киткәч,

житмәсә, бер-бер артлы ике кеше ишектән башын да тыгып карагач, түзмәде:

— Житеп торыр булмаса, Ксенофонт, эшкә кучик, — диде. — Сине ничек чыгардылар?

— Чыгармаслар иде, дәлилләре юк.

Сираев, ирен чите белән елмаеп, ышанмыйчарак карап торгач:

— Йомышыңны әйт тә, мин китим, мине бригатта көтәләр, — диде.

Сагайган шыпыртрак тавышка күчте:

— Ардуановны йомарга кирәк.

Сираев куңеленнән канат какты, әмма базарын күтәрер өчен:

— Анысы минем эш түгел, — диде.

— Ә кем эше соң?

— Белмим, иптәш постройком.

Сагайкинның йокысыз үткәргән төн һәм ике сәгатькә сузылган допростан соң тузып калган нервысы кинәт котырып китте, ул өстәл тартмасыннан уч төбе кадәрле кәгазь алып, аны Сираевның борын төбендә селкә башлады:

— Күрәсеңме менә моны? Русча грамотасыз язылса да, мөһере бар бу кәгазьнең һәм монда аермачык әйтелгән: Шакир Сираев Актаныш контоны Солтангол авылының кулак малае, диелгән. Авыл Советы секретаре булып эшләгән бажасыннан ялган белешмә алып авылдан качып китте. Сәнәкчеләр фетнәсе вакытында активист Мирсәет Ардуановка каршы компания оештырды, диелгән. Син бит... әллә кайчан дар агачында асылынып торасы яки Себер тайгасында урман аударып йөрисе аю!

— Житәр. Эшкә кучик, — диде Сираев, сабырлыгын җуймыйча. Миннән нәрсә таләп итәлә?

— Ардуановны йому. Менә шул. Үзең эшлисеңме, башкасымы — анысы үз карамагыңда. Таләбеңне әйт. Сузып торырга минем вакытым юк.

— Беренчедән, китер ул кәгазьне! — Алды, ут төртеп яндырды, янган кәгазь исен басар өчен, махорка төреп кабызды.— Икенчедән, Ардуанов бу заманда бик кыйбатка йөри,— бармагын бармакка ышкып күрсәтте: — кул ялы, иптәш постройком.

Сагайкин ишекне эчтән бикләп алды, сейфның эчкәрге тартмасыннан калын гына бер төргәк алып, Шакирга сузды:

— Кара аны, эшең чиста эшләнгән булсын. Алдарга уйлый күрмә, мәче тычканны буган кебек кенә...

— Ярарсана, өркетмә. Сабый бала юк бит монда.

— Ярый, — диде Сагайкин, сүрелә төшеп, — хәерле юл сиңа, сукмакларыбыз аерылса, әшәке итеп искә алма.

— Тырышырбыз,— диде Сираев.— Сукмакларның очрашып куюы да мөмкин... — һәм дагалы күн итекләре белән каты-каты басып чыгып китте...

Сагайкинның бригадир Сираев белән очрашуын шундук Морозовка хәбәр иттеләр. Морозов хәлне бүлек башлыгына җиткерде. Үзара киңәшеп, Березникидан чыга торган юлларга, тайганың аучылар гына йөри торган аулак сукмакларына постлар куйдылар. Көне буе күзәтсәләр дә, чыгып-кереп йөрүче күренмәде. Сагайкин беркая да китәргә җыенмый, Сираевтан кала беркем белән дә очрашмый, тиресеннән чыгардай булып, төзелеш мәйданнарында чаба, Крутановның, Хангильдянның, Мицкалевичның күзенә чалынырга тырыша, очрашкан чакта ягымлы исәнләшеп, төзелеш кирәк-яраклары турында бик борчылып сөйләшә, югалып торуының сәбәбен вакытлыча килеп чыккан аңлашылмау дип кыска гына аңлата, кыяфәтенә бер нинди дә рәнҗү чыгармый, бер сүз белән әйткәндә, ГПУдан да, төзелеш җитәкчеләреннән дә хәйләкәррәк булып, гаепсез икәнен төшендерергә чамалый иде.

Ә менә Шалага үзенә «койрык тагып» чыгарылуын белсә дә, гомере өчен кан калтырап тору сәбәпле, чамадан тыш беркатлы булып чыкты. Аңар Морозов бетончылар янында күренергә әмер биргән иде, әмерне ул тәгәл үтәде, бер сәгатьләр чамасы бетончылар тирәсендә буталып йөрде, башлыгы Сагайкинны очратмаммы дип Шакир Сираевка да барып килде, әмма постройкомга сугылудан уттан курыккан кебек курыкты, поручик Сагайкин аны сатканны беләдер дигән уй җанын кимереп тора иде. Кайсыдыр бер арада үзенә тагылып йөргән «койрыкнын» юкка чыгуын абайлап алды ул, анарда бандитларга хас житезлек, үзен-үзе саклау инстинкты уянды. Ул качып китәргә, «койрыкны» өзеп калдырырга карар кылды. Башта ул, кулларын чалбар кесәсенә тыгып, сызгырына-сызгырына, тайга сукмагына таба китте. Сукмактан гамьсез генә барган булды: янәсе, аның өчен барыбер, ник хәзер үк тотып алып атмыйлар. Аннары ялт-йолт каранып алды да, күршесендә дә, алдында-артында да кеше юклыгын белгәч, сукмактан төшеп, урман куелыгына чумды. Хәзер аның күңелендә кайнар төен булып бер генә уй яши: ничек тә ычкынырга, ычкынырга, юл саташтырырга! Ә урмандагылар? Ә Сагайкин? Ник барысы чәнчелеп китми! Үз башыңны коткару турында уйла инде син, Петруся. Хәлдән тайганчы урман чытырманлыгыннан чапты, изге апостолларны искә төшереп, мышный-мышный чапты, ботаклар, авырттырып, аның битенә бәрелде, кепкасы кайдадыр сыдырылып төшеп калды, егылып тезен канатты — барыбер туктамады, котылдым дигән уй, исән калдым дигән шатлык аны гел алга куды. Ниндидер бер мизгелдә ул үзенең урмандагы землянкага таба чапканын, инде шуңа якынлашып килгәнен чамалап алды. Ул аларны сатмады, ул «легавыйларны» хәйләләде, белмим диде, хәзер аларны алып чыгарга да отряд белән бергә качып китәргә кирәк. Калганына Сагайкин җавап бирсен.

Менә житәм, менә житәм дип ашкынып, землянка сукмагына килеп чыгуы булды, аны ике атлы сакчы тотып алдылар да авызына чүпрәк тутырып, кулларын артка каерып бәйләделәр. Озак та үтмәде, атлы биш сугышчысы белән Морозов килеп житте. Засада корып, юлга чыгучыларны күзәтә башладылар.

Тәүлектән озак булып тоелган чирек сәгать вакыт узды һәм беренче кош кармакка чиертте: тайга сукмагында күн курткалы берәү пәйда булды, аны да, Шалага кебек, буып алдылар, авызына чүпрәк тутырдылар, кесәсеннән ике алтатар, бер пычак, ниндидер карта да чыкты, күрәсең, качып китәргә җыенган, тирә-юньне тикшерү өчен разведкага чыккан иде.

Кайдадыр урман эчендә ярсып кешнәгән ат тавышы урманда ятучыларның качып китәргә җыенганын раслады. Әле генә тотылган күн курткалының аркасына мылтык терәп алдан җибәрделәр, ун-унбиш минут баруга землянка күренде, землянка морҗасыннан нечкә генә булып аксыл төтен күтәрелә иде.

Морозов сугышчыларына: землянканы чолгап алырга, морҗаны томаларга әмер бирде. Әмер шундук үтәлде. Морҗа томалануга эчтә кинәт шаулашкан, сүгенгән тавышлар ишетелә башлады, землянка эчена төтен тулды бугай. Морозов револьвердан һавага атып:

— Чыгыгыз, сез чолганышта! — дип кычкырды.

23

Төн.

Күкне болыт каплаган.

Көчле прожекторлардан төшкән яктылык инде төзелеп бетеп килә торган азот-тук заводының манараларын, аркаларын, виадукларын, таш белән кирпечтән салынган саллы авыр биналарын, сферик шарла-

рын, челтәр нәкышләредәй үрелгән ажурлы мачталарын һәм ярты күккә тикле сузылган кара моржаларын — барысын бер төбәккә туплый.

Химкомбинатның фундаментын койган бетончылар, тимер араталарын ялгаган сварщиклар, катлаулы механизмнарын җыйган слесарьлар көндәлек мәшәкатьләр һәм берәмтекләп эшләгән эшләрдән нәрсә оештырганнарын белмичәрәк йөргәннәр икән. Инде менә Урал тайгасында шундый да серле, шундый да әкәмәт бер могҗиза күтәрелгәч, алар үзләре эшләгән эшнең мәгънәсен һәм зурлыгын аңлап алып, билне тагын да ныграк буып тотындылар, аларда эшче горурлыгы дигән зур тойгы тагын да зуррак булып кабынды.

Күке-паровозның бетон төяп китергәнен көткән арада Ардуанов бригадасы ялга туктаган иде. Башлап Шамук тотынды.

— Мирсәет абзый, кәрәле, Мирсәет абзый, әгәр мин Балтачларны шушында алып килеп: «Менә бу заводны мин салдым!» дисәм, ышанырлар иде микән?

— Синме? Шушы заводнымы? Ха! Әдәм ышанмастайны чын булса да сөйләмә дип әйтте ди Хуҗа Насретдин.

— Ә нигә авыз ерасың, Сибай? Әллә мин прогул ясадыммы? Әллә эшкә чыкмый бригатны хур иттемме? Заводны мин намус белән салдым.

— Син, энем Шәмсетдин, салдым дип сөйләмә, салдык,— дип сөйләш,— дип, сүзгә җай гына катышып китә Бәхтияр абзый.— Аның бит бер почмагын әнә шыпырт кына утырган Нурләхмәт абзаң салды, бер почмагын Кинъябулат белән Исәнгол юктан бар иттеләр. Әгәренки каршы килмәсәгез, бу заводта минем үземнең дә кечтеки генә өлешем бар. Шулаймы, Мирсәет кордаш?

Ардуанов елмаеп баш какты. Соңгы вакытта бригадага бетон таптарга спецовка бирделәр. Озын кунычлы резин итек, брезент куртка киеп җибәргән егетләр ике ел элек кенә чабатадан торф сазы ерганнарын онытып, башны текә тотып йөриләр. Кара син Шамукны! Гел дә менә кеше көлдереп йөргән, гел дә менә сугыш чукмары булган Шамук нишли? Авыз тутырып: «Мин завод салдым!» — ди. Бу инде, туганкаем, уен эш түгел сиңа. Эшче кеше, пролетар сыйныфы туды аның сезончы грузчикларыннан. Дөрес әйтә Шамук: ул завод салучы! Нәбиулла Фәхриевка дошманнар юкка каныктымыни? Эшче кешенең зурлыгын белеп, иске дөньяны җимерергә килгәнлеген белеп каныктылар.

Нәбиулла исенә төшкәч, Ардуанов ыңгырашып җибәрер дәрәҗәдә сыкрап, тешен кысты һәм, егетләрнең сүзне шул темага борып җибәрүләреннән куркып, урыныннан кузгала башлады.

— Кара әле, кордаш, Сагайкин дигәннәре Колчак офицеры булып чыккан диме? Ишеттеңме син ул турыда? — дип, тагын җай гына сүзгә керешеп китте Бәхтияр Гайнуллин.— Дөрес булса, безнең Нәбиулланы үтерүчеләр дә шулар ди бит. Ун кешеме ди алар, унбишме, тайгада землянка корып, шайка булып җыелганнар диме? Постройком булып, акыл сатып йөргән булды бит, аждаһа!

— Аларны тотулары дөрес. Нәрсә эшләгән алар, пака белмибез, менә суд булыр, тикшерерләр, шуннан соң безгә дә әйтерләр, кирәк тапсалар, язып та чыгарлар,— диде Ардуанов.— Әнә безнең кукушкабыз килде, бетон катканчы бушатып бетерергә кирәк.

Күке-паровоздан бетон ташырга тиешле егетләр такта юлдан буш тачкаларын дыңгырдатып чаба башладылар.

Шамук әле һаман Ардуанов яныннан китәргә теләмичә, аның яныннан юыртып барган көйгә:

— Мирсәет абзый, дөрес булса, корткычлык шайкасында... дөрес булса, Шакир Сираев та катнашкан, диләр, Ә нигә ул иректә йөри, ә нигә аны ябып куймыйлар? — диде.

Ардуанов сәерсенеп тукталып калды, кепкасын күз өстенә таба шудырып, башын кашып торды:

— Менә анысын әйтә алмыйм, туганкай, ник дип әйтсәң — белмим: Шакир бик сак кеше, андый шайкага катнашыр микән?

Шуның белән сүз бетте.

Платформага килеп җиттеләр. Күке-паровоз бер вагонга төяп икешәр кубометрлы сигез чан алып килгән иде. Ардуанов беренче чанның эшермәсен ике куллап, чәрәшеп торып ачты да иң алдан килеп тукталган Сибай тачкасына бетон агыза башлады, аннары бу эшне Бәхтияр абзыйга тапшырып, үзе котлованга ашыкты.

Котлован тирән, бетонны улактан агызып төшерәләр, астагылар аны көрәк белән котлованның аргы почмакларына тикле таратып, тигезләп йөриләр, арматур челтәрендә һава калмасын өчен ныгытып таптыйлар иде.

Ярты сәгать чамасы эшләгәч, өстә эш барышын күзәтеп торган Мирсәет абзыйны кәҗән башлыгын күз өстенә үк төшереп кигән таныш түгел берәү чакыра килде:

— Мастер, казага тарыдык! Бетон бөялде. Тизрәк, тизрәк!

— Кайда? — диде Мирсәет абзый, ачыкларга теләп.

— Әнә анда! Әнә теге башта.

Котлованның аргырак почмагында бер төркем кеше өелгән, алар нидер әйтеп кычкыралар, тиргәшәләр, ни кычкырганнарын аңлап булырлык түгел иде.

Ардуанов кешеләрне аралап килеп чыкты да:

— Кайда? — диде.

— Әнә тегендә, аргы башта! — диде берничә тавыш берьюлы. Аргы башка котлован өстенә сузып салган дүрт кырлы бүрәнә — өрлек аркылы гына чыгарга мөмкин иде. Бөялеп торган бетонның ярты сәгать эчендә бернигә ярамаслык булып катып каласын белгәнгә, Ардуанов икеләнеп тора алмый иде. Ул өрлек аша чыга башлады: кулларын кош канаты кебек җәеп, тигезлек саклап барды. һәркем үз эше белән мәшгуль, аңа игътибар итүче юк иде. Ардуанов аска карамаска, өрлекне тизрәк үтеп китәргә тырыша, чөнки аста аркылы-торкылы тимерләр, арматур оялары белән челтәрләнгән упкын ята, бригадирның аз гына саксызлыгы да аны упкынга мәтәлдереп җибәрүе мөмкин иде. Матчаның аргы башына, бетон бөялеп торган урынга килеп җитә башлагач, ул иркен сулап куйды, әмма шул ук мизгелдә дошман тозагына эләккәнен сизеп алды, кире борылырга өлгергәнче астан кисеп куелган матча чатырдап уртадан сынды да, Ардуанов, канаты каерылган кош кебек, бер якка авышып, тимер-томырлар өстенә, упкынга очты, аның артыннан ук бөялеп торган бетон убылып төшеп китте.

## 24

Бу ниткән әкәмәт?! Ай күк йөзеннән җиргә төшкән, тегермән ташы чаклы сары түгәрәк булып Актаныш болынынннан тәгәрәп йөри, сикерепсикереп китә, аның тышкы ягы шундый кытыршы, шундый суык, ялан аяклап болыннан чабып йөргән Мирсәетнең ул битләренә, кулларына бәрелеп китә, бәрелеп киткән чакта кычкырып җибәрерлек итеп авырттыра. Мирсәет уң кулын янтыгына кысып тоткан, түгәрәк-сары-кытыршы ай кагылудан курка. Ул да түгел, ай әкрен генә җирдән куба, тәлинкә кебек кечерәя, аннары күздән югала, югала, югала... Ут кебек кызу, болын чәчәкләре төсле аллы-гөлле бер юл сузыла. Очсыз-кырыйсыз юл. Салават күпере түгелме соң бу? Ялан тәпиле Мирсәет белән ялан тәпиле Шакир салават күпере өстеннән баралар, гәүдәләре кавырый кебек җиңел, битләренә салкынча җил бәрә башлый. Алар Шакир

белән икәү баралар да баралар, баралар да баралар, бер-берсенә әйләнеп тә карамыйлар; бара торгач, салават күпере юкка чыга, алар болытка утырып баралар, Шакирның чәчләре озын, ике толым, әнә шул ике толым чәче белән ул, икедән үргән камчы кебек итеп, Мирсәетнең битенә чаж-чож китереп суга, Мирсәет битен куллары белән каплый, ләкин барыбер котыла алмый, Шакир аны сөлге белән биленнән урап ала, кисмәк кыршаулаган кебек итеп кыса, Мирсәетнең кабыргалары сытылып әчкә керә, һәм ул, авыртуга түзә алмыйча, ыңгырашып күзләрен ача...

Өстенә үк иелеп торган бер хатынны күрә, битенә аның кулы килеп орынуын һәм аның тавышсыз гына елаганын абайлый, шуннан соң тагын печәне чабып алынган Актаныш болынында зур күн итекләр киеп, авыр кәжәннәр киеп, кулына көрәк тотып әрле-бирле йөргәнен сизә, бу бит чын түгел, бу бит төш димәкче була, сүзен әйтә алмый. Төш түгел бу, өн бу, әнә бит айны ул икенче мәртәбә күрә, ай зур, тегермән ташы чаклы, ай якты, күзләрне чагылдырырлык якты, болын өсте аның нурыннан көмеш тәңкә белән тулган. Шәбез елгасы да агарып ага, эшлия-чуклар белән бизәлгән атлы арбалар бара, арбадагылар, йөзләре белән арбаның эчке ягына карап бер-берсен билләреннән алып утырганнар, баш өстендә чалгылары ялтырый, Шәбез болынында тәгәрәп йөргән ай әллә кая киткән, чалгылар барыбер ялтырый, юл зур бер өрлек булып завод котлованы аркылы сузыла, арбалар канатларын әле уңга, әле сулга янтайтып, матча өстеннән баралар. Кисәк-кисәк җил исә, битләргә рәхәт бәрелә, кулны, муенны, кабыргаларны авырттыра башлый, һава кыза, печәннәр кызыл төскә керә, битне ялкын өтә башлый һәм ул янып үлүдән куркып, ыңгырашып җибәреп, күзләрен ача. Аның янында ак яулыклы, зәңгәр күзле бер хатын утыра. Ник утыра ул хатын? Аңар ни кирәк?

Тагын икеме-өчме тапкыр утта янып уянганнан соң ул гел дә янында китми утырган хатынның Мәүгыйзәсе икәнен аңлап ала, күңеле тынычланып йоклап китә, бик озаклап, онытылып йоклый. Күзләрен ачкан чакта аның янында ак халатлы, дәү борынлы, көйләп сөйләшә торган кеше басып тора, аның Мәүгыйзәсе юк.

Ак халатлы аның бәйләнми калган кулын беләзек турысыннан кысып тотып, сәгатенә карап нидер саный һәм авызын җәеп елмая.

— Та-а-ак, так-так! Яшибез без, яшибез, күгәрченкәем. Кризисны уздырдык без. Дошманнарга үч итеп яшибез. Безнең организм беләнме? Безнең организм белән өч кабырга сыну нәрсә ул!

— Нәрсә, доктор, минем кабыргаларым сынганмыни?

— Без аларны ямадык, Ардуаныч. Ямадык без аларны. Кабырганы да, кулны да ямадык, ә менә умрау сөяге озаграк ялганыр. Әйдәле, дару эчеп алыйк әле без, менә шулай! Бик яхшы, бик яхшы, Ардуаныч. Ачымы? Ачы! Димәк, шәп.

Әкренләп, зур кыенлык белән Ардуанов тормышка кайтты. Беренче көннәрне аңар кыен иде. Гомер буе эш эшләп, берәүнең дә кулына карамый, үз дигәненчә яшәп өйрәнгән кешегә, Идел грузчигына, сестралар кулыннан гына түгел, хәтта хатыны Мәүгыйзә кулыннан ашау да кыен иде, гарьлекле иде, ләкин ни хәл итмәк кирәк, син инде исән калгансың икән, син әле башланмаган зур эшләргә кирәк икәнсең, тарих сине дошманнар мәкереннән эшче-крестьян властенең табиплары, врачлары кулы белән алып калган икән — син яшәргә тиеш. Дөрес, син, ике метрлы гәүдәң белән, сабан туйларында әллә ничә төбәккә батыр калган куәтең белән менә хәзер, ак марляга уралган хәлдә, бишектәге сабый бала төсле ятасың; кереп йөрергә рөхсәт ителгәннән соң, бригадаңнан җыелып килгән егермеләп егет синең хәзерге хәлеңне күргәч, тетрәп китте, Бәхтияр кордашың тавышсыз гына күз яшьләрен түкте; Шамуклар, Сибайлар, Исәнголлар иреннәрен тешләп,

аның елап бетергәнен көтеп тордылар. Аларга еларга ярамый иде. Аннары алар синең янында бик озак утырып тордылар, синең хәлеңә иләшеп җиткәнче, үзләрен синнән өстен итеп сизми башлаганчы утырдылар, ник дисәң, алар сине остазлары, киңәшчеләре, әтиләре итеп күрергә өйрәнгәннәр иде бит.

Алар синең әнә шул сабый бала кебек уранган хәлдә дә сөйләшә ала, мыекларыңны дерелдәтеп көлә ала, киңәш бирә ала икәнеңә тәмам ышангач, күңелләрендә йөрткән уйларын да әйтеп бирделәр.

— Мирсәет абзый, ә нигә ул корткычлар — муеннары асларына килгере, күзләре чәчрәп чыккыры! — нишләп алар гел безнең бригатка гына каныгалар?! Аларга бүтән кеше беткәнмени? Әллә безне татар дип басымчак итәләрме? — диде Шамук, өзгәләнеп.

Бәхтияр абзый Шамукны куәтләп алып китте:

— Менә без, кордаш, уйлаштык-уйлаштык та шундый бер фекергә килдек. Әгәренки, дидек, Мирсәет кордаш исән-сау булып, безнең белән сөйләшер хәлгә килгән булса, дидек, без аңардан барыбыз берьюлы киңәш сорарбыз, дидек. Менә Сибай да, Зариф та, Каюм да, башка егетләребез дә бу хәлләрнең барысын бәйнә-бәйнә сөйләп, газиткә язып чыгарга кирәк дип әйтәләр. Аллаһы боерган булса, язарбыз да, сөенмәсен дошман. Боларның котларын ботларына төшердем дип канат какмасын! Безнең кот бот тирәсендә түгел, югарырак икәнне дә белсен. Без бригат башыбыз Ардуановка булган һөҗүмгә каршы ударный эш белән җавап бирергә булдык!

— Дошман менә тотсын учлап-боргычлап! — дип өстәп җибәрде бер читтәрәк дәшми утырган Нурләхмәт, җебеп киткән борынын тартып.

— Чү, чү, балакайлар... диде Ардуанов, аннары тешен кысып, күз яшен тыеп, озак кына дәшми ятты.

Тагын бер атнадан аның хәлен белергә Зөлхәбирә килде. Янакларын ябып ук бөркәнгән кара-кучкыл яулыктан иде ул, шундый ук кара-кучкыл, куе зәңгәр төстәге күлмәк өстеннән ак халат салып кергән иде. Палата ишегеннән кергәч, идәнгә кадакланган кебек, бер урында таптанып торды, йончыган, хәсрәттән тоныкланып калган аксыл йөзенә караватта ап-ак булып яткан Ардуановны күрүгә куе кызыллык бәреп чыкты, тотрыксыз адымнар белән караватка тикле килеп житте дә, көне буе җыйган кыр чәчәкләрен кая куярга белми, кулында тоткан килеш, каушап калды. Керфекләрендә күз яше тетри иде, кинәт карават кырыена утырды, сүзен дә әйтә алмастан, Мирсәет абзыйның башын ике кулы белән кочаклап, кайнар күз яшен аның битенә, иреннәренә, мыегына коеп үксеп елап җибәрде. Ничәмә көннәр түзгән, сабырлыгын җыеп, ныгып килгән Мирсәет абзый булып ул да түзмәде, Зөлхәбирә белән бергә, ирләрчә мул күз яше белән тавышсыз гына елады.

Еларга хаклары бар иде аларның. Нәфуш-Сайрар кош икесенең дә газизе иде. Зөлхәбирә белән Мирсәет абзый бер-берсенә укытучылар, берсе грамотага өйрәтсә, икенчесе тормыш ныклыгына өйрәтә иде.

Елап туйгач, алар, тормыш дигән үги әнкәләре кыерсыткан нәүмиз балалар кебек, тынып калдылар. Зөлхәбирә Мирсәет абзыйның күзләренә карап озак утырды, әйтерсең азаккы минутларында бу батыр кешедән, бер генә нәрсәдән дә, бер генә эштән дә, хәтта авыруыннан да зарланмаган кешедән ул ныклык запасы алып китәргә тели иде.

— Мирсәет абзый... син рөхсәт итсәң... мин инде Березникидан китәр идем. Бик авыр бит миңа монда. Бер генә минутларга да исемнән чыкмый бит ул минем. Төшләремә керә, көлә-көлә урманнарда йөрибез. Кулларны тотышып йөрибез. Төнлә мин аны кояш итеп, ай итеп, йолдызлар итеп күрәм. Йа раббы, нинди сөенечләр белән керә ул минем төшемә! — Кулларын кушырып, озак кына идәнгә карап утырды, тагын тулышып киткән күңеле белән тартыша, олы агасына күз яшьләрен

бүтән күрсәтмәскә тели иде бугай.— Әйт, Мирсәет абзый, син ни дисәң — шул булыр.

Ардуанов аның, Нәфүсне искә төшерү сәбәпле, мәк чәчәге кебек кабынган, күңел тетрәтерлек чибәр йөзенә, моңсу күзләренә карап торгач, ифрат та үз итеп, якын күреп, аның әхлакый зурлыгына ышанып әйтте:

— Күңелең кушканча эшлә, балам. Берәү дә сине гаеп итмәс.

Алар, бер-берсен сүзсез генә аңлап, тагын бер кавым утырдылар. Аннары Зөлхәбирә китәргә җыена башлады. Мирсәет абзый аны бүтән кыстамады. Тик әйтә алмый калудан курыккандай ашыгып:

— Минем дә сиңа бер үтенечем барые бит әле, Зөлхәбирә,— диде.— Беләсеңме, егетләр килде миңа, гәҗиткә язасы сүзебез бар, диләр, син безнең бригатның күзен ачтың, теләкләре теләк килеш кенә калмасыные, булышсаң ие син аларга.

— Кулымнан килә торган булса, булышырмын, Мирсәет абзый. Ярый, сау бул, терел. Мәүгыйзәттәйгә миннән сәлам диген. Җае чыкса язармын, яза алмасам, онытты дип үпкәләмәгез, яме.— Куллары белән ике битен басып, бит очларының уттай януыннан оялгандай, әкрен генә баш иде һәм ашыгып чыгып китте.

Ардуанов, ул киткәч, йөрәгенең бер чите кителеп төшкәндәй, тынсыз калып, бик озак түшәмгә карап ятты...

Аны больницада тагын ике ай чамасы тоттылар. Хәле яхшырган саен килүчеләр күбәйде. Хангильдян белән Мицкалевич килеп, бригададагы эшләрнең яхшы баруын, бригада белән хәзергә Исәнгол Юлдыбаев җитәкчелек итеп торуын, егетләрнең Ардуанов исеменә турылыклы булуларын, бер генә мәртәбә дә тәртип бозмауларын, бөтен төзелешкә үрнәк күрсәтеп баруларын иренмичә, җеп бөртекләп сөйләп, Мирсәет абзыйга дәрт өстәп киттеләр. Аз гына вакытка Крутанов кереп чыкты, Ардуановлар гаиләсенә Бишьеллык урамыннан ике бүлмәле квартир бирелүе турындагы ордерны күрсәтеп һәм «Социализм юлы» газетасында басылган бригада егетләренең мәкаләсен калдырып китте. Мәкалә үтерүчеләргә карата ачы нәфрәт хисе белән ярсынып язылган иде. Мирсәет абзый янә бер мәртәбә Зөлхәбирәне искә төшерде, Кадерматова әйткән сүзендә торган, күңелендә кайнаган барлык уен-тойгысын, иске дөнья ялчыларына карата җанында саклаган ачы нәфрәтне бригада егетләре исеменнән әйтеп биргән иде. Шушы ут кебек кайнар, ярсу тойгыларны раслап бригаданың 116 кешесе кул куйган иде.

Үтәр еллар, агар сулар — бу документ утызынчы еллар комсомолының үзләреннән соңгы буыннарга әйтеп калдырган васыяте булып саклаңыр. Хәзергә ул, мылтык көпшәсенә куелган кайнар пуля кебек, газета битендә ята һәм Ардуановны, Зөлхәбирәнең моннан ике айлар элек үзен күреп сөйләшкәндәге кебек, тәүге көче белән дулкынландыра иде.

## 25

Август көне сүнеп бара иде. Кама буена, зур пароходлар рәтләп сәлам дә бирми китә торган бәләкәй генә пристаньга халык килеп тулды. Шаулыйлар, бәхәсләшәләр, төркем-төркем җыелып, тәмәке төтәтәләр, вакыт-вакыт көлү өянәге тирә-якны дер селкетә, ләкин озакка бармый, кинәт кабынган кебек кинәт сүнә һәм халык арасында эреп югала. Куера барган кичке эңгердә кешеләр күңелендә бер уй яши: нарком килә. Авыр промышленность халык комиссары Орджоникидзе. Нindирәк икән ул? Нинди изге уй белән йөри?

Наркомны каршы алырга килгән делегациядә Мирсәет Ардуанов та

бар. Ул кычкырып көлми, пароход шактый соңга калса да, борчылуын, башкалар кебек, кычкырып әйтми, аның күңелендә хатыны Мәүгыйзә яши.

Җир өстенә караңгылык иңә башлады инде. Кама өстендә маяк утлары кабына, пароход әле һаман юк. Мирсәет абзый түзмәде, делегация башлыгы Крутанов янына килеп:

— Никифор Степанович, булмаса, мин кайтыйм әле...— диде.— Хатын больницада минем.

— Больницада? Ни булды?

— Бала табарга киткән иде. Ардуанов, уңайсызланып һәм бер үк вакытта күңеле нечкәреп, төзелеш башлыгына карады.

— Авыр мәсьәлә бу, иптәш Ардуанов. Китмә дисәм, сәбәбең зур, ата кешене рәнҗетүдән куркам, кит дисәм — беренче ударниктан башка наркомны каршылау килешерме? Авыр мәсьәлә, иптәш Ардуанов.

Мирсәет абзый икеләнә иде әле, ул арада халык шаулаша, ташкын булып пристань дебаркадерына агыла башлады. Ул да түгел, Крутанов, Мирсәет абзыйны кулыннан эләктереп, үз янына тартып алды, делегация барачак юлга алып китте.

«Камский водник» дип, исеме ак буяу белән язылган бер палубалы бәләкәй пароход пристаньга туктап, мәңгерәп кенә кычкыртып куйды.

Матрослар җәлт кенә басма суздылар.

Пароходтан башта хәрби киемле өч егет чыкты, алар артыннан ук, урак-чүкечле фуражкасын баш өстендә болгый-болгый, кәҗән чабуларын җилфердәтеп, Орджоникидзе басмага килеп керде. Аны рәсемнәрендә күреп гадәтләнгән күперенке зур кара мыегыннан таныдылар. Ул шундый тиз атлый, коридор калдырып ике якка тезелгән халык төркеменә баш ия-ия, адәм ышанмастай бер ихласлык белән елмаеп-балкып килә иде ки, пароход көтеп үткәргән борчылу минутлары шундук юкка чыкты.

Орджоникидзе, делегация кешеләре белән кул биреп күрешә-күрешә, Мирсәет абзый янына да килеп җитте. Крутановның:

— Төзелеш ударнигы Ардуанов,— дип тәкъдим итүе булды, Мирсәет абзыйның сөялле дәү кулын нарком үз учына эләктереп алды. Ардуанов кабынып китте, яратып аның кулын кысты. Орджоникидзе очкынлы кара күзләре белән аңа төбәлеп, һәм авырткан кулын шаяртып селкеп:

— Химия ышанычлы кулларда,— диде.

Ул Ардуановны җилкәсеннән җиңелчә кочаклап, эшен-тормышын сорашып барды. Аннары, гафу үтенгәндәй, баш кагып, Мирсәет абзыйдан аерылды да сорауларны Крутановка яудыра башлады.

Автомобильгә утырып юлга чыктылар. Калкурак урынга күтәрелгәч, Орджоникидзе, аның белән бергә делегация членнары машинадан төште. Күрәсең, наркомның комбинатны ерактан ук күрәсе килгәндер. Ул, комбинат ягына карап, баскан урынында тын калды.

Алар каршында җирне-күкне иңләп, комбинатның беренче чираты — азот-тук заводының гигант силуэты күренә. Кап-караңгы күк йөзендә, йомгак-йомгак бөтерелеп, кайнап, ургылып, аксыл төтен югары менә. Комбинат морҗаларын төн карасы йотканга, төтен төтен булып түгел, һавада очып йөргән аждаһа булып күренә, күкерт цехы өстендәге сары ялкын әйтерсең әкият аждаһасының авызыннан бөркелгән ут иде.

Орджоникидзе тирән итеп бер сулады да, киредән машинага кереп утырды.

Крутанов аңардан җитди генә сорады:

— Бүген ял итәсезме, Григорий Константинович, әллә туп-туры заводка барабызмы?

Орджоникидзе көлеп җибәрде һәм балаларча шукланып:

— Ялны оныттык, иптәш Крутанов. Заводка алып барыгыз,— диде.

Азот-тук заводында ярты сәгать чамасы йөрделәр. Цехларда җыелып алынмаган тимер-томыр аунап ята, почмакларга чүп өелгән иде. Орджоникидзе цехтагы эшчеләрне үз янына җыеп алды, аның авызына керердәй булып тыңлаган баш инженерга карап түгел, нәкъ менә эшчеләргә карап, кулларын бик хәтәр бутап, ләкин йөзенә ачулы кыяфәт чыгармыйча гына:

— Производство культурасын күтәрергә кирәк, иптәшләр, — диде. — Беләсезме, Европада нәрсә диләр: хезмәт дисциплинасы белән производство культурасы — эшнең төп уңышы. Культурасызлык — безнең беренче дошманыбыз. Ул безне эленке-салынкы йөрергә өйрәтә. Культура, иптәшләр, культура!

Сәгать инде уннар тирәсе иде. Орджоникидзе ТЭЦка алып барулары үтенде. Станцаны карап-барлап чыкканнан соң, делегация белән бергәләп, төтен суырткычны карады, түбәгә менде. Түбәдә калын сайгаклар өстенә төтен суырткычның ремонтка дип сүтеп ташланган тимерләре тезеп салынган иде.

Орджоникидзе мыек астыннан көлемсерәп куйды:

— Түбә җиһаз кую өчен ябыламыни?

Баш инженер, уңайсызланып, аңлатма бирә башлады:

— Механизм булмау кулны тота, иптәш Серго. Йөк күтәрүче краныбыз юк, шундый авыр тимерләрне аска нәрсә белән төшереп, нәрсә белән менгезәсең? Вакытлыча түбәгә куеп торырга туры килде.

Орджоникидзе әрдәнәләп өелгән җиһазлар янына килеп, уйчан гына карап торды, башын чайкады, аннары авыр көрсенеп әйтте:

— Әйе, үкенечкә каршы, эшкә иң кирәкле, иң элементар механизмнарыбыз юк әле. Тизрәк үзебезнең техниканы булдырырга кирәк, производство өчен уңайлы, эшне тизләтә торган механизмнарны!

Ардуанов наркомның үз-үзен тотуында таләпчән бер гадилек сизде. Орджоникидзе — өйрәтми, акыл сатмый, үзен уратып алган эшчеләр, җитәкчеләр белән бергә, Березникидагы яңа эшләрне күздән үткәрә; берәр нәрсә күңеленә хуш килгәндә күперенке зур мыегы бөтен битен тутырып җәелә, тирә-якка күзләреннән нур көлтәләре чәчелә, җитешсезлек күрсә, мыек очлары түбән салына, эшчеләргә дә, җитәкчеләргә дә үз фикерен ул өзеп кенә әйтеп бирә иде.

Икенче көнне сода заводында йөргәндә Ардуанов аның сүзсез калуын, еш кына көрсенеп, баш чайкап куюларын күрде. Завод бик иске шул, купец Любимовлар заманында ук салынган. Известь сөте куып торучы поршняны насослар тузып беткән, ләкин әле, күрәсең, илнең аларны яңага алыштырырлык куәте юк. Шуңа күрсенә Серго, шуңа тавышсыз йөри. Ә Мирсәет абзыйның аны көләч чырайлы итеп, шат итеп күрәсе килә, рәхәтләнеп шаулап көлгәнен ишетәсе килә. Серго кебек ник ихтыярлы ихлас кешеләргә килешә андый көлү, тар холыклы, астыртын кешеләр генә кете-кете килеп, кәҗә көлүе белән көлә торган булалар.

Ардуанов төнлә больницага барып кайтты. Аның кызы туган. Мирсәет абзыйның шул куанычын нарком белән уртаклашасы килә, бәлки шул хәбәрдән Сергоның күңеле күтәрелеп китәр дип уйлый, әмма әлеге хәбәрне ул үтерсәләр дә әйтә алмаячагын яхшы аңлый. Юаш холыклы Мирсәет, юаш. Ә менә Шакир Сираев булса, наркомның күзенә чәчрәп керер иде...

Орджоникидзе заводның бер коридорында сода капчыклары ямап утырган хатын-кызларны күреп алды. Баш инженер наркомны ул турыдан никадәр тиз алып китәргә тырышмасын, булдыра алмады, хатын-кызлар әллә ни арада Орджоникидзены сырып алдылар. Җимгә җыелган үрдәкләр кебек бакылдап, тормыш кыенлыкларыннан, ипине вакытында бирмәүдән зарлана башладылар. Ипи карточка белән бирелә, кайсыбер көнне килми дә кала иде. Мирсәет абзый, Серго өчен үзе

җавап бирердәй булып, хатын-кызларның әрсезлегенә үртәнеп куйды. Әмма шул мизгелдә үк аның күңеленә: «Әйтеп шәп иттеләр!» — дигән икенче бер уй да килде. Юкса, ничәмә мең кешене көне буе ипisез калдыру житәкчеләрнең егетлеге түгел инде. Мирсәет абзый наркомның хатыннарны бик бирелеп, игътибар белән тыңлавын күрде, нәрсә әйтер икән дип, Сергоның җавабын көтә башлады.

— Ипи белән тәэмин итүдә өзеклек булмаска тиеш,— диде нарком, уң кулын йодрыклап һавада селкеп алды.— Ипи бездә норма буенча житәрлек, кем дә кем шул норманы боза, эшче халкын ипisез калдыра, шул кеше совет властеның гадел законнары алдында җавап бирергә тиеш!

Каты әйтте нарком, әйтеп кенә калмады, ипи өчен җаваплы кешене шундук эзләтеп таптырды: ОРС башлыгы Хесинны аерым бүлмәгә чакырып алды. Мирсәет абзый Хесинның ике минуттан, мунчадан чыккандай, тирләп-пешеп чыгуын һәм кулына бөгәрләп тоткан кепкасы белән битен сөртә-сөртә китеп баруын күрде.

Ишек төбенә җыелган эшчеләр:

— Коммерсантка нашатырь кыстырганнар!

— Артына ут капканмыни!

— Иртәгә ипи булыр инде! — дип көлешеп калдылар.

Орджоникидзе Мирсәет абзыйга ошаганнан-ошый бара, ул аның эшчеләр белән үз булып сөйләшә алуын да, барны бар, юкны юк дип, турысын әйтеп бирүен дә, яңарак кына салынып беткән культура сараенда яңа кәнәфиләргә утырып карап, аларның нык булуларына, шыгырдамауларына балалар кебек сөенүен дә — барысын, барысын үз итте, күңеле тынычланды. Ләкин бераздан аның күңеленә пошаман төште. Әгәр ул ударник Ардуановның гаиләсе ничек яшәгәнне карыйм дисә... Вәт булырсың әдәм мәсхәрәсе. Мәүгыйзә өйдә юк. Зур кунакны бәлеш пешереп тә сыйламагач...

Шул уйлары белән аптырашта калып торганда, ул наркомның сәхнәгә менеп китеп, ишекле-түрле йөгереп йөрүен сизми дә калды. Клуб директоры Брадский сәхнәнең әйләнә торган булуы белән мактанырга теләгән булса кирәк, Орджоникидзе белән икәү басып торган уңайга, сәхнә эшчесенә күз кыскан: токны тоташтыр, янәсе.

Китмәсеннәрме болар бер заман әйләнеп!

Карап торучылар кул чаба.

«Сөендеме Серго иптәш?» — Ардуановның күңеленә килгән беренче уй шул булды.

Сәхнә әйләнеп туктауга Мирсәет абзый наркомның йөзе җитди икәнен абайлап алды. Орджоникидзе сәхнә артындагы шкатурланмаган стенага төбәлгән иде.

— Бу нәрсә, иптәш директор?

— Бу ни... Григорий Константинович... декорация белән ябыла ул, тамашачыга күренми.

— Та-ак. Тамашачыга күренми, дисез. Ә артистларга? Артистларга күренәме? Сәхнәгә чыгуны көтеп торган артистларга? Ул аларның күңелен күтәрәме, әллә кәефләрен кырамы?

Клуб мөдире берни әйтә алмый, ык-мык килә.

Ул да түгел, Серго кинәт Мирсәет абзыйга таба борылды:

— Сезнеңчә ничек, иптәш Ардуанов?

— Бик күңелсездер анда...

— Ни өчен, иптәш Ардуанов?

— Йортны салып бетерми керсәң, үзенне урамда кебек тоясың.

— Менә шул шул! Төзүче кеше белә,— дип, ул Ардуановны мактап алып китте һәм шундук Мирсәет абзыйның һушын алырдай сүз әйтте: — Ничек уйлыйсыз, иптәш Ардуанов, төзелеш ударнигының яшәү шартларын карыйм дисәм, сез каршы түгелме?

— Рәхим... итегез, — диде Ардуанов.

Мирсәет абзый өйгә кайтып житкәнче ут йотып кайтты.

Гаиләсе ашарга утырган, Мирзанур белән Мирзашәрип идәнгә, кулдан суккан палас өстенә чүмәшкәннәр, Кәшифә тәрәзә төбенә утырып китап укый иде.

Орджоникидзе чеп-чиста итеп юылган, тәрәзә араларына чүпләм сөлгеләр эленгән, мебель булмау сәбәпле, аяк атлавы яңгырап торган буш бүлмәләрне күздән кичереп:

— Бу нәрсә бу, иптәш Крутанов? — диде төзелеш башлыгына. — Ударникның мебель алырга акчасы житмиме, әллә шәһәрдә мебель юкмы?

— Акча бар, иптәш Серго. Акча житә,— диде Мирсәет абзый өзгәләнеп. — Өстәл юк, иптәш нарком, кибетендә юк, каһәр суккыры! Барактагы тапчаннарны алып килергә теләмәдек.

«Акчасы да юк инде аның», — дип уйлады эченнән.

Орджоникидзе аның такт саклап, әдәп белән аңлатуын шундук аңлады, Крутановка карап: «Күрше бүлмәгә кереп сөйләшик әле», — дип ым какты.

Аулакта алар өчәү генә калдылар. Биредә кулдан ясаган ике табурет, бер бүкән бар иде. Иптәшләрен уңайсыз хәлгә куймас өчен, Орджоникидзе иң беренче булып үзе бүкәнне сайлап алды, бик әйбәтләп, жәелеп утыргач, елмая төшеп, җай гына сүз башлады.

— Миңа, иптәш Ардуанов, сезнең бетончылар бригадасы турында төзелеш житәкчеләре тулы информация ясады. Өч ел эчендә бригада членнары бер генә мәртәбә дә прогул ясамаган. Эш нормасын Ардуановларга карап билгелибез, диделәр. Төзелеш житәкчеләренә ышанырга хакым бармы минем?

— Арттырганнар,— диде Мирсәет абзый, уңайсызланып. Ул тирләп киткән маңгаен кулъяулыгы белән сөртеп азапланды.

— Арттыралар дисез, алайса?

— Әлбиттә.

Серго үтә дә үз итеп елмайды — күперенке зур мыегы бөтен битен тутырып жәелде.

— Тыйнаклык әйбәт сыйфат, иптәш Ардуанов, ләкин бит мин бригаданың эшен үз күзем белән күрдем.

— Кайчан? Ни арада? — диде Ардуанов, ышанып житмичә.

— Төнге сменада булдык без. Егетләрнең бетон коюын күрдек.

— Ничек соң, Серго иптәш?

— Бригада — минә дигән. Кстати, яратып эшлиләр эшне, белеп. Әйтегез әле, иптәш Ардуанов, каян килде сезнең бригадага шундый аңлы караш?

— Үзем уйлаганча әйтимме, Серго иптәш, әллә житәкчеләр сүзе белән әйтимме?

— Күңелегездә булганны әйтегез.

Крутановның күзләре зуррак ачылуын күреп, Ардуанов бер генә мәлгә тотлыгып калды, аннары ни булса ул дигәндәй, тәвәккәлләп сүз башлады:

— Сезнең, Серго иптәш, биләүдә яткан баланы күргәнегез бардыр инде.

— Күргәнем бар.

— Биләвен чишкән баланы да күргәнегез бардыр.

— Анысын да күргәнем бар, — дип елмайды Орджоникидзе.

— Менә шул инде... Патша заманасында безне бик озак биләүдә тоттылар.

— Богауда димәкче буласызмы?

— Ярый, богау дип әйтик. Безнең кул-аяк богауда иде. Кычкырсак та, жыласак та ишетүче булмады. Хәзер безнең кул-аякны чиштеләр,

Совет власте безгә талпынырга, үзебез теләгәнчә очарга ирек бирде. Әгәр без шул иректән файдалана белмәсәк, без адәм түгел, адәм көлкесе булыр идек.

Орджоникидзе дулкынланып бүкән өстеннән күтәрелде. Мирсәет абзыйның каты итеп кулын кысты:

— Рәхмәт, иптәш Ардуанов. Безгә сезнең кебек аңлы эшчеләр бик кирәк. Аңлы эшчеләр күбәйгән саен, илдә заводлар күбәячәк. Күбәячәк, иптәш Ардуанов! Серго әйткән иде диярсез! Тиздән без Мәскәүдә очрашырбыз дип уйлыйм. — Крутановка борылды, ягымлы-боеручан тавыш белән әйтте: — Ударник Ардуанов квартирында мебель булыр дип ышана аламмы мин, Никифор Степанович?

— Әйтүе кыен, Григорий Константинович!

— Ни өчен?

— Мебельгә түгел, заводларга курс тотабыз бит.

— Дөрес. Бик дөрес, иптәшләр. Дошман итеге астында тапталмас өчен безгә беренче чиратта заводлар кирәк. Ә мебельсез яшәп торырбыз. Торырбызмы, иптәш Ардуанов?

— Торырбыз, урманда агач күп, үзем ясармын.

— Кстати, төзелеш ударникларының исемлеген, характеристикасын хөкүмәт карамагына тапшырырга кирәк. Һич кичекмәстән. Парткомда сөйләшегез, мин кайтуга Мәскәүдә булсын. Сау булыгыз, иптәш Ардуанов.

Мирсәет абзый аларның ераклаша барган аяк тавышларын тыңлап, буш бүлмәдә ялгызы басып калды. «Аңлатып әйтә алдыммы соң?» — дип уйлаудан аның эче тырнап тора, аннан да бигрәк ата-баба йоласын үти алмавына — бу әйбәт кунакка бер чынаяк чәй дә эчертә алмавына ул чиксез үкенә иде...

## 26

Газета өр-яңа, буяу исе дә китеп бетмәгән иде әле.

«Промышленность төзелешендәге зур хезмәтләре, удар бригада оештырганнары, шуның белән социализм төзелешенең уңышын тәэмин иткәннәре өчен Ленин ордены белән бүләкләнәләр:

**Ардуанов Мирсәет** — Березникхимстрой эшчесе, бетончы;

**Громов Павел Андреевич** — Березникхимстрой эшчесе, балта остасы;

**Вотинов Николай Александрович** — Березникхимстрой эшчесе, слесарь.

Аннары төзелеш җитәкчеләре Крутанов, Хангильдян, Мицкалевич фамилияләре тезелеп китә, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнүчеләр графасында Березникхимстройдан Бәхтияр Гайнуллин һәм Исәнгол Юлдыбаев исемнәре бар иде.

Мирсәет абзый карарны «ССР Союзы Үзәк Башкарма Комитеты Председателе М. Калинин, секретарь А. Енукидзе» дигән өлешенә кадәр укып чыкты да, газетаны шыштырдата-шыштырдата бөкләп, кыска сукно пальтосының куен кесәсенә салып куйды.

Өенә кайтырга чыкты.

Карарны әле берәү дә белми, шуңа күрә юлда очраган танышларыннан аны берәү дә котламый, гадәттәгечә, ихтирам белән баш иеп, исәнләшеп кенә китәләр иде.

Ул үзе Карардан канәгать, моны дөрес дип саный, ник дисәң, Карар бүләкләнүчеләрне генә түгел, бөтен төзелешне ил алдында күтәрә иде.

Өйдә аны Мәүгыйзә түти каршы алды.

— Нәрсә булды, этисе, нишләп иртә кайттың? Әллә авырып киттеңме? — Хатынының зәңгәр күзләре хәвефле елтырап алды.— Урын җәеп бирммме?

— Авырмыйм. Урын да җәймә. Балалар кайда?

— Кәшифә мәктәптә, Мирзашәрип урамдадыр.

— Мирзанурдан хәбәр юкмы?

— Хәбәр юк. Күрәсең, эше күптер...

— Ала-аай... — диде Мирсәет абзый, бүтән сүз дәшмәде. Ул Карарны хатынына әйтергәме, юкмы дип икеләнеп калды. Үзе турындагы сүзне башлап әйтү гадәте булмаганга, эченнән тынды. Тынлык уңайсыз иде, шуңа күрә:

— Чәй әзерлә. Чәй эчәрбез,— диде.

Мәүгыйзә түти самавар кайнатып китерде, чынаякларга чәй агызды. Чәйгә сөт алырга җыенып кына торганда, карты, елмая биреп:

— Куерак яса, әнисе. Җәлләмә чәеңне! — диде.

Мәүгыйзә түти аның йөзенә күтәрелеп карады. Бик сәер аның бүген ире, бик сәер. Әллә ходаем, Мирзанурга бер-бер хәл булганмы?

Мәүгыйзә түти Нәбиулла үтерелеп, ире больницада ятып чыкканнан соң көннәрен шик-шөбһә эчендә, ут йотып үткәрә, Мирсәетенең эштән кайтканын дүрт күз белән көтеп ала иде.

— Нәрсә булган соң? Нигә миннән яшерәсең? — Иренә мөлдерәп, хәтта рәнҗеп карады.

Хатынын тынычландырыр өчен Мирсәет абзый инде яңа хәбәрне әйтергә дә җыенган иде, шул мәлне ишек шакымый-нитми Николай Вотинов килеп керде. Бу хәл хуҗаларны, бигрәк тә Мәүгыйзә түтине, сагайта калды: Николай аларга бик зур йомышы төшсә, яки куркыныч хәбәр әйтәсе булса гына килә иде. Мәүгыйзә түти көтелмәгән кунакның колакчын бүреген, сарыга каккан кайры тунын күрүгә көл кебек агарды.

— Бу йортка иминлек бирсен! — диде Вотинов, татарларның «салемалейкум» дигән сүзенең мәгънәсен исенә төшереп һәм башыннан картузын салды.

— Әйдүк, Николай Александрович, әйдүк. Түрдән уз.— Мирсәет абзый аңа кәҗәнен һәм сырмасын салырга булышты, киемнәрне стенага күп итеп кагып куйган агач чөйгә элде. — Мактап йөрисең икән, чәй янына утырган гына идек. Безнең татарларда шундый сүз бар: ашка туры килгән кунак — мактап йөрүче була... — дип, кече күңеллеләнеп, ләкин төчеләнмичә, юаш кына сөйләнде Мирсәет абзый. Николай күн итеген салып куярга да үрелгән иде, Мәүгыйзә түти аяктан салмаска кирәк икәнен, идәннең суык булуын кызу-кызу тезеп китте һәм аяк сөртергә ишек төбенә иске чүпрәк китереп салды. Хуҗа хатынның ни сөйләгәнен аңламаса да, якты чыраеннан килүемне ошаттылар дип фараз итте.

Николайга кинәт рәхәт булып китте. Ул сап-сары итеп юылган буяусыз идәнгә аяк очлары белән генә басып, тәрәзә буендарак торган өстәл янына узды, кызыл башлы сөлгеләр элеп куйган тәрәзәләргә, стена буендагы ак калайлы зур яшел сандыкка күз төшереп алгач:

— Квартирның яхшысын биргәннәр бит сиңа, дядя Мирсаид,— диде.

— Әйе, фатир кайгысы бетте, — диде Мирсәет абзый, мыегын каты тырнаклы зур кулы белән сыпырып куйды.— Үзендә ни хәлләр? Семьяңны китермәдеңме әле? Әнисе, самаварны яңартып чыгар әле. Итең булса ит тә җылытып китер...

Мирсәет абзый Николайның нигә килгәнен сизенә иде, ләкин үзе әйтми торып чәчрәп төшәргә ашыкмады.

Сыер ите белән бер таба кыздырылган бәрәңге өстәл өстенә килеп утыргач, Вотинов ишек янына барып, кәҗән кесәсеннән бер шешә аракы алып килде. Мәүгыйзә түти кыштырдап йөргән эчке бүлмәгә башы белән ымлап, ярап бетәрме икән дигәндәй, иренен очлайтып куйды; кан тамардай кызыл-кара-кучкыл сәламәт битендә акбур белән сызып куйган төсле аермачык күренгән аксыл кашлары тетрәнеп китте, ачык һәм туры карый торган күзләре бер генә секундка хәвефле ачылдылар.

— Ярый, ярый, — диде Мирсәет абзый, өстәлгә ике буш чынаяк куйды. Николай чынаякларга аракы салды.

— Дядя Мирсаид, мин беләм, син эчмисең, бәлкем бүгенге шатлыгыбыз хакына тотарсың, ә?

Ардуановның киң һәм биек маңгаенда берьюлы ике сызык барлыкка килде, алар күзгә күренеп тирәнәйде.

— Николай Александрович... мин сине ихтирам итәм. Шатлык безнең уртак, ләкин миңа үпкәләмә, мин аны гомер буена да авызыма алганым юк... — Аракысы белән чәкәште, чәен эчеп җибәрде.

Вотинов аракылы чынаягын күтәреп куйгач, озаклап ипи иснәп утырды, аннары табадан агач кашык белән бер генә сыңар бәрәңге алып капты. Мирсәет абзый чүмәлә кебек итеп өелгән бәрәңгене аңа таба ишеп төшерде, ит калҗаларын аңа таба этеп-этеп куйды.

Кинәт алар гадәттәгедән көчлерәк тавыш белән, кычкырып сөйләшә башладылар, тавышка почмак яктан Мәүгыйзә түти килеп чыкты.

— Әтисе, әллә ходаем... Булмаганны?

Вотинов аяк өсте басты:

— Тетя Маугиза... Мин сине котлыйм. Орден белән котлыйм.

— Нинди әрдир, фатир булды бит инде. Нәрсә ди ул, әтисе?

— Безгә бит орден биргәннәр... Ленин ордены. Николайга, миңа, Павелга. Хөкүмәт биргән, Калинин.

— И-ии, ходаем. Әйтәм аны баядан бирле күкәй салалмаган тавык кебек әйле-шәйле йөрисең. Ни үзеңнең, ни сүзеңнең рәте юк. Бая ук әйткән булсаң сун, кунак киләсе бар миңа дисәң, бәйрәм кабартмалары пешереп, әзерләнеп торыр идем. Менә син, э... И-ии, ходаем.

Ул баскан җирендә катып калды, иреннәре дерелди, керфек төпләренә, әчеттереп, яшь килә иде. Ахырда түзә алмады, тавышсыз гына елап җибәрде дә, битен яулыгы белән каплап, почмак якка чыгып югалды...

Икенче чынаяктан Николай сәер генә исереп китте. Күзләре елтырый, күңелендә сүз күп җыелган бугай, ул менә хәзер шушы минутларда, шушы бәхетле халәтендә үзе кебек үк эшче кешегә аларны әйтеп калырга ашыга, ләкин теле аңа бернichек тә буйсынмый иде.

— Дядя Мирсаид... а, дядя Мирсаид...— дип берничә мәртәбә әйтте инде ул, кулын Мирсәет абзый җилкәсенә салды.— Без менә... менә бер вакыт... без үләрбез... Безне бер кабергә күмәрләр.

— Ничек бер кабергә? — диде Мирсәет абзый, аңламыйча.

— Ну анда, әйтик, сине... үзегезнең гадәт буенча... Ләхет белән, кәфенгә төреп... мин бит Пермь малае... Татарларны күмгәнне күрдем... Нәрсә әйтәдер идем әле?

— «Без үләрбез».

— Әйе, без үләрбез. Безне күмәрләр. Сине ләхет белән, мине табутка салып.

— Шуннан, я, я, шуннан? — Мирсәет абзый елмайды.— Шуннан без нишләрбез?

— Бер нишләмәбез. Югарыда, якты дөньяда, сөйләшерләр: менә, ичмасам, бар иде кешеләр, пермяк Коля Вотинов, ягъни ул мин булам, Николай, һәм шулай ук татарин Ардуанов, димәк ки, ул син, дядя Мирсаид. Менә бар иде кешеләр, ал димәделәр, ял димәделәр, эшләделәр. Илебезне ныгыттылар. Әйтерләрме шулай дип?

— Әйтерләр, Николай Александрович. Ниприминно әйтерләр, боерган булса.

Вотинов каядыр читкә карап бармак янады.

— Не-не-не... шаяртмыйча, Ә мин уяныrмын да шул вакыт, сорармын: дядя Мирсаид, син йоклыйсыңмы? — диярмен.

— Ә мин нәрсә әйтермен?

— Син әйтерсең: никак нет, Коленка, мин йокламыйм. Миңа йокларга ярамый. Кешеләр әнә анда, өстә, безнең хакта сөйләшәләр,

диярсең.— Ул туктап хәл җыйды, аннары кулын янә дә Ардуановның җилкәсенә салып, күзләренә туры карап әйтте: — кешеләр безне сөйләр. Дөньяны күмеп утлар янар. Заводлар эшләр...

27

Ике атнадан Березникига трибунал килеп төште. Ул химстройда корткычлык эше алып барган дошманнар төркеменең эшен карады. Төркемнең җитәкчесен атарга, калган унөч кешесен унар елга ирекләреннән мәхрүм итәргә хөкем иттеләр. Хөкем карарын тыңлаганда Сагайкин аяк өсте баса алмады. Хөкем карары аның миен кайнар кургаш кебек яндырып, аякларының хәлен алган иде. Бите буйлап бер тамчы күз яше агып төште: гомерлек дошман күргән Совет строеның җиңүен, ә үзенең тарих тәгәрмәче астында сытылып калуын белеп үлү аңа ифрат авыр иде.

## Саубуллашу сүзе

Ардуан батыр турындагы хикәяне шушында туктатырга да булыр иде. Ләкин ике ел буе аның турында материал туплау, ике ел буена аның уй-хисләре белән яшәү мине аның белән шул хәтле дә якынайткан икән, хикәягә соңгы ноктаны куйгач, аерылышу шундый да кыен булып китте, мин әзер кулъязмамны портфельгә салып, Березники каласына, Ардуановның гаиләсе һәм кайчандыр бергә эшләгән иптәшләре яшәгән якларга кабат юл тоттым.

«Казан — Соликамск» поезды безне, пассажирларны, төн урталары җиткәндә юлга алып чыкты. Мондый төнге сәгатьләрдә ерак йөри торган поездларда чәй-мазар эчертергә бик әллә ни этәләнеп тормыйлар, урын-җир өләшәләр дә, тыныч йокы, тәмле төшләр теләп китеп баралар.

Бу юлы да шулай булды. Проводница апаның матур елмаеп әйткән сүзләрен минем күршем — җитен кебек ак чәчле, күзлекле, җитмеш яшьләр тирәсендәге ыспай гәүдәле карт бик теләп кабул итте, үз нәүбәтендә миңа тагын бер мәртәбә тыныч йокы, тәмле төшләр теләп, астагы урында одеял астына чумды. Минем әле йоклыйсым килми, әсәремдәге герой белән очрашырга бару, гәрчә ул инде исән булмаса да, мине чиксез дулкынландыра иде.

Юлдашымнан: «Әгәр бераз укып ятсам, ут мишәйт итмәс микән?» — дип сорадым.

— Хет таңга хәтле укы. Миңа барыбер. Мин теләсә нинди шартларда йоклый алам, — диде җитен чәчле, акыллы картым.

Мин аңар күңелемнән рәхмәт әйтеп, Константин Паустовский китабын ачтым. Мине тәүге мәртәбә Ардуанов турында хикәя язарга канатландырган кыска гына, китап бите белән бер бит ярымлык кына язманы табып, ике ел эчендә инде ничәнче кабат укырга тотындым:

«Су чистарту» цехы төзелешендә бетончы Ардуанов бригадасы эшли иде. Бригада бөтенләе белән русча юньләп белмәгән татар-башкортлардан гыйбарәт. Алар төзелешкә Идел буе далаларыннан килгәннәр. Күбесе кулларына көрәк тә тота белмәгән бу кешеләр рабочком бүлмәсендә уңайсыз гына таптаналар иде. Стенасына Ворошилов портреты эленгән, кызыл материягә плакатлар язып кадакланган такта барак аларга патша сарае кебек тоела. Алар кеше күз алдында тәмәке тартырга уңайсызланалар, шушы искиткеч бинада, өстәл янында утырыш үткәргән кешеләргә комачауламас өчен, әдәп саклап, учларына йөткеренгәлиләр иде.

Элекке Пермь грузчигы Ардуанов дала кешеләрен игътибар белән күздән үткәреп:

— Булдырырбыз! — дип сөйләнеп куйды.

Ул татар-башкорт бригадасы оештырды.

Газета жаргоны һәм кыскартылган сүз яратучы профсоюз хезмәткәрләре аларга шундук «нацменнар бригадасы» дигән исем такты. Ардуанов берничә ай узуга кичәге

эшче-батраклардан беренче кул бетончылар әзерләде. Бер елдан Ардуанов Ленин ордены алды. Орденга цемент тузаны кунган һәм ул яшькелтрәк булып тоела.

Ардуанов бригадасы бетончыларыннан бер генә кеше дә бер генә көн дә прогул ясамады. Ардуановларның кысыграк ягымлы күзләреннән аларның намуслылыгы, тырышлыгы һәм чыдамлылыгы, әлифба китабына язган төсле, аермачык күренеп тора.

Биредәге рәхимсез суык кышта, иллешәр градуслы салкыннарда алар жылы спецовкадан башка да җәйге челләдә эшләгән кебек бик ансат эшлиләр иде. Аларның хезмәте хәтта сүлпән холыклы пермякларны да кабызып җибәрде.

Әмма Ардуановлар белән бергә җәнҗалчылар йөри иде. Җәнҗалчы кем? Ул эшче исеме мина теләсә нишләргә ирек бирә, бернинди вазифа да йөкләми, мин «шешәгә куып кертелгән көрәшче, мин революция өчен көрәшәм» дип санаучы истерик, яки авызыннан көмешкә исе аңкытып торучы, хулиганлык һәм рекрут чаялыгы белән дан алган тукмак битле хулиган. Ул прорабларны, инженерларны аллалары, кабер такталары белән сүгә, эш киеменең әйбәтрәген, ашның тәмлерәген таләп итә, йомычка арасында тәмәке сасытып йөри. Шакмаклы чуар кепкасы җыерчык баскан маңгаена ук төшереп киелгән булыр, карлыгып беткән бугазына яшел кашне урар. Ул ударникларның артыннан төкереп кала. Большевиклар аны «бөлдергәннәр», гаилә куышында һәм калын баш капкачы астында ул алардан үч алу теләге асрап йөри.

Җәнҗалчыларның ачуы кабарды — «татарва» аларны эшкә өйрәтсен, имеш. Татарларга бармак төртеп күрсәтә башладылар, аларның эшен хөкүмәт күреп алды, татарлар арасында җәнҗалчылардан эш таләп итәләр, аларның ялкаулыгы өскә калкып, контраст булып килеп чыкты.

Нишләмәк кирәк — финка хутка китте. Ардуановларның икесен пычак белән кададылар. Хулиганлык тактикасы таләп иткәнчә, алдан сугыш оештырып эшләделәр бу эшне. «Исерек хәлдә, сугышып яралаганбыз, янәсе. Ләкин җәнҗалчылар ялгыштылар. Аларны хулиганлык өчен түгел, контрреволюция өчен хөкем иттеләр. Ардуанов бригадасын Уралның «Кызыл кенәгәсенә» — көнчыгышта яңа индустрия базасы төзүчеләрнең Мактау кенәгәсенә яздылар».

Кара әле, романтик кеше булган бит бу Паустовский дигәннәре! Романтик кына микән? Кыска гына язмада бөтен бер халыкның характерын ачып бирә алу өчен талантлы да, олы йөрәкле дә булу кирәктер. Иксез-чиксез илеңне анда яшәгән барлык халыклары белән бергә ярата алу кирәктер. Максим Горький шундый булган. Берәр халык турында үз сүзен әйткәнче ул әнә шул халык белән житмеш жиде пот тоз ашаган, шуннан соң гына әйтер сүзен авыз тутырып әйтеп биргән.

Поездның, станцаларга якынлашкан чакта, халыкларга якынлашкан кебек, сәламләп гудок бирүен тыңлап ята торгач, йоклап киткәнмен. Иртән күземне ачканда, юлдашым күптән уянган иде инде.

Бит-күземне юып кергәч, чәй көткән арада сөйләшеп киттек. Башка вакытта айлар буена эшләнә торган эш — танышу поездда бер көндә эшләнә.

Җитен чәчле картым үзен: «Иван Федорович Коновалов», дип таныштырды, мин дә исем-фамилиямне әйттем. Бу исемнәр әле безгә, берберебезне белмәгән кешеләргә, берни дә әйтми иде. Без тирәнгәрәк керә башладык. Моңысы инде — кем кайсы станцага хәтле бара диган сүз. Мин — Березникига. Иван Федорович та Березникига икән ләбаса! Менә сиңа кирәк булса! Без инде туганнар диярлек!

Мин, профессиям таләп иткәнчә, аның кем икәнен сорарга һәм үземнең кем икәнемне әйтмәскә тиеш идем.

Ул — Березники шәһәренең төп гражданы, ул гына да түгел, туган ягын өйрәнүче икән, Казанга бик тә мөһим бер йомыш белән килгән. РСДРПның II съездына Югары Кама партоешмасыннан делегат булып сайланган кешенең документларын, Югары Кама партоешмасының Уставын ул Казанга килеп эзләгән һәм... тапкан. Ай буе кайгырып, борчылып үткәргәннән соң тапкан. Менә ни өчен ул кичә тыныч күңел белән йоклап китә алган икән.

Гаҗәеп хәлләр бар бу дөньяда! Бәлки әле ул минем героемны да беләдер. Крайны өйрәнүче булсын да белмәсен!

— Гафу итегез, Иван Федорович, бәлки сез, Березникида яшәгәч, Ардуановны да беләсездер? — дидем мин, ә үзем «Какого Ардуанова?» дигән сорау ишетергә әзерләнеп, аның күзләренә төбәлдем.

Аның коңгырт чиста күзләре яратып елмайдылар:

— А как же! — диде ул.

Мондый сүзне, гадәттә, конкрет җаваптан котылырга теләүчеләр әйтә торган була. Юк, акыллы картым, син әле миннән алай тиз генә котыла алмассың, безнең профессия тәгәллекне ярата.

— Сез аны күреп беләсезме? — дидем.

— Без аның белән кырык ел янәшә яшәдек,— диде Коновалов.

Мин тыныч кына утырган җиремнән сикереп тордым да:

— Яки минем бәхетем баса, я мин төпсез тагаракка утырып калам! — дип кычкырып җибәрдем.— «От землекопа до члена правительства» дигән очеркның авторы сезме?

— Мин булсам, ни диярсез?

— Паустовскийның «Коноваловские ребята» дигән очеркының герое да сезме?

— Мин булсам, ни диярсез?

— Иа хода, мин бит сезне теге баруымда атна буе эзләдем. Ә бу юлы сез миңа үзегез килеп каптыгыз. Кадерле Иван Федорович, кичтән үк әйткән булсагыз, мин бит атаклы Коновалов дигән булсагыз, без әллә кайчан танышкан була идек бит.

Карт, күзлек пыялаларын елтыратып, уңайсыз гына елмайды.

Без сөйләшеп киттек. Мин Иван Федоровичның очеркын Казан университеты китапханәсеннән табып укыганымны, аның үлем түшәгендә яткан Ардуановтан үз вакытында, гаять зур сабырлык белән аның тормыш юлын сорашып калуын, менә хәзер шул фактларның кайсы да булса бер язучыга повесть язарга файда итәчәген ычкындырып ташладым.

Иван Федорович үз нәүбәтендә гаҗәпләнеп:

— Сез язучы түгелме? — диде.

— Юк, — дидем мин, нык итеп. — Мин типография эшчесе. Мин наборщик. Ләкин әле бу һөнәр миңа Ардуанов биографиясенә битараф карарга хокук бирми.

Коновалов кибәккә алдана торган чыпчык булып чыкмады.

— Я сез нинди һөнәр иясе икәнегезне төгәл әйтәсез, яки мин сезнең белән сөйләшүдән баш тартам,— диде. Картларча бер үҗәтлек белән, иреннәрен турсайтып, коридорга чыгып китте.

Тыйнаклык сакларга тырышуым миңа кыйбатка төште. Коновалов белән кабат сөйләшеп киткәнче тагын өч сәгать чамасы вакыт узды. Шулай да без бер-беребезне аңладык һәм уртак тел таба алдык.

— Иван Федорович, сез Мирсәет Ардуанов белән кырык ел янәшә яшәгән кеше булгач, беләсездер, аның һәйкәл кадәр һәйкәл куйдырырлык төп сыйфаты нәрсә? — дип сорадым мин, миңа моны ачыклап калу бик тә мөһим иде.

«Житен чәчем» беркавым сүзсез утырды, аннары йокысыннан айнып киткәндәй, миңа төбәлеп карап:

— Минемчә, Ардуановның иң төп сыйфаты — эхлакый сафлык, — диде. Гүя мин аңлап бетермәс дип курыккандай, аңлатырга тотынды: — Әйтик, Мирсәет сабан туй үткәрә, көчле кеше иде, туганкай, ой, көчле, сабан туеның ярты байлыгын бирүзе җыеп чыга, сүз әйтүче, шелтәләүче юк, ә ул риза түгел, кече сабан туй җыя, бригадасын ярыштыра, алган барлык байлыгын өләшеп бетерә. Әнә нинди көчле кеше иде ул. (Минем җаным канат какты: димәк, мин аның шәхси сабан туе үткәргәнен дөрес алганмын.) Бишьеллык урамында квартир бирделәр моңа, больницада ятып чыкканнан соң. Беренче катта иде. Операциядән соң югарыгы катка менеп йөрү кыен булыр дип уйлаганнар булса кирәк. Ә квартир суык — нишләтәсең аны! Башка берәү булса, шундук гауга куптарыр иде. Юк, Ардуанов яши бирә, квартирның янәсын таләп итми. Бер дә бер көнне шәһәр Советыннан килделәр. Иптәш Ардуанов, диләр, тезе-

леш ударнигы итеп, без сиңа яңа урыннан өч бүлмәле квартир бирергә булдык, диләр. Кая ул! Тузгып китә картлач. Кызы Кәшифәне тиргәп ташлый. Синең эшең бу, янәсе, синең телең озын. Син горсоветка баргансыңдыр. Миңа бу фатирны эшем өчен бирделәр. Менә мин үләрмен, үзегез эшләгәнгә алырсыз яңа фатирны. Шунсыз авызыгызны да ачмагыз. Менә нинди көчле кеше иде ул, туганкай! Тәки сүзендә торды, гаиләсе хәзерге өч бүлмәле квартирын да ул үлгәч кенә ала алды.

— Балаларына да бит квартирны эшләгән өчен биргәннәрдер.

— Сездә, татарларда, бер мәкаль бар: оясында ни күрсә, очканда шуны күрә. Балалары да булдыклы булып чыкты. Олы малае милиция органнарында эшләде, теге авыр заманнарда аны комсомол тәртип сагына мобилизовать итте. Уртанчы улы инженер-конструктор, әтисе салган заводта, ике кызы врач, барысы да югары белемлеләр. Барысы да тыйнаклар. Булдыклылар, күргән саен үзләрен Ардуан батырны күргән күк булам. Беләсезме, юлдаш, бер кеше бөтен бер милләт турында фикер уята ала икән. Ардуанов яраттырды миңа татар халкын. Ардуанов миңа бер кешенең нәрсәгә сәләтле икәнен аңлатып бирде. Эшләгән эшен ил дә күрде шул: Бөтен Союз Үзәк Башкарма Комитетына член булып сайланды. Калинин белән Орджоникидзе Мәскәүгә чакырып кунак иттеләр, Конституция кабул иткән съездда катнашты. Березникида булдым диден бугай, музейда да булгансыңдыр инде, анда Мирсәетнең киемнәре саклана, мин әзерләп бирдем аларны, ордены әле беренче дәвер ордены, цемент тузаны, төзелеш тузаннары кунып калган сыман яшькелтрәк төстә. Березники эшчеләре аның һәйкәлен үзе салган завод янына куеп дөрес иттеләр, эшкә килсәләр дә, эштән китсәләр дә, намусларын, фидакарьлекләрен Ардуанов намусы белән үлчиләр. Ишеттенме әле, без бит шушы арада Мирсәет Ардуанов исемендәге премия булдырдык, һәр елны иң яхшы төзүче булып танылган бригадага биреп барачакбыз.

Миңа көмеш чәчле юлдашымны, Мирсәет Ардуанов белән кырык ел буе янәшә яшәгән өлкән кешене, халкымны ихтирам иткән кешене тыңлау рәхәт иде. Бу минутларның мин озаккарак сузылуын тели идем. Шул ук вакытта мин аңардан күңелемдә уянган сорауларга җавап та алып калырга ашыга идем:

— Әйтегез әле, Иван Федорович, Ардуановка ни өчен һәйкәл куйдылар. Әйтик, Маяковскийга һәйкәл бар — ул шагыйрь, иҗатчы, Чайковскийга һәйкәл бар — ул композитор, шулай ук иҗатчы, Чапайга һәйкәл бар — ул сугыш батыры, революцияне саклап калучы...

Коновалов минем әйткәннәремне сабыр гына тыңлап бетерде. Аннары миңа дустанә бер караш ташлап, мөлаем елмаеп әйтте:

— Син моны үзең дә беләсең, әлбәттә. Әмма ләкин моны сиңа минем авыздан ишетү кадерлерәк, күрәсең. Әйтәм: Ардуан батыр да әнә шул Маяковскийлар, Чайковскийлар, сезнең милли батырыгыз Җәлилләр кебек иҗатчы иде. Поэма түгел, симфония түгел, Яңа заманны, Яңа дөньяны иҗат итте ул, социализм дөньясын. Менә шуның өчен аңар һәйкәл куйдылар. Рус шәһәрендә татар эшчесенә беренче һәйкәл.

Поезд ашкынып алга чаба. Халыкларга сәлам биргән кебек, станцаларны гудоклары белән уятып, безне «химия республикасына», Ардуан батырны тудырган калага, Березникига алып бара.

Березники — Казан.

1972—1973.

## Рәшит Гәрәй

### Җайлашмыйбыз

Кайберәүләр, шулай, өстән генә
Сугып китә безнең иңнәргә.
Нигә, имеш, бераз җайлашмыйсыз
Аркан исә торган җилләргә.

Җайлашмыйбыз! Менгән манарабыз
Булса булсын, әйдә, тәбәнәк.
Җирнеке без! Һәрчак җиргә гашыйк,
Хисләребез, җаныбыз сәламәт.

Җил уңайга салган манаралар
Күренә, дөрес, төрле тарафка.
Хуҗалары ләкин җирнең ямен
Күрә алмый шуннан карап та.

### Бәхет хакында

Дөнья куйган чакта бабам миңа
Таш пулатлар мирас итмәгән.
Солдат әткәм соңгы сулышында
Васыять әйтү белән чикләнгән.

Ата-бабам нигезе такыр булгач,
Ярлылыкка шактый бай булдым.
Тик кешеләр бәхетен көнләмәдем,
Алар кайгырсалар — кайгырдым.

Шушы көнгә кадәр белмим әле
Тулы бәхет нинди булганын.
Мин киткәндә җирдән әзер бәхет
Сорамасын миннән улларым.

### Канатлар ныгысалар да

Якты дөньяга килдек тә
Канат чыгардык җирдә.
Кырыс күңелле булырга
Кирәктер кыю иргә.

Өзәңгеләрне зыңлатып
Чаптык елгыр атларда...
Ә соңыннан җылы сүзләр
Яздык сәлам-хатларда.

Уттан алып, суга салып,
Сынады безне заман.
Канатлар ныгыдылар, тик
Күңелләр йомшак һаман.

## Дилбегәләр

Киттеләр, ил-йортны яклап,
Иң хәвефле елларда.
Киттеләр... дилбегәләрен
Биреп безнең кулларга.

Атларга камыт кидердек,
Арба өстенә басып...
Тормышка без шулай кердек,
Җил капкаларны ачып.

Атларыбыз һаман давыл
Эченнән җилдерәләр.
Чыдаса да чыдый икән
Кулдагы дилбегәләр!

## Башка чыгучылар ашыктыра

Киң җилкәле ирләр киң урамда
Бура күтәрәләр язларын.
Бу шигыремне алар күтәрәчәк
Бүрәнәгә утырып язамын.

Сагыз исе аңкый тирә-якка
Гәрәбәдәй сары нараттан.
Авыл, авыл, сиңа ямь өстәгән
Биек бураларны яратам.

Башка чыгучылар ашыктыра,
Син аларга тел-теш тигезмә.
Көтелмәгән яңа бәхет иңсен
Алар кора торган нигезгә.

## Разил Вәлиев

### Туган як

Таныш ярлар, якын ярлар, туган җир —
Уйна да көл, шатлан, сөен, җырлап йөр.

Күптән качкан моннан дошман яулары,
Шуңа горур, шуңа мәгърур таулары.

Туган җирдә безгә һәрчак кадер бар,
Адым саен анда таныш каберләр.

Үткән көннәр — безгә сагыш-истәлек.
Бу сагышлар тормасачы өстәлеп.

Җылырак шул туган якның кояшы.
Монда безнең юл азагы, юл башы.

Чакыра тик ерак чүлләр, себерләр...
Тимер булды эштән сезнең сеңерләр.

Җылынды күк хәтта Себер кояшы.
Тик туган як һаман хәтер юлдашы.

Гөлгә күмдек ач даланы, чүлләрне.
Безнең тирдән тозланды ил күлләре.

Туган якның сулары да тоз иде.
Алыштырмый ләкин күлләр диңгезне.

Җылытсак та салкын Себер җилләрен,
Кошлар көзен монда очып килмәде.

Язлар саен кабатлады гел алар,
Сау-сәламәт, диеп, анда оялар.

Дәртләнеп без тагын эшкә тотындык.
Колак тыңлый ил хәбәрен йотылып.

Кайтырбыз без, салкын Себер гөл булгач.
Сагышыңнан үлә күрмә, сандугач.

Ә хәзергә ташка тамсын кайнар тир.
Түз, егет бул, «туган як» дип җырлап йөр.

## Диңгездә ява яңгыр

Чүлләрнең кипкән ирене,
Сөяк булган саксаул.
Оеп утыра барханнар —
Диңгездә ява яңгыр.

Саргайган йөзе болынның,
Иелгән бодай башы.
Күзе күктә игенченең,
Моңсу аның карашы.

Тын калган басу юллары,
Юк бер юлчы узганы.
Бер көндә куна тарихның
Бер гасырлык тузаны.

Искереп бетте кояш та,
Уңды күкнең буявы.
Күңел төбенә күмелгән
Авыр уйлар уянды.

Саекты тирән елгалар,
Инешләр корыр инде...
Диңгезгә барып егылды
Даланың кайнар җиле.

Кунды йөзгә җыерчыклар —
Җир-анага, ай, авыр...
Әлсерәгән басу-кырлар...
...Диңгездә ява яңгыр.

# ОЧЕРКЛАР

## КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ФЕВРАЛЬ, 1973.**

«Быел Питтсбургтан (АКШ. *Ред.*) барган инженерлар Мәскәүдән 600 миль көнчыгыштарак булган Чаллы шәһәре янына урнашачаклар. Рус монтаж бригадалары белән бергә, алар Кама автогигантының кою җайланмаларын урнаштырачак. Американың Россия территориясенең үзәгенә, Идел елгасы бассейнына барып чыгулары АКШ белән Советлар Союзы арасындагы үсә барган сәүдә-экономик бәйләнешләрнең яңа этабы булып тора».

**«Бизнес уик». Нью-Йорк**
**(«За рубежом» журналыннан).**

Хәзер бөтен илебездә «Алтын шайба» призына ярышлар бара. Бу ярышларда Чаллы шәһәре балалары да катнаша. Уеннарга 16 команда катнашты. Һәр очрашу зур спорт омтылышы белән узды. Әлбәттә, уңыш иң яхшы әзерлек күргән спорт коллективлары ягында булды.

Ярышлар тәмамлангач, КамАЗга килгән Олимпия уеннары һәм дөнья чемпионнары Игорь Ромишевский белән Валерий Харламов җиңүчеләрне тәбрикләделәр, аларга грамоталар, шәһәр комсомол комитетының махсус призларын тапшырдылар.

**«Социалистическая индустрия»**
**на строительстве Камского автозавода».**

51 нче номерлы төзү-монтаж идарәсе коллективы Татарстанның атказанган төзүчесе, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены кавалеры Гевор Ашапович Геворгянның «Жилстрой» трестында 20 ел эшләвен тантаналы төстә билгеләп үтте. Ул Татарстан нефтенең беренче башкаласы Бөгелмә шәһәрен, Лениногорск шәһәрен төзешкән, хәзер Чаллы шәһәрен төзи. Хезмәттәшләре бригадирга зур бүләк әзерләделәр — мәктәп бинасын төзүне бер ай урынына 24 эш көнендә тәмамладылар.

**«Труд». Мәскәү.**

КамАЗдагы яшь төзүчеләр адресына беренче бишьеллыклар ветераннары А. Стаханов, М. Виноградова, П. Кривонос, А. Бусыгин һәм И. Гудовларның ачык хаты басылып чыкты. Моннан бер ел элек безнең теләктәшлек сүзләребезнең Чаллы шәһәрендә җылы каршы алынуы белән горурланабыз,— диелгән ул хатта.— Быел да, тугызынчы бишьеллыкның хәлиткеч елында да, «һәр көннең, һәр атнаның, һәр айның заданиесен һәр объектта яхшы сыйфатлы итеп арттырып үтәргә!» лозунгысы астында социалистик ярышны тагы да киңрәк җәелдерерсез дип ышанабыз.

КПССның Чаллы шәһәр комитеты бюросы Социалистик Хезмәт Герое А. Б. Новоладский, М. Д. Харитонов, Гыйниятулла Шәйдуллин, Г. П. Новгородскийларның патриотик башлангычын яхшы дип тапты. Алар бишьеллыкның өченче елы заданиеләрен сугышчан, чын-чынлап иҗади ярыш шартларында арттырып үтәү йөкләмәләре алдылар.

**«Социалистическая индустрия»**
**на строительстве Камского автозавода».**

Советлар Союзы җитәкчеләре белән президент Р. Никсон, СССР Тышкы сәүдә министрлыгы белән АКШ Сәүдә министрлыгы арасында Совет-Америка экономик һәм сәүдә мөнәсәбәтләрен яхшырту турындагы сөйләшүләр нигезендә Нью-Йоркта сатып алу комиссиясе булдырылды һәм эшкә кереште.

Бу комиссиянең төп бурычы — Кама автомобиль заводы өчен җиһазларга һәм технологик процессларга заказларны хәл итүдә совет тышкы сәүдә оешмаларына булышлык күрсәтү. Сатып-алу комиссиясе булышлыгы белән 2 февральдә Питтсбург шәһәрендә (Пенсильвания штаты) КамАЗның кою заводы өчен автомат линияләр җибәрү турында зур контрактка кул куелды.

Хәзерге вакытта ГФРда Советлар Союзы белән теге яки бу формада эшлекле бәйләнешкә кермәгән зур фирмалар юк. Узган ел ахырында ГФРның ике зур фирмасы булган «Липхерр» станоклар төзү заводы һәм «Хюллер» машиналар төзү заводы СССРдан 400 миллион маркалык заказлар алдылар. Алар Кама буенда, Чаллы шәһәрендә төзелә торган Европада иң зур йөк машиналары заводына җиһазлар сатачаклар. Кама предприятиеләренә шулай ук «Рейншталь АГ» концерны да җиһазлар җибәрәчәк. Бу — ике як өчен дә файдалы булган хезмәттәшлекнең матур үрнәге. «1972 елда безнең станоклар төзү промышленносте, әгәр Камадагы завод өчен безнең фирмаларга тәкъдим ителгән заказларны кабул итмәсә, очны очка ялгый алмаган булыр иде»,— дип язды «Франкфуртер альгемайне» газетасы.

ТАСС.

«Татар драматургы Д. Вәлиевнең «Дәвам» исемле пьесасы КамАЗ төзүчеләр тормышы материаллары буенча язылган. Казанда В. И. Качалов исемендәге зур драма театры бу пьесаны сәхнәгә куйды».

**«Театральная жизнь»**. Мәскәү.

**«КамАЗ өчен театр. Ул нинди булырга тиеш?» — «Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода»** газетасында шундый баш астында КамАЗ комсомол комитеты хезмәткәрләренең Ленинград дәүләт театр, музыка, кинематография институты вәкилләре һәм завод җитәкчеләре белән әңгәмәсе басылып чыкты.

«Сезнең шәһәрдә театр булсын һәм мөмкин кадәр иртәрәк булсын өчен без барысын да эшләрбез,— дип җавап бирә яшь КамАЗ төзүчеләр соравына институтның комсомол комитеты секретаре Вячеслав Ларионов.— Безнең институтта бу эш белән шөгыльләнү өчен оештыру комитеты булдырылды. Аның бурычы — театр ачу мөмкинлекләрен ачыклау. Институт өчен шул нәрсә ачык: булачак театр өчен без труппа әзерли алабыз».

Сәнгать социологиясе секторы аспиранты Лариса Солоницына бу мәсьәләгә фәнни яктан килә.

«Без Чаллыда театр булдыру мөмкинлекләрен киң планда өйрәнергә тиешбез,— ди ул.— Чөнки сүз вакытлы театр турында түгел, даими театр турында, үзешчән театр турында түгел, профессиональ театр турында бара. Без тамашачының зәвыгын, дәрәҗәсен, яшен, белемен, кайдан килгәнлеген, киләчәктә аның нинди булачагын белергә телибез».

«Әлбәттә, бик табигый, театрның матди ягын да истә тотарга кирәк,— дип сүзгә кушыла институтның экономика һәм оештыру бүлеге студенты Владимир Григорьев.— Труппаның составы, булачак театрның урыны, тамашачы залының реаль сыйдырыш проценты, финанс чыганаклары — берсен дә онытырга ярамый».

Автозаводның генераль директоры Л. Б. Васильев, аның урынбасары Ф. С. Раимов, партком секретаре А. А. Родыгин һәм завком председателе И. Б. Закирҗановлар да әңгәмәгә катнашучыларны күп кенә яңалыклар белән таныштырдылар.

«Ул кичә тамашачыларда да, «Мечте навстречу» спектаклендә уйнаучы артистларда да зур тәэсир калдырды. Башкаланың Цветной бульвардагы цирк бинасында күрсәтелде ул спектакль. Бу спектакль үз иҗатлары белән Кама автомобиль заводын төзүчеләрне таныштырырга теләгән цирк артистларының теплоходта Чаллыга сәяхәте турында сөйли».

Артистлар бу спектакль барган көнне Болгариядән сәяхәттән кайтышлый Мәскәүгә тукталган өч йөздән артык КамАЗ егетләре һәм кызлары белән очрашканнар.

Мәскәүдә чыга торган **«Советская эстрада и цирк»** журналы бу җылы очрашу турында кызыклы мәкалә биргән.

Әхәт Гайнуллин

# АШКЫНУЛЫ БУЛСАҢ...

БРИГАДИР КӨНДӘЛЕГЕ

Күр син монда: кеше КамАЗ төзи,
Тирә-юньдә мең төр авазлар...
Ә кешенең үзен корыч итеп
Чыныктыра шул ук КамАЗлар...



1971 ел, 18 июнь. Без, Чаллыга юнәлеш тотучы ике иптәш, икенче көн инде менә пароходта барабыз. Баш төртергә дә урын юк. Халык, халык. Ыгы-зыгы... Күбесе Чаллыга Кама автомобиль заводы һәм яңа шәһәр төзелешендә катнашырга ният-ләгән, шунда ашкынып баручы яшьләр. Шау-шу. Үзара бәхәсләр...

Иптәшем Бари белән саф һава суларга палубага күтәреләбез. Минем Казаннан чыгып киткәннән бирле бераз гына ямансулап баруымны сизеп булса кирәк, кәефне күтәреп җибәрер өчен үгет-нәсихәт биреп маташа:

— Кайгырма, дускай, Чаллыга бик тиз ияләшеп китәрбез, менә күрерсең, тик, давай, сынатмыйк,— ди.

Чынлап та, нәрсәгә кайгырырга, ни сынатырга? Юлларны мин бик күп йөргән кеше ләбаса. Чирәм җирләр... Себер төзелешләре... Киресенчә, күңелдә... куану гына... куану...

Мин Барига шушы хакта үз фикерләремне әйтергә теләп башымны күтәргән генә идем, каршы яктан безгә таба ике егетнең нәрсә турындадыр кызу-кызу бәхәсләшеп килүен күргәч, бүленеп калдым. Якынрак килеп туктауларына әлеге ике адәмнең сүзләре аермачык ишетелә башлады.

Кепкасын тирән батырып кигәне мишәр акценты белән сөйли:

— Син выт Казан ягыныкы. Әт әле син миңа, нинди җир ул Чаллы? Әпәй турында сүләмә, безгә сәмән кирәк. Выт безнең авылның Кәлине әтәм, Тольяттида акцаны каерды да каерды гына инде, малай. Хәзер, имеш, Чаллыда тагын акцаны бик каты суга, дир...

Икенчесе сүзгә катыша:

— Кем белгән инде аны, бәлки начальство тирәсендә куштанланып йөргән берәр портянкадыр шунда, кем белгән... Тәресенә күрә тактасы, чиләгенә күрә капкачы дигән шикелле, хезмәтенә күрә акча сыдыр инде ул, малай.

Күңелгә әллә ничек кенә чиркәнчек булып китте. Менә бит ул ничек?! Күрәсең, кайберәүләр Чаллыга озын сумнар өчен генә баралар икән. Белмим, егетләрнең әңгәмәсе Барига нинди тәэсир калдыргандыр, ул Кама дулкыннарына караган килеш нидер уйлый иде.

Бу вакытта палуба өстендә башта акрын гына җыр сузылды.

Кама буе туган як ла,
Гөлләр үсә торган як.

Комсомол путевкасы белән КамАЗ төзелешенә баручы татар, чуваш, рус егетләре һәм кызларының дәртле, яңгыравыклы бу көмеш тавышлары, кичке тынлыкны ярып, Кама дулкыннары өстендә бик озак тирбәлде.

**19 июль.** Ниһаять, Чаллыга килеп җиттек. Безне яхшы гына каршы алдылар. Кадрлар бүлеге янында 50—60 лап кеше — барысы да яңа килүчеләр. Никадәр җаваплылык — әле генә килеп җиткәннәрнең барысын да гостиницага урнаштырып бетерергә кирәк. Торак мәсьәләсендә монда бик читен, ди. Кешеләр вагоннарда, палаткаларда торалар икән. Гаиләле кешеләргә аерата кыен, ди. Егермешәр, утызар километр ераклыктагы авылларда квартираларда торучылар бар, имеш. Тагын шуны да белдек: Чаллыда һәр көнне 150—200 ләп кеше кабул ителә икән. Менә бу сан!.. Искитәрлек.

Безне Кама култыгындагы иске пароходка — «гостиница»га урнаштырдылар. Пароходның исеме «Павел Холзунов». Кайсыдыр шаяртып, җиңел кулдан «Астрахань шәһәренә юл тота» дип язып та куйган, Астрахань шәһәреннән килүче яшьләр эшедер инде бусы.

**20 июль.** «Башсантехмонтаж» трестының 1 нче төзү-монтаж идарәсенә слесарь-сантехник булып эшкә урнаштым, 1 нче участокның Иван Савоськин бригадасына билгеләделәр. Прораб Зайцев иртәгә үк эшкә чыгарга кирәклеген әйтеп, вакытлы торак урыны итеп вагон күрсәтте. Бардым. Вагон ишеген ачып керсәм, гаҗәп хәлләр: урын-җир җыештырылмаган, анда-санда ботинкалар, кием-салым аунап ята. Өстәл өстенә күз төшердем, анда каткан ипи сыныклары, кефирдан бушаган шешәләр, аракы һәм төрле зурлыктагы одеколон куыклары дисеңме, нилэр генә юк, гомумән, тәртипсезлекнең иң чиге — чүплеккә әйләнгән вагон кисәге. Кинәт одеал астыннан бер тере баш күтәрелде. Битләре шешенгәнлектән, күзләре кысылып калган бу адәмнең хәле бик авыр иде булса кирәк, кем кергәнен абайламыйча:

— Иван, Иван дим! — салып бир әле тизрәк, салып бир,— дип бер чайкалды да лып итеп идәнгә килеп тә төште. Көч-хәл белән яңадан аякка басты.— А-а, яңа таныш икән! Александр Македонский сезнең алда!

Мин сүзсез генә исәнләштем. Кешеләр эштә вакытта аның ни сәбәптән эштә булмавын белешмәкче булдым.

— Эшләп кем баеган? Акча алган идек, менә, өченче көн инде башны күтәрә алмыйча ятам. Сухой закон монда, товарищ. Күрше районга барып алып кайткан идем, бетте... Әле дә ярый, менә коньяк кына калган икән,— дип сөйләнә-сөйләнә, кесәсеннән одеколон тартып чыгарды.

— Эчәсеңме?

— Юк.

— Дуслык өчен, әйдә, берәрне күтәрәбез.

— Юк, мин эчмим бит, кем... Македонский.

Шул чак, ишекне киң иттереп ачып, сүгенә-сүгенә тагын берәү кайтып керде. Кергә керешли үк, ул өстәл өстендәге одеколон салынган стаканны ялт иттереп алды да эчеп тә җибәрде.

— Саша, син иртәгә эшкә чыгасыңмы, юкмы, югыйсә, икебез дә янабыз! Әле бүген дә...

Мин чыгып киттем. Кая барырга? Кем белән сөйләшергә? Кәеф шәптән түгел, билгеле. Мондый типтагы кешеләрнең характеры миңа күптән таныш. Себер төзелешләрендә һәм чирәм җирләрдә эшләү дәверендә андыйларны күргәләгәнем булганлыктан, «Македонский әфәнде»ләргә бик исем китми. Күрәсең, алар берсеннән-берсе «яхшы»лар. Эшләмиләр. Кыскасы, эшләргә яратмыйлар. Андыйларның күбесе куркак була, тыштан гына ялтыраган итәләр.

Беренче көнне үк шундый хәлне күрү кызганыч, әлбәттә. Шулай да апатиягә бирелергә һич ярамый. Төзелешне, яңа шәһәрне карап кайту теләге белән автобуска утырдым.

Гидротөзүчеләр поселогына бер генә урам. Башка урамнарда әлегә асфальт-бетон җәю белән мәшгульләр... Тегендә дә, монда да актарылган җир, чокыр-чакыр... Әмма шәһәрдә зур җанлылык сизелә. Кая карама — яшьләр, яшьләр... Берәүләр эштән кайта, икенчеләре кичке сменага ашыга. Русча, татарча, грузинча, чувашча, тагын әллә нинди телләрдә сөйләшкән сүзләр колакка чалына.

Атлый торгач, «Чулпан» кинотеатрына килеп чыктым. Тузанлы эш киемнәрен дә алыштырмыйча кинога билет алучы яшьләргә сокланып карап тордым.

Мин яңадан вагонга әйләнеп кайтканда, егетләрнең барысы да өйдә иде. Эштән кайткан егетләрнең берсе Астрахань егете, ә икенчесе Башкортстаннан килгән Якуп белән танышып, Камада су коенып кайттык. Икесе дә шоферлар икән, ә теге исерек башлар, икенче атна инде эшкә чыкмыйча, ялган справка белән эштән «азат ителеп», трай тибәләр икән.

**21 июль.** Безнең участок идарәдә иң артта сөйрәлүчеләрдән икән. Мин эшли торган бригада да ялтырамый, таркаулык сизелә, бердәмлек юк. Бригада Орловка авылында яңа мәктәпне монтажлауда соңгы операцияләрне тәмамлап килә. Эш сыйфаты түбән. Кайсыбер сантехник приборларны яңадан тәртипкә китерергә кирәк. Бригадир белән уртак тел таба алмабыздыр шикелле.

**22 июль.** Эштән кайтып кына керүемә Якуп та минем арттан ук кайтып җитте. Ул инде эш киемнәрен алмаштырып та өлгергән.

— Виктор кайда соң?

— Аның эш ходта, парень. Ашханәдә эшләүче Маша белән любовь крутить итәргә китте.

— Ә син?

— Миңа нәрсә? Уфада кура җиләге кебек сөйгәнем калды.

Сагындым үзен, күрешә алмыйча ут йотып ятам шушы Чаллы калаларында.

— Ничева, түзәргә кирәк, брат. Я, Якуп, төзелеш турында сөйлә әле син миңа. Әш нәрсәдә, ничек соң?

Нәрсәсен сөйлисең инде аның? Төзелеш төзелеш инде. Пычрак, тузан, рәтле кием киеп йөрерлек түгел. Җеннәр төзесен бу КамАЗны! Беләсеңме, дус кеше, әле соң түгел, ычкын син моннан. Бернинди кызыклык та юк монда. Яшьләр өчен тем более.

— Юк, Якуп, мин китәргә килмәдем,— дим мин аңарга.— Беренче автомобильне чыгарышуда без дә кирәк.

— Беренче автомобиль ун елсыз да булмый.

— Тагын ике-өч елдан һичшиксез булачак.

— Юк инде, син мине агитировать итмә,— ди ул.— Миңа агитация үтми, тирем калын минем.

Безнең сөйләшү җанлана алмады, шуның белән өзелде.

**24 июль.** Иван белән Македонский һаман айнып җитә алмыйлар әле. Менә бүген дә өстәл артында исерешеп утыралар. Мин килеп керү белән, Македонский урыныннан күтәрелеп минем иң башыма кулын китереп сала, ә мин аның кулларын җилкәмнән бик тиз генә кире төшерәм.

— Браток, положениегә кер, баш авырта, бир әле «пәнҗеки», бир,— ди бу миңа.

— Юк. Исерекләргә бөтенләй бирмим.

Кинәт кенә аның күзләре ялтырап, йөзләре агарынып китте.

— Әле шулаймы?

— Шулай.

Ул бераз үзен кулга алгандай булып йомшаграк сөйләшә башлады.

— Слушай, браток, расчет алганда мин синең белән квито ясыйм, менә расчет кына бирмиләр, каһәр. Ычкындырасылары килми, факт, как-нибудь шофер первого класса бит абзаң. Ас, понимаешь?

— Яхшы, телисеңме, әйдә, расчет алырга мин сиңа үзем булышам.

Кинәт ул бер мәл чайкалып китте дә артка чигенеп куйды.

— Юк, расчетны, егет, мин сиңа үзем ясармын,— дип, яңадан миңа таба килә башлады. Мин аның кулларында ялтырап киткән финка күрәм, ә шул вакыт миңа икенче яктан урындык ыргытыла. Бусы Иван эше. Нишләргә?!. Икесенә каршы берүзем. Дөрес, кеше үтерүгә кадәр алар барып җитәргә тиеш түгел. Җинаять өстенә җинаять эшләргә җыенмаслар. Ләкин алар исерекләр. Исереклек сөреме белән бусын да эшләүләре мөмкин. Кире чигенергә ярамый.

Шул вакыт Македонский алга таба тагын бер адым ясый.

— Кил якынрак, гад...

— Ташла финкаңны! — дим мин аңа.

Безнең аралар бары ике адым чамасы.

— Кызылланасыңмы, гад?!

Мин идәндә аунап яткан урындыкны күтәреп кую хәйләсе белән хәрәкәт ясап иелгән булам да тиз генә аның кулын артка каерып финкасын үз кулыма алам.

Ниһаять, уенның уйналып беткән икәнлеген икесе дә сизделәр һәм тиз генә ишектән чыгып та сыздылар.

**29 июль.** Без эштә чакта теге исерек башлар, вагонга кайтып, егетләрнең костюм-чалбарларын, күлмәкләрен алып тайганнар. Шулай итеп, аларның безнең вагонга кайтулары соңгысы булды.

**3 август.** Бүген Барига бардым. Килеп керсәм, ул да чемоданнарын әзерләп куйган.

— Җитте! Бүген үк Казанга очам. Билетым кесәдә.

— Ни булды?

— Булмый, беренчедән, салкын вагонда яшим, икенчедән, көнтөн эшләтәләр, кайттың исә юынырга су да юк...

— Аңлашылды, качасың?

— ??

Әйдә, торманың сирәге яхшы, диләр бит. Бу дөрестер.

Авырлыкка түзә алмаучылар, шыңшып йөрүчеләрнең исемлеге күбәйгәннән-күбәя бара. Иван, «Македонский», Якуп, Бари...

Китә бирсеннәр. Иләктән иләнгәннәре генә кала, димәк.

**12 август.** Яңа тулай торактан урын бирделәр. Шәп! Бүген яңа урында, җылыда рәхәтләнеп бер йоклыйм әле, ичмасам.

**27 сентябрь.** Көннәр бер-бер артлы уза тора. Бүген идарә начальнигы үзенә чакырып мине бригадир итеп билгеләргә уйлаганын әйтте.

— Иптәш Гайнуллин,— диде ул миңа.— Уфадан профтехучилище бетереп килгән яшь кадрлар килде. Алар белән эшләргә сездә сәләтлелек барын күрәм, үзегез ничек уйлыйсыз? Иртәгә үк бригаданы кабул итәсез.

Миңа ике дә уйлап тормастан эшкә куша.

— Владимир Хачатурович, белмим шул, булдырып булыр микән, чөнки барысы да яшьләр бит, аннан соң үзегез дә беләсез, тәҗрибәләре... ташка үлчим...

— Булмаса, карарбыз, ләкин булдырырга кирәк,— дип, сүземне бүлдерде ул.

Олыраклардан тагын ике сварщикны бригадага алу шарты белән риза булдым.

**28 сентябрь.** Безнең бригадага беренче объект итеп ЗЯБ поселогыннан балалар бакчасын бирделәр. Моңа кадәр бу объектка берничә бригада тотынып караган булган, әмма, ни сәбәптәндер, берсе дә тәмамлап чыга алмаган. Башлаганнар, ташлаганнар. Китерелгән монтаж җиһазлары күбесе югалып беткән, кайберләрен башка объектларга файдаланганнар. Кыскасы, безнең булачак объектыбыз ташландык хәлендә һәм безгә аны башкарып чыгарга кирәк. Аннан соң, участогыбыз буенча план үтәлешенә тоткарлык ясаучы төп нокта — шушы балалар бакчасы. Эш җаваплы, үтәү срогы кыска — 1 декабрьга тапшырырга кирәк.

Егетләремә дә шул турыда — мәсьәләнең катлаулылыгына басым ясап, алынган йөкләмәне вакытында төгәлләп чыгарга кирәклеген аңлатам.

Мин егетләрнең уйчанланган йөзләренә карыйм. Чыннан да, башкарып чыга алырбызмы? Үзем дә шикләнәм. Минем алда Башкортстаннан килгән пәһлевандай көчле уналты татар, башкорт, рус егетләре басып тора. Уналты егеттә уналты төрле акыл һәм характер. Мин аларның барысын да белергә, өйрәнергә тиешмен.

— Я, ничек, Салават Юлаев токымнары?! Булдыра алырбыз микән?

Егетләрем кыяр-кыймас кына бер миңа, бер читкә карап елмаеш-

тылар, аннан, дәррәү гөрләшеп, «Булдырабыз!» «Тырышабыз»,— диген булдылар.

Әйе, егетләр яшьләр, тәҗрибәсезләр, аның караvы, аларда күпме яшьлек дәрте янып тора! Мин моны аларның очкынланган күзләреннән күрәм. Күп эшләргә туры киләчәк. Кырда үскән яшь каенга охшатам мин аларны. Каен да бит шулай җил искән уңайга бөгелә.

Егетләр белән якыннанрак танышу теләге белән иртәгә — ял көненә барысын да үземә кунакка чакырам.

Эш көне шуның белән тәмам, таралышабыз.

Башта мең төрле уйлар белән акрын гына КамГЭС поселогына таба атлыйм.

**29 сентябрь.** Кунакларым озак көттермәделәр. Вахтерша хатынның да, күршеләрнең дә исе китте.

— Каян җыйдың шул кадәр бала-чаганы, Әхәт? Керәләр дә сорыйлар, «Без Әхәт абыйга»,— диләр. Җавап биреп бетерә алмыйм. О, менә тагын бер әртил, кабат «Әхәт абыйга» диләр.

— Нинди бала-чага булсыннар,— мин әйтәм,— минем бригада членнары, минем егетләр ич!

Көлешәләр.

Битләре кызарынып киткән егетләрем мәгънәле генә рәвештә берберсенә карашып елмаешалар.

Минем кечкенә генә бүлмәм шырпы кабы сыман тулды да куйды. Кая утыртып бетерергә? Күршеләрдән бу көнне урындык һәм савытсабаны күп ташырга туры килде.

Бүген көне буе алар белән булдым. Бергәләп төзелешне карадык.

Тагын шулай очрашырга сүз куешып, соң гына таралышабыз.

**5 октябрь.** Әйе, яшьләр белән эшләүдә синең коры, гади бригадир гына булуың җитми шул әле. Син аларга бригадир булу белән бергә олы иптәш тә, киңәшче дә, остаз да, гомумән, яшьләргә дөрес тәртип бирү өчен педагог да була белергә кирәк. Алар бүгенге көндә киләчәккә, олы тормышка беренче адымнарын гына ясыйлар бит. Шулай да, беренче адымнарын шушы олы төзелештә башлаулары нинди зур горурлык! Үз кулларың белән үз шәһәреңне — яшьлек шәһәрен — төзү ул — бәхет!

**12 октябрь.** Бүген бригадабыз белән «Чулпан» клубына концерт тыңларга бардык. Егетләргә концерт бик ошады.

**18 октябрь.** Эшләр шәптән түгел. Материал җитешми. Участок начальнигы Лев Николаевичның йөзен сакал-мыек баскан. Беләм, аның өстендә зур җаваплылык, күбрәк аңа борчылырга туры килә. Әле кичә генә хатыны Ленинградка кайтып китте. Күрәсең, монда яшәргә теләмәде, ахрысы. Киткәндә ул:

— Ә, син, Лев, КамАЗыңа өйләнеп торырсың инде,— диде дә саубуллашмыйча гына вагоннан чыкты да китте.

Менә бит ул ничек?! КамАЗ чыдамлыкны таләп итә. Түзәргә кирәк.

**20 октябрь.** Көзге көндә бик тиз караңгы төшә. Подвал яктыртылмаган, караңгы. Генподрядчикларга подвалны яктырту турында берничә мәртәбә әйтелгән булса да, нәтиҗәсе күренми. Караңгыда канализация торбаларын үткәргән чакта Илдус Каюмов ялгыш бармагына суккан. Бер кеше сафтан чыкты дигән сүз. Бу турыда ул миңа бер сүз әйтмәде. Якынрак килеп карасам, кулын аннан-моннан гына чүпрәк белән бәйләп куйган булган.

— Нигә әйтмәдең? — дим мин аңа.

— Орышырсыз дип уйладым. Эш тә күп бит, абый!

— Бар хәзер үк медпунктка!

Көчкә озаттым.

**22 октябрь.** Үземнең һөнәр мәктәбен тәмамлаганнан соң, беренче мәртәбә бригадага килгән көннәремне искә төшердем. Безнең бригадир Ходов Петр бик таләпчән кеше иде. Беренче көнне, килү белән үк, торбаларның диаметрын сораша башлады:

— Менә бу торбаның диаметры күпме була?

Мин җавап бирәм.

— Ә бусыныкы?

— Менә бу нәрсә?

— Кран.

— Ярый, яхшы, син боларның барысын да белергә тиешсең, өйрәнерсең. Без башта синең белән сөйләшик әле! Танышыйк,— диде ул.

Мин аңарга кайда туганлыгымны, ничә класс бетергәнлегемне сөйләп бирәм.

— Дөрес, синең биографияң юк әле. Ул башлана гына. Ә син беләсеңме, эшче кеше нинди булырга тиеш?

Мин аның ул соравына төгәл генә җавап бирә алмадым.

— Ә-ә-ә, туган, эшче кешенең кем икәнлеге турында белмисең шул әле син... Ярар, син моны аңларсың...

Беренче бригадир яшьләр өчен бик истә калучан була. Эштә җитез, көнкүрештә культуралы, җыйнак, пөхтә киенә белүче, һәр яктан белемле, уңай кеше булып күренә иде ул безгә. Буш вакытларда ул безгә В. Маяковский, С. Есенин шигырьләрен укый торган иде. Аның шигырьләрне яхшы итеп укый белүенә без гашыйк идек, әлбәттә. Бригадирыбызның шул яхшы сыйфатларын искә алыпмы, күбесенчә, без һәр яктан аңарга охшарга тырыштык.

Шундый хәлләрне хәтерлим: бирелгән эшне көн азагына кадәр тәвәккәлләп чыгу өчен без йөгереп кенә йөрибез. Кем әйтмешли, аяклар җиргә тими... Төшке ашка бармыйбыз, көндезге ялны эшләп уздырабыз. Олыларга моны сиздермибез. Ни өчен? Югыйсә, хурлык, бригадир биргән эшне көн ахырына бетерә алмавыбыз мөмкин. Бу — бригадирдан курку түгел, олылар безне булдыксызга санамасыннар өчен.

Шаярган вакытлар да бар иде.

Бервакытны шулай, олылар күрмәгәндә (автоген белән эретеп ябыштырырга өйрәнәбез, янәсе), үзәктән җылыту системасының торбасына тагын бер торба ябыштырып канализациягә тоташтырдык.

Җылы җибәргән вакытта бу «хәлне» — безнең «конструкция»не тапканнар бит! Системадан канализациягә байтак кына су агызылган. Без бу шуклыкны соңыннан онытканбыз. Хәер, ул көнне олылардан шәп эләкте үзебезгә. Шулай итеп, безнең автогенчы булу теләген бик тиз сүндерделәр.

**24 октябрь.** Ашханәдән кайтып, көндезге ялда вагонга җыелышып кергән генә идек, Илдус Каюмовның:

— Әхәт абый! — дигән тавышын ишетәм.

— Ни булды?

— Безнең бригада һаман шулай балалар бакчасын гына монтажлаячакмы? Югыйсә, безнең ЗЯБ поселогында тагын бер балалар бак-

часы төзелеп килә. Шунда эшләргә соңга калмыйбыз микән? — ди ул.

— Ни дип мондый сорау бирдең әле син?

Мин аның сорауны ни сәбәптән биргәнен аңлыйм һәм үзем Илдусның кызарган йөзенә карыйм. Бу көннәрдә безнең бригадага олылар тарафыннан «балалар бакчасы» дигән кушамат та тагылып өлгергән иде инде. Егетләргә бу кушамат бик ошап бетмәде, күрәсең.

— Нигә дип балалар бакчасы гына булсын ди. Менә, озакламыйча, каршыда гына тагын бер йорт салалар, мондагы эшне бетергәч, шунда күчәбез. Борын салындырырга ярамый, без кешедән киммени? Ә хәзергә хезмәтебезгә сынауны шушында үткәрергә туры килә,— дип, мин аларны юатырга тырышам.

Сүзләремнән канәгать булып, алар бер-берсенә мәгънәле генә карашып елмаешып куйдылар.

**26 октябрь.** Егетләрем эшкә күнегә башладылар. Тырышканлыкларын сизәм. Әнә бит кечкенә генә буйлы Илдус Каюмовны гына ал. Җитезлеге, тырышлыгы белән бик күпләргә үрнәк булып тора. Василий Деминский да аңардан калышмый. Шулар белән бергә эшләүче, иптәшләре тарафыннан «полк улы» булып йөртелүче Низамиев Ильяс башка характердарак егет. Ул араларында буйга да иң кечкенәсе, яшькә дә иң яше. Эшендә төгәлсезлек җибәргәнлектән, аның эшен яңабаштан эшләргә дә туры килә. Вакытны бушка әрәм итү булып чыга.

Мондый хәлләр булмасын, кабатланмасын өчен, эш җиренә җиткезеп эшләнсен өчен, мин аларга сызымнар сызып, практик эш урынында детальләрнең бер-берсенә ничек бәйләнергә тиешлеген күрсәтәм. Шулай иткәндә дә сантехника нечкәлекләре егетләремә барысына да җиңел генә бирелми. Аның каравы, миңа күп йөрергә, күп чабарга туры килә. Эштән арып кайтыла. Белмим, әгәр эшебездә һаман шулай нәтиҗәсезлек дәвам итсә, идарә начальнигының ышанычын аклап булмас, дип уйлыйм.

**1 ноябрь.** Бүген әллә нигә кәефем юк, салкын тидердем, ахры. Аяк чолгаулары юеш, киптерергә урын юк. Бүлмәдә салкын. Торак йортларга җылы бирү сезоны күптән башланган булса да, үзәктән җылыту системасы әзер булмаганлыктан, тагын бер атнага тоткарланачак. Быелгы көз бик яңгырлы булды, тездән пычрак ерып йөрергә туры килә. Чаллыдагы бу һава хәлләренә карата шаяртып «нәкъ Мәскәүдәге кебек — йортлары да биек, тик асфальты гына сыек», диләр. Җиһазлау материаллары, детальләр төялгән автомашиналарны төзелеш мәйданына кертә алмый интегәбез. Автомашиналарны тракторлар белән тарттырырга кирәк, ә тракторлар җитешми. Бирелгән заданиене срогында башкарып чыга алуыбызга шикләнәм. Шунлыктан эштән соң да калып эшләргә туры килә.

Егетләрем үзләренчә тырышкан булалар, тик тәҗрибәсезлек кенә бераз әрнетә. Минем аларның аркаларыннан сөясем, кочаклап үбәсем, кулларын кысасым килә. Тик... эмоциягә бирелергә ярамый, егетләремне бозуым, сүрелдерүем бар...

**14 ноябрь.** Эшкә соңга калып килүләр, прогул ясаулар кабатлана. Бу яман чирдән ничек арынырга соң? Менә бүген Евгений Изотов белән Фәйзи Әхмәдуллин тагын эшкә чыкмадылар. Тулай торакларына барып килергә булыр.

Башымны иеп вагон эчендә берүзем утырам. Бригадада дисциплинаны какшатырга ярамый. Бу турыда нык кына уйланырга кирәк. Шул вакыт идарә начальнигы белән баш инженер килеп керделәр.

— Но, нәрсә, командир? Канаты каерылган кош шикелле утырасың, ни булды? — диләр алар.

— Булмый, Владимир Хачатурович, мин бу яшьләр бригадасы белән бер нәрсә дә башкарып чыга алмыйм, алыгыз мине.

— Бу хакта бернинди сөйләшү дә булырга тиеш түгел. Карыйк әле, нәрсә эшләнгән, ниләр эшләнмәгән. Һәрбер этапны, һәрбер сантехник узелларны үз күзе белән күреп, тикшереп чыкканнан соң, ул, тукталып, минем кулны кысты.

— Менә бит, иптәш Гайнуллин, мин ялгышмадым, эшегездән бик канәгатьмен,— диде ул.— Беренче декабрьга кадәр шактый гына вакыт бар. Этажларда, күп дигәндә, бер-ике көнлек эшегез калган, ә менә нолевой циклга шактый көч куярга туры килә. Шулай булса да, вакыттан урынлы файдалана белгәндә эшегез күп калмаган. Эш процессы буенча нинди тоткарлыклар бар?

— Әгәр генподрядчиклар траншеялар казуда тоткарлык ясамасалар, бәлки...

— Бернинди «бәлки» дә түгел, эшне тәмамлап чыгуыгыз анысы реаль, генподрядчиклар белән траншея хакында үзем сөйләшәм. Эшегездә уңышлыклар телим,— дип, ул кәефне күтәреп китеп тә барды.

**29 ноябрь.** Ура! Без җиңдек! Начальник беренче объектыбызны вакытында башкарып чыга алуыбыз уңае белән үзе килеп җитте. Ул егетләрне котлап, безнең адреска бик күп җылы сүзләр сөйләде.

— Киләчәктә бу бригаданың тагын да катлаулырак эшләрдә үзен күрсәтә алачагына ышанычым зур, сынатмагыз,— дип бетерде ул сүзен.

Егетләремнең авызлары колакларына кадәр ерылган. Алар канәгатьләр. Әйтерсең лә безнең бүген олы бәйрәм. Күңелләр шат. Әйе, бу егетләргә хәзер ышанырга була. Тик барысына дамы? Эшнең иң кызган, иң киеренке вакытында төзелештән качып китүче Фәйзи Әхмәдуллин белән систематик рәвештә прогул ясаучы Евгений Изотовка да ышанырга буламы?..

**30 ноябрь.** Эш беткәч, бригада җыелышы ясап алдык. Фәйзи Әхмәдуллин белән Евгений Изотовның язмышын хәл итәргә кирәк иде.

— Иптәшләр, Фәйзи Әхмәдуллин ике атналык сәяхәттән соң үзен яңадан бригадага алуны сорый. Аннан соң көн аралаш прогул ясаучы Изотовны киләчәктә бригадада калдыра алабызмы? Нишлибез? Егетләр, сезнең карамакта, мин үзем генә хәл итә алмыйм, сез ничек уйлыйсыз?

Әйтерсең күкерткә ут төрткәннәрмени, малайларым дәррәү кабынып киттеләр. Каюмов Илдус белән Василий Деминский чөгендер кебек кызарышкан Фәйзигә, Женяга тагын да утлы күмер естәргә тотындылар. Чыдап кына тор.

— Безгә качаклар кирәкми!..

— Тунеядцлар бригадасы юк ич бездә, сорап торасы да юк. Килмешәкләр!

— Борылып кайтасы да калмаган, нишләп кайткан? Бер төкергән коедан яңадан килеп су эчмиләр...

— Алмыйбыз, алмыйбыз! Нәрсәгә кирәк безгә эрәмтамаклар? — дип ду куба башладылар.

Хәлнең бу кадәр кискен борылыш алачагын мин үзем дә көтмәгән идем. Малайлар әле бик озак шаулаштылар. Башларын түбән игән Фәйзи белән Женя яшьтәшләренең мондый көчле тәнкыйть

утына каршы авыз күтәреп бер сүз дә әйтерлек түгелләр иде. Үз иптәшләреннән шундый сабак алу иң зур хөкем иде аларга ул минутта.

Калтыраган тавыш белән үзләрен кичерүләрен үтенделәр. Бу минутта бик кызганыч кыяфәттә иде алар. Чыннан да, әллә бер юлга кичерергә микән? Үз фикеремне бригада членнарына җиткердем.

Соңыннан җыелыш беркетмәсенә шундый җөмләләр язылды:

«Фәйзи Әхмәдуллин белән Женя Изотовка бер ай төзәтү срогы билгеләргә һәм һәр икесен дә бригадада түбәндәге катгый шарт белән калдырырга:

а) тагын бер генә мәртәбә эш ташлау, эшкә соңга калып килү очраклары булганда, бернинди кисәтүсез бригададан куарга.

б) Женя Изотовка чираттагы квалификация разряды бирүне бер айга кичектерергә».

Җыелыш карары бертавыштан кабул ителде.

**1 декабрь.** Яңа объектка — торак йортны монтажлауга күчәбез. Ике бригадага бер йорт. Срок кыска. Көн саен тугызар-унар сәгать эшлибез. Балавыз сыгарга ярамый. Төзелеш андыйларны яратмый.

Фәйзи белән Женя йөгереп кенә йөриләр. Кайда авыр эш, шунда ашыгалар, әйтеп торганны көтмиләр.

**28 декабрь.** Торак йортны да тәмамладык. Эшләр гөрләп бара. Җиңелдән генә булмады, билгеле. Нолевой циклдагы канализацияне командировкага килгән кешеләр эшләп киткәннәр. Су тутырып карасак, иләк кебек, һәр стыктан су ага. Яңадан безгә эшләргә туры килде.

**1972 ел, 5 январь.** Идарә буенча үткән айның нәтиҗәсе безнең бригаданы икенче урынга чыгарды. 20 бригада арасыннан икенче урынга чыгу бу безнең зур җиңү.

**1972 ел, 10 октябрь.** Бүген идарәнең комсомол комитеты секретаре Людмила Анцибор тагын шатлыклы хәбәр китерде. Социалистик ярышта югары күрсәткечләре өчен ЦК ВЛКСМ органы «Молодой коммунист» журналының махсус призы «Кызыл канәфер» белән бүләкләнгәнбез! Шатлыклар зур һәм шатланмаслык та түгел. Бу призга хуҗа була алу бик җиңел генә булмады. Монда һәркемнең үз өлеше кертелгән. Партия оешмасы секретаре Виктор Степанович һәм комсомол секретаре Людмила безне җылы тәбрикләделәр, кулны кысалар. Кечкенә генә митинг булып үтте. Һәркемнең куанычтан нидер сөйлисе, әйтәсе, шатлыкларны уртаклашасы килә.

— Алдынгылар сафыннан төшмәскә!

— Сүз бирәбез!

Группа комсоргы Евгений Изотов сүз алды.

— Әйдәгез, егетләр, күршебез Сопкин бригадасын ярышка чакырабыз! Алар да комсомол-яшьләр бригадасы — тиңдәшләр. Көч сынашыйк! — дип бетерде ул сүзен.

Бригада членнары бу тәкъдимне бик хуплап каршы алдылар.

**15 октябрь.** Яңа шәһәрдә 2/08 нче йортны монтажлыйбыз. ЗЯБ поселогында да 15/17 нче йортны сафка кертү бурычы тора. Объектларның төрле җирдә булуы хезмәттә рациональ көчләрне тулы файдалануга комачаулык китерә. Хезмәт ресурсларыннан тулы файдалану һәм простой булдырмау хакында бүген бригада членнары белән киңәшләштек.

Иртәгә ЗЯБ поселогындагы йортны сафка кертү өчен кайбер өзерлекләр күрү кирәклеген искә төшереп, үземнең шунда булачагымны әйттем.

— Ә бригадир өчен кем?

— Бригадир өчен Дамир Мостафин кала,— дим мин аларга. Барысы да көлешәләр. Дамир Мостафин барысыннан да иң яше: бары унҗиде яшь. Шулай булуга карамастан, җитез, чая, эшендә һәр вакыт төгәллек.

— Гомумән, ул бүгенге көннән соң һәр вакыт бригадир ярдәмчесе булачак, белегез, иптәшләр.

— Но, Дамир — начальник! — дип елмаешалар егетләр.

Дамир, үзенә таба авызын ерып торган Изотовка карап, сүзгә кереште:

— Нигә авызың ерасың, комсорг кеше?! Әхәт абый, иртән радиаторлар өчен кронштейннар беркетергә кирәк, пистолетчик-операторыбыз юк,— диде ул.

— Нишләп юк, Изотов бар бит.

— Мин иртәгәдән бригадир булгач, эштән куам аны, вәт нәрсә...

Барысы да көләләр.

— Ай-һай, бригадирның усалына килеп эләктек! — дип шаулашалар, көлешәләр.

Дамир үзе көлми дә, елмаймый да, сүзен дәвам итә:

— Нигә көләсез, шулай... Тышта 20 градус суыклык, ә ул резина итек белән эшкә йөри. Биш минут эшли, ун минут аягын җылыта, болай эш бармый... Кызларга конфет суыртып, акчасын туздырып бетерә, итек алырлык та акчасы юк ич...

— Ә үзең соң кызларга шоколад алмыйсыңмыни! — ди аңа Вася.

— Ә мин кызлар белән чуалмыйм, лучше үзем ашыйм,— ди ул, уңайсызлана төшеп.

Автобуста кайтканда да малайларым бу темага озак бәхәсләштеләр, шаярыштылар.

17 октябрь. Кичә ЗЯБ поселогындагы йортны тапшырдык. Бригада членнарын сөендерим дип иртәрәк килсәм, Дамир миннән дә элегрәк килеп җиткән.

— Но, я, ничек эшләр, бригадир? Иртәләгәнсең...

— Бригадир беркайчан да соңга калмый. Үзең шулай дисең бит?!. Эшләр әйбәт. Кронштейннарны беркетеп бетердек. Женяны итекле иттем, суыкта каткан әтәч шикелле өшеп йөрмәс инде бүтән... Складка кичә итек китергән иделәр, Женя бәхете.

— Тагын нинди яңалыклар?

Ул кичә «Молодой коммунист» журналыннан хәбәрче килгәнен сөйләп бирде.

— Эшләгән эшләрне күрсәтеп йөрдем. Минем вакыт юк, ә ул һаман минем арттан калмый. Гаҗәпләнә. Сораулар бирә. «Кай арада өлгерәсез?», «Ничә класс бетердегез?», «Эштән соң ничек ял итәсез?» Фәлән дә фәсмәтән. Аннан соң ул кулын суза. «Кулларым майлы» дим, ап-ак куллары белән безнең майлы кулларыбызны кысмыйчан тынычланмады. Чудак кеше!

30 декабрь. Бүген идарәдә СССРның 50 еллык юбилеена багышланган тантаналы зур җыелыш. Шунда ашыгабыз. Кичке тынлыкта салмак кына яуган тәңкә карлар аша яңа шәһәрнең биек ап-ак йортларыннан сибелгән якты нурлар, әкияттәге кебек, матур җемелдәшәләр. Шушы табигый матурлыкны сизеп микән, автобус тукталышына килгәндә, кинәт кенә Женя Изотовның:

— Туктагыз әле, егетләр! Шәһәр нинди зур булып үсеп килә бит, ә?! — дигән тавышын ишетәм.

— Үзебезнең шәһәр...— дип җөпләп куя аны Дамир Мостафин. Аларның сөйләшүенә кушылып, яңа үсеп килгән шәһәргә сокланып карап торабыз. Дөрес, гаҗәп түгел, төзүче кешенең шундый гадәте бар: ул эш бетергәч тә әле, төзелеш мәйданына яңадан кайта-кайта борылып карый һәм күңелне бизи алырлык үз хезмәтенең җимешен күргән көйгә сөенә-сөенә атлый. Әйе, егетләрнең горурланырга хаклары бар. СССРның 50 еллык юбилеена багышлап алган югары социалистик ярыш йөкләмәләрен үтәүдә аларның да хезмәтләре зур булды.

Әнә бит алар, бүгенге көннең батырлары: Илдус Каюмов, Дамир Мостафин, Ильяс Низамиев, Женя Изотов, Вася Деминскийлар! Аларның йөзләре елмаюлы — үзләре төзегән йортларга сокланып карап торалар. Шатлыклар зур һәм шатланмаслык та түгел шул, алар бүген социалистик ярышта югары күрсәткечләр өчен икенче мәртәбә ВЛКСМ Үзәк Комитеты органы «Молодой коммунист» журналының махсус призы «Кызыл канәфер» белән бүләкләнделәр!

Менә бу «балалар бакчасы» бригадасы! Олыларның борыннарына шәп чиертә! Тик уңышлар белән генә масаеп калмыйк, безне алда зур эшләр көтә! Алда яңа үрләр!

Яшьлек, яшьлек!
Көтә сине, көтә
Төзелешләрнең бердәм гүләве.
Ашкынулы булсаң, юлга чык син,
Йөрәк шунсыз тынгы беләме?!.

Кушыл да кит, әнә, дулкыннарга,
Ташкыннарда бергә агарга;
Җир өстендә гөлләр үссен өчен
Янгырлары булып яварга.

............

**Гыйлемдар Рамазанов**

# ҮКЕНДЕРМӘС МИНЕ ҮТКӘН ГОМЕРЕМ...

Шагыйрь дустым, гаҗәеп мөлаем һәм киң күңелле, эчкерсез һәм саф хисле Гали Хуҗиев искә төшкән саен, мин аның белән фронтта беренче очрашуымны хәтерлим. Бигрәк тә аның ихлас тойгылы, саф хисле шигырьләрен укыганы күз алдымда тора. Менә ул тонык кына ягымлы тавыш белән укый. Аның чын күңелдән чыккан йөрәк сүзләре безне туган якларга алып китә, илдә калган якыннарны, туганнарны, сөйгән кызларны күз алдына бастыра:

**Кошлар кайта төркем-төркем**
**Агыйдел буйларына;**
**Дустын сагынып карый һәркем**
**Очар кош юлларына...**

**— Әй, кыр казы, төш яныма,**
**Полесье күлләренә,**
**Хат кыстырыйм канатыңа,**
**Илтерсең сөйгәнемә...**

Ул көннәрдән соң бик күп сулар акты инде. Шагыйрь белән без туган җирләрдә — Казанда, Уфада да күп тапкыр очраштык. Ләкин шул беренче очрашу, солдат дуслыгының туусы һаман да күңелдә, ул онытылмый да, җуелмый да.

Гали Хуҗиев мин белгән кешеләр арасында иң ихлас, иң ачык күңелле, кайнар йөрәкле, юмарт тойгылы кешеләрнең берсе иде. Поэзияне җаны-тәне белән яратучы, аңа бөтен гомерен багышлаган саф күңелле, тормыш сөючән кеше, үзенчә бер ягымлы чын дус иде ул. Дуслыгыбыз, утларны үтеп, тыныч тормышта тагын да ныгыды. Һәм нинди аяныч: шагыйрь дустыбыз һич көтмәгәндә арабыздан китеп тә барды. Әле булса моңа ышанасы килми. Хәзер инде мин аның яшенә җитеп килəм.

Ә ул шул көенчә — яшь көйгә кала бирә. Хәзер миңа ирексездән аның турында: «Ул шулай иде, ул мондый иде», дип үткән заманда язарга туры килә. Менә мин бүген шагыйрь һәм солдат дустымның дистәләгән китаплары белән сөйләшеп, серләшеп утырам. Алар миңа дусның тере, җанлы тавышы һәм йөрәктән чыккан васыяте кебек яңгырыйлар. Бу әсәрләрдә шагыйрьнең зур йөрәге — янар йөрәк, юмарт йөрәк тибә.

* * *

Гали Хуҗиевның тормыш юлы, безнең барлык замандашларыбызга хас булганча, гади дә, якты һәм зур да. 1972 елда шагыйрьгә алтмыш яшь тулган булыр иде. Ул 1912 елның 12 октябрендә Татарстанның Кайбыч районы Карамасар авылында крестьян семьясында туа. Туган җирдәге кечкенә татар авылы турында ерак Польша җирендә, Сандомир плацдармында, безнең фронтташ дустыбыз шагыйрь Мөхәммәт Садри шундый сүзләр язган иде:

**Карамасар яны кара урман,**
**Җир җиләге пешә балланып,**
**Сандугачлар сайрый, чишмә ага**
**Таң кояшы белән алланып.**

**Карамасар авылы — изге бишек!**
**Сандомирда сине белдем мин,**
**Җыр һәм штык белән сугышучы**
**Солдатыңда сине күрдем мин.**

Шагыйрь Гали Хуҗиев үзе бөтен иҗат юлы буена туган ягына, Кайбыч урманнарына дан җырлады. Шушы урманнарны ул бөтен йөрәге белән ярата иде.

Менә шушы Кайбыч урманнары шаулап торган яктан, алтын бала чагының изге бишеге булган Карамасар авылыннан булачак шагыйрь зур тормыш юлына чыкты. 1927—1930 еллар. Гали Хуҗиев җидееллык мәктәптә укый. Шул чакта, 1929 елда, ул комсомол сафына керә һәм шул көннән башлап үзенең бөтен гомерен комсомол белән, яшьлек белән бәйли. Чөнки, шагыйрь буларак, безнең дустыбыз һәр чак яшьлек җырчысы, иң яхшы, иң югары мәгънәсендә комсомол шагыйре булып калды. Ялкынлы яшьлек еллары югары уку йортына хәзерлек курсында үтә, ә 1937—1941 елларда яшь шагыйрь, эштән аерылмыйча, Казан дәүләт педагогия институтының кичке бүлегендә укый. Бу еллар Гали Хуҗиевның комсомол газеталарында, яшьләр матбугатында дәртләнеп эшләү еллары иде. «Кызылармеец» газетасында әдәби сотрудник булып эшләгәннән соң, 1934 елдан «Яшь сталинчы» исемле комсомол газетасында җаваплы секретарь һәм редактор урынбасары, 1941—1942 елларда Гали Хуҗиев ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетының пропаганда буенча секретаре булып эшли.

Бөек Ватан сугышының дәһшәтле көннәре. Танылган шагыйрь һәм журналист, күренекле комсомол эшчесе бу көннәрдә тыныч кала алмый. Сәламәтлеге бик үк яхшы булмаса да, ул үзе теләп фронтка китә һәм Воронеж, Беренче Украина фронтларында татар телендә чыгып килгән хәрби газетаның җаваплы секретаре була; биредә ул Кызыл Йолдыз ордены һәм сугышчан медальләр белән бүләкләнә.

Сугышта җиңү яулап кайткач та шагыйрь дустыбыз әлеге комсомол матбугатында озак еллар эшли. Бу елларда без аны «Кызыл Татарстан»ның үз хәбәрчесе

һәм «Яшь сталинчы»ның редакторы постында күрдек. Бик күп яшь талантларны үз тирәсенә җыя иде ул. Язучылар союзында да ул байтак еллар яшьләр белән эшләде. Гомумән, шагыйрьне яшьлектән, яшьлекне шагыйрьдән аерып карау мөмкин түгел.

* * *

Шагыйрьнең «Шатлык» исемле шигырьләр китабы 1936 елда дөньяга чыкты. Шул көннән алып утыз елдан артык вакыт эчендә шагыйрь дистәләгән китап чыгарды, татар совет поэзиясенең алгы сафында атлады. Яшьлек мәхәббәте, яшьлек романтикасы. Яңа гына иҗат юлына аяк баскан шагыйрьнең беренче китапларының төп юнәлеше шул. Ныклабрак баксаң, шагыйрьнең бөтен китапларында да шушы бетмәс-төкәнмәс яшьлек рухын, тормышка һәм заманга сүнмәс мәхәббәтне күрергә мөмкин. Яшьлек һәм батырлык. Бу ике төшенчә Гали Хуҗиев поэзиясенең пар канатлары иде. Шушы канатлар белән шигърият күгендә кыю очты ул. Бөтен гомере буена шагыйрь дустыбыз яшьлек һәм батырлык, сафлык һәм тугрылык җырчысы булды. Менә 1938 елда чыккан «Яшьлек тавышы» исемле җыентыкка кергән «Сагыну минутларында» исемле шигырь. Гадәти тема — кыз сөйгәнен сагына. Ләкин бу кыз — заман кызы, безнең көннәр кешесе. Сагындырган егет тә гади түгел, ул — солдат, чик сакчысы. Шулай итеп, бик традицион темага язылган әсәргә заман сулышы, бүгенге көннең давыллы-дәһшәтле сулышы бәреп керә:

**Казлар оча күлләреннән,**
**Моңсу кала ул яклар;**
**Алмагачлар алма коя,**
**Алтынлана яфраклар.**
**Казлар үтә безнең өстән,**
**Казлар китә тезелеп;**
**Алар күздән күмелгәнче**
**Карап калам өзелеп.**
**...Җил каерса каурыйларны,**
**Син табарсың, диләрме,**
**Кич утырып, сөйгәнеңә**
**Хат язарсың, диләрме!..**

Безнең буын шигърияткә шулай Ватанны җырлап, аны данлап килеп керде. Шул ук вакытта безнең буынга Ватанны сөюне — патриотлыкны сүз белән генә түгел, ә сугыш кырларында корал белән, кан белән расларга туры килде. Әдәбиятка яшьлек һәм Ватанны җырлап килеп кергән Гали Хуҗиев та нәкъ шундый заман сынавын үтте.

Дәһшәтле сугыш еллары утызынчы еллар поэзиясендә бер кадәр сизелә башлаган хуш күңеллелектән бик тиз арынуга китерде. Шигырь көрәш коралына, яуга чыккан халыкның сугышчан юлдашына әверелде. Шагыйрьләр утта-ялкыннарда бик тиз чыныктылар. Гали Хуҗиев поэзиясе дә бу чыныгуны тиз үтте. Шагыйрьнең сугыш чоры лирикасы — алгы чиктәге солдатның йөрәк сүзе, аның ихлас хисләре ул. Фронт шартларында туган нечкә тойгылар сугышчы йөрәгенә барып җиттеләр. Иң яхшы шигырьләрне солдатлар күңелләренә ятлап алдылар, фронттан җибәрелгән өчпочмаклы хатларда үзләренең җан сөйгәннәренә күчереп язып җибәрделәр. «Дүрт елга илендә син» (1944) шигырендәге хисләр, мәсәлән, һәр солдат өчен уртак иде:

Ерактан, Идел буеннан
Хат килә айда гына,
Китмисең, иркәм, уемнан
Булсам да кайда гына.

Баш куйсам соры шинельгә,
Чолгыйсың төшләремне;
Ә карап язгы сиреньгә,
Искә алам күзләреңне.

...Син бүген миннән еракта,
Дүрт елга илендә син,
Икебез туган туфракта,
Без үскән Иделдә син.

Иделдә дулкын тынса да,
Хисләр соң ничек тынсын!!
Аралар ерак булса да,
Йөрәкләр якын булсын.

Җиңүче гаскәрләр белән Европага азатлык алып килгән солдат-шагыйрь Эльба буйларында, Австрия Альпларында сөекле туган республикасын — «дүрт елга илен» сагына, үзенең бөтен барлыгын, бүгенгесен, кичәгесен һәм соңгы сулыш алу сәгатен дә туган туфрагы белән бәйли.

* * *

Ягымлы лирик әсәрләрендә замандашның гүзәл тойгыларын ачу белән бергә, Гали Хуҗиев совет кешесенең, гомумән югары идеяле, сынмас ихтыярлы кешенең эпик образын тудыру өлкәсендә дә бик күп эшләде. Кешенең батырлыгы, үлемсезлеге, югары идеаллары — Гали Хуҗиевның эпик поэмаларының үзәгендә торган тема шул. Шагыйрь поэма жанрында иң актив эшләүче татар шагыйрьләренең берсе иде. Ул безгә замандашның гүзәл сыйфатларын, рухи батырлыгын һәм матурлыгын күркәм образларда сурәтләгән дистәдән артык поэма һәм балладалар калдырды. Шушы эпик әсәрләргә үзенә бер төрле шигъри увертюра-кереш булып, 1944 елда фронтта «Россия» поэмасы туды. Мин әле дә бу көчле, югары тондагы канатлы шигырь белән язылган әсәрне шагыйрьнең үзе безгә ашкынып укыган чакны хәтерлим. Туган илгә, партиягә, совет солдатына гимн булып яңгыраган бу әсәрне шагыйрь әерым бер дулкынлану белән укый торган иде:

Артта калды авыр сугыш юлы,
Без әйләнеп кайттык кабаттан;
Эчтек йотылып тагын Прут суын,
Апрель җиле исте Карпаттан.

Сулышың булып исә апрель җиле,
Җиреңдә яз кабат, Россия;
Йөрәктә яз,—
Гомер китмәс яз бу,
Туган илем, азат Россия!

Фашизм белән хәтәр көрәшләрдә гомерен биргән үлемсез батырлар — Гали Хуҗиев поэмаларының иң күркәм геройлары. Үзенең поэмаларында шагыйрь бөек көрәштә һәлак булган каләмдәшләре Муса Җәлил, Фатих Кәримгә үзенчәлекле шигъри һәйкәл куйды, атаклы чех язучысы Юлиус Фучикның һәм Сталинградны яклап үлгән, рус солдаты һәм татар егете белән бергә туганнар каберенә күмелгән Испания улы Рубен Ибарруриның якты образларын тудырды. Бу әсәрләрдәге ялкын, дулкынлану, тирән хисләр укучыга да күчә. Батырларның үлемсезлеге Фатих Кәримгә багышланган поэмада аеруча көчле образларда бирелгән:

**Менә рәсемең... Ни дип сорыйсың син,**
**— Күзләреңдә нигә яшь, димсең!**
**Мин шулай дим:**
**— Син үлмәдең, дустым!**
**Син үлмәдең, шагыйрь, яшисең!**
**Синең гомерең — илең өчен яну,**
**Ә җырларың — гомер чәчәгең;**
**Безнең йөрәктәге ялкынлану —**
**Бу синең дә җирдә яшәвең.**

Сугыштан соңгы чорда язылган һәм тыныч хезмәт кешеләренә багышланган «Каенсар», «Салават күпере», «Тормышка кайту», «Янар йөрәкләр» кебек поэмаларның геройлары да — кичәге сугышчылар, алар яуда күргән авырлыкларны, бирелгән корбаннарны онытмыйлар, бүгенге көндә сугыш геройларының батырлыкларын дәвам иттереп яшиләр.

Шагыйрь кешеләргә бик игътибарлы, киң күңелле иде. Шуңа да аның дуслары бик күп иде. Үзенең иң кайнар хисләрен — иң ихлас шигырьләрен шагыйрь үзенең күп санлы дусларына багышлады. «Таныш күзләр, таныш карашлар» (1966) дигән шигырендә ул сугыш яланнарында гомерләрен ил өчен биргән каләмдәшләре Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Хәйретдин Мөҗәй, Демьян Фәтхи, Мифтах Вәдүт, Хәбрә Рахманнарны сагыну тойгылары белән искә ала. Гали Хуҗиевның утызынчы елларда башкорт даласына эшкә килгән ялкынлы комсомол шагыйре Сергей Чекмаревка һәм аягына баса алмый торган каты авыру килеш бик яхшы китаплар язган рус язучысы Николай Бирюковка багышланган балладалары бар. Иң ихлас шигырьләрен ул каләмдәш дуслары Зыя Мансур, Госман Бакиров, Риза Ишморат, Ләбибә Ихсанова, башкорт шагыйре Мостай Кәрим, җырчы Фәридә Кудашева һәм башкаларга атап яза.

Безнең арадан вакытсыз киткән шагыйрь дустыбызның Фатих Кәримгә багышланган иң яхшы поэмасы «Гражданин, солдат, шагыйрь» дип атала. Гали Хуҗиев үзе дә бөтен гомере буена чын мәгънәсендә гражданин, солдат, шагыйрь булды. Икенче бер поэмасын шагыйрь дустыбыз «Янар йөрәкләр» дип тикмәгә генә атамаган, күрәсең, ул үзе дә янар йөрәкле, юмарт йөрәкле кеше иде. Аннан безгә мирас булып калган әсәрләрендә чынлап та гражданин, солдат һәм шагыйрь Гали Хуҗиевның янар йөрәге, юмарт йөрәге тибә.

# ЛЕНИНГРАД ЯНЫНДА НЕМЕЦ-ФАШИСТ ИЛБАСАРЛАРЫН ТАР-МАР ИТҮГӘ 30 ЕЛ

## ЛЕНИНГРАД ӨЧЕН СУГЫШЛАРДА

*Ленинград стенасы янында дошманны тар-мар итүгә утыз ел тулды. Нева буендагы бөек шәһәр 900 көнлек камауга чыдады һәм җиңеп чыкты. Шушы канлы сугышларда илебезнең барлык халыклары белән бергә татар егетләре дә үзләрен сынатмадылар, арысландай сугыштылар. Түбәндә без журнал укучыларына үзәк хәрби архив документлары белән бергә Ленинград фронтының «Ватанны саклауда» һәм Волхов фронтының «Фронт правдасы» газеталарының төрле жанрдагы материалларын тәкъдим итәбез. Материалларны тарих фәннәре кандидатлары Ж. Гыйльманов, А. Айнетдинов әзерләделәр.*

„Изге бурычымны үтәрмен,— дип башлый гвардия ефрейторы Д. Искәндәров үзенең «Фронт правдасы» редакциясенә язган хатын.— Мәгърур Ленинград минем туган Татарстанымнан ерак булса да, миңа якын һәм кыйммәт ул. Бөек Ленин тудырган хакыйкать яктылыгы, халкымның азатлыгы һәм бәхете шушыннан, Нева буйларыннан килде безгә.

Сугышка кадәр мин укытучы идем. Хәзер минем кулымда сугыш коралы, фашистлар шәһәрне күп тапкырлар кинәт бәреп алырга маташып карадылар — булдыра алмадылар. Алар аны интектереп җиңмәкче булдылар — барып чыкмады.

Без блоканы өздек, ләкин хәлиткеч бәрелеш алда әле. Һәм без яңа һөҗүм сугышларына хәзерләнәбез. Ленинград янындагы сугышларда мин ике тапкыр яраландым. Үз яраларым өчен, Ленинград яралары өчен мин егерме фашистны дөмектердем. Бу бик аз. Ватаным алдында әле мин бурычлы».

### Батарея күзе

...Ленинград дошман боҗрасы белән камап алынган. Немецлар шәһәрне ачлык һәм артиллериядән атулар белән буарга маташтылар. Шушы авыр көннәрдә Ладога күле аркылы боз трассасы — «Яшәү юлы» төзелде. Зариф үзенең зенит часте белән бергә боз

трассасына чыкты. Ут ноктасы күлнең уртасына, боз өстенә урнаштырылды.

Зариф биноклен кулга алып үзенең үткен күзләре белән һаваны туктаусыз күзәтә. Бик каты салкыннар да, сөякләргә кадәр үтеп керә торган ачы җилләр дә, дошман атулары да батыр разведчик Зарифның сизгерлеген йомшарта алмадылар.

Личный состав тәүлекләр буена эшләде. Орудиеләрнең басымы, атулар нәтиҗәсендә боз шартлап, кайбер урыннарда су бәреп чыкты. Ут позициясе бик еш бер урыннан икенче урынга күчерелде. Зариф бу чакта тәүлеккә 12 шәр сәгать постта торды. Аяклар бер урында басып торганлыктан туңа, күзләр бертуктаусыз күзәтеп торганлыктан арыйлар иде. Ләкин Зариф күзәтүне туктаусыз алып барды.

Зарифның дөрес һәм ышанычлы мәгълүматлары нәтиҗәсендә аның ут алып баручы сугышчан дуслары дошманның цельләрен уңышлы рәвештә зарарладылар. Автомашиналар колоннасы боз өстендә туктаусыз хәрәкәт итеп тордылар. Ленинград яшәде һәм сугышты.

...Сугышлар Карелия бугазында башланып китте. Һөҗүм итүче гаскәрләрнең девизы: «Алга — Выборогка!» иде. Зариф та үзенең сугышчан дуслары белән анда ашыкты. Зенитчиклар су аша кичүче гаскәрләргә ярдәм итәргә тиешләр иде. Часть немец-фин самолетларына каршы бер ай сугыш алып барды. Ут позициясе һәр вакыт дошман артиллериясе һәм минометларның уты астында торды. Зариф сугышчан хезмәтне намуслы рәвештә алып барды. Өч атна эчендә ул дошманның 563 самолетын таныды. Танылган самолетлар арасында сугыш барышында батарея 29 самолетны бәреп төшерде.

Сугышта күрсәткән батырлыклары һәм кыюлыгы өчен Зариф Ерижипов (Рәҗәпов) «Батырлык өчен» һәм «Ленинград оборонасы өчен» медальләре белән бүләкләнде.

«Ватанны саклауда» газетасыннан

## Ленинград фронты герое— Гыйльми Баһаветдинов

Армиягә Гыйльмине озаткан чакта: «Батыр бул, улым, немецны рәхимсез кыйна!» дип калалар Афзал ага белән Һөмәйрә апа. Ата белән ана улларының Советлар Союзы Герое исеменә лаек була алуын бәлки күз алдына да китерә алмаганнардыр. Шөгер егете, 21 яшьлек комсомолец Гыйльми Баһаветдиновның батырлыгы турында полкташлары арасында гына түгел, ә бөтен Ленинград фронты күләмендә телдән-телгә сөйләнелә, листовкаларда, газеталарда языла.

Безнең частьлар һөҗүмгә бара иде. Алда — дошманның ике елдан артык төзегән ныгытмалары. Анда тимер-бетон корылмалар, таш надолбалар, чәнечкеле тимер чыбык киртәләр һәм башка бик күп төрле оборона корылмалары бар. Безнең артиллерия сәгать ярым буена дошманның алгы сызыгындагы ныгытмаларын утка тотты. Батареялар утны йөз метрлар чамасы дошман оборонасы тылына күчерү белән, атака рубежына тупланган сугышчылар өстеннән һавага кызыл ракета күтәрелде.

— Ватан өчен, алга! — дигән тавыш яңгырады. Озын буйлы, башына корыч каска кигән автоматлы егетнең яткан урыныннан сикереп торып алга ташланганын күреп, сугышчан тәртиптәге барлык сугышчылар берьюлы дошман өстенә ташландылар.

Ике-өч минут үтүгә атака җитәкчесе булып алга йөгергән шул ук егетнең расчеты, үз пулеметын дошман окобына урнаштырып, озын нәүбәтләр белән ут ачты. Ул өлкән лейтенант Онищенко подразделениесенең станоклы пулемет расчеты командиры сержант Гыйльми Баһаветдинов иде.

Көтмәгәндә икенче флангтан дошман пулеметы безнең һөҗүм итүчеләр юлына кыйгач прицеллы ут ачты. Бер минутка соңга калу никадәр күп кан түгү булуын яхшы аңлаган Гыйльми алты граната алып дошман дзотына таба шуышты. Бер-бер артлы ташланган гранаталар дошман дзоты амбразураларына очып, пулеметны тынчыктырдылар.

Дошман пулеметы тыну белән Гыйльми дзот башына менеп ал байрак кадады да тиз генә дзот эченә керде. Ул анда пулемет янында аунап яткан өч дошманның үле гәүдәсен күрде.

Дзот башындагы кызыл байрак барлык сугышчыларны алга чакырган төсле алланып җилфердәде. Рота үзенең герое артыннан тагын алга ташланды.

Икенче рубежда, урман чатында дошман тагын каршылык күрсәтергә маташты. Баһаветдинов «Максим»ының артына үзе ятты.

Траншея эчендәге кызу сугышларда дошман снаряды ярчыгы аның аркасын яралады. Баһаветдинов перевязкадан соң санчастька китмәде, дошманны тагын да көчлерәк ачу белән кырырга тотынды.

Кечкенә елганы кичкән вакытта дошман снайперы рота командирын сафтан чыгарды. Баһаветдинов пулеметтан нәүбәт биреп чыршы башына урнашкан дошман «күкесен» бәреп төшерде.

Аннан соң, рота белән командалык итүне үз өстенә алып, якында күренгән авылдагы дошманны штурмлау өчен китте. Алар тиздән авылдан фашистларны куып чыгардылар.

Сержант Баһаветдинов ротаны төркемнәргә бүлеп, урман эче белән әйләнеп чыгарга һәм дошманның чигенү юлларын кисәргә кушты.

Арыслан йөрәкле батыр командир Баһаветдинов, бер төн эчендә ике тапкыр яраланса да, ротаны калдырып тылга китмәде. Ул шушы сугышта автоматчылар төркеме белән дошманның өч пушкасы янына барып чыкты. Безнең автоматчыларны күреп дошман ездовойлары атлары белән бергә качарга маташсалар да, безнекеләр юлны кисеп дошманның 7 артиллеристын (3 пушка һәм атлары белән) пленга төшәргә мәҗбүр иттеләр.

Татар халкының данлыклы улы — каһарман сугышчы сержант Гыйльми Баһаветдиновка Советлар Союзы Герое дигән югары исем бирелде. Аның туган районы — Шөгер районы хезмәт ияләре һәм ул туып үскән Сарабиккул авылы колхозчылары үзләренең яшь батыр улы белән хаклы рәвештә горурланалар.

Герой туган җиренә кайта алмады. Ленинградны азат иткәч, фашистларның үз өннәрендәге сугышларда катнашты һәм бер бәрелештә каты яраланып һәлак булды.

## Батыр гвардияче

1941 елның июль аенда Смоленск шәһәрендә кызыл армеец Тимерхан Булатов башкалардан үзенең җитезлеге, батырлыгы белән аерыла, киң күкрәкле, таза беләкле, ачык йөзле бу егетнең исеме үк корыч-тимер булуын әйтеп тора.

Бер көнне дошманның һөҗүмен туктату өчен лейтенант Стояновның взводы җиде тапкыр контратакага бара. Анда Булатовтан баш-

ка Әхметов, Хисамов фамилияле татар егетләре була. Дошман юлында алар стена кебек торалар, йөзләгән фашистларны дөмектерәләр. Бу сугышта Тимерхан штык һәм приклад белән өч гитлерчыны юк итә. Икенче бер сугышта Булатов каты яраланып госпитальгә эләгә. Терелеп чыккач, Булатов Ленинград фронтына җибәрелә.

Тәҗрибәле сугышчы Булатовка сержант исеме бирелә. Отделение командиры Булатов сугышларның берсендә сафтан чыккан рота командиры Логиновны алмаштыра. Атака уңышлы тәмамлана. 1943 елда Тимерхан хезмәт иткән полкка гвардиячеләр исеме бирелә, ә сержант Булатовның погоннарына берьюлы икешәр йолдыз тагыла.

Гвардия лейтенанты Булатовның ротасы Ленинград янындагы Пулково биеклегеннән ерак түгел шоссе юлын саклый. «Бутылка» дип аталып йөртелгән бу участоктан гитлерчылар шәһәргә үтә алмыйлар. Бу урынның куркынычлы булуы дошманның өч яктан уратып кечкенә бер биеклектә урнашкан ротаны һәр вакыт пулемет, миномет утлары астында тотуында була. Шунда Тимерхан Булатовның ротасы унлаган дошман атакасын кире кайтара, үз позицияләрен нык саклый.

Ләкин гвардиячеләр бүгенге көн белән генә яшәмиләр, ә яңа һөҗүмгә хәзерләнәләр.

1944 елның январь көннәрендә Булатов ротасы беренче булып дошманның тимер чыбык киртәләрен, миналы кырларын үтеп, дошман өстенә ташлана. Булатов тәрбияләгән өлкән сержант Әхмәдуллин, кызылармеец Әхмеров бу сугышларда унлаган фрицны юк итәләр. Дошман позициясе алына һәм сугышчылар тагын алга омтылалар. Шушы җирләрдә гражданнар сугышы елларындагы кызылгвардеецлар кебек дошманны тукмыйлар һәм Ленинград өлкәсен азат итүдә дан казаналар. Тимерхан Булатовның погонында тагын бер йолдыз өстәлә. Ул Кызыл Йолдыз, «Кызыл Байрак» орденнары һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнә.

## Онытылмас көннәр

1944 елның 19 январь көнендә Ленинград фронты сугышчылары Пулково һәм Ораниенбаум районнары буенда һөҗүмгә күчәләр. Нәтиҗәдә фашистларның 7 пехота дивизиясе тар-мар ителә, күпләгән авыр артиллериясе кулга төшерелә. Моннан соң гитлерчылар Ленинградны тупка тота алмыйлар. Менә ничек башлана ул 19 январь көне лейтенант Ибраһим Галиев өчен...

— Иптәш лейтенант! Сезгә взводыгыз белән дошман тылына үтеп керергә туры киләчәк,— дип приказ бирә комбат.

Тактик әзерлек вакытында үткәрелгән өйрәнүләр үзенең җимешен сугыш кырында күрсәтә. Лейтенант Галиев взводы немецларның борын төбеннән тавышсыз-тынсыз аларның тылына үтә. Алдан билгеләнгән сигнал буенча, Галиев автоматчылары кинәттән дошман позицияләренә ут ачалар.

Траншеялардан сикерешеп чыккан гитлерчылар, кемгә атарга, кая таба качарга белмичә, буталыша башлыйлар.

Безнең подразделениеләр, дошман оборонасындагы туган бу паникадан файдаланып, һөҗүмгә күчәләр һәм, моңа кадәр ныклы каршылык күрсәткән немецларның көчен сындырып, алга омтылалар. Батальон сугышчан бурычны үти. Лейтенант Галиев үзенең взводы белән йөзләгән фашистны юк итә һәм 18 ен пленга ала. Яшь офицер комсомолец Ибраһим Галиев үз өстенә йөкләнгән бурычны сокланырлык осталык белән башкара һәм аны хөкүмәтебез II Дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкли.

## Лейтенант Вәли Галимов 131 гитлерчыны дөмектерде

Татар халкының татар фронтовикларына язган хатында шундый сүзләр бар: «Йөз немецны дөмектергәч, туктап калма, йөз дә беренчесен мушкаңа ал!»

Татар халкының данлы улы лейтенант Вәли Галимов (Татарстанның Шөгер районы, Керкәле авылыннан) ай ярым эчендә йөз немецны үтерә. Икенче көнне 101 нче фрицны эзләп позициягә чыга.

Тимер юл янында ком тутырган капчыклар артыннан немец снайперының каскасы күренеп кала. «Әһә! Син минеке!» — ди Галимов һәм винтовкасын чыбыклар, яфраклар белән маскировкаланган бруствер өстеннән немец каскасы күренгән ноктага төзәп куя. Каска тагын бер күтәрелеп чума, бу юлы фрицның күзләренә терәгән бинокль пыяласы ялтырап күренеп кала. Галимов үзенең ярдәмчеләренә «дәшмәгез» дигән ишарәне аңлатып, күз кысып куя. Ләкин немецның бер күтәрелеп, бер чума торган башы, аның куркаклыгы көләсене китерә: «прх!» итеп куя бирәү. «Көлмәгез, шайтаннар!» — дип кисәтә Галимов. Ул фрицка тагын бер тапкыр күтәрелергә һәм үзен сизмәүләрен күреп тынычланырга мөмкинлек бирә. Тынычланган фриц кыюланып китә, башын тагын да югарырак күтәрә һәм... винтовка шартлавы артыннан ук кыйгаеп авып төшә. «Менә хәзер көлегез инде!» — ди Галимов иптәшләренә.

101 нче үтерелгән фриц артыннан шулай ук 102 нчесе, 103 нчесе, 104 нчесе... тезелеп китә. Туры килгәндә Галимов винтовканы автомат, кул пулеметы белән алыштыра, фрицларны берәмләп кенә түгел, икешәрләп, өчәрләп, күпләп кырып ташлый.

Томанлы көннән файдаланып, Галимов бер көнне кул пулеметы алып, немец позицияләренең алдына килеп урнаша. Җиде фриц үзара нидер гагылдыйлар. Араларында берсе, калын мыеклы офицер, кулларын әреләнеп кенә кесәләренә тыгып тора. Галимов пулеметны каен ботагына җайлап, ярдәмчесенә: «Миша, тотып тор пулеметны, чайкалмасын!» — ди. Үзе фрицлар өстенә бил тиңентен төзәп, берьюлы ярты диска җибәрә. Офицер кинәт кулларын кыяфәтсез чайкап авып төшә. Немецлар егыла башлагач, Галимов аларның аякларына төзәп ата.

Җиде немецтан икәве генә качып котыла. Шунда ук исләрен җыеп, фрицлар Галимов торган урынга рота миномётыннан котырган ут ачалар. 47 мина ташлыйлар фрицлар, тирә-яктагы каеннар теткәләнеп бетә, бруствернын яртысын мина җимереп китә. Галимов үзенең ярдәмчесе Миша Лукъянов белән дискаларны атып бетермичә торып позициядән китмиләр.

Галимовны снайперларның армия күләмендәге слетында «Батырлык өчен» медале белән бүләкләгәндә ул инде 106 фрицны дөмектергән була.

Аның данлыклы снайпер исеме армия күләменнән тыш та, тылның ерак почмакларына барып җитә. Моңарчы таныш булмаган кешеләр аңа соклану һәм котлау хатлары язалар.

«Иптәш Галимов, сез яраланмадыгызмы, сәламәтлегегез, кәефегез ничек?» — дип кайгыртып яза аңа таныш түгел бер кыз.

V класста укучы Рая Пыховская Уралдан яза: «Кадерле Вәли Шакирович, сезгә, сөекле Ватаныбызның данлыклы сакчысына хат язуым белән мин горурланам. Сезнең сугышчан хисабыгызда 129 үтерелгән фриц барлыгын белдем. Данлыклы эшегезне дәвам иттерегез, мөкатдәс совет җирендә немец еркычларының исен дә калдырмагыз!»

Лейтенант Галимовның сугышчан исәбендә 131 дөмектерелгән фриц. Ләкин бу аның рәсми исәбе. Снайперлыгына кадәр ул Волхов фронтындагы бик күп каты сугышларда, гитлерчыларны Тихвиннан куып чыгаруда, аларны Волхов елгасы артына ыргытып ташлауда катнашкан. Винтовка һәм штык белән ул анда бик күп фрицларның башына җиткән. Аның 131 исәбе менә шушы сугышларда кырган фрицларның дәвамы булып китә.

Үзенең снайперлык хезмәтен ул яшь сугышчыларга өйрәтә. Үзләренең сугышчан исәпләрендә дистәләрчә үтерелгән фриц булган Локтионов, Касимкулов, кече лейтенант Шестопалов һәм башкалар — аның шәкертләре.

Иптәш Галимов хезмәт иткән частьның командованиесе батыр снайперның атасы Шакир абзыйга улының сугышчан батырлыгы белән котлап махсус хат язды. Үзенең туган авылы Керкәледән командование исеменә Шакир абзыйның җавап хаты килде. Бу хатта түбәндәге сүзләр бар.

«Минем дүрт улым Ватан сугышының төрле фронтларында немец илбасарларына каршы сугышалар. Бар да коммунистлар һәм комсомолецлар. Күптән түгел кече улым Гатаның «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнүен ишетеп шатланган идем. Инде Вәлинең шундый зур батырлык белән дан алуы — минем өчен шатлык өстенә шатлык».

Лейтенант Галимов фрицларны берәмләп, парлап, күпләп юкка чыгаруын 1944 елны январь аендагы сугышларда дәвам итә.

## Татарстан кызлары

Казан шәһәренең Беренче гинекология клиникасында эшләүче профессор Зәйнәп Шәйхиевна Гыйләҗетдинованы күргәч, аның Ленинград блокадасында булуын күз алдына китерү дә кыен. Шат йөзле, тормышны яратучы, яшәү яме таба белүче кеше ул. Ә үзе сугыш, ачлык күргән, меңнәрчә кешеләрнең үлемен күргән.

Хәрби врач Гыйләҗетдинова 239 нчы укчы дивизиядә була.

18 январь көнендә Синявино районында ике яктан һөҗүм итеп килгән Ленинград һәм Волхов фронтлары очраша. Гыйләҗетдинова бу көнне әле дә хәтерли — йөзләгән яралы сугышчылар аның кулы аша үтә. Аның өчен һәр сугышчы кадерле. Ә каты яраланганнарның күңелен табу, тормышларын саклап калу җиңел түгел. Ләкин 26 яшьлек Зәйнәп ару-талуны белми, дошман бомбаларының шартлавын да ишетми.

Зәйнәп Шәйхиевна өчен иң кадерле минутлар — сугышчыны үзенең частена озату. Күпме рәхмәтләр әйтелә!..

* * *

Дошман блокадасының авыр шартларын гаять зур чыдамлылык белән кичерүчеләр арасында Татарстан кызлары: Мәрьям Кадыйрова, Факиһә Юсупова, Заһидә Вафиналар да бар. Бу кызларның батырлыгын сурәтләп һәм аларны 8 Март (1944 ел) белән котлап «Ватанны саклауда» газетасында мәкалә басылып чыга. Бу өч кыз зенит артиллериясе частьларында хезмәт итәләр. Алар дошманның һава һөҗүмен кайтару вакытында үз бурычларын төгәл үтиләр.

Кызларга ял вакытында да эш күп. Сугышчан дусларының гимнастеркаларын ямыйлар, керләрен юалар, тәмле-тәмле ашлар пешерәләр.

## Ике орден кавалеры



1943 елның җәендә ак төннәр башланды. Аны безнең очучылар оста файдалана. Еракка хәрәкәт итүче бомбардировщиклар эскадрильясе командиры кече лейтенант Н. Корбанов Ленинград өлкәсендә урнашкан дошман аэродромын бомбага тотарга дигән приказ алды.

Берничә минуттан Корбанов экипажы һавада иде. Ике мең метр биеклектә самолет уңышлы рәвештә фронт линиясен үтте. Цельгә җитәр алдыннан экипаж командиры Корбанов үзенә бирелгән биеклектән дүрт йөз метр югарылыкка күтәрелде. Шуннан соң ул, моторларны туктатып, цельгә таба тавышсыз атылды. Штурман, команда бирелгәч, бомбаларны дошман аэродромына яудырды. Аннан тагын бер атака ясалды. Нәтиҗәдә: биш урында янгын күтәрелде, шартлау тавышлары ишетелде...

Ак төннәр вакытында уңышлы очышларның бу беренчесе түгел иде. Кызыл Байрак һәм Ватан сугышының II Дәрәҗә орденнар кавалеры Н. Корбанов экипажы июнь төннәрендә тугыз очыш үткәрде. Шуларның дүртесендә ул гүзәл нәтиҗәләр күрсәтте. Туры төшерелгән бомбаларның куәтле ударлары белән дошманның бик күп складлары һәм амбарлары көлгә әйләндерелде. 1944 елның һөҗүмнәре алдыннан батыр татар егете Корбанов 150 дән артык сугышчан очыш ясады. Аның Ленинград янында дошманны кыруда үз өлеше бар.

«Фронт правдасы» газетасыннан

## Онытылмаслык тантана

Җиңү көннәрендә сугышчылар кабат-кабат дәһшәтле көннәрне хәтерләренә төшерәләр. Гвардия өлкән лейтенанты К. Яһудин (ике тапкыр Кызыл Йолдыз ордены, I, II Дәрәҗә Ватан сугышы орденнары һәм «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән) һәм гвардия сержанты З. Гайфуллин (II Дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм «Батырлык өчен», «Ленинград оборонасы өчен» медале белән бүләкләнгән) менә нинди истәлек язалар.

«Без тугыз йөз көн буена ленинградлылар белән кулга-кул тотынып, җилкәгә-җилкә торып Нева ярындагы шәһәрне саклап, явыз фашистларга каршы сугыштык. Без бөтен кайгыларыбызны, шатлыкларыбызны бергә уртаклаштык. Бер теләк белән Ленинградны саклап калырга, дошманны тар-мар итәргә һәм җиңүне яулап алырга омтылдык.

Шушы теләк һәм уй белән Неваның сул як ярында дошманның боҗрасын өздек һәм аны җиңдек. Ленинградлыларның бәхете өчен Синявино биеклегендә, Пулково янында, Карель бугазында сугыштык.

Безнең һәркайсыбыз уннарча тапкыр атакага барды. Безнең һәрберебез солдат бәхетенә төшә торган авыр сынауларны кичерде. Ленинградлыларның туган шәһәрне саклауда батырлыкларын онытмабыз. Алар ачлыкта, ял итүне белмичә, тәүлекләр буена артиллерия уты астында станоклар янында безне корал белән тәэмин иттеләр. Бу безгә көч бирде һәм яңа батырлыкларга рухландырды.

8 июльдә иртән сәгать 9 да (1945 ел) без кабат шәһәр урамнарына аяк бастык. Без шәһәр урамнарында ленинградлылар каршында үзебезнең бурычыбызны намуслы үтәвебез белән горурланып йөрдек. Күп сугыш кырларында җилфердәгән сугышчан байракларыбыз батыр ленинградлыларны котлыйлар. Пулково биеклегеннән алып Сарай мәйданына кадәр ленинградлылар чын күңелдән безне котлыйлар. Алар безне йөз меңләгән чәчәк букетлары белән күмделәр, туган уллары итеп, иң кадерле хөрмәт күрсәттеләр, безне кочтылар: «Рәхмәт сезгә, гвардеецлар-бөркетләр, сез рус коралының данын арттырдыгыз»,— диделәр.

Рәхмәт хөрмәтегезгә, батыр ленинградлылар!»

«Ватанны саклауда» газетасыннан

## Повар-сугышчы

№ берләшмәсенең ял йортында торып ял итеп киткән сугышчылар һәм командирлар үзләренең бу йорт турындагы фикерләрен һәм тәкъдимнәрен ял йортының аерым дәфтәренә язып китәләр. Бу язмаларның һәрберсендә аеруча урынны ял йортының ашханәсе һәм повары тота.

«Без ял иткәндә аш һәр көнне төрле, туклыклы һәм бик тәмле булды».

«Повар безгә бик ягымлы һәм кунакчыл булды. Ул безне беренче класс ресторан ашлары белән сыйлады».

«Повар безне һәр вакыт туклыклы, тәмле сыйлавы белән генә чикләнмәстән, һәркайсыбызга килеп, ашны тагын да ничек яхшыртырга кирәклек турында фикерләр һәм киңәшләр сорап торды».

«Ашханәдә һәм кухнядагы чисталык мондагы хуҗаларның ял итүчеләр турында аеруча кайгыртучанлык күрсәтүләрен әйтеп тора».

Бу язмалар эчендә шулай ук ял йортының эшен тикшергән командирларның имзалары бар һәм алар да шулай ук ашханәнең эше турында югары бәя бирәләр. Атаклы повар Казанның зур гына бер эшчеләр ашханәсендә эшләгән Хәбибулла Имаметдинов булып чыкты.

— Сезне монда бик яраталар икән, Хәбибулла абзый!

— Яманлаганнары юк. Үземә килгәндә, мин эшемне намус белән үтәргә ятатам. Мин үзем сугышларда шактый булдым, тормышның ачысын да, төчесен дә татыдым. Мин сугышчыга нәрсә кирәклеген беләм,— диде ул.

— Нинди сугышларда булдыгыз?

— Мин Ленинградны саклау сугышларының башыннан алып диярлек катнаштым. Пулково обсерваториясе янында сугыш белән ясалган разведкада катнаштым. Ленинград янында минометчы булып сугыштым. Немецлар безне чолгап алырга теләгәннәр иде, бирмәдек. Аннары без немецларны Тихвиннан бәреп чыгардык...

Менә дигән повар, батыр сугышчы Хәбибулла иптәш Имаметдиновның Кызыл Армия сафындагы хезмәт юлы, кыскача гына итеп әйткәндә, менә шундый. Кыскасы, кая гына, нинди эшкә генә куйма, булдыра торган егет ул!

Административ хезмәт өлкән лейтенанты
Ә. ФӘЙЗИ.

## Комсомолец Фасих Гыйльмановның батырлыгы



Безнең подразделение халык яши торган пункт янында дошман белән очрашты. Пулеметчик комсорг Гыйльманов, сугышчан бурыч белән танышкач, ротаның комсомолецларын җыйды. Беседа сугыш вакытындагыча кыска иде.

Комсомолецлар пехотаның сугышчан тәртибендә үзләренең урыннарын алдылар. Атакага сигнал булды. Гыйльманов үзенең «Максим»ын алга тәгәрәтеп, юл янына уңайлы позициягә урнаштырды. Аңардан йөз метр ераклыкта дошман пулеметы ата башлады. Гыйльманов ату белән җавап бирде. Немец пулеметы мәңгегә тынды. Ләкин сул яктан дошманның икенче пулеметы ата башлады. Гыйльманов пулеметын уңайлы позициягә урнаштырып, дошман пулеметына чират бирде. Немецларның пулеметы сафтан чыкты.

Батыр пулеметчик Гыйльмановны гитлерчылар күрделәр һәм аңар автоматлардан ут ачтылар. Фасих Гыйльмановны дошман пулясы авыр яралады.

Батыр комсомолец дошманның контратакага җыенганын күрде. Гыйльманов актык тамчы канына кадәр дошманга каршы сугышырга карар итте. Гитлерчылар совет пулеметчысын үлгән дип санап, безнең подразделениенең тылына әйләнеп үтмәкче булдылар. Ләкин җиңүгә ышанган комсомолецның кайнар йөрәгендә дошманга каршы нәфрәт яши иде. Ул бөтен көчен җыеп пулеметка тотынды һәм контратакага килүче фашистларны кырды.

Гыйльмановның иптәшләре ярдәмгә килеп өлгергәч, аны кан эчендә күрделәр. Гыйльмановтан ерак түгел 30 лап гитлерчының үле гәүдәләре ята иде.

Безнең подразделение авылга бәреп керде, һәм Фасихның каны өчен комсомолецлар фашистлардан рәхимсез рәвештә үч алдылар.

## «Ленин шәһәре өчен сугышларда татарлар»

Ленинград фронтының политик идарәсе татар телендә «Ленин шәһәре өчен сугышларда татарлар» исемле брошюра чыгара. Брошюрада басылган очерклар данлыклы татар сугышчылары, Ленинград фронты геройлары турында сөйлиләр.

Танк йөртүче механик, өлкән сержант Хәмидуллин сугышта дан яулап ала. Ул үзенең дәһшәтле машинасы белән фашист илбасарларны рәхимсез рәвештә юк итә. Сугыш операцияләренең берсендә дошманның мина кырлары аркылы, снарядлар белән казылып беткән, сазлык җирләр аркылы үтәргә кирәк була. Танкист Хәмидуллин, юлдагы барлык тоткарлыкларны җиңеп, үзенең машинасын һич тә ялгышмыйча, туп-туры дошман дзоты өстенә алып бара. Аннан сикереп чыккан бер немец танкның чылбырына граната ыргытмакчы була. Ләкин Хәмидуллин фашистны юк итә һәм дзотны таптап үтеп, анда булган гитлерчылар группасын күмеп калдыра. Юлны дәвам итеп батыр танкист дошманның тагын ике дзотын, берничә землянкасын җимерә һәм ике пушканы сафтан чыгара. Шул арада немецлар да Хәмидуллин танкысын сафтан чыгаралар — мотор эшләми башлый. Батыр йөрәкле егет куркып калмый, тиз-тиз моторны карый һәм ток килә торган чыбыкның өзелгәнлеген күреп ала. Шул арада немецлар танкны камап алалар.

— Бирел! — дип кычкыралар фашистлар.

Ләкин шул чакта машина яңадан эшли башлый һәм бөтен көче белән алга омтыла. Куркуга төшкән немецлар төрле якка сибеләләр.

Татарстанның батыр улы Камил Акчурин да Ленинград янында дан казана. Татар халкының турылыклы улы Заһит Рәхмәтуллин үзенең частенда снайперлык хәрәкәтен башлап җибәрүчеләрнең берсе була һәм кырып ташлаган фашистларның санын көн саен арттыра бара. Заһит Рәхмәтуллин үзенең төз атылган пулялары белән 200 гә якын немец солдатын һәм офицерларын юк иткән. Ленинград фронты командующие Советлар Союзы маршалы Л. А. Говоров татар халкының тормышын якыннан белә. Ул үзе дә безнең якташыбыз, I империалистик сугыш елларына чаклы Алабугада реаль училищеда укый. Л. А. Говоров татар сугышчылары турында болай яза: «Татар солдатларының сугышчан эшчәнлекләре иң югары бәягә лаеклы. Алар, үзләренең рус туганнары һәм Советлар Союзында яши торган башка халыкларның уллары белән бергә, терсәккә-терсәк булган хәлдә, Ватаныбызның намусы һәм бәйсезлеге өчен, бөек Ленинград өчен немец илбасарларга каршы батырларча сугыштылар. Ленинград фронты гаскәрләре составында алар блокада көннәрендә дошманга каршы үз-үзләрен аямастан нык сугыштылар. Ленинград янында, Карелия тамагында гитлерчыларны тар-мар итү сугышларында һәм, ниһаять, Советлар Эстониясен азат итү өчен барган соңгы сугышларда батыр һәм үтә кыю хәрәкәт иттеләр...

Татар сугышчылары сугыш кырларында үзләренең иң яхшы сыйфатларын — Ватанга чиксез бирелгәнлек, дошманга аяусыз нәфрәт, җиңеп чыгу өчен үлемнән курыкмау, батырлык, кыюлык, чыдамлык һәм теләсә нинди авырлыкларга да түзү сыйфатларын гәүдәләндерәләр. Алар Совет Ватаны алдындагы үзләренең хәрби бурычларын намус белән үтиләр...

Советлар Татарстаны немец-фашист илбасарларга каршы чын совет патриотларыча кыюлык һәм фидакарьлек белән көрәшкән фронтовик уллары белән горурланырга хаклы».

Габдрахман Әпсәләмов

# КОЯШ ТОТЫЛГАНДА ТАБЫЛГАН ХӘЗИНӘ

1973 елның январь-февраль айларында берникадәр вакыт миңа «эшсез» торырга туры килде. «Казан утлары» журналында «Күк күкрәр» романын басу тәмам хәл ителеп бетмәгән иде әле.

Әсәрне, бигрәк тә зур әсәрне, журналда бастыруның төп максаты шунда, син гүя аны чакма ташка куеп, ныклыгын сыныйсың, меңләгән укучыларның карашын, фикерен беләсең. Укучы әсәрне ничегрәк каршы алыр, ашыккансың, тагын бераз эшләргә кирәк иде димәсме? Бигрәк тә Ленин темасы кебек аерата җитди темага тотынганда укучының фикере принципиаль әһәмияткә ия. Бездә бит бу теманы яктырту тәҗрибәсе зур түгел, ә укучының күзе үткен, ул күпне күрә.

Яшьрәк чагымда мин бер әсәремне тәмамлауга, шунда ук икенчесенә тотына идем, басылып чыкканын көтеп тә тормый идем. Күңелдә ышану шул кадәр көчле булганмы, темасы үзгәлекме, тәҗрибәсезлекме моны китереп чыгарган? Әмма хәзер саграк эш итә башладым. Яңа әсәргә тотынырга атлыгып тормыйм, картларча сабыр фикер йөртәм: янәсе, алда гомер булса, язармын әле. Ә монысын тәмамларга кирәк, ярты юлда калмасын.

Шул, «эш юктан» иске кәгазьләремне актарырга тотындым, басылып чыккан мәкаләләремне күздән кичердем. Әдәбият һәм публицистика мәсьәләләре буенча шактый күп нәрсә язылган икән. «Җил капканы ачканда»ны кабат укып чыктым. Моңарчы әдәбиятчылар аның белән кызыксынмаган иде, хәтта «Ялкын» журналында өзекләре басылып чыккач та игътибар итүче булмады. Бары тик соңгы вакытта гына бер әдәбиятчы иптәш кульязманы үзе сорап алды һәм укып чыккач: «Бу истәлекләрне язган өчен рәхмәт»,— диде. Шуннан минем башка уй килде: нигә бүтән истәлекләрне дә тәртипкә китермәскә? Алар вакытында язылган, мин алардан файдаланганмын да. Мөстәкыйль әсәр булмасалар да, язучының иҗат лабораториясе материаллары сыйфатында әдәбият белән кызыксынучыларга кирәк булуы мөмкин.

Китап укучылардан миңа байтак хатлар килә. Теге яки бу әсәрегезне ничек яздыгыз, материал каян алдыгыз, китаптагы геройлар бүген дә исәннәрме, аларның адресларын бирә алмыйсызмы, дип сорыйлар. Менә шундый хатларның берсе:

«...Мин үзем Пермь өлкәсе, Барда районыннан... Авылда сигезенче классны тәмамлагач, Осага, авыл хуҗалыгы техникумына укырга килдем. Зоотехник булачакбыз...

«Ак чәчәкләр» романын берничә тапкыр укып чыктым. Минем андагы геройлар: Гөлшәһидә, Мансурның хәзерге вакытта Казанда яшәү-яшәмәүләрен беләсем килә. Ул геройлар үзләренең чын исемнәре белән язылганмы? Болар белән мин генә түгел, безнең бүлмәдә торучы башка татар кызлары да кызыксына. Хәзер бер кыз шул романны укый. Әгәр минем хыялым тормышка ашкан булса, мин, һичшиксез, Гөлшәһидә, Мансур белән танышкан булыр идем. Мин бит Казандагы театр училищесына керергә хыялланган идем... Мөмкинлек булу белән үземнең теләгемне үтәргә тырышачакмын... Гөлзадә».

Кайбер тәнкыйтьчеләр мондый хатларны «җитдигә» санамый, янәсе, аларның авторлары эшләре юклыктан гына язучыга шундый беркатлы хатлар язалар. Мин үзем башкачарак фикердә торам. Сүз юк, укучы бер генә төрле түгел, аның таләбен һәм зәвыгын өйрәнгәндә материалны мөмкин кадәр киңрәк күләмдә алырга кирәк. Ләкин бүген укучыларның хатларын бер җиргә туплау мәсьәләсе хәл ителмәгән бит. Ә укучы фикерен бары тик фактик материал нигезендә генә ачыкларга мөмкин.

Мин алай уйлыйм, мин болай уйлыйм дигән сүзләрнең бәясе, кем генә әйтсә дә, әллә ни кыйммәт түгел. Һәрхәлдә, укучыларны «җитдиләр һәм җитди түгелләр» дип икегә бүлү — үзе үк җитди мәсьәләне артык гадиләштерү генә. Әгәр төптәнрәк уйласаң, тегеләре дә, болары да безнең укучылар лабаса. Алыгыз шул ук Гөлзадәне. Хаты беркатлырак, ләкин ул ихлас күңелдән язылган, хисләре саф, дөньяга карашы якты. Бүген ул студент, иртәгә — терлекчелек өлкәсендә белгеч. Ихтимал, яшьлек хыялы да тормышка ашар, дәртле тавышы, зур сәхнәләрдә булмаса да, үзешчән сәхнәләрдә яңгырар. Ничек инде, «җитди түгел» дип, шундый укучыдан кул селтисең? Аннары югары зәвыклы, матур әдәбиятны тирәнтен аңлый торган укучыны тәрбияләү эше дә безнең өстә тора бит. Берәү дә безгә күңелебез теләгән, коеп куйган, үзе зәвыклы, үзе әдәбиятны тирәнтен аңлый торган укучылар тәрбияләп бирмәс...

Минем бу язмаларым барысы бер әсәргә — «Ак чәчәкләр»гә материал туплау турында. Медицина дөньясы минем хыялымны күптәннән уйнатып килә иде. «Алтын йолдыз»да, «Газинур»да мин аларны беркадәр биреп тә карадым. Ләкин врачлар, үзенең темасы белән, аерым әсәр сорый иде. Материал җыю һәм, беренче чиратта, очерк язу нияте белән Әгерҗегә, тимер юл больницасына киттем. Анда минем авылдашым — хирург Әхмәт абый Айдаров эшли иде. Бардым, күрдем, больницасында йөрдем, операция ясаганын карап тордым. Бала чакларны искә төшердек. Ләкин... очерклык та материал җыя алмадым. Дөресрәге, медицина дөньясы үзенең зурлыгы, катлаулылыгы белән мине куркытты. Мин ул дөньяны бик өстән белә идем.

Шулай еллар үтте. Ниһаять, минем үземне больницага илтеп салдылар...

## Беренче дәфтәрдән

(Май — август, 1958 ел)

Бу язмалар шифаханәдә туды. Миокард инфаркты кичергән кешеләр беләләр, сиңа өстәл янына килү түгел, караватыңда утырып торырга да рөхсәт ителми, хәтта төнлә ян-якка борылма, дип кисәтәләр... Язуларны чалкан ятып, дәфтәрне күкрәк өстенә куеп, карандаш белән генә сызгалаган идем. Бу, туры мәгънәсендә, көндәлек түгел, шуңа күрә вакытын күрсәтеп бармадым. Тик кайбер урыннарда гына көннәр теркәлеп узылган.

Шифаханәгә — Алтынчы август урамына — мине ашыгыч ярдәм машинасы белән илтеп салдылар. Өйдән алып чыкканда Габдрахман Минский белән Хөршидә бар иде. Хәлем авыр иде, нindidер сөрем эчендә яткан кебек яттым. Кайбер вакытларда миңа кояш тотыла кебек тоела иде.

Бала чакта мин кояш тотылганны берничә тапкыр күрдем. Ап-аяз көн кинәт караңгылана башлый, этләр өрә, мал-туар борчыла, кешеләрнең йөзләрендә курку. Корым сөртелгән пыяла белән кояшка карыйсың: аның инде яртысы гына калган, ул һаман кими, җиһан әллә нинди куркыныч төскә кереп бара, күңелгә шом тула, карчыклар кычкырып елый...

Шифаханәдә дә нәкъ шул хәл кабатлана иде кебек. Мин күзләремне йомам, шунда ук ачам да: көн тагын да караңгылана төшкән, кояшның инде чиреге дә калмаган. Минутларны саныйм бугай, күрәсең, бик кыска вакытка аңымны да җуям. Мин инде караңгы баз төбендә ятам, имеш, торырга маташам, булмый. Аннары маңгаемда сестраныңмы, врачныңмы салкын кулын тоям, күземне ачам... Атнаун көн мин шул хәлдә ятканмын. Күз алларым яктыра башлагач, дәфтәр белән карандаш соратып алдым...

Газаплануларымны күп язмаганмын. Ник? Тәгаен генә әйтә алмыйм. Язуларны бер дә укыдым, ике дә укыдым, өч тә. Каян бу кадәр оптимизм?.. Ул чакта миңа илле дә юк иде әле. Күрәсең, алда

гомер барлыгына күңелдә нык ышаныч булган, төшенкелеккә бирелмәгәнмен, бу дөнья белән алыш-бирешне өзәргә уйламаганмын. Эшне миннән өлкәннәр дә эшләп бетерә алмаган алуын, әмма мин бик аз эшләдем бит әле. Бу вакытта минем «Ак төннәр» повестем, «Алтын йолдыз», «Газинур» һәм «Сүнмәс утлар» романнарым басылып чыккан булса да, болар миңа бик аз тоела, минем яңадан тизрәк иҗат эшенә утырасым килә иде. (Бүген иске көндәлекләремне күчерергә утырам икән, мин моны гади һөнәрче кебек кенә эшләмим, алай булса, машинисткага гына бирер идем. Хәзер мин, яхшымы-яманмы, җиде роман авторы инде. Димәк, күп нәрсә уйланган, тәҗрибә тупланган. Шул югарылыктан артка борылып карасаң, элек томанлы булган нәрсәләр дә хәзер ачык төс ала. Ләкин шунысы шатландыра, үткәнем белән бүгенге көнем арасында бернинди идея каршылыклары булмаган. Бу хәтта көндәлекләр кебек үтә субъектив язмаларда да чагылмаган.)

Башта дүрт кешелек палатада без өчәү яттык. Сул якта, тәрәзә янында, Исмәгыйль Хәлиуллин (Татсоюзның элекке җитәкчесе), аңа каршы Акташ райкомының секретаре. Ишек төбендә — мин, миңа каршы карават әлегә буш. Минем палатадашларның икесе дә торып йөри ала. Билгеле, беренче көннәрдә мин беркем белән дә сөйләшә алмадым, алар да минем яннан сүзсез генә үтеп китәләр иде. Аннары таныштык.

Безнең палатага тәбәнәк кенә, юантык кына бер авыру кергәли иде. Аңа карыйсың да, мәшһүр артист Игорь Ильинскийны күргән төсле, ул сүз әйтмәс борын ук, елмая башлыйсың. Аның гүя тәне түгел, кашы-күзе, борын-иреннәре сөйли һәм син барысын да төшенәсең. Александр Александрович дип йөртәләр, подшипниклар заводының директоры. Шул кадәр туры килер дә икән, гүя ул подшипниклар кебек тавыш-тынсыз һәм гаҗәп җиңел әйләнә. Авыруы да гүя шулай шома гына узган. Башта аңарда инфаркт түгелме дип шикләнгәннәр. Алай булып чыкмаган.

— Шома гына әйләнеп үттем мин ул инфаркт дигәннәрен,— диде ул, һәм авыз-борынын шундый итеп хәрәкәтләндерде, без елмаймыйча түзмәдек.— Йөрмә, утырма, диделәр. Миңа нәрсә, атаклы ялкау кебек, сузылып ята бирәм. Үзем заводта ялкауларны пешерә идем, ә монда сүз әйтүче юк. Менә рәхәт, мин әйтәм, нинди хәлләр була икән дөньяда. Шәп нәрсә бу инфаркт дигән нәмәрсәкәй,— диде Александр Александрович һәм авыз-борынын, кашын-күзен шундый уйнатып алды, без яңадан елмаеп куйдык.

Безнең палатада сестра нигәдер бик озак күренмәде. Ниһаять, килеп кергәч, гаепле сыман итеп куйды:

— Сез инде миңа үпкәләмәгез, каты авырулар күп, ә сезнең палата кырыйда — Сахалинда.

Моңарчы мин безнең палатаның кайда икәнен күз алдына китерә алмый идем.

Үз өеңдә, сәламәт кешеләр арасында, сиңа бар дөнья сәламәт кебек тоела. Авырулар турында уйламыйсың да, уйласаң да, ничектер бик җиңел уйлыйсың. Шифаханәдә башка. Менә Исмәгыйль Хәлиуллин, кара халатын ябынып, әйе, кимичә, шәл кебек ябынып, йоклый алмыйча, төннәр буе караңгы коридорда йөренә. Ятып та тора алмый, утырып та. Тәүлегенә өчәр-дүртәр тапкыр өянәге кузгала. Уколлар кадап, кислород иснәтеп кенә аңга китерәләр икән.

Аның авыруы — сугышта яралану нәтиҗәсендә. «Миндә җитмеш җиде төрле авыру бар»,— диде ул, чак-чак тын алып. Шул хәлендә дә ул сер бирмәскә тырыша, үз хәле турында юмор белән сөйли. Кеше дигәнең гаҗәп, нинди авыр хәлдә дә яшәүдән туймый. Кан басымы ике йөз иллегә җитә, астмасы көчәйгәндә рәтләп сулыш та

ала алмый, кукрәгендә, тамырларында нәрсәседер тавышланып тора. Ул үлгәнче шулай газапланачак икән. Коточкыч сугыш мирасы! Мин яңадан сугышта йөргәндәй булам. Күңелдәге нәфрәтнең чиге юк. Исмәгыйлләр берәү, икәү генә түгел бит, шифаханәләрдә алар йөзәрләп тә меңәрләп. Тынычлык өчен көрәшнең кешелеккә никадәр мөһим икәнен монда тирәнрәк аңлыйсың!

Акташ райкомы секретаре үзе белән булган бер гыйбрәтле вакыйганы сөйләде. Колхозлашу еллары, сыйнфый көрәшнең кызган чагы. Авыл Советы халык белән шыгрым тулы. Берәүләр колхозга каршы, берәүләр колхоз яклы. Бер ярлы егет кызып-кызып авылдашларын колхозга керергә димли. Бик эссе, егетнең битеннән тир ага. Ул әледән-әле тун җиңе белән йөзен сыпырып ала. Бер заман йөзе зәп-зәңгәр була. Кемдер кычкырып җибәрә:

— Җәмәгать, карагыз, ходай орды моны, җен алмаштырды!

Халык борылып карый һәм шакката: егетнең йөзендә кеше төсе юк. Кемнәрдер көлә, сызгыра, каһәр яудыра:

— Синька — коммунар, ха-ха!

— Ходай кугәртте үзен!

— Шул кирәк лыгырдыкларга. Чәнчелсен колхозлары!

Җыелыш өзелә. Бары соңыннан гына белеп алалар: кулак ялчыларыннан кемдер егетнең тун җиңенә кер синькасы сипкән. Егет аны-моны белми, тирләгән йөзен тун җиңе белән һаман сыпыра биргән...

Көл дә, уйла да!

Мин караватта кузгалмыйча чалкан ятам. Ишек ачык чакларда каршы як тәрәзәдән урам, дөресрәге, бер катлы агач йортның түбәсенә беркетелгән озын колгада сыерчык оясы күренә. Көндез ул бөтенләй диярлек күзгә ташланмый. Ә кич, батып барган кояш яктысы аңа төшкәндә, ул миңа гаҗәп нәрсәләрне хәтерләтә. Миңа караватта яткан җиремнән морҗалар да рәтләп күренми, бары тик күк бушлыгында ниндидер могҗиза белән биеккә-биеккә ашкан шул сыерчык оясы гына асылынып тора. Колгасы юкка чыккан, күренми. Бер караганда, мин аны зәңгәр диңгез эченнән калкып чыккан серле кыяга (Баренец диңгезендә, фиордларда шундыйларны күргәнем бар иде), икенче караганда, дала уртасындагы таш әбигә охшатам,— Казагыстанда һәм Кыргызстанда аларны да күргәнем бар иде. Кояш нуры йөземә төшкәнче шул турыда уйланам, ә кояш нәкъ минем йөземә төшкәч, мием кайный башлый кебек. Күзләремне йомам, ләкин моның файдасы асла юк, ә кузгалырга, читкәрәк борылырга ярамый. Миңа бары тик ишекне ябуларын үтенергә генә кала. Палатада болай да бөркү, башка иптәшләрнең ишекне яптырасы килми...

Тизрәк Даниянең яшел суын эчеп җибәрәм. Башка көннәрдә: бу яшел суыңны эчә-эчә үзем дә яшелләнә башладым, дип шаяртканый идем. Бүген тагы булса да эчәр идем. (Йөрәк белән авыручыларга бирә торган зеленинны без яшел су дибез.)

Шифаханәнең үз теле бар икән. Анда яткан кешеләргә кирәгеннән артык аңлашыла, ә бүтәннәргә ул шигъри сүзләр генә булып тоелуы мөмкин: райские боли, симфоническая музыка...

Тагын Александр Александрович килеп керде. Сүздән сүз чыгып, үзенең яшь чагы турында сөйләп алды. Укытучылары аңа, синнән бик әйбәт комик чыгачак, дип әйтә торган булганнар. Егет үзе дә артист булу турында хыялланган. Шундый теләге барлыгын әтисенә дә әйткән. Әтисе күп сөйләп тормыйча, дилбегәне урталай бөгеп, улын үкертә-үкертә бер ярган да әйткән: «Менә хәзер чын артист булдың, я әле, көлдереп кара!..»

Безнең палатаның, билгеле, үз тәрәзәсе бар. Тик мин аны күрмим. Башымны артка каерганда гына аның бер почмагы күзгә бәрелә. Минем аңа карыйсым килә. Тәрәзә почмагыннан берничә яшел яфрак һәм тәрәзә турыннан сузылган тимер чыбык күренә. Кайчак ул гади генә була, кайчак бик юанаеп китә. Бусы инде минем җайсыз каравымнан, күзләрем тала башлаудан киләдер. Шулай да карыйм, ниндидер юаныч эзлим. Кешегә юаныч, өмет кирәк икән! Ул аңа башын артка ташлап булса да карарга әзер.

Кайчандыр укылган бер хикәя искә төшә. Бер кыз шифаханәдә авырып ята. Көз була. Яфраклар коелып беткәч, ул үләргә тиеш. Менә бер-ике генә яфрак кала. Иртән алар да өзелеп төшәрдер инде. Кыз, куркып, таңны көтә...

Хикәянең ахырын яхшы гына хәтерләмим. Кемдер тәрәзәгә тыш-кы яктан өзелгән яфракларны ябыштырып куйган була. Кыз моны белми, ә көнеле шул яфракларга карап юана...

Бер генә минутка күңелем шомланып куя. Аннары бу ямьсез уйларны тизрәк куарга тырышам. Нигә шикләнергә? Тышта көз түгел бит — яз. Яз көне яфрак коелмый. Бераздан әлеге хикәяне язган авторның талант көче турында уйлыйм. Ул язучы кеше күңелен бик тирән белгәндер, ихтимал, үзе дә шундый хәлгә дучар булгандыр. Язучының халәте ниндидер күләмдә геройларының халәтенә туры килмәсә, ул геройларын җанлы һәм тормышчан итеп сурәтли алмый. Моны мин үз тәҗрибәмдә дә сынаганым бар...

Кичәле-бүгенле хәл нигәдер начарлана тора. Кич. Күземне ачып җибәргән саен ишегебез янынннан карага бөркәнгән ниндидер кешеләр узып киткәнен күрәм. Алар кешеләр дә түгел кебек, әйтерсең карачкылар гына. Гүя үлек янына җыелучы әбиләр. Кайда күргән идем үзләрен? Кинодамы? Нишләп алар безнең палата тирәсендә йөренәләр? Нигә гел минем караватка карыйлар? Әллә саташам. Түшәмдә электр чыбыгын тотып торган ролик астына үлем яшеренгән кебек. Хәлем авырайган минутларда ул шуннан башын суза, мин аның коточкыч күзләрен генә күрәм, имеш, аннары, пәрәвез җебеннән төшкән үрмәкүч кебек, минем өскә төшә башлый. Йөзе маймылга охшаган. Әнә үрле-кырлы сикерә. Юк, туктады, төшми, бармак яный, бераздан тиз-тиз югары үрмәләп китә, яңадан ролик астына кереп поса. Нигә шул каһәр суккан роликны алып ташламыйлар дип уйлыйм. Әгәр алып ташласалар, хәлем берьюлы яхшырып китәр иде төсле...

Врач Мансура ханымнан тыш, мине еш кына доцент Шолом Исаакович карый. Ул, карт яһүд, яхшы кеше булса кирәк, бик ипле сөйләшә, шаяртып та алгалый.

— Киләчәк буын кешеләренә,— ди,— инфаркт бер дә куркыныч булмас, чөнки тапкан чакта ук әниләре аларны запас частьлар белән табарлар. Бу йөрәгең тузган икән, рәхим ит, яңасын куйдыр. Ә хәзер, туганкай, селкенмичә ят. Авыру үзе терелим димәсә, врач әллә ни кыра алмый. Бергәләп тотынсак, инфарктны һичшиксез җиңәрбез.

Безнең палатага, буш урынга, артист Николай Иванович Якушенконы салдылар. Йөрәк, стенокардия. Элек мин аны сәхнәдә, төрле җыелышларда гына күрә идем. Артист үлем түшәгендә дә артист икән. Сестра-хозяйка Клавдия Ивановна һәр вакыт бүлмәсен биклән йөри һәм һәр вакыт халат кесәсен капшый, янәсе, ачкычым мондамы. Ул зур кара күзле, карсак буйлы, юантык гәүдәле өлкән яшьтәге хатын. Мин аны татар хатыны дип уйлый идем. Руслар еш кына исемнәрне үзләренчә үзгәртеп әйтәләр бит. Безнең халык өлкән хатын-кызны шаяртмый, бу килешми, әдәпкә сыймый. Ә Нико-

лай Иванович килгән көненнән үк сестра-хозяйканы шаярта башлады.

— Һәй-әй, кадерле Клавдия Ивановна, ачкычыңны төшереп калдырдың бит!

Клавдия Ивановна «ах!» дип кисәсен капшарга тотына...

Акташ райкомы секретаре да, Исмәгыйл Хәлиуллин да кайтып киттеләр. Берсе сәламәтләнеп, шатлыклы хезмәткә, ә икенчесе... тулмаган сәгатьләрен тутырырга, газабына чыдый алмыйча китте. Соңгы күз карашы бик озакка хәтеремдә калды. Әрнү белән тулы иде ул. Гүя исәннәрне кисәтә иде бу караш: беркайчан да онытмагыз сугыш михнәтләрен! Алар сугыш кырында гына бетми, сугыштан соң да алар дәвам итә. Менә безгә карагыз! Онытмагыз! Кешелек һәр вакыт моны исендә тотсын иде.

Мине Хәлиуллин урынына, тәрәзә янына күчерделәр. Бу болай булды: инфарктлы авыруны урыныннан кузгатырга ярамый. Шуңа күрә, Хәлиуллинның караватын алып, мине, караватым белән, аның урынына этәреп куйдылар. Дөнья яктырып киткәндәй булды, тәрәзәгә кул сузсаң, кул җитәрлек. Яшел яфраклар да һаман шунда. Алар пыялага ябыштырылмаган! Тышта аз гына җил булса, әнә, ничек тибрәнеп торалар.

Миңа каршы якта, Акташ секретаре урынында, хәзер Григорий Иванович Бакшаев ята. Ул атаклы авиатор, зур такыр башлы, гәүдәгә мәһабәт булса кирәк. Кычкырып сөйләшә, аз гына саңгыраурак. Аның да авыруы йөрәгендә.

— Без бер бакча җиләкләре икән. Дүртенчебез кем булыр тагы? — диде артист Николай Иванович.— Алланың изге бәндәләре! Беләсезме, инфаркт тегенди-мондый гаврикларга эләкми ул.

Мин көлемсерәдем. Бер көнне сестра сөйләгән иде: безнең палата үзенә күрә мәшһүр икән. Монда Салих Сәйдәш, Иван Заботин, Габделхәй Хәбиб, Закир Тинчурин, Газиз Иделле, Нәби Дәүли ятып чыкканнар. Иң яхшы истәлек композитор Салих Сәйдәш калдырган. Аның кешелеклелеге, йомшаклыгы, эчкерсезлеге турында сөйләп бетерә алмыйлар. Ә хәзер күрше палатада аның тормыш иптәше ята диләр...

Салих Сәйдәш турында күбрәк уйлаган, күбрәк ишеткән саен, мин шундый фикергә киләм: бөек затларда талант һәм кешелеклелек аерылмас бер сыйфат икән, аларның берсе икенчесеннән башка була алмый. Нигә безнең тәнкыйтьчеләр, әдәбиятчылар шуңа басым ясамый икән? Без бит гүзәл кеше өчен көрәшәбез. Әгәр яшьләр гүзәллеккә бөек затлардан өйрәнмәсә, кемнән өйрәнсен!

Исемә төште: мин бит бу палатада элек бер булган идем, Иван Заботин янына килгән идем. Ул әнә Якушенко яткан урында ята иде. Без аңа әле яңа гына типографиядән килгән «Лобачевский» романын китереп бирдек. Хәзер ихтыярсыз уйлап куям: китабы калган, ә үзе..

Язучының үлемсезлеге аның әсәрләрендә. Бу бик дөрес сүз. Шулай да яшьли үлү бик кызганыч һәм гомумән кеше гомере бик кыска икән. Вакытның кадерен белеп яшәргә кирәк. Урының җирдә буш калмасын иде.

Өстәлдә шешәгә утыртылган алсу чәчәкләр тора. Алар гаҗәеп матурлар һәм һич тә шиңмәсләр кебек. Берничә көн үткәч, палатаны җыештыручы няня аларга чак кына кагылган иде, чәчәкләр коелдылар да төштеләр. Шәрә сабаклар белән шешә генә торып калды. Няня аларны чиләккә сыпырып төшерә башлады. Мин берничә яфракчыкны сорап алып дәфтәрем битләре арасына салдым. (1973 елда да дәфтәр битләре арасында ул яфракчыклар бар иде. Хәтерлим, бу чәчәкләрне безнең авиаторга китергәннәр иде. Чәчәкләрдән бер яфракчык булса да калган, ә ул мәһабәт ир... юк инде...)

Артист Николай Иванович түшәмгә карап ята. Эче поша булса кирәк, еш кына көрсенеп ала.

— Җаның ни тели, барысы да бар, тик җир җиләге тоткан унтугыз яшьлек җанаш кына юк янда,— ди ул кинәт һәм тагын «эх, һи-һи!» дип сузып көрсенеп ала. Ә без елмаябыз. Картлач унтугыз яшьлек кызлар турында уйлый бит. Хәер, монысы бәлки хәйлә генәдер, ә чынында ул тормыштан китеп барудан курка торгандыр. Яшәү, нинди кадерле нәрсә ул яшәү, кешенең аннан һич аерыласы килми.

Кеше күңеле гаҗәп киң икән. Ул яткан хәлендә дә әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр сөйли, гүя хәят дәрьясында балык кебек йөзә һәм тормышның матурлыгын никадәр тирән тоя. Бәлки ул, сүзгә мавыгып, бераз онытылырга гына тели торгандыр. Юк, алай булмаска тиештер, игътибарлырак тыңларга гына кирәк.

Әнә Николай Иванович... шәһәрне яшелләндерү турында сөйли. Ул Татарстан Верховный Советы депутаты. Бер заман, ди, шәһәр башлыгы янына барасың, кабул итә, аяк өсте басып каршы ала, теге-бу, фәлән-фәсмәтән. Бу депутат берәрсенә квартир сорарга килгәндер дип уйлап, квартир бирә алмаганлыгын башта ук искәртеп куя. Мин агачлар турында сөйли башлагач, абзаңның авызы ерыла. И, моны булдырабыз, Николай Иванович, моны аңлыйбыз, ди. Мин сүздән туктыйм. Башлык аңласа, шул җиткән, агачлар шаулап үсәчәк, имеш. Шулай гына булса икән. Без чыбык төртәбез, ә рәшәткә куймыйбыз, су сипмибез. Мин унбер ел депутат, унбер ел шул турыда сөйлим, ләкин гади генә нәрсәләргә берәүне дә ышандыра алмыйм бугай. Нигә бездә чыбык утырталар, ә Куйбышевта, Горькийда уникешәр еллык юкәләр? Үз башыбыз җитми икән, нигә күршеләрдән үрнәк алмаска? Ел саен миллионнар җилгә оча бит. Бишбалтадан килә торган дамба буена никадәр агач утырттык, аннары бер дә бер көнне барысын ком белән күмдек. Миңа:

— Казанны бүген Рига ясар идеңме? Булмый ул, бер кырык елдан рәхим ит,— диләр.

— Кырык елдан соң минем каберем дә җир белән тигезләнгән булыр. Мин ул матур агачларны бүген, иртәгә күрергә телим,— дим. Шундый сәяхәттән соң бер заман өйгә кайтып керәсең, хәл беткән, температура 35,2.

— Иптәш автор! — ди кинәт Николай Иванович миңа,— яз әле шундый бер пьеса, мин шәһәр башлыгын шулай уйнар идем, сәхнәдән үзен күргәч, бәлки ул ил алдында оялыр иде.

Безнең палатадагы Петр Матвеевич Леонтьев дигән кеше кергәли башлады. Әллә ни күп сөйләшми дә, көлдерми дә, ләкин җанга якын шундый бер сүз әйтеп китә, палатага әйтерсең кояш тула. Тик шунысы кызык, аның сүзләрен кәгазьгә язып булмый. Николай Ивановичның сүзләрен менә язам, ә Петр Матвеевичның сүзләрен күпме тырышсам да булмый. Тик сулышың җиңеләеп китә, өметең яңара. Ул синең өеңә шалтыраткан була, гаиләңне тынычландырган, сиңа килгән иптәшләрең белән сөйләшеп өлгергән, хәлең начар булса, врачны, сестраны эзләп таба...

Ул үзе йөри ала торган авыру. Башы чыңлый. Аны уколлар белән дәвалыйлар. Шифаханәдән тыш ул ничек киенеп йөри торгандыр, тәгаен генә әйтә алмыйм, монда өстендә буй-буй кызыл пижама, башы чал, буе озын, карашы үткен.

Бүген палатабызның кәефе яхшы иде. Әллә шуны сизепме, Леонтьев, карават башына таянып, кызык бер вакыйга сөйләде. Шушы шифаханәдә булган хәл. Паралич суккан яшь кенә бер хатын ята. Бу хатын медицина фәннәре докторы икән. Аның янына абыйсы килеп йөри. Бик чибәр, мәдәниятле, сөйләшүләре әдәпле. Әмма

эче... күгәргән. Әлеге чибәр, мәдәниятле кешебез өенә бер сестраны йөретә, яшәрергә теләп, новокаин уколлары кадата икән. Сеңлесе авыргач, квартирасына кереп утырган, бик күп акчасын үзләштергән. Сеңлесе ул килеп керүгә бәргәләнә-суккалана башлый. Бу бер дә исе китмичә бичара сеңлесенә карап утыра. Сеңлесе ул китергән ашларга кагылмый, агу кушкандыр, дип курка. Аңардан артык килмә дип үтенәләр, ләкин ул килә. Ул килгән саен сеңлесенең хәле начарлана...

Беркөнне Леонтьев моның белән сөйләшә, бу кешенең барлык авыруларда нәфрәт уятуын яшермичә әйтә. Теге кеше әтәчләнә, миндә эшегез булмасын, ди. Алай булгач, синең дә бездә эшең булмасын дип, Леонтьев тегене якасыннан тотып ишектән төртеп чыгара.

Мин моңа ышанырга да белмәгән идем, ләкин Леонтьев зур урыннарда эшләгән бик мохтәрәм кеше бит! Беркадәр вакыт Ленин белән Смольныйда эшләгән.

— Ленин безгә әйтә торган иде,— диде ул бер көнне,— кеше ялгыша икән, аңа аңлат, төшендер, кеше адашкан икән, аңа дөрес юлны күрсәт. Әгәр ул бер явыз җан икән, аны үгетләп маташма, күрмәмешкә дә салынма, якасыннан эләктер дә читкә ат, яхшы кешеләргә комачауламасын!

Леонтьевка хөрмәтем бермә-бер артты.

Шундый асыл ирләрнең икенчесе Иван Федорович Антипкин иде. Мин элек тә аны бераз белә идем. Аның яратып кабатлый торган бер сүзе бар: «Выходит дело»...

— Выходит дело, син дә авыргансың. Безгә, картларга, әзрәк ярый, ә яшьләргә килешми ул,— диде минем яныма утыргач.

Революция эшенә якыннан катнашкан, Совет властен төзешкән, утны-суны кичкән карт гвардия баш очына килеп утырсын да дулкынланмыйча түз менә!

Ул әкрен генә кулыма кагыла да:

— Озак ятма, терел,— дип чыгып китә. Тагын кереп хәл беләсен әйтә.

12. 6. 1958 ел. Минем яныма берәүне дә кертмиләр иде. Бүген берьюлы ике кеше килеп керде: Закир ага Тинчурин һәм Абдулла Гомәр. Алар Николай Иванович янына киләбез дип алдалаганнар, чөнки алар алдыннан гына Сибгат Хәким белән Зәки Нури булганнар, аларны кертмәгәннәр. Закир Вәлиевич монда яткан кеше, бәлки шуңа күрә каршы килмәгәннәрдер. Сибгат Хатыйп Госманның юбилей билеты артына бернечә сүз язган. Сестра билетны китереп биргәч, кертмәүләре өчен бик борчылдым. Сөйләшәсе килгән иде. Закир агалар белән сөйләшеп күңел әзрәк басылды.

— Дөньяда Гомәр булырга кирәк. Алла каршында да туры юлдан гына йөрергә димәгән! — дип көлемсерәде Тинчурин.— Тагыдак та килсәләр, өрәтеп җибәрербез үзләрен.

Көннәр үтә торды. Күкрәк өстендә, «күрмичә» язу никадәр уңайсыз икән. Николай Островский ничек яза алгандыр? Иркен сулыш белән, хыялны кысмыйча бер язасы иде. Ә болай бик тиз кул тала, баш авырта, карандаш төшеп китә, аннары таба алмыйсың. Соңга таба җае чыкты, каләмне озын җеп белән карават башына бәйләп куйдым.

Николай Иванович авыз эченнән әле Чайковскийның «Мой костер светит в тумане» романсын көйли, әле театр турында берәр мәзәк сөйләргә керешә. Хатын-кыз врач күренсә, чакырып алып, театрдагыча кулын үбә. Сестраларның гомумән теңкәләренә тия: кызарта, оялта, бүген иреннәрең кып-кызыл, җаным, бир суырып үбимче, ди. Артист халкын болай якыннан күргәнем юк иде, бигрәк

тәкәллефсез кешеләр икән. Хәер, хатын-кызлар да аңа ачуланмыйлар. Тик Дания генә оялып йөгереп чыгып китә.

Бүген Николай Ивановичның тарагы югалган. Барлык няняларны чакырып шуны эзләтә. Мин күзәтеп ятам: берәүләр йөрәкләре сызлаганда да сестраны борчымаска тырышалар, аңа бит болай да эш муеннан, ә артист каядыр төшкән тарагын эзләтеп баш катыра. Утыра да, йөри дә алмаган кешегә пычагыма кирәкмени ул тешсез тарак!

Карчыгы Николай Ивановичка уенчык сыман бәләкәй чынаякларга салып балын, маен, вареньесын китерә. Николай Иванович шул савытларның әле берсен, әле икенчесен кулына алып, аларга баладай сокланып карап ята, җанлы нәрсәгә дәшкән кебек иркә сүзләр сибә. Мөгаен, алар кадерле истәлекләрдер. Артист халкының тормышын каплап торган чаршауны бер күтәрсәң иде. Анда әллә нәрсәләр бардыр!

Николай Иванович бәләкәй чынаякларга шулай куанып ята-ята да бөтен палатага гына түгел, коридорга да ишетелерлек итеп кычкырып җибәрә:

— Әй, Нюра, подать телевизор! Хәзер тикшереп карыйбыз, бу рәхмәтле клизма миңа тәэсир итәме, әллә минем үз тәэсирем көчлерәкме?

Бер ун минуттан Николай Иванович бөтенләй икенче нәрсә турында сөйләп китә.

— Шифаханәләрдә мин, дуслар, күп яттым. Төрлесен күрдем, яхшысын да, яманын да дигәндәй. Ә бер тапкыр чын-чыннан могҗизага тап булдым. Авыру үләргә әзерләнә иде. Аның янына яшь кенә сестра килде. Пульсын тикшерергә.

— Һай, күкрәк алмаларыгыз нинди матур,— диде ул, иреннәрен чак кыймылдатып, һәм бер минуттан җан бирде.

Артистның сүзе бетәсе түгел икән.

— Пермь шәһәре зиратында, чиркәү артында гына, бер кабер бар. Кабер өстендә авыр чуен плита. Плитага елан сурәте төшерелгән һәм: «Будь проклята, дочь моя!» дип язылган.

Төрмә начальнигының бик матур кызы булган. Ул каторжаннарны сөргенгә озатучы сакчыларның башлыгы — яшь офицерны яраткан. Офицер аны, әтисенә сиздерми генә, үзе белән алып киткән. Кирәге беткәч, юлда ташлаган. Кыз, хур булып, әтисе өенә кайткан, озакламый үлгән...

— Ә менә Тула шәһәре зиратында, аерым төрбәдә, беренче гильдия купецы Балашовның... сыңар кулы җирләнгән. Ниндидер бер җәнҗалда купецның кулын имгәткәннәр, больницада аны кисәргә туры килгән. Күзгә төтен җибәрергә яраткан сәүдәгәр, поплар чакыртып, тәреләр күтәртеп кулын җирләттергән. «Мәрхүм» кулны бөтен шәһәр буйлап күтәреп барганнар ди...

Икенче көнне Николай Иванович бөтенләй башка нәрсәләр турында сөйләде:

— Чыгыш ясарыңнан элек нәрсә турында сөйлисеңне бел. Оратор сәнгатенең беренче кагыйдәсе бу. Бездә, җыелышларда, шундый хәлләрне күрергә туры килгәли: берәү чыга да алдан язган кәгазен укый. Тыңлаучылар аптырашта: бу кеше үзенең сүзләренә шатланамы, борчыламы? Шатланса — нигә рухы сүнгән, борчылса — нигә бу кадәр тыныч. Ул нәрсә турында сөйләгәнен белми! Шул!! Сез, агай-эне, җыелышларга йөргән кешеләр, беләсез, бар шундый кешеләр, нәрсә сөйләсәләр дә, ун сәгать буе кузгалмый утыра алалар, ә мин ике минут саен сикереп торам...

14. 6. 1958. Эч поша. Эч пошу шундый бер нәрсә ул, моны үзеңнән башка берәү дә аңламый һәм үзең дә башкаларга аңлата алмыйсың.

Авырганда эч пошу тагын да әшәкерәк. Болай да какшаган нервылар тәмам котыра. Үз-үзеңне, элекке заманнардагыча, туп авызына бәйләтеп аттырасы килә.

Ярый әле, Николай Иванович тезгенне эләктереп ала.

— Юк, валлаһи,— ди ул,— алдамыйм, чын дөресен әйтәм, ул туганда ук йөз тапкыр юләр булып туган. Югыйсә, көненә йөз тапкыр үбешмәс иде. Хатын-кызны үпсә, каян килеп кая китмәс иде, ир булып ирләрне үбә бит. Авызына кундырасы килә.

Николай Иванович моны шактый билгеле режиссёр Б. турында әйтә.

Менә аның төнге сөйләшүе:

— Няня, кадерлем, ничек торасың? Бик кыен түгелме?

— Торам әле шунда селкенеп, Николай Иванович. Менә минем белешем бал-май эчендә йөзә.

— Кибеттә эшлиме әллә?

— Юк, анатомичкада. Анда көн саен берничә мәет. Якыннары буш итми.

Нинди генә кешеләрең юк, дөнья!

— Шифаханәгә килеп кергәнче мин дә кеше идем, йөри, утыра ала идем. Монда китереп салгач, син авырыйсың, ятып кына тор, кузгалма, селкенмә, диделәр. Инде күпме ятабыз. Алда безне нәрсә көтә?

Бу инде күңел төшенкелегедер. Мин бу уйларны куарга тырышам. Азмыни башка уйлар. Уйла!

Башта мине сүзләрнең яңгырашы кызыксындыра иде: зәңгәр, алсу, яшел дисәм, алар бит һәрберсе үзенчә генә яңгырый, аларны кулга тотып карарга мөмкин төсле. Һәр язучының теле холкына бәйләнешле була. Берсенең теле йомшак тәгәрмәчле файтун кебек, икенчесенең теле ташлы урамнан килгән буш мичкәдәй дөберди.

Ха-ха! Врачлар сүзенә колак салырга теләмәгәнгә — ул урыныннан торып коридорга ук чыккалый башлаган иде — Николай Ивановичның пижама чалбарын алып киттеләр. Хәзер инде теләсәң, теләмәсәң дә ятып торырсың, диделәр.

Шифаханә тормышында күңел кайтаргыч нәрсәләр җитәрлек. Син бит ир башың белән тулысынча хатын-кыз кулында, хәтта битеңне иртә саен юалар, күлмәгеңне урыныңнан торгызмыйча гына алмаштыралар... Хатын-кыз күңелендәге шәфкатьнең зурлыгына һәм матурлыгына искитмәле. Ул няняларны, сестраларны, кулыңнан килсә, алтын белән коендырыр идең!

Нинди шатлык: радио тыңларга рөхсәт иттеләр. Һәрберебезгә наушниклар куйдылар. Дөнья хәлләре тыныч түгел икән. Әйтерсең җир шары тыгыз ләгыйннәргә!

Николай Ивановичның үз туксаны туксан.

— Я, ходай, нининдидер Вера Григорьевна яшәү законнарын белгели. Сөйләшергә ярамый ди. Ә мин сөйләшми тора алмасам? Әнә безнең изобретательгә сөйләшмәсә дә ярый, ник дисәң, бөтен уе сызымнарда, язучыга тагын... Аның өчен геройлары кирәгеннән артык такылдый. Артист үзе сөйләмәсә, кем аны тел батыры дияр!

Ишектә дарулар өләшүче сестра Вера Григорьевна күренде. Ул инде олы яшьтәге хатын.

— Вера Григорьевна, сезнең кайчан да булса бер елмайганыгыз бармы?

— Иртә белән генә елмайдым, Николай Иванович.

Башка сестралар булса, артист: «Во поле стояла березонька»ны бергәләп җырлыйбызмы ди, ә Вера Григорьевнага ни әйтсен?

— Әй, алланың рәхмәте төшкере, Дания! Синең ал бант беркеткән киң кырлы эшләпә кигәнең бармы? Ак күлмәккә ал бант бик

килешә бит. Бергәләп ялгыз каен төбенә барып утырыр идек. Утка янсын бу больница.

— Эх, дуслар,— дип яңадан башлый Николай Иванович,— егетләр артист булырга җан атып тормый, ә кызлардан котылып булмый. Бер көнне берьюлы ике кыз килгән минем янга. Берсе кылый, икенчесе тотлыга. Сездән артист чыкмый дигән идем, үкереп елый башладылар. Сез, Николай Иванович, таш бәгырьле, диләр. Шул кызларның каргышы төшкәнгә менә авырып ятам. Билләһи. Бәла! Булмаса, художниклар турында сөйлим. Алар бездән акыллырак. Берсе минем рәсемемне ясады. Мин карадым да:

— Бу мин түгел, бу нindидер бер исерек баш,— дидем. Художник минем белән килешмәде.

— Сезнең эстетик зәвыгыгыз юк, Николай Иванович,— диде.

Комиссия бу рәсемне яхшы дип табып, Мәскәүгә, Бөтен Союз күргәзмәсенә җибәргән. Шул араларда миңа да Мәскәүгә барырга туры килде. Күргәзмәдә үз рәсемемне эзләп таптым. Матур гына урынга элеп куйганнар. Рәсем каршына туктаган бер кешедән сорыйм:

— Ничегрәк?

Төрлесе төрлечә җавап бирә, ләкин берсе дә бу рәсемнең оригиналы мин дип әйтми.

Казанга кайткач, художникка шуны әйткән идем, ул:

— Рәсем фотокарточка түгел, фотокарточка гына иясенә охшый. Иясеннән яхшырак чыккан булса, фотографны мактыйлар да әле,— дип авызымны каплады. Хәзер бу рәсем бүтән күргәзмәләрдә йөри, ди. Минем аны кабат карыйсым килми.

Иртәгә Татарстан язучыларының дүртенче съезды ачыла. Съездга кыска гына хат яздым. Укысалар, шат булыр идем. Күңелемдә халыкка чиксез ышаныч һәм иман булмаса, бер юл язмас идем, чөнки бу мәгънәсез бер эш булыр иде.

(Хатны укыганнар. Рәхмәт. Хат көндәлекләрдә булмаса да, мин аны архивтан табып алдым. Билгеле, русча язылган. Хәзер татарчалаштырып күчерәм.)

«Иптәшләр!

Әдәбиятыбызның зур бәйрәменә катнашырга сәламәтлегем начарлыгы комачаулады. Ләкин күңелем белән мин сезнең янда. Ышанам, съезд югары идея-политик дәрәҗәдә үтәр.

Без укучыларыбыз, халкыбыз алдында зур бурычлы. Үзе бөек хезмәт иясе булган халык язучыларыннан да хезмәт батырлыгы көтә. Күзне дә, йөрәкне дә куандырмый торган буш сүз букетларына ул риза түгел. Безнең әсәрләр, һичшиксез, максатка юнәлдерелгән булырга тиеш.

Тормышны өйрәнү иҗади командировкалар һәм литфонд акчасы булганда гына мөмкин, дип исәп тотучылар тирәнтен ялгышалар. Безнең геройлар һәр вакыт һәм һәр җирдә безнең белән, тормышны һәм хезмәтне яраталар, үзләре гаҗәп тыйнаклар. Мин андый, мин мондый дип, күкрәк сугып мактанмыйлар. Бары тик художник күзе генә аларның гади бөеклеген күрә һәм матур образларда гәүдәләндерә ала.

Һәр начарның яхшысы да була диләр. Мин күптән инде данлы медикларыбыз турында берәр нәрсә язу турында хыялланып йөри идем. Хәзер минем күңелемдә шундый тойгы, әйтерсең больницага иҗат командировкасына, булачак геройларымны өйрәнергә килгәнмен. Дөрес, тормышны шушы юл белән өйрәнүне мин бүтән беркемгә дә теләмим, инфаркт әшәке нәрсә. Атналар буе селкенми-нитми чалкан яту һәм гел бер төрле ак һәм җансыз түшәмгә карап тору — теләсә нинди җәзадан авыррак. Ләкин язучы йөрәге теләсә нинди шартларда да, соңгы сулышына кадәр, иҗат итәргә тиеш».

*Дәвамы бар*

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

Хәсән Сарьян

# «АЛАЙ ДА БУЛА!»— БУЛМАСЫН

Миллэт булып оешып җиткән һәр халык тарихи үсешенең бер чорында үзенең асыл йөзе булган телен дә ныклап, тамырына төшеп өйрәнә башлаган. Тел гыйлеме дип аталган үзенә аерым фән шулай хасил булган. Әгәр дә без татар тел гыйлеменең җеп очын эзли китсәк, җепне сава-сава, Гали Мәхмудов, Салихҗан Күкләшев, Хөсәен Фәезханов, Ибраһим Хәлфин һәм, ниһаять, мәшһүр бабабыз Каюм Насыйрига барып чыгачакбыз. Ләкин ул заманнан бирле күп сулар агып, бер гасырдан артык вакыт кичте. Бу вакыт эчендә әдәби телебез үзе дә, тел гыйлеме дә бик нык үсеп алга атлады. Әмма бу үсешнең иң куәтле агымы ирекләре буылып-томаланып яткан халыкларга чын ирек биргән совет чорына туры килә. Бөек Октябрь революциясенең җиңеп чыгуы, революциянең нигез ташларыннан саналган милли политиканың гамәлгә ашуы, тигез хокуклы милләтләрне берләштергән СССРның төзелүе — боларның һәммәсе дә илебездәге гаять күп телләрнең колач җәеп үсүенә иркен юл ачты. Үзебезнең татар әдәби теле моңа ачык мисал. Совет чорында ул бик каты җегәрләнеп, дөньядагы алдынгы телләрдән һич калышмас дәрәҗәгә басты. Чыннан да, әгәр остасына эләксә, җәүһәр-алмазлар уйната ул безнең тел! Галимҗан Ибраһимовлар, Һади Такташлар, Муса Җәлилләр, Гомәр Бәшировлар, Әмирхан Еникиләр, Сибгат Хәкимнәр теле әнә шундый.

Ләкин әле моңа карап кына: телебез тәмамынча камил, чишәр мәсьәләсе юк, әйдә шулай торсын дип, канәгатьлектә оеп утыра алмыйбыз. Бүгенге җитез тормыш әдәби телебез алдына да мәсьәләне куеп кына тора — берсен чишеп өлгермисең, икенчесе килеп чыга. Хәер, фән шулай инде ул: проблемасыз, бәхәссез булмый. Ләкин, миңа калса, бәхәс әле күбрәк алынма сүзләр тирәсендә урала. Хәтта профессор М. Зәкиев аны «бик катлаулы һәм күп тавыш куптарган» проблема дип атый. «Хәзерге көндә дә мәсьәлә инде ачыкланган һәм көрәш туктаган дип уйлау, ким дигәндә, беркатлылык булыр иде», ди. (М. Зәкиев. Туган тел үсеше. 1967. 57 бит.)

Шулай да мин моны ул кадәр катлаулы, көрәшле нәрсә санамыйм. Нинди телдән күпме сүз алу яки алмау мәсьәләсен заман үзе хәл иткән һәм итә — аласын ала, калдырасын калдыра. Әйтик, хәзер бер язучы да **индустрия, промышленность** урынына **санагат** сүзен кире кайтарыйк дип дәгъва кылмый. Әмма ләкин сүзнең аһәңе, эчке ритмы хакына берәр язучы меңгә бер, анда да сүз сөрешеннән җиңел аңлар-лык итеп, **санагат** сүзен кыстырып җибәрә икән, аңардан гына татар әдәби теленең бер чите дә кителеп төшмәячәк.

Мәгәр заманы булган — телебезгә кемнән сүз алу, ягъни **кемгә** йөз тоту мәсьәләсе тирәсендә каты бәхәсе дә, көрәше дә булган. Тарихтан беләбез: дөньяда бер халык та, океан эчендәге исемсез атау кебек, үзенә генә аеры яшәмәгән. Гасырлар

дәвамында көч-куәт, культуралар үзгәреп тору сәбәпле халыкларның урыннары алмашынып, үзләре дә, телләре дә төрле йогынтыга эләгә торган. Җөмләдән, татар телен алыйк. Әле бер, әле икенче тарафтан агым-агым килеп кагылган күпме тел йогынтысы кичергән ул! Безгә иң дәвамлы (мең ел буена!) йогынты ясаганы ул — гарәп теледер. Әгәр бүгенге татар әдәби теленең лексик байлыгын тикшереп карасак, лингвист булмаган кеше, мәсәлән, кайсы татар, кайсы гарәп сүзе икәнлеген аера да алмый. Грамматик яктан бөтенләй башка — берсенең сыгылмалы флектив, икенчесенең үзгәрмәс аглютинатив тамырлы булуларына карамастан, гарәп сүзләре «бер сузыкка бер тартык» моделе белән калыпка калып, авазга аваз дигәндәй кергән дә утырган, кергән дә утырган. Ләкин һәр нәрсәнең чамасы була. Әгәр читтән бер сүз чама белән, котылгысыз ихтыяҗ, кирәклек аркасында гына алынган булса иде, ул чакны ничә еллар бу хакта сүз сөйләп, бәхәс корының хаҗәте дә калмас иде. Кызганычка каршы, татарда да әүвәл үз мәнфәгатьләрен генә кайгырткан өстен сыйныфлар телне дә сыйнфый итәргә тырышканнар; язганнары гарәпчә булып, төркичә дигәнендә дә унга бер генә татар сүзе туры килгән.

«Пролетариат әдәбияты турында» дигән хезмәтендә Галимҗан Ибраһимов болай яза: «Без, бердән, хәзер гарәпчә сүзләргә каршы сугыш ачтык. Буржуазия заманында борынгы чыгтай төркисеннән бер адым атланып, гарәбизм киметелгән иде. Ләкин пролетариат аңа тукталмады, **халыклашмаган** (курсив минеке — Х. С.) Гарәбстан сүзләреннән әдәбиятны коткару мәсьәләсен уртага куйды. Әле без моны эшләп җиткерә алмадык, ләкин шуңа барабыз». Әмма ул гарәп сүзләрен тоташ кырып чыгу юлына басмый, ә без бүген дә онытмаска тиеш булган дөрес принцип белән эш итә. Ләкин бер чор булып алды ки, Галимҗан Ибраһимовтан соңгы ике дистә ел эчендә кайберәүләр гарәп сүзләрен генә түгел, үзләре белмәгән теләсә нинди татар сүзен дә «халык аңламый» дип кисә башладылар. Бәхетебезгә, ул вакытлар инде артта калды, әмма «аңламый» дип халыкка япсаруның әле булса бетеп җиткәне юк. Хәлбуки без бер хакыйкатьне истән чыгармаска тиеш: әдәби телдәге барлык сүзне, каян гына алынса да, бер халык та йөз процент аңлап бетерми һәм бетермәячәк тә. Үз иҗатында татар теленең гүзәл үрнәкләрен биргән Кави Нәҗми бу хакта ачынып: «Барлык татар халкының яше, карты бер тигез белгән сүзләрне генә әдәбиятка кертү принцибы белән эш итсәк, телебезне ярлылатудан башка нәтиҗә чыкмаячак» дип язган иде. (Әсәрләр. 1960. 4 том. 235 бит.)

Мәгәр мәгълүм: гарәп безгә бик ерак — җиде диңгез, җиде тау артында: без гомер-гомергә гарәп белән түгел, рус белән бергә яшәгәнбез. «Россия кешесе (руслар — Х. С.) мөселманнар белән бер җирдә торган һәм... бер икмәкне ашап үскәнлекләре сәбәпле, бу ике халык бер-берсенең гадәтен вә могамәләсен яхшы беләләр», ди Каюм Насыйри. (Сайланма әсәрләр. 1956. 87 бит.)

Октябрь революциясе Россия халыкларына политик ирек, яңа культура ишекләрен каерып ачкан кебек, өр-яңа сүзләрен дә нурдай чәчеп җибәрә. Татар халкы моңарчы ишетмәгән, әйтергә теле дә әйләнмәгән бу сүзләрне әйләндереп йотып кына тора. Бу дулкын әдәбиятка да килеп кагыла. «Чөнки Кызыл Армия фронтында, продналог отрядында, крестьян җыеннарында, хәзерге вузлар эчендә кайнаган яшь каләмнәребез, шулай ук завод-фабрик, шахта төбеннән күтәрелгән рабкорларыбыз татар әдәбиятына үзләренең шул дөньяларында өйрәнгән сүзләре, тәгъбирләре белән киләләр. Шулай итеп татар теленә яңа байлыклар бирәләр». (Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 1960. 180 бит.)

Бу әле ул вакытта. Ә хәзер? Техник прогрессның космик адымнар белән алга китүе, дөнья цивилизациясе, халыкларның еллап түгел, көнләп аралашуы, ил эчендәге миграция, матбугат, радио, телевидение информациясе — боларның һәммәсе дә бер телдән икенче телгә яңа сүз алуны туктаусыз ихтыяҗ итә. Чөнки көне-сәгате белән колакка килеп ирешкән яңа төшенчә, мәйданга килгән яңа предмет өчен һәр халык, үзле-үзенә мир җыены ясап, сүз уйлап утыра алмый — ул мөмкин эш түгел. Шуңа күрә без техникага, фән я башкага бәйле өр-яңа сүзләрне рус теленнән шул көе я тәрҗемә итеп алабыз. Рус теле дә сүз өләшеп кенә ятмый, без турыдан-туры ала алмаган дөнья телләреннән үзе дә туктаусыз сүз алып тора. Димәк ки, башка бер телдән ихтыяҗ белән, кирәккәнгә сүз алу әдәби телебез өчен гаять тә зарури бер хәл икән. Ләкин монда бер таләп бар: ягъни читтән алынган һәр сүз **бу теленең**

генә каты законына буйсынып, грамматик кысасына кирәргә тиеш. Юкса читнеке түгел, үз сүзеңнең дә ят булуы бар. Чөнки бер телнең чын мөстәкыйльлеге алынма сүзләрнең аз я күплегенә карап йөрми (составында 70—80 процент чит сүз булган телләр дә бар), ә бәлки гасырлар буена бөртекләп кенә салынып, цементтай ныгый килгән грамматик кагыйдәләр мөстәкыйльлегенә, һәр сүзнең шул кагыйдәгә мотлак буйсынуына карап йөри. Менә ике мисал:

**Бул кеше, байбәтчәләрнең калдыгы хәмрен көтеп,**
**Алты еллык образованиеңне йөрмә селкетеп.**

*(Г. Тукай. Әсәрләр. 1955. 2 том. 103 бит.)*

**Бу көнне**
**кызлар**
**тик бер аны гына сөйделәр,**
**[хәтта хатынына көнләп көйделәр].**

*(Ш. Мәхмүдов. Юл өстендә кояш. 1971. 71 бит.)*

Тукай шигырендә ике чит сүз бар: хәмер һәм образование. Әмма икесе дә татар теленең үз кагыйдәсенә буйсынып, әүвәл изафә формасы белән, аннары, фигыль таләп иткәнчә, төшем килеш кушымчасы белән төрләнгән. Шулай итеп, һәр кайсы ике кабат татарлашкан. Инде Ш. Мәхмүдовның шигырен карап карыйк. «Хәтта»-дан башкалары — һәммәсе татар сүзе. Башка телдә бәлки башкачарактыр, мәгәр безнең татар телендә «көнлим» дигәндә, «кемнән кемне» моделе генә бар. Татар кешесе бер вакытта да: «иремә яки хатыныма көнлим» дип сөйләмәс, **кемнәндер** «иремне яки хатынымны көнлим» дип сөйләр.

Телне мөстәкыйль иткән, аны мәңге хәрәкәттә тоткан нәрсә — ул грамматик чара. Шуның аркасында гына сүзләрдән **тел** дип аталган гүзәл бер бина хасил булган. Шул бинага карап без төзүчесенең, ягъни һәр халыкның үзенә хас булган үзенчәлекле фикерләү ысулын күрәбез. Җыеп кына әйткәндә, **һәр телнең үзенә җитәрлек грамматик ысуллары бар.** Тик аны белергә генә кирәк. Кызганычка каршы, бу соңгы елларда кайбер яшь язучы һәм журналистларыбыз телебезнең грамматик кануннарын, агач кортыдай, әкрен-әкрен генә кимерә башладылар. Ләкин берсе дә моны махсус эшлим димәс. Чөнки язу язучылар хәзер бик күбәйде. Яхшысы бар, начары бар. Әлбәттә, яхшысы күбрәк, ләкин начары да җитәрлек. Бер ишесе, мәсәлән, телне тумыштан ук белми, аны инде үгетләү түгел, дегетләсәң дә бер ни чыкмый; кайберсенең тел тою хисе атрофияләнгән, ул хәзер кайсы дөрес, кайсы ялгыш икәнлеген дә аермый, «алай да була!» дип, телебезнең төзек һәм мөкәммәл бинасына үзе сыярлык кына тишек тишеп, шуннан йөри башлаган; өченчесе исә үз телен өйрәнер-өйрәнмәстән Европа я Азиянең модалы бер агымына ияргән була да, телне мескен бакага әйләндереп, мәктәп баласыдай тәҗрибә ясый; тагын бер ишесе бар: болары исә «мин беләм инде!» дигән җирдә туктаган да, бүтән бер адым алга атламас. Әмма һәр кайсының нәтиҗәсе бер: телне бозалар!

Башлыйк орфоэпиядән. Татар телендә бер кагыйдә бар: яңгыраусыз ябык тартыкка беткән сүздән соң сузыкка башланган сүз әйтелсә, тартык аваз ачылып яңгыраулана. Мәсәлән: **дибәйтә** (дип әйтә), барыбал (барып ал) һ. б. Ләкин кайбер яшьләр, бигрәк тә җырчыларыбыз, орфоэпик нормаларны белмәү сәбәпле, бу нигез кагыйдәне бозалар: **дипәйтә, барыпал** диләр. Үзара сөйләшкәндә әле бер хәл, алай әйтмә, болай әйт дип, төзәтеп була. Әмма инде, көн саен булмаса атна саен, радиодан: «татарлар елмаепүлделәр» дип җырлыйлар икән — радионы борып куеп кына котылып булмый.

Татар шигърияте ндә берничә эндәш аваз — ымлыклар бар. Алар: **и, а, аһ. (Их, ах, ух, әй** ләр бу исәпкә керми, алар үзенә башка.) Шушы өч шигъри авазның берсе дә диярлек дөрес кулланылмый — **и әй** гә, **а ô** га, **аһ ах** ка әйләнде. Менә Р. Гатауллинның «Күңел ташлары» дигән китабына күз салыйк. Исеме бик начар. Ләкин «Күңел ташлары» инде ташка басылган! Безгә мисал эзләү генә кала. Р. Гатауллин үлеп ô ларны ярата. «О, бу тема!», «О, нинди яр анда», «О, кешеләр», «О, Сальери

түгел элеккечә!», «О, без нинди матур идек!», «О, язмыш!», «О, ул, бәхетем!», «О, горур гүзәл!», «О, матур таулар!», «О, бәхетле таулар!», «Ой, дәдә! Ой!»... Барысын да чүпләп чыктым шикелле, бүтәннәргә дә күз төшерик: «Оһ-оһ-оһ, күп әле аңлашылмаган нәрсәләр» (Р. Батуллин. Уйларымны кеше белсен); «һо! Кайттыңмы?» (А. Ганиев. Сүзсез җыр); «О, мәрхәмәтле хуҗа, алай димәгез!», «Оһо! — дип куандылар бораулаучылар» (Ш. Бикчурин. Каты токым.) һ. б.

Бу нинди ô лар, ôй лар, ôһ лар, һô лар? Тукайда бармы? Дәрдмәнд я Такташта бармы? Җәлилдә бармы?.. Илла кызык булыр иде, әгәр Тукай я Дәрдмәнд болай язса:

**О туган тел, ô матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!**
*(Г. Тукай. Туган тел.)*

**Җитәр, ô Дәрдмәнд, сүзне озайтма,**
**Катып уңган күңелләргә боз атма!**
*(Дәрдмәнд. Куанды ил.)*

Мәгълүм ки, татар телендә киң әйтелешле ô авазы юк. Ул фәкать рус теленнән кергән сүзләрдә генә бар: **сôвет, сôциализм** һ. б. Бәлки Р. Гатауллинның Тукай, Дәрдмәндләрне кабатлыйсы килмидер? Шигырь саен **а** дип сокланасы киләдер? Бездә дә бар ул а! Тик ул ô дип язылмый, ә «ат» дигәндәге а кебек языла һәм шулай әйтелә дә. Мәсәлән, Р. Гатауллин бик яраткан Бабич белән Такташта нәкъ шулай:

**Андамы, әйтимме!.. А!.. Анда гаять**
**Кадре зур бер нәрсә ул — «Әбелхаят!»**
*(Ш. Бабич. Газазил.)*

**А, атомнарны кояштан**
**Каплаган җир катлавы,**
**А, кояшны без атомнардан**
**Яшергән көл тавы!**
*(һ. Такташ. Янар таулар.)*

Миңа калса, Р. Гатауллин шигырьләрендәге сөекле ô ларның күбесен **и** белән алмаштырып булыр иде: «И язмыш!», «И горур гүзәл!» һ. б. Әнә чордашлары шулай язган бит: «И җәрәхәтле дулкыннар» (Р. Харис), «И җанның дәулы мизгеле!» (Зөлфәт).

Телдәге авазлар бик аз булганы хәлдә, алардан ясалган сүзләр санап бетергесез, ә мәгънәләре тагын да күбрәктер. Чөнки заман арты заман үтү белән өр-яңадан сүз ясау я кимегән, я бөтенләй тукталган. Аң ирешкән яңа мәгънәләр беренчел тамыр сүзнең тамыр мәгънәсеннән ишәеп үрчи башлаган. Бер сүзе бер генә мәгънә аңлаткан тел дөньяда юк. Хәтта синоним сүзләрнең дә оясы оягә тәңгәл төшеп утырмый. Бу хакыйкать көн саен сүз белән эш иткән һәр кемгә билгеле булырга тиеш иде югыйсә. Әмма көндәлек тел практикабызда алай түгел: менә дигән бер сүзне башка бер сүз кысрыклап чыгарып, аның бөтен мәгънәсен бер үзе били башлады. Мин аларны «универсаль» сүзләр дип атадым. Менә берничәсе: **катнашу, тудыру, башкару, җитештерү, кайгырту, чакыру, белдерү, җәелдерү, күрсәтү, күрсәткеч, буенча, почмак, бара** һ. б. һәр кайсына мисал меңләгән — ерып чыкмалы гына түгел! Шулай да беразын әйтеп үтми булмас.

**Тудыру** дигәненә берничә мисал: «Шушы елларда Салих Сәйдәшев мәшһүр «Совет Армиясе маршы»н **тудыра**»; «Хәзер инде Нигъмәтуллина һәм Рогожин тарафыннан **тудырылган** Сәйдәшев образы», «Хатыны икенче баласын тудыра». Кыскасы,

**тудыру** сүзе туып кына тора! Ләкин бу мисалларның берсендә дә ул **дөрес** кулланылмаган. Ни өчен? Чөнки **тудыру** сүзе ясалмыш кененнән үк нәсел ишәйтү процессына бәйләнгән. Мәгълүм ки, нәсел ишәйтүгә бәйле байтак сүзләр, дөньяга әдәп иңгәч, әйтелми башлаган. Шуңа күрә безнең татар әниләре нәсел ишәйтү серләрен чишмәс өчен **тудыру** сүзен әйтмәгән; моның өчен берәр нейтраль сүз, ягъни **таптым** дигән сүзне тапкан: коедан **таптым**, чишмәдән **таптым**, болыннан **таптым** һ. б. Чынлап та кайсыгызның әнисе: «Мин биш бала **тудырдым**» яки «Мин сине, улым, фәләненче елны **тудырдым**» дип сөйли икән?! Халык җыры да бар:

**Әнкәй мине т а п к а ч т ы н да ак биләүгә биләгән...**

Такташ та болай яза:

**Рәхмәт, әнкәй, сиңа,**
**Ярый әле, мине т а п к а н с ы ң...**

Ә без әдәбиятчылар — әдәп кешеләре — нишлибез? Әти-әниләребез әйтергә дә кыенсынган сүзне авыз тутырып, **тудырдык** дип кычкырабыз: **әсәр тудырдык, образ тудырдык, материаль байлыклар тудырдык** һ. б. Хуш, **тудыру**ны кулланмагач, **родильный дом**ны ничек тәрҗемә итәргә соң? Әлбәттә, **бала табу йорты** дип! Ә образны **иҗат итәләр**, әсәрне **язалар да, иҗат та итәләр**, рәсемне **ясыйлар**, материаль байлыкларны **булдыралар** һ. б. Янә, үзенең туган моментын үзе белмәгәнлектән, татар кешесе **тудым** дип сөйләми, **туганмын** ди. Шулай да **тудым** дип язучылар **да** күзгә чалынып тора. Мәсәлән: «Мин Башкортстанның Чакмагыш районы Яңа Мортаза авылында 1940 нчы елда **тудым**». (Р. Идиятуллин. Беренче карлыгачлар. 1969.)

**Күрсәтү** һәм **күрсәткеч. Күрсәтү** дигәне байтактан килә. Ул хәзер бер үзе генә дә җиде-сигез сүзне алмаштыра: әйтте, өйрәтте, аңлатты, сөйләде, язды, төшендерде, раслады — бөтенесе урынына да **күрсәтте** йөри ала. Бер генә мисал: «Мондый катнаш сөйләмнең булуын революциягә кадәр үк М. Гафури да **күрсәткән** иде». (М. Зәкиев. Туган тел үсеше.) Бу җөмләне укыганнан соң минем күз алдына Гафуриның «Менә!» дип бармагы белән төртеп **күрсәтеп** торган позасы күз алдына килеп баса.

**Күрсәткеч**нең гомере озын түгел әле. Ул күзгә алтмышынчы елдан соң гына чалына башлады. «Икенче урында Әхмәтсолтан Әминов бригадасы. Аның да **күрсәткече** безнеке чамасы үк»[1]. (Моны бригадир егет әйтә.) **Кискеч** — киселә торган предмет булмаган кебек, **күрсәткеч** тә күрсәтелә торган әйбернең, төшенчәнең, ягъни **уңыш, җиңү, нәтиҗә** һ. б.ның үзе түгел. Нигә предмет я төшенчәне үз исеме белән атамаска!

**Буенча** дигән бәйлек сүзгә берничә мисал. «Электрлаштыру **буенча** механик» (кирәк: электрлаштыру механигы); «Районда хезмәтне механикалаштыру **буенча** башкарасы эшләр гаять зур» (кирәк: районда хезмәтне механикалаштырасы эшләр гаять күп); «Мәктәпләр төзү **буенча** районның алдагы елга планнары нинди?» (кирәк: мәктәпләр төзүнең алдагы ел планнары); «Һәр группада терлекне симертү **буенча** технологик карта төзедек» (кирәк: терлек симертү өчен); «Уфа телевидениесе **буенча** чыгыш ясадылар» (кирәк: Уфа телевидениесеннән сөйләделәр); «Шагыйрьнең әсәрләрен популярлаштыру **буенча** нәрсәләр эшләнә?» (кирәк: популярлаштыру өчен); «Казан шахмат клубында йөз шакмаклы шашка **буенча** Татарстан чемпионаты тәмамланды» (кирәк: шашка уенының); «Иң җиңел үлчәүдә казанлы Р. Бикметов очколар **буенча** А. Самедовны отты» (кирәк: очко саны белән, яки: очколар ягыннан); «Туфан Миңнуллинның «Ир егетләр» пьесасы **буенча** эшләнгән спектакль (кирәк: пьесасыннан эшләнгән я куелган спектакль).

Кыскасы, **буенча**ны көн буе санасаң да бетәсе юк.

Бер-ике мисал белән генә **почмак** һәм **бара** дигән ике сүзгә тукталып үтәм. **Почмагыбыз** да хәзер, бик кыршылып йөри торгач кыры шомарып, түгәрәкләнеп килә. Менә: «Илнең барлык **почмакларын** күргән» (Ә. Баянов. Ут һәм Су); «Дөньяның төрле **почмак**ларыннан күренекле врачлар җыела» (Тат. календарь. 1969); «Җир

[1] Авторлары күрсәтелмәгән мисалларның һәр кайсы газеталардан алынды.

шарының төрле **почмакларыннан** алынган хәбәрләр» (Тат. радио, 1972). Телебездә илнең, **җирнең**, **дөньяның** **чите** бар, әмма шарның ни чите, ни кырые, ни **почмагы** булмый. Әлеге өч мисалда **почмак** нинди сүзләрне кысрыклап чыгарган соң? Санап бирик. «Илнең барлык **почмаклары**» түгел, ә бәлки «илнең барлык **җире**, барлык **урыны**, барлык **өлкәсе**, барлык **төше**, барлык **ягы**, барлык **тарафы**» һ. б. Ә «дөнья» дигәндә аңа **илләре**, **дәүләтләре**; «Җир шары» дигәндә **кыйтгалары**, **континентлары** килеп өстәлә. Күпме сүз!

Инде **бара** дигән сүзне бөтенләй аздырдык. Без язган, сөйләгәннәрдә хәзер ни генә бармый! Вакыйга **бара**, квартал **бара**, сүз **бара**, җыелыш **бара**, кино **бара**, конкурс **бара**, бәхәс **бара**, смотр **бара**... Бара да бара, бара да бара! Әгәр үз аягы белән генә бара алмаса, **алып баралар**. «Разведчиклар Арча җирендә эзләнү эшләре **алып баралар**» (Ә. Фазылҗанов. Һөнәрлеләр ягы); «Ә бу юлы исә концертны **алып баручы** булмау үзен бик нык сиздерде» (Р. Гарипов, М. Харисов. Зур концертка зур таләп); «Рояль партиясен **алып бара**» (Тат. радио, концерт программасы). Кая баралар? Кая алып баралар? — Һич мәгълүм түгел. Мисалның һәр кайсында **бара** сүзе үзенең төп мәгънәсен җуйган — хәрәкәттән халәткә авышкан. Хәлбуки аның телебездә бик популяр ике мәгънәсе бар: беренчесе хәрәкәтнең үзен, икенчесе дәвамлылыгын аңлата, ул чагында ярдәмче фигыль вазифасын гына үти. Беренчесенә мисал:

**Китте болар. Б а р а, һаман б а р а, б а р а,**
**Күренмидер күзләренә ак һәм кара.**

*(Г. Тукай. Кәҗә белән сарык хикәясе.)*

Икенчесенә мисал:

**Күзләре й о м ы л ы п б а р а инде аның әкрен генә!**

*(Г. Тукай. Миңубикә.)*

**Бара**, **алып бара** кебек хата мәгънәле фигыльләрне нинди сүзләр белән алмаштырып була соң? Җөмләсенә карап төрле сүз я конструкция белән алмаштырып була. Әйтик, пьесаларда язган кебек: «Вакыйга безнең көннәрдә бара» дип түгел, ә «безнең көннәрдә булган вакыйга» дип, конкурсны **башланды**, **дәвам итә**, **тәмамланды** дип, рояль партиясен **уйный** дип төзәтү мөмкин иде. Шулай ук Ә. Фазылҗановның да «Разведчиклар Арча җирендә эзләнү эшләре **алып баралар**» дигәнен гадирәк итеп — **эзләнәләр**, нидер **эзлиләр**, **эзләнүне дәвам иттерәләр** һ. б. кебегрәк итеп — үзебезчә язып булыр иде.

Озынга сузмый гына, җитәкләшеп кизү йөргән тагы бер-ике дежур сүзгә тукталып үтәм. Алары җөмләнең «зур роль уйный», «зур әһәмияткә ия», «зур урын алып тора» кебек универсаль хәбәрләре.

Бу мәкаләне язганда мин яңадан бер мәртәбә Г. Тукайның «Халык әдәбияты» дигән мәкаләсен укып чыктым. Бармы анда **зур роль уйный**лар, **зур әһәмияткә ия**ләр, **зур урын алып тора**лар? Ләкин шундый да гади, шундый да гыйльми, чын безнеңчә мәкаләләр тагын да язылсын иде!

Җөмләнең «дежур», «универсаль» хәбәрләре бу бер-ике ел эчендә тагы бер тәгъбиргә артты әле. Анысы — **өлеш кертү**. Элек ара-тирә, **тәкъдим әйтте** диясе урынга, тәкъдимне генә **кертәләр** иде. Хәзер — **өлеш кертәләр**. Әйтергә кирәк, өлешләп кенә түгел, күмәртәсе белән кертәләр. Мисаллар: «Бу эшкә аларның һәр кайсы үз **өлешен керткән**» (Н. Саттарова. Гүзәллек җырчысы); «Мәктәп коллективларының укыту процессын камилләштерүгә зур **өлеш** **кертүләре** әйтелде» (М. Ягъяев. Заман таләпләре); «Урып-җыюны югалтуларсыз үткәрүгә зур **өлеш кертте**» (С. Дементьев. Коммунистның җаваплылыгы); «Ул һәм аның семьясы колхозның районда алдынгы хуҗалыклар рәтенә басуына зур **өлеш** кертә» (Г. Галимҗанов. Алар — бер колхоздан).

Сүз төрләнү кануннары бик нык унификацияләнү сәбәпле татар теленә кушымча һәм бәйлек тавтологиясе хас түгел. Әмма ләкин сүз ясау ысулы буларак телебез түрендә тавтологиянең үз урыны бар. Тик без аны — я онытхан, я белмибез, дөрес-

рәге: бик тә «мудрить» итеп язарга тырышуыбыз аркасында бу садә, үзебезчә сүзләрдән файдаланмыйбыз. Нинди сүзләр соң алар? Менә алар: 1) форма тавтологиясе — буяу буяу, чәчү чәчү, чигү чигү, кичү кичү, кәтү кәтү, язу язу, каю каю, сату, сату, тәрәү тәрәү, биләү биләү, кату кату, сүрү, сүрү, туку туку, ташу ташу, тегү тегү һ. б.; 2) тамыр тавтологиясе — эш эшләү, буа буу, аш ашау, бәйләм бәйләү, яшен яшьнәү, өем өю, урам урау, кием кию, таң таң ату, йокы йоклау, җыр җырлау, көй көйләү, күк күкрәү, салым салу, иләк иләү, атлам атлау, ау аулау, им имләү, ярма яру, уй уйлау, тугым тугу һ. б. Бу сүзләрнең инде күбесен оныттык. Онытмаганнарын да, ике кабат кабатлаудан курыккан булып (аннары бик тә үзебезчә була бит), икенче өлешен икенче сүз белән алмаштыра башладык. Шуның берсе — **башкару** дигән сүз. Мәсәлән, **кәтү кәтә** генә түгел, ә «Тормыш иптәше Әсләх терлекче-**кәтүче хезмәтен башкара**»; **эш эшләнде** генә түгел, ә «Клубларның материаль базасын яхшырту буенча шактый **эш башкарылды**»; **кызлар тегү тегә** генә түгел, ә **кызлар тегү эшен башкаралар**; **чигү чигәләр** генә түгел, ә **чигү эшен башкаралар**; **фәлән җырчыбыз җыр җырлый** гына түгел, ә **җыр башкара** яки **фәлән җырчыбыз башкаруында фәлән җыр ишетерсез** һ. б. Нинди тел бу? Кем теле? Нигә **җырлый** гына түгел? Гел **җырлый** гына дисәк, бер төрле генә булып, телебез фәкыйрьләнә дисезме? Ә гел башкара гына дигәч, тел фәкыйрьләнмимени? **Җыр җырлый** дигәннең әле аның, кирәк кешегә, **җыр әйтү** формасы да бар. Мәсәлән: «Безнең турыга җитәрәк, егетләрнең берсе (мөгаен Әхәттер!) гармун көенә сәер генә **җыр да әйтте**». (Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр. 3 том. 1968. 256 бит.)

**Мәгънәсе бозык сүзләр.** Болар да гел күренеп тора. Мәсәлән, **вакытлы матбугат** дигән терминдагы **вакытлы** сүзен, безнеңчә, мотлак үзгәртергә кирәк. Чөнки **вакытлы** сүзенең чын мәгънәсе, күпме тартсаң да, **вакытлы** дигәнне генә аңлата: **вакытлы эш, вакытлы кеше, вакытлы хөкүмәт, вакытлы хәл** һ. б. Димәк ки, миңа калса, **вакытлы** дигән (һәм грамматик, һәм политик яктан) бик хата сүз урынына **көндәлек** дигәнне кабул итсәк, һәр яклап та дөрес булыр иде. Бу сүзнең мәгънәсе, киңәеп, **айлык** я **атналык**ка да кучә ала. Чөнки ай да, атна да — **көн**нең күплеге генә, шулай булгач барысының да мәгънә тамыры бер. Әйтергә кирәк, **көндәлек матбугат** дип өлкән журналистыбыз Сәгыйт ага Фәйзуллин күптән яза: «Кайвакыт мәктәп дәреслекләре белән **көндәлек матбугат** арасында да терминнарны куллануда аермалар очрый». (Ике тел хәзинәсе. 1964.) Болай язу газета-журналларда да күренә башлады: «Хәзер Казан диңгезе булып җәелгән Казанка елгасы буенда **көндәлек матбугат** чыгару өчен яңа комбинат салына». («Казан утлары». 1970. 10 сан.)

Язу язучыларыбыздан хәзер **ничек** белән **нинди** сүзен бутаучылар барлыкка килде. Мисаллар: «Өстендәге йон күлмәге **ничек** килешә аңа» (Мәгъсүм Хәбибуллин. Кискен җыры.); «Ах, **ничек** сагындырганl» (Зиннур Мансуров. Сагыну); «Мин сине ничек яраттым!» (Р. Фәйзуллин. Монологлар); «Аһ, син **ничек** каты уйлыйсың!» (Р. Харис. Кайтаваз); «Күрәсезме, аларның таҗ яфраклары **ничек** сизгерләр» (Р. Төхфәтуллин. Давыл чәчәге).

**Ничек сүзе**, гамәлнең рәвешеннән тыш, төрле дәрәҗә аптырау, гаҗәпләнүне аңлата. Янә дә үрнәге Тукайда бар: «**Ничек** соң без табындык потка?» дип хәйранга калганнар». (Г. Тукай. Иһтида.) Ә мин әйткән мисалларда исә **ничек**? дип аптырау түгел, ә гамәлнең куәт дәрәҗәсе, соклану я таң калу булырга тиеш иде. Мәсәлән, Р. Фәйзуллинның уенда, әлбәттә, «Мин сине **нинди** яраттым! дип, яратуының көчен әйтү теләге булган, ләкин сүзен таба алмагач, теләгенең бөтенләй киресе килеп чыккан. Ягъни, «Мин сине **ничек** яраттым?» дип аптырап, хәйраннар калып тора. Бу урында, әлбәттә, **нинди** сүзе кирәк иде. Әнә, Тукайлар шулай язган. «**Нинди** елмайган авызлар! Күрсәнә, ул нинди шат!» (Мияубикә). «**Нинди** оста алдадым түгелме ди», «Шул әнә, **нинди** әнә, **нинди** яна». (Ш. Бабич. Газазил.) «Күрәсең, әнә Йолдыз да **нинди** сагынган үзеңне». (Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр, 1 том, 50 бит.)

Аерым сүзләрнең генә түгел, тоташ җөмләләрнең дә ялгыш мәгънәле булу мисаллары бар. Менә берсе: «Ул акча тора». (Н. Дәүли. Җимерелгән бастион; А. Расих. Каһарманнар юлы, журнал варианты.) Бу иптәшләр әлбәттә русчаның «Он денег стоит» дигәнен татарча әйтергә уйлаганнар, ягъни «аңа бит акча түләнгән», «ул бит акча җимеше» дип әйтәселәре килгән, әмма «ул акча тора» җөмләсенең татарча мәгънәсен белмәүләре сәбәпле, бөтенләй башка мәгънәле җөмлә килеп чык-

кан, ягъни «ул акча тора» дигәндә без: **ул акча тора**, **тотылмаган**, **куйган килеш тора** дип аңлыйбыз.

Радиодан көн саен һава хәлен әйтәләр. Ләкин «бүген төнлә салкын **булды**» дип, гап-гади генә әйтәсе урынга, «бүген төнлә салкын һава **сакланды**» яки «салкын һава **күзәтелде**» диләр. **Аязучан болыт**, **алмашынучан болыт**лар да радионыкы. Кем язып бирә моны? Болыт **алмашынмый** бит, болыт **аязмый** бит! Болыт **чыга**, болыт **каплый**, болыт **агыла**, болыт **тарала** һ. б. Әгәр күктә болыт йөзеп тә, кояшны каплый алырлык булмаса, андый көнне без гомумән **аяз** дибез. Инде бер болыт та булмаса, анысын **чалт аяз** дибез. Радионың **аязучан болыт**, **алмашынучан болыт** дигән башваткычы безнеңчә **аяз** көн була микәнни инде ул? Аннары халкыбыз, гомумән, **һава** дип сөйләүгә караганда, күбрәк **көн** дип сөйли: **көн** аяз, **көн** болытлы, **көн** начар, **көн** юеш һ. б. Ләкин бу әле һич тә **һаваны** **көн**гә алмаштыру кирәк дигән сүз түгел: һәр кайсының үз урыны бар. Әйтик, Тукай: «Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта **һава**» дип язган икән, моны инде **көн**гә әйләндереп булмый: **урта** көн килеп чыга. Радиодан янә бу араларда: «Республика юлларында яңгыр **ява**» дип әйтә башладылар. Анысы тагы нинди яңгыр микән — юлга гына ява торган!

Мәгънәсе бозык сүзләребез байтак, барысын да санап чыгу һич мөмкин түгел — бик нык күзгә кереп торганнарын гына әйтеп китәм. **Кыска вакыт** түгел, **аз вакыт**, чөнки вакыт **озын** я **кыска** булмый — **аз** я **күп** була. **Вакыт** **ничә** яки **вакыт** **күпме** дип сорау дөрес түгел, вакытны беләсе килгәндә **сәгать ничә** дип сорау дөрес. Чөнки, беренчедән, вакытны бер, ике, өч, дүрт... дип санамыйлар; икенчедән, гомумән вакыт ул бик күп — чиксез! Янә, шигырьне **уку** бар, **сөйләү** бар: карап укыса, **укый** була, яттан сөйләсә, **сөйли** була. Әмма бу ара шагыйрьләребез, ни сәбәптер, халык алдына чыкты исә: «Мин сезгә хәзер берничә шигырь **укыйм**» дияр дә, китапканигә күз дә атмастан, ике кулын селти-селти яттан шигырь **сөйләп** җибәрер. **Янә металл ватыклары** түгел — **тимер-томыр**. Чөнки металл кирәч савыт шикелле ватылучан, уалучан әйбер саналмый. Янә өйне, бинаны, башканы **торгызмыйлар** — ауган, егылган, яткан әйберләрне генә торгызалар; өйне **күтәрәләр**, **салалар**, **төзиләр**, **җиткезәләр** һ. б.

**Кушма сүзләр.** Бу мәсьәләдә безнең үз телебезгә генә хас булган мөстәкыйль кагыйдәбез юк диярлек — барысы да күчерелгән, барысы да алынган. Бер генә мисал: рус телендә **унбердән** алып **унтугызга** кадәр саннар кушылып языла. Бу — рус теле өчен бик дөрес кагыйдә. Чөнки хәзерге рус телендә **дцать** дигән мөстәкыйль сүз юк. Ә безнең телдә **ун**ы да, **бере** дә бик мөстәкыйль ике сүз. **Ун бернең илле бер**, **йөз бер**, **мең бер** дигән саннардан нинди грамматик үзгәлеге бар? Ләкин **ун бер** кушылып языла, ә **йөз бер**, **мең бер** аерып языла. Әгәр үзебезнең мөстәкыйль кагыйдәбез булган булса, я боларның икесе дә кушылып, я икесе дә аерылып языла иде.

Гомумән, бездә хәзер теләсә кем теләсә нинди сүзне куша ала. Бер мәгънә аңлата диләр дә, ике сүзне китереп кушалар. Хәтта компонентларына карап бу сүзләрне үзенә күрә классификацияләгән дә булалар. Әйтик, беренче компоненты — **гомум**, **бөтен**, **ярым**, **һич**, **бер** һ. б.; яки икенче компоненты — **ара**, **чак**, **еллык**, **томлык** һ. б. сүзләр. Менә көндәлек матбугаттан да, китаплардан да чүпләнгән «кушма» сүзләребез: **бөтенхалык**, **бөтендөнья**, **гомумүсеш**, **радионокта**, **радиотыңлаучылар**, **ультрасул**, **унтомлык**, **икееллык**, **ярымшар**, **ярымүткәргеч**, **җирбиләүче**, **егетчак**, **кызчак**, **шулчак**, **күпчак**, **сукояр**, **сусаклагыч**, **телара**, **кабиләара**, **халыкара** — бихисап күп болар! Яратышмый, көчләп өйләндерелгән егет белән кыз кебек.

Ике сүз кушылыр өчен иң әүвәл беренчесенең басымы юкка чыгарга тиеш. Чөнки татар телендә сүз басымы **һәр** вакыт соңгы иҗектә була — кушмамы ул, ялгызмы. Мәсәлән, **ташбака**, **билбау**, **кыргаяк** (монысында хәтта нәкъ кушма сүзләр өчен кирәк булган тагы бер шарт бар: **кырык** сүзенең инде формасы да җуелган). Болар кушма сүз, чөнки басым фәкать соңгы иҗектә генә. Әгәр беренче сүзгә дә басым куйсак, бу сүзләр шундук ике якка аерылып китәр. Мәсәлән, **таш бака** (таштан ясалган бака), **бил бау** (бил һәм бау), **кырык аяк** (ягъни аяк икәү генә түгел, ә кырык). Шулай итеп, никахсыз кушылган ике сүзнең беренчесе дә басым белән әйтелә икән (яки әйтелә ала икән), алар кушма сүз түгел. Мисаллар: һәр вакыт,

һич нинди, һәр кайсысы, һәр кеше, һәр җир, теләсә кем, әллә нинди, бер ни, җир биләүче, халык-ара, ике еллык, ярым шар, дөнья-күләм, бөтен халык эше һ. б.

Теләсә нинди ике сүзне кушардан әүвәл аналогия дә ясап карау кирәк. Мәсәлән, газета: «Галимҗан Ибраһимовның **унтомлыгы** чыгачак» дип хәбәр итте. Әлбәттә, **ун томлык** кушылган. Ләкин моны кушкан иптәш, аналогия ясап, уйларга тиеш иде: «Ярый, **ун томлык**ны куштым. Ә Чеховның **ун ике томлыгын**, Горькийның **утыз алты томлыгын** ничек язарга?» дияргә тиеш иде. Аналогиягә тагы бер мисал: **радиотыңлаучы**ны кушып язган иптәш тә иң әүвәл: «Ярый, **радио** тыңлаучыны куштым. Ул чагында **сүз** тыңлаучы, **концерт** тыңлаучы, **опера** тыңлаучы, **кинәш** тыңлаучыны нишләтергә — кушаргамы, юкмы?» дип аз гына миен селкетергә тиеш иде! Чынлап та нишләтергә соң: икенче компоненты барсының да бер, ә беренче компонентлары — һәр кайсының мөстәкыйль сүз?

Теләсә нинди ике сүзне кушып язмаска кирәклекнең тагы бер шарты бар: ул — сүзләрнең фотографиясе. Без, мәсәлән, китап я газетаны алып укый башлау белән, фотодан берәр танышыбызны күргән кебек, тиз генә сүзне дә танып алырга тиешбез. Ләкин сүзләр кушылып беткәч, мин аларны танымый торам, хәтта ничек укырга да белмим. Мәсәлән, **күпсерияле** дигәнне мин башта үзебезнең **күпсену** дигән сүз кебек, тамырын **күпсер** дип укый башлыйм. Ә менә сукояр ни дигән сүз? Мин аны танымыйм, үзебезчә укыр идем — специфик татар авазлары юк, шуңа күрә мин аны русча итеп **сукóяр** дип укыйм. Берничә елдан соң гына белдем: русчадагы Водолей йолдызлыгын шулай тәрҗемә иткәннәр икән. Сý коя́р дигән сүз икән ул.

Һәр кемгә билгеле: татар телендә кыска сузыклы, озын сузыклы сүзләр юк. Ләкин куша торгач, андый ялган сүзләр дә барлыкка килде: **суүсем, кабиләара, икееллык** һ. б. Боларның икәвесе — әлбәттә кушма сүз. Тик алар кушылып түгел, ә сызыкча аша язылырга тиеш иде: су-үсем, кабилә-ара һ. б. Бер көн газетадан **трансиран** дигән сүз укып аптырадым. Бераз баш ваткач кына белдем: ул **тран-сиран** түгел, ә **транс-иран** икән. Ә мин ни өчен аны **тран-сиран** дип укыйм? Чөнки татар телендә сүз уртасына ике тартык янәшә килсә, аның берсе бер, икенчесе икенче якта кала, ягъни сүз уртасындагы иҗек һәр вакыт тартык аваздан башлана. Шуңа күрә бу сүзне мин **тран-сиран** дип укыйм да. Димәк, **тран-сиран**нар, **тран-сатлантик**лар килеп чыкмасын өчен безнең телдә андыйларны дефис белән бүлеп язарга иде: **транс-иран, транс-атлантик.** Татар телендәге иҗек сүз уртасында сузыктан башланмый дидек. **Халыкара**ны иҗекләргә бүлек карыйк: **ха-лы-ка-ра.** Ләкин безгә **халыкара** кирәкми (бу мәгънәсез), безгә халык-ара кирәк. Шулай булгач, соңгы компоненты **ара** булган ярым кушма сүзләрне дефис аша язарга кирәк: дефис бу очракта бик кирәк булган ике сүзнең басымын да саклап кала: халы́к-ара́.

Нәтиҗә: татар теле өчен иң дөресе — мөстәкыйль сүзләрне кушмау. Чөнки, әйткәнемчә, телебез флектив тамырлы түгел; сүзләребез дә ничек бар, шул килеш каткан — механик кушудан гына аның мәгънәсе үзгәрми: аеры торганда ни мәгънә бирсә, кушылгач та артын алга әйләнеп басмый. Аннары тагын, әйткәнемчә, тел кагыйдәләребез бик нык унификацияләнү сәбәпле бездә бер нинди мөстәсна (искәрмә) юк. «Башка телләрдә бар бит, бездә дә булсын әле», дип кенә ясалма исключениеләр ясау — үз тел кануннарың белән исәпләшмәү генә ул. Безгә дә тел кагыйдәләребезне камилләштерергә вакыттыр инде? Тормышта бит ялгышлыклар төзәтелеп тора; телдә дә ул шулай булырга тиеш иде. Әнә рус теле үрнәк. Аның кайбер кагыйдәләре, тормыш таләбенчә, без белгәндә генә дә берничә кабат камилләштерелде инде.

**Кушымчалар.** Монда да буталчык күбәйде. Алыйк халкыбыз җан кебек күргән изафә категориясен. Ул безне бик күп артык сүзләрдән азат итә, җөмләбезне кыска, экономияле итә, чөнки сүзнең **кемгә, нәрсәгә** япсаруын бер кушымча әйтеп бирә. Тик без моны хәзер нигәдер аз куллана башладык. Гыйбрәтле бер генә мисал (дөрес, бу тәрҗемә, ләкин тәрҗемә дә безнең тел бит!): «Сез безгә үзегезнең товарларыгызны саткан өчен алырга тиеш булган акча өчен сез бездә безнең товарларны ала аласыз». («Кызыл таң» газетасы.) Күрдегезме, **сезнең, безнең** ди торгач, күпме сүз килеп чыккан! Хәзер моңа изафә формасы белән операция ясап карыйк. Менә: Безгә саткан товарларыгыз акчасына бездән товар ала аласыз». 17 сүз урынына 8 сүзлек җөмлә!

**Килеш кушымчалары.** Болар бер сүзне икенчесенә бәйли. Бәйләнгән сүз бәйләгән сүз таләбенә карап бер килеш кушымчасы кабул итә. Мәсәлән, **катнашу** сүзе фәкать юнәлеш килеш кушымчасы таләп итә, ягъни **кемгә, нәрсәгә** катнашу? Шуңа күрә **җыелышта** катнашу, **бәхәстә** катнашу — дөрес түгел, дөресе: **җыелышка** катнашу, **бәхәскә** катнашу. Мәсәлән: «Без буржуа да түгел, пролетарий да түгел, без сыйнфый **көрәшкә** катнашмыйбыз диделәр». (Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. 105 бит.) Яки **кайгырту** сүзе. Матбугатта әледән-әле күренеп тора: кайбер иптәшләр ни сәбәптер **турында кайгырту** моделе белән язалар. Хәлбуки, **кайгырту** сүзе һәр вакыт төшем килеш кушымчасын гына таләп итә. Халыкта аның классик мисалы бар: **иртәгесен ишәк кайгырткан** диләр. Менә язучыларыбыздан да мисал: «Инде мин чирлисен чирләгән, улым, **мине** кайгыртма» (Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр. 2 том. 24 бит); «Үз кайгың колагыңны күмгәндә ниндидер Ычтапаннарның кайгы**сын** кайгыртып ятма әле» (Г. Мөхәммәтшин. Тынгысыз төн.).

**Хыялла**ну сүзе дә үз бәйлеген җуя башлады — аңа да хәзер икенче сүзне **турында** белән бәйлиләр. Ә халыкта аның **дип хыяллана, белән хыяллана** калыбы бар. Беренчесе мәгълүм, икенчесе күбебезгә мәгълүм түгел ахры — мәгълүм булсын: «Берсе — Иран купецының кызы Сәлимә, икенчесе — дөньяның иң ерак илләрен барып күрү **белән хыялланучы** Казан шәкерте» (К. Нәҗми. 4 том. 133 бит); «Ул вагон сәкесенә менеп ята да, үзенең мәктәптә уздырган матур көннәре турында уйлана, яисә киләчәге **белән** хыяллана иде». (Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр. 1 том. 150 бит.)

**Өстәл артында утыра, руль артында утыра** кебек тәгъбирләр дә бер заман бик еш күренә башлаган иде, без аларны хәзер шактый киметтек. Шулай да кайвакыт татарча белмәүчеләр яки татарча уйлап җиткермәүчеләр телендә бүген дә күренгәләп китә. Мәсәлән: «Идарә пульты **артында** ике кеше утыра». Нәрсә, качып утыра микәнни алар? «Яшь Салих (Сәйдәшев — Х. С.) көннәр буе гармун тарткан, пианино **артында** утырган». Көннәр буе нишләп алай кешедән качып утырды микән ул егет?

**Күплек кушымчасы.** Телебездә күплек кушымчасы да бер төрле генә. Монда да тел тавтологиядән бик җиңел котыла. Чөнки безнең исем, сыйфат, фигыль, модаль сүзләребезнең һәр кайсында, ясалмышында ук, күплек идеясе бар. Мәсәлән, **бүрәнә.** Бу күп. Күп булмаса, **бүрәнәдән** йорт салып булмас иде. Яки: **таш.** Бу да күп. Күп булмаса, таш ташыйбыз димәсләр иде. **Аягыңа итек, кулыңа бияләй ки** диләр. Моңа карап аягы да, кулы да бер генә микәнни дип кем уйлар! Г. Тукай болай язган:

> **Каты йоклап Ай бишектә мәгърипкәчә,**
> **Торып чыга, көлеп җиргә н у р ы н чәчә.**
>
> *(Ай һәм Кояш.)*

Нур**лар**ын чәчә димәгән. Яки: «Минем **күз** күпне күрә, колак күпне ишетә» диган, мәгәр хәзергечә: «Минем күзләрем күпне күрәләр, колакларым күпне ишетәләр», димәгән.

Алай булгач **берлек** идеясен ничек аңлатырга соң? Аны, сүз сөрешенә карап, сүз үзе яки **бер** дигән артикль аңлата. Әйтик, **тарыдан** ботка була, ә **бер** тарыдан ботка булмый. Инде күплек кушымчасының үзенә кайтыйк. Әлбәттә, аның беренче мәгънәсе, вазифасы — әйберләрне ишәйтү, күбәйтү. Ләкин ул моның белән генә чикләнми, моннан тыш әле аның тагын ике төп вазифасы бар: берсе — исем ясау, икенчесе — сүзнең экспрессив куәтен куәтләү.

> **Факелда җилләр шаяра,**
> **Алланып куя һава,**
> **Сабан туй батыры кебекл ә р**
> **Вахтадан кайтып бара.**
>
> *(Х. Туфан.)*

**Кебек кә лә р** кушылып, сүзне күбәйтмәгән, ә исем ясаган: кемнәр? — сабан туй батыры кебекләр. Ә менә бу шигырьдә дүрт күплек кушымчасының дүртесе дә фәкать экспрессив куәт өчен куелган:

**Килмә якын зәһәрләнеп ес л ә р е м ә!**
**Ерткычлык чыккан синең йез л ә р еңә!**
**Канат л а р ың канлы синең, килмә! Куркам.**
**Кан йөгергән агу, зәһәр күз л ә р еңә.**

*(Һ. Такташ.)*

Кыскасы, күплек кушымчасының кайчан куела, кайчан куелмавын үзенә бер мәкалә язып сөйләргә була. Тик мин монда озынга җибәрмичә шуны гына әйтәм: язу язучыларыбыз нигәдер күплек кушымчасы белән артык мавыга башладылар. Кирәгенә дә куя, кирәкмәгәненә дә куя. Хәлбуки, телебездә, зәгыйфь я авыру җәнлекләрне аулап йөргән бүре төсле, күренмәс бер санитар бар. Ул — шушы телнең генә үз кануны. Бу канун һәр грамматик категорияне чамалап кына, пропорциясен белеп кенә кулланырга өйрәтә, **лар** га да бик ларылдарга ирек бирми. Ләкин канун бер, аны белү-белмәү икенче нәрсә. Менә тагын ике мисал. Дәрдмәнднең «Сайланма әсәрләр»енә кергән бар⁻ык шигырендә 3820 сүз бар, шуларның 257 сенә күплек кушымчасы кушылган. Ягъни 15 сүзгә бер **лар** туры килә. Ә менә Р. Фәйзуллинның «Гадиләргә гимн» шигырендә җәмгысе 499 сүз булып, шуларның 144 енә күплек кушымчасы кушылган. Ягъни өч сүзнең берсе, Тукай әйтмешли, ларылдап тора!

**Тыныш билгеләре.** Бу өлкәдә шулай ук бик нык буталчыклык хөкем сөрә. Әгәр кушма сүзләрдә яратышмаган ике сүзне тотып кушсак, монда исә ана белән баладай җитәкләшеп барган ике я өч сүзне аерабыз. Әйтик, **дип** сүзе. Ул үзе юкса ике сүзне чат ябыштырып куярга тиеш иде. Ләкин ул хәзер бер ни дә эшли алмый: әллә нинди кагыйдәләр, искәрмәләр чыгара торгач, **дип** ләребезне ике яктан да тешле-тырнаклы, тырмалы-сәнәкле тыныш билгеләре эченә тыгып куйдык та, ул хәзер, мескен, мәзюс карашлы бер мәхбүскә әйләнде. Тыныш билгеләре куйганда мәгънә ягы гына түгел, синтаксик ягы да искә алынырга тиеш диган булып, катлаулы хәбәрләрдәге **күрәсең, ахры, югыйсә, ичмасам, мөгаен, әйдә, имеш** ләрне үз аналарыннан аерып бетердек. Мәсәлән, менә бу җөмләне ничек аңларга: «Әни дөрес әйтәдер, мөгаен, корычтыр аның куллары». (Г. Бәширов. Сайланма әсәрләр, 3 том. 11 бит.) **Мөгаен** кайсы якта — «әни дөрес әйтәдер мөгаен»ме, әллә: «мөгаен корычтыр аның куллары»мы? Яки: «Бер күсе йөгерә, имеш тә, бу куган төсле була» (Г. Тукай). **Имеш** кайсы якта? Яки тагын: «Бөлсәк бөләрбез, әйдә, бездән калмасын» (Г. Бәширов). Ягез, моның **әйдәсе** кайсы якта — «бөлсәк бөләрбез әйдә»ме, әллә «әйдә бездән калмасын»мы? Менә шулай адым саен өтергә абынып, ни йөгереп кенә укып китә алмыйча, ни мәгънәсен аңлап бетерә алмыйча утырасың.

Хуш, соңгысы итеп Г. Тукайдан тагы бер мисал алам. «Тәләһһеф» диган шигыренең актык строфасы болай:

**Керләнә өс, өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк,**
**Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк!!**

Шагыйрьнең дүрт томлыгына да, соңгы «Шигырь китапханәсе» сериясендә дә **керләнә өс** дигәннән соң, язганымча, өтер куйганнар. Хәлбуки язучы һәм галимебез М. Мәһдиев әйтүенчә, Тукайның үз оригиналында **керләнә өс**тән соң бер билге дә юк икән. Чөнки ул вакытта дефисләр дә, нилэр дә булмаган, гомумән тыныш билгесен — кирәк булса куйганнар, кирәк булмаса куймаганнар. Ә без, әлбәттә, үзебезне Тукайга өтер куеп чыгарга кирәк дип саныйбыз да, **керләнә өс** артыннан боргычлап бер өтер сылыйбыз. Шуннан **керләнә өс** чыга да, **өстенә рух** дигәне бер мәгънәсез аерылып кала. Ә Тукай алай дип түгел, ә бәлки «Керләнә өс-өстенә рух» (ягъни рух өсле-өстенә керләнә) дип язган икән. Шуңа күрә дә: «Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә — мунча, **җанга** — юк?» дип әйткән дә. Менә сиңа өтер!

Табигать безгә күрергә күз, ишетергә колак, сөйләргә тел биргән. Болар һәр кемнең яшәвен якты, моңлы, җырлы иткән өч гүзәл шәйдер. Ә безнең өчен алар унлата, йөзләтә кирәк: без халыкка үткен күз, сизгер колак, чын телебез белән хезмәт итәргә тиеш. Өстәвенә тел — безнең **бердәнбер** эш коралы да. Ул бер, ә без

мең! Шуңа күрә без инде аны меңебез мең яктан бозмыйк. Киресенчә, меңебез мең яктан үстерик, баетыйк. Ә моның өчен әүвәл телнең үзен өйрәнү кирәк.

Әдәби телебез турында, фәнни сөйләшүләрдән тыш, конкрет анализлы популяр мәкаләләр язылсын иде. Ләкин бу елларны андый мәкаләләрнең популярлыгы бетте. Радиодан сөйләмибез, телевидениедән сөйләмибез, газета-журналларга язмыйбыз. Дөрес, «Социалистик Татарстан» сүзләр этимологиясе, авыл, кеше исемнәре этимологиясен бастырып әйбәт итә, шулар янына тел турында да мәкаләләр бирә барса, нинди әйбәт булыр иде. Язучыларның үзләрендә дә күпмедер дәрәҗә гаеп бар. Менә бер әсәргә анализ ясыйлар, эчтәлеге тикшерелә, идеясе тикшерелә, ә теле — юк. «Кайбер җитешсезлекләренә карамастан, теле әйбәт» диген, аркылысы-буе бер тигез шаблон җөмләдән узмыйбыз. Хәтта «әсәре әйбәт, теле генә начар» дигәнне дә ишеткән бар. Бу ни дигән сүз? Көйнең чын моңы булмаса, без аны Илһам Шакиров җырласа да тыңламыйбыз. Теле, моңы булмаган язучы да макталырга тиеш түгел. Чөнки сәнгать теле булмаганда, бер нинди гүзәл идеяләрне дә сәнгать дәрәҗәсенә менгезеп булмый. Чөнки идея һәм тел — бер кешенең ике күзе, ике кулы, ике аягы; ниһаять ул — бер кешенең сөяге белән каны, акылы белән йөрәге! Чын идея чын тел белән язганда гына халык күңеленә төшеп сеңә.

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карары язучылар алдына яңа бурычлар куйды, идеологик көрәшнең сыйнфый асылын ачты һәм фронт сызыгын сызды. Без язучылар шул сызыкның иң алгы буена басарга тиеш. Шуңа күрә безнең төп эш коралы булган телебез дә булаттай ялтырап торырга тиеш икән. Зәгыйфь телле имгәк әсәрләр белән генә бу көрәштә җиңеп булмаячак.

# «ЧИКЕРТКӘ»—ТАТАР ТЕЛЕНДӘ БЕРЕНЧЕ САТИРИК ЖУРНАЛ

1905 елгы Беренче рус революциясе Россия халыклары тормышында зур җанлану тудырды. Революциянең шифалы йогынтысы нәтиҗәсендә илнең күп кенә почмакларында яңа газета-журналлар чыга башлады. Күбесенең бик кыска гомерле һәм аз тиражлы булуына карамастан, алар илдәге иҗтимагый фикер үсешендә әһәмиятле роль уйнадылар, массаларны үткән революция сабакларында тәрбияләү буенча зур эш эшләделәр.

1906 елның 23 апрелендә Оренбургта чыга башлаган «Чикерткә» дә үз өстенә әнә шундый мактаулы бурыч алган журнал булды. «Чикерткә»нең дөньяга килүе русларның «Саранча» журналы белән бәйле. «Саранча» уртача форматта 36 биттән тора торган журнал булып, «Чикерткә» аның эчендә татар тексты белән басыла. Бу журналның бары биш саны чыгып кала. 1906 елның ахырында «Саранча» һәм аның белән бергә «Чикерткә» дә чыгудан туктатылалар.

«Чикерткә», һичшиксез, татар телендә чыга башлаган беренче сатирик журнал булып исәпләнергә тиеш. Чөнки Уральскида «Уклар» журналын чыгаруга рөхсәт алданрак алынган булса да, аның чыга башлавы «Чикерткә»дән соңгарак кала.

«Чикерткә» беренче санында ук үзен «көлке вә әдәби журнал» дип тәкъдим итә һәм укучыларына «Оренбург вилаяте мәгыйшәтеннән рәсемнәр, һәҗүиләр вә ачы кинаяләр, гомуми кызык шәйләр, әдәбият вә мәгыйшәт хакларында вак-вак мәкаләләр» биреп барырга вәгъдә итә.

Халыкның азатлыкка бару юлында беренче зур киртә самодержавие булуын, әлбәттә, журнал редакциясе яхшы аңлый. Ләкин цензура рөхсәте белән чыгарыла торган басмада самодержавиегә каршы ачыктан-ачык көрәшү бик кыен эш була. Шулай булса да «Чикерткә» мондый көрәш мөмкинлекләрен таба. Бу — журналда басылган материалларны укыганда ачык аңлашыла. «Чикерткә»нең самодержавиега мөнәсәбәтен белү өчен аның дүртенче санында басылган «Манифест» дигән сатирик әкият[1] бигрәк тә характерлы. Әкият болай башлана:

«Борын-борын заманда бар иде, юк иде бер патша илә хатыны.

Патша бөтенләй кешегә охшаган: борыны бар, сакалы бар, башы җилкәсе өстендә. Башка җирләре дә бар. Нәкъ кеше диярлек».

Шушы беренче юлларда ук авторның патшага карашы ачык чагыла: патша адәм кыяфәтендәге хайван ул, дип әйтергә генә калган! Аннан соң китерелгән детальләр сүзнең Россия патшасы турында барганын төсмерләргә, аның образын күзалларга мөмкинлек бирәләр.

Патшага илнең халкы да хайван булып күренә. Түрәләргә ихтирамның әсәре дә юк аларда. Шулай да патша «мәрхәмәтле». Ул аюларга «яхшылык кыла»: «Үрчегез, күбәегез!» — ди.

Аюларның саны, чыннан да, арта. Әмма, һәрбер җан иясе шикелле, аларга да ашарга кирәк. Аю иртә тора да аяк табанын ялый, көндез аяк табанын ялый, кич тагын шулай. Көн үтә, төн үтә. Бер заман аюлар ачлыктан акыра башлыйлар.

Патшага бу ошамый, акырмаска кушып фәрман тарата. Ике көн тынлык. Ләкин ач корсак чыдатмый: өченче көнне болар тагын да катырак акырырга тотыналар.

«Тыныч патшалык» итәргә теләгән патша үзенең министрын чакырып ала. Министр, бик озак уйлагач, шундый киңәш бирә: урманда кандала, бет кебек корчаңгылар күп бит, әйдә, шуларны аюларга

[1] «Манифест»ны, «Чикерткә»дән алып, «Чүкеч» журналы да урнаштыра (1906 ел, № 1), Русчасы «Саранча»ның өченче санында басылган,

башлык итеп куябыз, аларга аюларны күзәтү эшен тапшырабыз.

Патша белән министр шулай эшлиләр дә. Ләкин файдасы күренми. Аюлар элеккедән дә ныграк акыра башлыйлар.

Тагын озак кына баш ватканнан соң бер вакыт патша: «Хәйлә таптым бит!» — дип кычкырып җибәрә. «Әйдә, синең белән икәү манифест языйк»,— ди ул министрына. Күп тә үтми, бөтен шартларына туры китереп язылган, бик күп нәрсәләр вәгъдә иткән манифест барлыкка килә.

Манифест беркатлы аюларга башта нык кына тәэсир итә. «Аюлар авызларын ачтылар да торган урыннарында катып калдылар. Ачлык та онытылды... Йөрәкләр тынычланды...» Шуның артыннан ук зәһәрле ирония: «Аюларның яртысы шунда ук үлеп калды: шатлыктан булса кирәк».

Монда 1905 елгы 17 октябрь манифесты турында сүз барганлыгы бик ачык. Халыкның бер өлешендә патша манифестына ышаныч һаман да сакланып килгән чакта, журнал аның революцияне туктату өчен хәйлә генә булганлыгын әкият жанрына хас аллегорик алым белән әйтеп бирә.

«Ватанпәрвәр язу» (патриотик язма) дигән фельетонда (I сан) манифестның асылы тагын да ныграк ачыла. «Эчке дошманнар Россиядә хөррият юк дип кычкыралар. Нинди зур усаллык! Бездә булган хөрриятләр башка җирләрнең һич каюсында юктыр» диелә анда ачы ирония белән. Ә бу хөрриятләр нидән гыйбарәт соң? Менә Россиядәге сүз азатлыгы. Патша вәгъдә иткән бу азатлыкның асылы фельетонда ике сүз белән: «авызыңны да ачма!» дип билгеләнә. Илдә җыелышлар уздыру иреге дә бар икән — гражданнар зинданнарга җыелалар! Матбугат азатлыгын да юк дип булмый — чөнки судебный приставларның повестка язу хөррияте бар! Шулай итеп, фельетонда бер-бер артлы манифест биргән хөрриятләрнең асылы ачып салына.

Самодержавиега, патша хөкүмәтенә нәфрәт журналның башка саннарындагы материалларның да төп рухын тәшкил итә. Менә беренче санның «Телеграммалар» бүлегеннән бер хәбәр: «Юк шәһәр. Җирле халыклар хөкүмәттән гаять разилар. Хосусан, алар Витте белән Дурновны[1] яраталар».

Бирәдә «разилар», «яраталар» сүзләренең ирония белдергәнен аңлау кыен түгел. Телеграмманың «юк шәһәрдән», ягъни булмаган җирдән сугылуы үзе үк аның чын мәгънәсен аңлатып бирә. Ә икенче урында бу патша чиновникларыннан «Чикерткә» мәкальләр калыбына салып көлә: «Дурнов кайдан барса, Витте дә шуннан бара».

Бишенче елгы революция палачы Треповка «Чикерткә» биргән характеристика да бик тапкыр. Зур сарай алдында адәм башлы, сакал-мыеклы, ерткыч һәм хәйләкәр күзле эт ята. Башында кокардалы фуражка. Янында кимереп ташлаган сөякләр. Җентекләбрәк караганда, этнең муенсасында «Трепов» сүзен укырга мөмкин. Патшаның ышанычлы ярдәмчеләреннән берсе, Петербург генерал-губернаторы Трепов Лотфулла Мостафин карикатурасында шулай сурәтләнә. (Лотфулла Мостафин турында сүз чыккач, бу һәвәскәр художникның татар сатирик графикасы пионеры икәнен дә әйтеп үтәргә кирәк. Соңрак аның таланты «Чүкеч», «Карчыга» журналларында тагын да киңрәк ачыла.)

Патша ялчыларының революцион хәрәкәттән, һәрбер азат фикердән куркуы «Мәҗбүри низамнар» фельетонында (I сан) бик ачык чагыла. Менә губернатор проекты буенча һичсүзсез үтәлергә тиешле кагыйдәләр:

— һәркем йокыдан торгач та, городовойга барып, шул көнне нинди фикердә булырга тиешлеген белсен. Үз фикерендә, үз карашында калырга теләгән кешеләр, өч гербовой марка ябыштырылган прошение биреп, губернатор канцеляриясенә кимендә 500 мең сум залог кертәләр;

— һәр кеше гакылның дәрәҗәгә (чинга) карап үскәнлеген баласына һәм баласының баласына тукып торырга тиеш;

— төш күрү катгый тыела. Карышучыларга 200 мең сумга кадәр штраф салыначак. Шулай да җирле губернаторны төштә күрүдән зыян юк. Тик аның парадный формада булуы шарт.

Бу соңгы пунктка искәрмә дә бар: төш күрәсе килгән кешеләр башта аны цензурага күрсәтергә мәҗбүр ителәләр.

«Чикерткә» патшалык тәртипләре сагында торучы аңгыра чиновникларны да нык кына тешли. Мәсәлән, беренче санда үк бер чиновникның үз начальнигына: «Яңа туган балалардан политик ышанычлыгы турында кәгазь таләп итәргә микән?» — дигән сорау белән мөрәҗәгать итүе хәбәр

---

[1] Витте — 1905—1906 елларда министрлар кабинеты председателе. Дурнов — эчке эшләр министры. Алар монархия режимын ныгыту, революцияне бастыру өчен күп көч куйдылар һәм халыкның ачы нәфрәтенә дучар булдылар.

итела. Россиядәге деспотик режимнан журнал әнә шулай ачы көлә.

Кызыл төс, кызыл байрак — революция, көрәш, азатлык символы. Шуңа күрә патша ялчылары һәр кызыл нәрсәгә куркып, котлары очып карыйлар. Журнал моннан да мәсхәрәле итеп көлә. Ул үзенең беренче санында ироник хәбәр урнаштыра. Бер станция каравылчысы пассажир поездын һәлакәттән коткарып калу өчен кызыл флаг күтәргән. Ә аны җавапка тартып, төрмәгә утыртканнар! Шул ук кызыл төс турында тагын бер игълан игътибарны җәлеп итә. Журнал бу игъланда музыка кибетендә яңа җырлар сатылуын, арада «Текмәсәнә, әнкәем, миңа кызыл күлмәк» дигәне дә барлыгын яза һәм моның да революциядән өркү галәмәте икәнлегенә ишарә ясый.

Һәрбер азат фикернең авызы томаланган, кулга алулар массовый төс алган бер чорда «Чикерткә»нең әнә шулай яза алуы, әлбәттә, зур батырлык иде.

Самодержавиега каршы көрәшне оста алып барган журнал тормыштагы башка вакыйгаларга да игътибарсыз калмады. Мәсәлән, ул патша «мәрхәмәте», буржуазия тырышлыгы белән җыелган Думаның ярлы халык көткәнне бирмәячәген башта ук ачык күрде. Татар байларының, руханиларның Думага сайланган үз депутатларыннан нәрсә көткәнлеге «Каргалы мөселманнарына ни кирәк?», «Оренбург мөселманнарыннан Государственный Думадагы мөселман членнарына телеграмма» дигән материалларда бик ачык чагыла. Аларда Каргалы һәм Оренбург реакционерларының Думага биргән наказлары фаш ителә.

Наказда хезмәт халкы файдасына бер генә сүз дә юк. Консерватор байларның, кире беткән муллаларның иң беренче теләге: «Мөфти, духовное собрание элеккечә калсын. Мәктәп, уку тугрылары әүвәлгедән үзгәртелмәсен. Үземезнең тереклек вә тормышларымыз борынгыча булсын».

Иң курыккан нәрсәләре — алдынгы рус культурасы. «Сак булыгыз, русча укырга риза була күрмәгез», дип кат-кат кисәтәләр алар. «Думада түбәтәйсез утыра күрмәгез, урамда эшләпә киеп йөрмәгез, ...рус пешергәнне ашамагыз».

Бу реакционерлар татар телендә газета-журнал чыгаруга, мәктәп-мәдрәсәләрдә татарча укытуга да каршы. Алар уйлавынча, һәммәсе гарәпчә генә булырга тиеш. Наказ авторларының һәр төрле азатлык дошманы икәнлеге аларның хатын-кызларга булган карашларында да ачык күренә: «Мөселман хатыннарына язу өйрәтелмәсен... Хатыннар урамга чыкканда, чапан бөркәнгәннән соң, битләренә ат кылыннан ясалган рәшәткә киеп, күзләре генә күренеп калсын».

Журнал халыкка аң-белем бирүне, аны һөнәрле итүне халык тормышын яхшыртуда, җәмгыятьне үзгәртеп коруда җитди чара дип исәпли, бу өлкәдә руслардан, Европа илләреннән һәм Япониядән үрнәк алырга чакыра. Әнә шул фикер «Төшемдә төрле-төрле татарлар» дигән фельетонда[1] (4 сан) аллегорик образлар аша үткәрелә. Анда японнарның белемле, һөнәрле булуларь күрсәтелә дә, алар белән чагыштырганда, татарларның кызганыч хәле тасвир ителә. Татарлар черек такталар өстендә басып торалар (ә черек такта ул — «наданлык һәм белемсезлек»). Такталар астында тәмуг кебек төпсез тирән баз. Ләкин кешеләр моны сизмиләр. Алар японнар ашый торган җимешләрдә корьән сүзләре кебек ниндидер язу күреп калганнар да[2], шуңа шатланышып сикерәләр. «Анлар шушылай юкка шатланып сикерә торгач, аяк асларындагы тактаны сындырып, җиде кат җирнең астына китү ихтималы бар!» — дип искәртә автор. Ләкин, бау ташлап, аларны черек такталар өстеннән сөйрәп чыгарырга хәзер торучы кеше дә бар: «Ул исә газетачы татардыр». Шулай итеп, халыкны белемле, мәгърифәтле итүдә, аны һәлакәттән коткарып калуда «Чикерткә» матбугатны, газетаны бик югары бәяли.

Вакытлы матбугатны революциянең зур казанышы итеп исәпләү белән бергә, журнал аларның барысын да бер төсле итеп карамый. «Бәянелхак»ның беренче номерына репликасында ук журнал аның «карагруһчылар газетасы» булуын, «мулла вәгазьләре, әби хикәятләре, әлфе-әйлә хыяллары» белән тулып чыгуын әйтә. «Әгәр «Бәянелхак»ның кулыннан килсә, ул татарларга гарәпчә генә сөйләшергә закон төзеттереп һәм «Бәдәвам»ны гарәпчәгә тәрҗемә кылып, Думага биреп утвердить кылдырыр иде», — дип яза.

Журнал «Йолдыз», «Таң йолдызы» (ул аны «Саз дуңгызы» дип атый) газеталарын

---

[1] Бу фельетонны, «Чикерткә»дән алып, «Чүкеч» журналы да басып чыгара (1906 ел, № 1),

[2] Биредә, японнар мөселман динен кабул итәргә җыеналар, дигән ялган хәбәр күздә тотыла булса кирәк.

де чеметеп-чеметеп ала. «Йолдыз» нашире һәм мөхәррирә Һади Максудиның үз газетасын, башлыча, табыш һәм эгоистик максатларда чыгаруын (4 сан), «Таң йолдызы»н чыгаручы татар әсәрләрының принципсызлыгын (2 сан) күрсәтә.

Журнал үзенең битләрендә ишаннарны, фанатик муллаларны рәхимсез камчылый. Мәсәлән, Буа шәһәрендәге иске һәм яңа мулла арасындагы талаш гыйбрәтле (2 сан). Башта алар арасында күп «дипломатик мөзәкәрәләр була», бераздан «икәве дә куштаннарны сыйлап, фатиха белән алдап», берсенә-берсе «сугыш» игълан итәләр. Ләкин бу һич тә искелек белән яңалык көрәше түгел, ә муллаларның, динне корал итеп, күбрәк байлык җыю чарасы гына. Журнал алар арасындагы низагның табигый нәтиҗәсен болай хәбәр итә: «Инде хәзер яңа мулла-иске мулла ширкәт илә әфиюн, вак тәмәке, тәсбих фабрикасы ачу шарты белән солых иткәннәр».

Журналда надан муллалар карамагындагы мәктәп-мәдрәсәләрнең аянычлы хәле турында да байтак материал бар. Менә «мәдрәсә эчендәге бозык һава берлә буталып, мантый берлән төшләнеп яткан Вәли мулла шәкертләре» һәм «мәдрәсәләрне төзәтергә кирәк, дәрес китапларымыз юк, дигән кешеләрне мөселман дәфтәреннән чыгарырга» тәкъдим итүче Каргалы муллалары (2 сан). Ә «Шәкертләр чүбек чәйнәрме? Кызлар «Мөхәммәдия» җырлармы?» дип аталган фельетонда (4 сан) иске мәдрәсә тәртипләрен кыюсыз гына тәнкыйтьләгән бер мәкаләнең дә муллалар өерендә нинди шау-шу кузгатуы сурәтләнә. Фельетоннан күренүенчә, мәдрәсәләрне искечә дәвам итү, өстәмә табыш чыганагы итеп файдалану көннән-көн кыенлаша. Дин исеме белән байлык артыннан куучы бер фанатикның фикеренчә, «иң табышлы нәрсә: Азия тарафына китеп, һәртөрле рәвештә сарт вә кыргызларны алдамакта вә анларга үзеңне сөйдереп инанып өчен һәр өйгән тупракны шәехләр кабере дию дәгъва кыйлып, суфилык сатмакта».

Әйтергә кирәк, журнал татарлар тормышын яктырту белән генә чикләнми, шул ук вакытта Урта Азия мөселманнары арасындагы караңгылык, артталык, йомыклык күренешләрен дә кискен тәнкыйть итә. Бохара әмиренең, Хива ханының ахмак эшләреннән көлә. Менә дөнья эшләреннән бихәбәр булып, үзенең зиннәтле сараенда кәеф-сафа белән гомер кичерүче Хива ханы (4 сан). Бервакыт Иран шаһының Европага, Бохара ханының Кырымга һәм Кавказга сәяхәт итүе турында ишетеп, аның да Ташкентка сәяхәт ясыйсы килә. Ләкин «юлда суык тию ихтималы булганга күрә, кузгалып чыга алмый». Хива белән Ташкент арасында «мунчалы, госелханәле һәм җылы тимер юл вагоннары йөри башлагач барыр, ахрысы», дип тәмамлый автор үзенең усал фельетонын.

«Чикерткә»нең берничә генә саны чыгып калса да, аларда без жанрларның искиткеч байлыгын күрәбез. Журнал сатираның бик күп жанрларын татар матбугатында беренче булып куллана. Аның битләрендә, сатирик әкият, сатирик шигырь, фельетон, мәзәк кебек жанрлар белән бергә,ләгать, игълан, диалог, мәкаль формаларын да табарга мөмкин. Эчке һәм тышкы хәбәрләр, телеграммалар бүлекләрендә кыска һәм тапкыр язылган сатирик миниатюралар күп. Самодержавиега, азат фикерне буучыларга каршы көрәштә журнал аларның барысыннан да оста файдалана.

Әйе, «Чикерткә» Октябрьга кадәр үк киң колач алган татар сатирик журналистикасының көчле бер үзәге булды. Аны, һичшиксез, хәзер чыгып килә торган «Чаян» һәм «Һәнәк» журналларының элгәргесе итеп исәпләргә кирәк.

**Ү. ГЫЙМАДИЕВ,**
**Башкорт дәүләт университеты доценты, филология фәннәре кандидаты.**

# КОЛХОЗЧЫ ШАГЫЙРЬ ГАЛИМ НАСЫЙРОВ

**Әнә анда тимер аргамаклар,**
**Кәсләр ата тыр-тыр трактор.**
**Иске илнең мирас сукалары,**
**Музейлардан карап елап тор!**

**Их, трактор, әйдә барсын бетер,**
**Искелекне бетер, олактыр!**

Бу ялкынлы шигырь юлларының авторы — колхозчы шагыйрь Галим Насыйров. Илебездә колхозлашу яңа гына башланган чорда, 30 нчы елларда, газета-журнал битләрендә, «Көрәш бүләк» колхозы исеме белән рәттән, Галим Насыйров исеме дә еш очрый иде.

Галим Насыйров — Татарстанның көнчыгыш чигендә, хәзер нефть чыга торган якларда, иң беренче күмәк хуҗалык булган «Көрәш бүләк» колхозын оештыручы һәм гомеренең соңгы көннәренә кадәр шул колхоз тормышында кайнап, аның өчен җаны-тәне белән көеп яшәгән кеше.

«Көрәш бүләк» колхозы 1929 елда алпавыт Мәлековлар хуторында төзелә. Бу елны бирегә күрше Бәйрәкә, Колчан, Каразирәк авылларыннан, Абдекәш, Аитов поселокларыннан 26 крестьян семьясы күчеп килеп, күмәк хуҗалыкка берләшә. Оештыру җыелышында Галим Насыйров крестьяннарга колхоз тормышы, аның зур мөмкинлекләре турында дәртләнеп сөйли. Шунда ук ул үзенең бик күп конкрет тәкъдимнәрен дә әйтә. Колхозчылар бу җыелышта Галим Насыйровның күмәк тормышка өндәүче ялкынлы йөрәкле кеше генә түгел, ә яңа оешкан күмәк хуҗалыкны җитәкли алырлык, сәләтле оештыручы да икәнен күрәләр. Шул җыелышта аны колхоз председателе итеп сайлап куялар.

Бергәләшеп яңа тормыш төзергә керешкән «Көрәш бүләк» крестьяннарының киләчәге якты, ниятләре зур була. Ләкин шул ук вакытта ул ниятләрне тормышка ашыру өчен каяндыр үрнәк алырлык тәҗрибә дә булмый. Шуңа күрә председатель булып сайланган Галим Насыйров алдына бер-бер артлы төрле сораулар килеп баса. Эшне каян, ничек башлап җибәрергә? Кем белән киңәшергә? Каян ярдәм алырга?

Бу сорауларга җавап эзли торгач, ул Сөләйман Нуримановка мөрәҗәгать итәргә була. Сөләйман Нуриманов та шул ук Баулы районында, Әпсәләм авылында туып үсә һәм Мәскәүдә Тимирязев исемендәге Авыл хуҗалыгы академиясен тәмамлаганнан соң, белгеч-агроном булып эшли. Галим Насыйров белән алар гражданнар сугышында бер отрядта булалар, шул елларда бу ике большевик дуслашалар да. Ә Галим Насыйров бөтен көчен биреп авылда яңа тормыш төзү эшенә тотынгач, белем һәм тәҗрибә җитмәгән чакларда, агроном дусты аңа ярдәмгә килә. Шул олы дуслыкның шаһитләре булып Галим Насыйровның шәхси архивында Сөләйман Нуримановка язылган бик күп хатлар саклана.

Менә аның 1929 елның 23 июнендә язылган хатыннан бер өзек: «...Шул безнең оешып килә торган әртилдә нәрсәләр эшләргә мөмкин булачак. Шул турыда син фикереңне яз әле. Мин эшнең барышы турында һаман язарга сүз бирәм. Ничек эшләү, ничек каралты, йорт төзү турында да яз әле һәм ничек сөрмая тупларга?



Кымызлык (кымыз эчү ял йорты) ачарга ярыймы киләчәктә? Тагын электрификация эшләренә ничек керешергә? — һәрберсен язарсың инде. Гомумән, эшне кайдан башларга? Үрнәк булырдай колхозлар турында син миңа материаллар җибәр әле. Кайда ничек эшлиләр, шул турыда брошюралар җибәрсәң, яхшы булыр иде...

Сәламәтлеккә бик авырлык киләчәген белсәм дә (Галим Насыйров гражданнар сугышыннан туберкулез белән авырып кайта.— Ф. М.), коммунистлыгымның соңгы көрәш тантанасы булыр дип, югарыдагы әртилдә ныклап, ахыр гомеремә кадәр эшләргә, юлбашчылык кылырга җөрьәт иттем һәм бик зур мәсьүлиятле эшне алдым. Дәрт, өмет, теләк чамасыз зур. Татарстанда үрнәк колхоз ясауга кадәр өмет бар, туган... Шуңа син тагын нәрсә диярсең?»

Шулай итеп, Галим Насыйров үзенең язмышын «Көрәш бүләк» белән аерылмаслык иттереп бәйли. Әртилнең яшәве һәм уңышлары аның иң зур шатлыгына әверелә. Билгеле, алпавыт утарында колхоз төзү җиңел эш түгел. Кулаклар һәм аларның күп төрле ялчыннары колхоз эшенә һәр җирдә аяк чалалар, крестьяннарны колхозга каршы котырталар. Әнә шундый шартларда беренче мәртәбә күмәк язгы чәчү үткәрү яңа әртил өчен зур сынау була.

Чәчүгә ашыккандай, бу елны яз да иртә килә. «Көрәш бүләк» колхозчылары 18 апрельдә үк чәчүгә чыгалар. Киң, иркен, ызаннар белән бүлгәләнмәгән басуларга чәчүгә чыгу беренче колхозчылар өчен күптән көтелгән бәйрәм кебек шатлыклы вакыйгага әйләнә. Ләкин шуның белән бергә, аларга бик күп кыенлыкларны да җиңәргә туры килә. Иң зур кыенлыкларның берсе чәчүлек орлык җитмәү була. Ләкин Галим Насыйров кебек оештыручыларның колхоз эшенә чиксез бирелгәнлеге һәм күпчелек крестьяннарның тырышлыгы нәтиҗәсендә бу кыенлыклар җиңелә: орлыкны базардан сатып алалар, фуражны бераз киметәләр. Шулай да әртил чәчү планын үтәп чыга. Чәчү белән бер үк вакытта Галим Насыйров әртилне ныгыту, зурайту, аңа яңа крестьян хуҗалыкларын тарту буенча да туктаусыз аңлату эше алып бара. Ул тырышлыклар бушка китми: колхоз торган саен үсә, ныгый.

Колхозның, авылдагы яңа тормышның шулай әкренләп күтәрелә баруын күрү исә Галим Насыйровны иҗатка, шигырьләр язуга рухландыра. Шушы елларда ул бик күп шигырьләр яза. Аларның берсе, «Ант итәбез, корыч партия» дип аталганы мондый юллар белән башланып китә.

**Сүз бирәбез, корыч партия:**
**Большевикча чыктык ярышка.**
**Кыенлыктан куркып тетрәмәскә,**
**Чигенмәскә артка карыш та.**

Галим Насыйровның ул елларда язылган шигырьләре — колхоз тормышы, аның иң әһәмиятле мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнгәннәр. Аларның һәрберсендә диярлек күмәк хуҗалык үсеше өчен бик кирәкле берәр тема күтәрелә. Ә кайбер шигырьләрен Галим Насыйров турыдан-туры «Трактор», «Тракторлы молотилка», «Силос» дип атый һәм әсәрләрендә шуларны җырлау аша крестьяннарга колхоз тормышының өстенлекләрен аңлата.

Галим Насыйровның бу чордагы тормышына күз салсак, тынгысыз большевикның искиткеч бирелгәнлек белән халык, партия эше өчен янып йөргәнлеген күрәбез. Ул һәр вакыт халык арасында була, алар белән иң үткен, иң кирәкле темаларга сөйләшә, партиянең политикасын аңлата.

Колхозчыларны большевистик рухта тәрбияләүдә дә аңа дусты Сөләйман Нуриманов күп ярдәм итә. Ул колхозга бүләк итеп 61 данә китап җибәрә, ә «Керәш бүләк»тә алардан китапханә оештырыла. Авыл хуҗалыгына кагылган китапларны бергәләп укып өйрәнү өчен махсус түгәрәк тә төзелә.

Шулай итеп, «Керәш бүләк» һәр яктан көч җыя бара. Бу керәштә Галим Насыйров, бер яктан, колхоз җитәкчесе буларак бөтен көчен куйса, икенче яктан, ул матбугат аша да колхоз тормышын кайнар яклап шигырь, мәкаләләр яза.

Ләкин әнә шундый ярсу тормыш белән яшәгәндә Галим Насыйровның гражданнар сугышы фронтларында алган авыруы көчәя башлый. Ул берничә айга Кырымга китеп дәваланырга мәҗбүр була. Анда Галим Насыйров язучы Галимҗан Ибраһимов белән очраша. Бу турыда ул үзенең 1931 елның 8 ноябрь хатында болай яза: «Мин хәзер декабрьга кадәр Кырымда калырга — Ялтада «Чаевка» дигән санаторийга урын алдым... Менә 10 ноябрьда шунда күчәм. Г. Ибраһимов белән райкомга барып, аның ярдәме белән урын алдым... башкача һичбер төрле рәт калмаган иде... Бик озак сөйләшеп утырдым... «Чаевка» санаториесе аның квартирасыннан ерак түгел. Аның янына барырга булыр әле».

Кырымда дәваланып, бераз хәле әйбәтләнеп кайтса да, Галим Насыйров аннан соң инде колхозны җитәкли алырлык хәлдә булмый. Ләкин, шуңа да карамастан, кулыннан килгәнчә ул һаман колхоз эшләрендә катнаша. «...Өйдә аякка басып тора алмыйм... колхозның цифрларына анализ ясап җибәргән идем райкомга. Райком секретаре «үләргә яткан көенчә Насыйров менә нинди эшләр эшләп ята» дип, үрнәк итеп сөйләгән диләр. Мин кайтканга кадәр уполномоченныйлардан да күп кеше юк иде безнең колхозда. Хәзер берәү дә юк инде... Түшәктә яткан көенчә... шул уполномоченныйларны алыштыра алуыма (рәсми булмаса да) үземне бәхетле саныйм аптырагач! Колхозчылар яныма киләләр. Алар белән яткан җиремнән сөйләшәм. Дәртләрен күтәрәм. Үзләре дә: «Синең янга килгәч, күңелләр күтәрелә, шуның өчен авыру булсаң да киләбез инде, борчылма», дип чыгып китәләр. Кая миңа борчылу, шуның аркасында үземне терелгән итеп хис кылам. Темплар да күтәрелгәч, бу миңа борчылу түгел инде. Бу сезнең мине дәвалавыгыз. Колхозда тырышып эшләп, мине дәвалавыгыз өчен рәхмәт, иптәшләр, дим...» дип яза ул бер хатында.

Галим Насыйровка аннан соң да Кырымга барып дәваланырга туры килә. Шул вакытларда колхоз тормышыннан аерылып, күз-колак булып тора алмаганга күрә, кайткач колхозда күргән хәлләр аны нык борчый. Ул еш кына колхоз җитәкчеләренең үз эшләрен башкара алмауларын, шуңа күрә зур кыенлык белән оештырылган хуҗалыкның таркала башлавын күрә. Мондый чакларда ул большевикларча принципиальлек белән үзен борчыган мәсьәләне күтәреп чыга.

Шундый принципиальлекне без аның шул елларда язылган шигырьләрендә дә ачык күрәбез.

**Бөек сынау язгы хәзерлеккә,**
**Кемнәр — лодырь, кемнәр — батырлар,**
**Кемнәр — җебегән эштә, кемнәр — уңган,**
**Сүздә генә кемнәр акырган.**

. . . . . . . . . . . .

**Андыйларга — позор!**
**Андыйлар — хур!**
**Алар — күмәк төзелеш дошманы,**
**Чын колхозчы түгел алар берсе,**
**Тик кулакның сатлык куштаны.**

Шул елларда «Керәш бүләк» колхозының уңай эш тәҗрибәсен өйрәнү өчен «Кызыл Татарстан» газетасының махсус хәбәрчесе килә. Ул үзенең мәкаләсендә Галим Насыйровның тормыш-көнкүрешен түбәндәгечә тасвирлый:

«...Ике бүлмәле, кечерәк кенә, барысы өч тәрәзәле, түбәсе калай белән япкан агач өй. Түрдәге бүлмәдә урыны җәюле бер кровать, китап этажеркасы, бер өстәл, савыт-саба шкафы, 4—5 урындык. Өстәл янында ике пионер тырышып-тырышып, алмаш-тилмәш стена газетасы язалар...

Озынча битле, озынча борынлы, зәңгәр күзле, гадәттән тыш ябыккан «редактор» җәюле урынынннан торып утырган да язучыларга хәбәрләр, мәкаләләр әйтеп тора... «Керәш бүләк» колхозында иртә культуралар чәчүгә әле бер атнадан артык вакыт бар, ә Галим Насыйров стена газетасының 6 нчы санын яздырып утыра».

Ләкин Галим Насыйровның тагын да күбрәк эшлисе килә. Бер хатында ул: «Мин пролетариат өчен бик-бик аз эшләдем шул. Мине туберкулез көрәштән аера, минем актив эшләвемә ирек бирми... Мине шигырь генә бер дә канәгатьләндерми. Бер минут түшәктә ятмый торып колхозны җитәкләшәсе, социализм төзелеше үрнәге ясасы килә. Бюрократизм, кулак калдыклары белән аяусыз көрәшәсе, колхозчыларны идея ягыннан иң югары баскычка күтәрәсе килә. Игенне әдәм ышанмаслык дәрәҗәдә уңдырасы, сөлек кебек таза атлар булдырасы, булганнарын саклыйсы, елтырап торган көр, күп сөтле сыерлар үрчетәсе килә. Әнә шундый «киләләр» алар бик күп. Менә шул «киләләр»не тормышка ашыруда актив катнашудан мин гаҗиз. Шуңа күрә түшәктә булса да янып-көеп җырлап җибәрәсең... Мине түшәктә җырларга мәҗбүр иткән сәбәп әнә шулар... «Минем даруларым»ны (ягъни шигырьләрне.— Ф. М.) Азнакайда киңәшмәләрдән, җыелышлардан соң декламировать итәләр дип ишеттем. Шулай ук Минзәлә, Актаныш, Мөслим районнарындагы мәктәп балалары минем җырларымнан файдаланалар... хатлар алдым. Болар, әлбәттә, минем өчен күңелле хәбәрләр»,— дип яза.

Язган шигырьләренең халык тарафыннан яратып кабул ителүе, аларның сәхнәләрдән сөйләнүе, җыелышларда яңгыравы колхоз шагыйре Галим Насыйров өчен зур шатлык булса, 1932 елда Казанда басылып чыккан «Колхоз җырлары» исемле җыентыгы исә аның яңа тормышны котлаган зур иҗат букеты иде.

Бу китапка шагыйрьнең 17 әсәре кертелгән. Китапның исеменнән үк күренгәнчә, андагы шигырьләр авылның яңа тормышына, социализм тудырган яңа кешеләргә багышланганнар. Шигырьләрнең барысына да диярлек крестьянның үткәне һәм бүгенгесе турында уйлану һәм шуннан туа торган дәртләнү, романтик күтәренкелек хас. Менә китапка кергән «Ахун — колхоз, колхоз — Ахун» шигыре. Автор бу әсәрен колхоз тормышындагы күңелле бер күренештән — Ык буенда колхозчыларның печән чабуыннан башлап китә.

**Суган кебек яшел печәннәрне**
**Эскерт-эскерт өйдек, әй, тезеп.**

Шундый юллар белән колхозчыларның күмәк хезмәтен тасвирлаганнан соң, шагыйрь фикерен конкретлаштыра, ачыклый төшә. Аның карашы аерым бер кешенең язмышына, анда нинди үзгәрешләр булуын ачыклауга юнәлә. Ул кеше Ахун дигән карт. Ахун карт элек боярларда тир түккән, бик күп газаплар кичергән.

Ә аның бүгенгесен Галим Насыйров болай тасвирлый:

**Ахун абзый колхоз аланында**
**Күмәк маллар карый — үз малы.**
**Ахун — колхоз!**
**Колхоз — Ахун!**
**Ничек Ахун хуҗа!**
**Колхоз үз «җаны!»**

Шулай итеп, колхозчы шагыйрь крестьян язмышындагы төп үзгәрешне аның иркеле хезмәт кешесенә әверелүендә күрә һәм укучыга да шул фикерне җиткерергә тели. Гомумән, «Колхоз җырлары» җыентыгының шигырьдән шигырьгә кызыл җеп булып сузылган фикере әнә шул дияргә була.

Аның шигырьләрендә сурәтләнгән уңай геройлар барысы да шул ук колхозда көн-төн тиргә батып, тырышып эшләүче, җирне яратучы, материаль байлык тудыручы конкрет кешеләр — хезмәт батырлары, ул үзе дә шундыйларның берсе иде.

Галим Насыйровның соңрак язылган шигырьләреннән «Ударникларга хат» дигәненең язмышы кызыклы.

Бу шигырь Татарстанда иң беренче тапкыр Бәйрәкәдә колхозчыларга җирдән мәңгелеккә файдалану турында Дәүләт акты тапшыру тантанасы уңае белән язылган.

Анда Галим Насыйров та катнаша һәм тантанага җыелган колхозчыларны «Көрәш бүләк» исеменнән котлый. Шуннан соң ул тантана уңае белән махсус язылган шигырен укый. Аның бу шигыре тыңлаучыларга шундый көчле тәэсир итә, аны унлап мәртәбә бүлдереп кул чабалар. Ә сөйләп бетергәч, Галим Насыйровны Казаннан һәм Мәскәүдән килгән газета хәбәрчеләре уратып ала. Алар арасында «Правда» газетасының да хәбәрчесе була. Галим Насыйров аның белән таныша, аңа үзенең хәлләрен сөйли.

Ә анда сөйләнгән шигырь, озак та үтми, 1935 елның 21 октябрендә «Кызыл Татарстан» газетасында басылып чыга.

Галим Насыйровның авыруы торган саен көчәя, ләкин шуңа да карамастан, ул зур иҗади планнар белән яшәвен дәвам итә һәм берничә сәхнә әсәре дә яза. Аның «Атлар өчен көрәшкәндә» дигән әсәрен район театры колхозларда куеп йөри. Колхозчылар бу әсәрне яратып карыйлар. Ә бер хатында Галим Насыйров үзенең «Мещанка» исемле пьеса язуын хәбәр итә һәм «Көрәш бүләк»тә булган сыйнфый бәрелешләр, корткычлыклар нигезендә тагын яңа сәхнә әсәре язарга җыенуын әйтә. Гомумән, бу елларда ул тулысынча иҗат эшенә чума, көнне һәм төнне белми эшли. Аның кульязмаларында «бу шигыремне төне буе утырып, бәрәңге лампасы яктысында яздым. Лампа сүнде, тәмамлый алмадым», дигән сүзләр дә еш очрый.

Бу елларда Галим Насыйров иҗат итеп кенә калмый, ә бәлки язган әсәрләренең сәнгатьчә көче турында да җитди уйлана. Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен һәм Һади Такташ шигырьләрен бик яраткан Галим Насыйров аларның әсәрләрендәге осталыкка, поэтик көчкә соклана. Менә аның бер хатыннан өзек: «...әле Галимҗан Ибраһимов томнарын укыдым. Анда каләм шомалыгы, тасвирга байлык! Минем язулар хәзергә шома түгел, тасвирга да бай түгел... Каләмне шомарту, яңа образлар табу — болар минем алдагы эшләр, терелсәм — болар булачак...»

Әйе, колхозчы шагыйрь Галим Насыйровның киләчәккә планнары, алда эшлисе эшләре күп була. Ләкин эшләнгәне дә аз булмый инде. Аның исеме бөтен тирә-якка тарала, яңа тормыш җырчысы булып халык күңеленә кереп урнаша. Галим Насыйровның ул елларда никадәр танылган кеше булуын шундый факт та ачык сөйли. Аның авыруы көчәйгән вакытта Азнакай районында чыга торган «Коммуна» газетасында «Галим Насыйров иптәшкә» дигән шигырь басылып чыга. Ул шундый юллар белән тәмамлана:

**Безнең уңыш —**
**Синең даруларың.**
**Кызганмабыз аны, бирербез.**
**Чирең белән**
**Без дә көрәш ачтык,**
**Ярдәмеңә килеп торырбыз.**

Ләкин шәфкатьсез авыру ялкынлы йөрәкле колхоз шагыйре Галим Насыйровны яшьли безнең арадан алып китте.

Галим Насыйровның күп санлы кульязмалары: шигырьләре, сәхнә әсәрләре, мәкаләләре һәм хатлары калды. Аларның саны йөздән артык. Кайсын гына алып карасак та, без анда бу кешенең ялкынлы йөрәге типкәнен тоябыз. Галим Насыйровның замандашы Һади Такташ үзенең бер мәкаләсендә шундый юллар язган иде: «Безнең идеалларыбыз күктә яшәмиләр. Алар безнең көнкүреш тормышыбызда, бүгенге бай көрәш вакыйгалары эчендә туалар, яшиләр һәм хәрәкәт итәләр...

Пролетариат шагыйре шул хәрәкәтләрнең эчендә торып, бүгенге көрәш тәҗрибәсе белән якыннан таныш булса гына һәм шул көрәштә шул теләкләре өчен көрәшүче булып катнашса гына, үз әсәрләрендә бүгенге көрәшкә кирәкле булган актуаль идеяләрне вакытында күреп җанландыра ала һәм аларны үзенең иҗат аппаратында формалаштырып массага бирә ала».

Галим Насыйров та нәкъ әнә шундый шагыйрь, әнә шундый җәмәгать эшлеклесе иде.

**ФАТИХ МАХИЯНОВ,**
**СССР Журналистлар союзы члены.**

**Яхъя Абдуллин,**
философия фәннәре кандидаты

# ДИНИ ТӘГЪЛИМАТКА ҺӘМ СУФИЧЫЛЫККА КАРШЫ

Россия империясе составындагы татарларны капиталистик мөнәсәбәтләр ташкынына тартып кертү (бу эш бигрәк тә XIX йөзнең икенче яртысында киң колач ала) халыкның рухи тормышында тирән үзгәрешләр китереп чыгара. Татар халкының алдынгы вәкилләре, иҗтимагый фикер мәсьәләләрендә Шәрык йогынтысыннан йотыла барып, көнбатыштагы фәнни-философик фикер һәм культура казанышларына, барыннан да элек, алдынгы рус иҗтимагый фикеренә һәм культурасына йөз белән борылалар. Халыкның рухи тормышындагы әлеге үзгәрешләрнең нәтиҗәсе буларак, бездә мәгърифәтчелек хәрәкәте туып-үсә башлый. Башка халыкларның мәгърифәтчелек хәрәкәте кебек үк, татар мәгърифәтчелеге дә феодализмга каршы идея хәрәкәте төсендә барлыкка килә. Мәгърифәтчеләр урта гасырчылык калдыкларын, торгынлыкны, искелекне, караңгылыкны фаш итәләр һәм шул ук вакытта иҗтимагый яңарышны, фикер хөрлеген алга сөрәләр.

Шәрыктагы күп кенә башка халыклардагы кебек үк, татарлар арасында да иске иҗтимагый-икътисади мөнәсәбәтләрнең идея терәге булып ислам дине тора. Үзенең авторитеты белән ул һәр төрле искелекне, торгынлыкны һәм караңгылыкны изге нәрсә дәрәҗәсенә күтәрә, сыйнфый каршылыкларны яшереп калдырырга, изелгән халыкның хәерчелеген һәм газаплы тормышын акларга тырыша. Коръәнгә таянып, дин башлыклары язмышка буйсынып яшәүне алга сөрәләр, хезмәт ияләрен күндәмлеккә һәм өстен сыйныфларга буйсынып хезмәт итәргә өндиләр. Иҗтимагый яңарыш юлында киртә булып торган һәм массаларны коллыкта тотуны мәңгеләштерергә ярдәм иткән һәр нәрсә дини пәрдә артына яшеренә. «Дин ул,— дип яза К. Маркс,— бу тормышның гомуми тәгълиматы, аның энциклопедик сөземтәсе, популяр формадагы логикасы, ...энтузиазмы, әхлакый санкциясе, тантаналы өстәмәсе, тынычланыр һәм акланыр өчен гомуми таянычы» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. Рус телендә. 1 том. 414 бит). К. Маркснең бу сүзләре мөселман диненең татарлар арасында тоткан урынын дә ифрат төгәл билгели.

Дини һәм дөньяви законнарны бергә кушу, аларны берләштерү — мөселман диненә хас үзенчәлекләрнең берсе. Бу, үз чиратында, аның халык тормышындагы ролен бик нык көчәйтеп җибәрә. Нәтиҗәдә дини күрсәтмәләр иҗтимагый тормышның бөтен якларын иңләп ала, халык арасында: «хокук һәм әхлак нормалары, сәяси тезелешләр тормыш ихтыяҗларына бәйләнмәгән, җамгыять тәкъдир кушканча йөри икән, диган караш тамыр җәя. Моның аяныслы нәтиҗәсе буларак, «узган йөзнең икенче яртысына кергәндә, татар дөньясы һәр төрле дини хорафат, фикер торгынлыгы, чиксез бер дини

фанатизм, бөтен руханиларга, ишаннарга сукырларча тәкъдим астында башаягы белән күмелеп калган; шулар тоткынлыгында изелүнең дә чигенә җиткән иде. Бөтен нәрсәне тәкъдиргә тапшыру да татар игътикадының үзәгендә иде» (Г. Сәгъди. Татар әдәбияты тарихы. Казан. 1926 ел. 65 бит).

Реакцион дин башлыклары фәнни эзләнүләрне һәм хөр фикерне төрлечә эзәрлеклиләр. һәм үзләренең бу кара эшләрен фәннең абсолют характерда булуы белән акларга тырышалар: фән, янәсе, тормыш шартларына карап үзгәрә, заманнар узуга карап үсә бармый. Кеше акылы аңа берни өсти дә, аннан берни ала да алмый. Бу абсолют фән, имештер, бабаларыбыздан калган изге китапларда бәян ителгән, бүгенге кешеләр, иң яхшы дигәндә, аларны аңлата һәм шәрехли генә алалар. Шуның аркасында, татар мәгърифәтчесе З. Бигиев сүзләре белән әйткәндә, Шәрыктагы мөселман халыклары фәнни һәм философик белемнәрдән тәмам читләштереләләр, мәдрәсә дәресләре файдасыз шәрехләүләрдән һәм иске фәлсәфәләрне кабатлаудан узмый (З. Бигиев. Мавараэннәһергә сәяхәт. 1908. 10 бит).

Кыскасы, тормышның һәр өлкәсендә диярлек фәнни тәгълимат — кәлям һәм суфичыл-мистик карашлар шактый нык тамыр җәя.

Кәлям — спекулятив алымнар белән исламның догмаларын һәм инануларын нигезләргә тырышкан дини система. Гарәпчә бу сүз сөйләшү, гәпләшү, коръәнне шәрехләү дигән мәгънәне белдерә. Фәлсәфи бәхәсләр алып бару һәм логик нәтиҗәләр ясау юлы белән, кәлямчеләр дин өчен файдалы карашларны ныгытып калырга, ә дини инануның төп догмаларына каршы килерлек фикерләрне юкка чыгарырга тырышалар. Кәлямдә алланың асылы һәм аңа хас сыйфатлар, әйберләрнең шәригать законнары буенча барлыкка килү, яшәү һәм юкка чыгулары турындагы схоластик өйрәтмәләр зур урын тота. Мөселман дөньясында ныгып алган кәлям системасы ортодоксаль ислам кысаларына сыймаган берниндн үзгәрешләрне танымый, дини догмалардан аз гына читкә китүне дә, хакыйкатьне мөстәкыйль рәвештә эзләргә һәм чынбарлык күренешләрен акылга муафыйк төстә дәлилләргә омтылуның теләсә нинди чагылышын диннән ваз кичү, аның асылын шик астына алу дип бәяли, андый кешеләрне рәхимсез эзәрлекли. Нәтиҗәдә хөр фикерле кешеләргә яшәргә бернинди мөмкинлек калмый. Мондый шартларда фән белән һәм нинди дә булса кәсеп, һөнәр белән шөгыльләнү дингә каршы эш дип бәяләнә һәм каһәрләүгә дучар ителә.

Кәлям шактый ук дәрәҗәдә суфичылык идеяләре белән дә аралашкан була. Дөрес, башта суфичылык халык массаларының феодаль изүгә каршы протестларын чагылдырган идеологик көрәшнең бер формасы буларак туа. Суфилар арасында дини өйрәтмәләрнең чынлыгын шик астына алган хөр фикерле кешеләр шактый була. Аерым татар суфилары да социаль изүне, хакимнәрнең комсызлыгын һәм ерткычлыгын гаепләп чыгалар. Мондый тенденцияләр, мәсәлән, мәгълүм татар шагыйрьләреннән Мәүла Колый, Әбелмәних Каргалы, һибәтулла Салихов һәм Шәмсе дин Суфи иҗатлары өчен характерлы була. Әмма, тулаем алганда, суфичылык ул — мистик һәм аскетик агым. Тәсаувыф суфичылыкның төп теориясе булып тора. Бу караш буенча, дингә ышанучы кешенең бөтен уйлары алла турында гына булырга тиеш. Суфилар фикеренчә, кеше алланы акылы белән түгел, ә бары йөрәге һәм хисләре белән генә танып-белә ала. Аллага якынаю өчен, дип өйрәтә суфизм, кеше фани дөнья мәшәкатьләреннән ваз кичәргә, үзенең табигый хис һәм теләкләрен тезгенли белергә тиеш. Суфичылыкка хас мондый мистик тенденцияләр халык массаларының игътибарын чорның үткен социаль мәсьәләләреннән читкә алып китә, аларда буйсынучанлык, басынкылык кебек сыйфатлар тәрбияли.

Мулла һәм ишаннарның тырышлыгы бушка китми, кәлям, шулай ук суфичылык идеяләре халык арасында шактый киң таралыш таба. Ят гарәп телендә язылган булганга күрә, коръән һәм хәдисләр татар халкының күпчелегенә аңлашылмаган. Бөтен дини пропаганда кәлямчеләрнең-мөтәкаллимнәрнең дини әсәрләренә һәм суфичылык карашларына нигезләнеп аңлатылган. Шуңа күрә XIX йөздә яшәгән татарлар арасында нәкъ менә кәлямне һәм суфичылыкны тәнкыйтьләү аеруча мөһим һәм җитди әһәмияткә лаек эш була.

Үз ватандашларының игътибарын шушы мәсьәләгә башлап юнәлтүче кеше Г. Курсави (1770—1814) була. Аның заманы өчен файдалы һәм алдынгы идеяләрен алга таба татар мәгърифәтчелегенең Ш. Мәрҗани, К. Насыйри һәм Ш. Көлтәси кебек күренекле

вәкилләре дәвам иттерә. Бу соңгылары татар халкы яшәгән тынчу атмосфераны һәм дини тәгълиматның реакцион идеологиясен кискен фаш итеп чыгалар.

Татар мәгърифәтчеләре kәламне бөтен афәтләрнең һәм ялгыш фикерләрнең төп сәбәпчесе, кеше күңелен боза, аның акылын богаулап, яңалыкны һәм хакыйкатьне эзләү юлында киртә булып тора торган көч дип саныйлар. Хәр фикерне басып тору, динне тормышка, фәнгә һәм һөнәрчелеккә каршы кую һәм соңгыларының үсешен тоткарлау, мәгърифәтчеләр фикеренчә, kәламчелек идеяләренең таралуы аркасында килеп чыккан күренешләр. «Әльхикмәтельбалига», «Назурательхак» һәм «Әльгазалбельфират» кебек хезмәтләрендә Ш. Мәрҗани kәламне философик төшенчәләрне ясалма төстә дин догмалары белән бутау, берләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килгән күренешләр дип исәпли. Аның фикеренчә, ул реаль мөнәсәбәтләрне чагылдыра алмый, аның бөтен әһәмияте бәхәс алып бару ысулларын эшкәртүгә кайтып кала.

Татар мәгърифәтчелек фикеренең икенче бер вәкиле Ш. Көлтәси kәламне үләксә белән, ә гыйлем чыганагы буларак kәламгә таянуны соң чиккә җиткәндә үләксә ашау белән тиңли. «Һәйәте җәдидә» исемле хезмәтендә, kәлам һәркемгә мәҗбүри дини кагыйдә һәм кешеләргә файда китерүче белем чыганагы, дип фикер йөрткәне өчен, ул Имам Газалины кискен тәнкыйть итә. Мондый карашлар, дип яза Ш. Көлтәси, бик аяныч нәтиҗәләргә, kәламне өйрәнеп, яшьләрнең кадерле вакытларын бушка сарыф итүгә китерә. Газали мөтәкәллимнәрнең сүз һәм дәлилләрен сырхау кешеләргә файдалы дару белән чагыштырган була. Ш. Көлтәси бусын бөтенләй нигезсез эш дип бәяли. Дөрес, kәламнең дә кемгәдер файда китерүе мөмкин, тик халык массаларына гына түгел, ди ул. Kәлам белән килешеп яшәү үз янында, кара көнгә дип, үләксә йөртү белән бер. Үз янында үләксә йөрткән кеше, иртәме-соңмы, әлеге үләксә тараткан йогышлы чирдән үләчәк. Kәлам белән килешеп яшәүнең дә нәтиҗәсе шундый ук. «Бу юл (kәламчеләр тоткан юл.— Я. А.) илә халыкка килә торган зарар,— дип яза Ш. Көлтәси,— kәламчеләр килеп чыкканнан вә kәлам сәнгате таралудан бирле туып тора торган фетнә вә зарарларны күрү белән генә дә исбат ителәдер» (Ш. Көлтәси. Һәйәте җәдидә. Казан. 1896 ел. 52 бит).

Kәламне һәм мөтәкәллимнәрне фаш итү белән бергә, татар мәгърифәтчеләре шулай ук суфичылыкны һәм аның тарафдарларын — ишан һәм шәехләрне тәнкыйть утына тоталар, суфичылык һәм ишанлык белән шөгыльләнүнең зарарын аңлаталар, әлеге мистик агымның таралуы никадәр зыян китерүен ачып салалар.

Татар мәгърифәтчелегендә суфичылыкны тәнкыйтьләү Г. Курсавидан башлана, суфи булырга тырышкан наданнарны ул бозык һәм әхлаксыз кешеләр дип бәяли, ә суфичылык теориясе — тәсаувыфка таянуны тирән чоңгылга илткән юл белән чагыштыра. «Халык арасында безнең гасырыбызда һәм үткән гасырларда,— дип яза Г. Курсави,— тәсаувыхка мәнсүб булу һәм «иршад» вә «истиршад»ны дәгъва кылу таралып китте. Ләкин алар тәсаувыфның мәгънәсе һәм аннан максат нәрсә икәнен белмиләр. Шуңа карамастан, һаман алар берсе өстенә икенчесе булган катлаулы караңгылык эчендә томаланалар: яки болар төпсез диңгезгә батканнар да, анда дулкын өстенә дулкын күтәрелеп аларны һаман каплый, баса бара». (Өзек Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» буенча китерелә. 23 бит.)

Ш. Мәрҗани әсәрләрендә суфичылык доктринасын турыдан-туры тәнкыйть итүләр очрамый диярлек. Әмма замандашларының истәлекләренә караганда, мөтәсаувыфлар хакында сүз чыкса, Мәрҗани аларны яратмавын сиздергән, ә суфичылык белән шөгыльләнүне файдасыз эш дип санаган. Шулай бер вакыт Дагстан ишаны Мәхмүт аңардан: «Сез тәсаувыфны бик кямил беләсез, нигә мөритләр тотмыйсыз?» — дип сораган. Мәрҗани: «Минем андый эшкә вакытым юк», — дип җавап биргән. «Мөкаддимәте...» исемле хезмәтендә ул яңалык һәм фәнни белемнәр таралу юлында торган киртәләрнең берсе тәсендә надан ишаннарның баш булып утыруларын күрсәтә. «Күп вакыт,— дип яза ул,— үзендә гыйлем дә юк, сәлях та юк, сөннәткә дә иярмәгән, тарикага (суфиларның дини камилләшү юлы.— Я. А.) да кермәгән гавамның берсе шәехлек дәгъва кылырга тотына, иршад вә тәрбиягә иҗазәт алганлыкны дәгъва кыла; аның бар тәрбиясе дөнья өчен этләшмәк вә дөнья ияләре өчен ялганнан хошугъ күрсәтмәк вә дәшмичә генә тормактан гыйбарәт була. Моңа наданнар мәел итәләр вә аның

тирәсенә коршыйлар, ишанның дәрәҗәсе күтәрелә, көче арта, сүзе үтә, кешеләрне мәсхәр кыла» («Мәрҗани» җыентыгы. 496 бит). Шундый надан ишаннарның йогынтысы көчәю аркасында, ди Ш. Мәрҗани, чын галимнәр күләгәдә кала, бу исә гыйлемнәр таралу һәм яңалык эшенә зур зыян ясый.

Суфичылык һәм ишанлыктан аеруча ачы көлгән кешеләрнең тагын берсе К. Насыйри була. Тәсаувыф тарафдарларын ул икейөзле булуда һәм ялганчылыкта гаепли, алар кеше алдында үзләрен тәкъва итеп күрсәтергә тырышалар һәм моны бик күп дини булмаган максатларда — дөнья байлыкларын кулга төшерү өчен файдаланалар, ди. Тәсаувыф тарафдарлары теләсә нинди очракта икейөзле бәндәләр: әгәр аларның начар киемнәре тәкъвалык омтылышларына тәңгәл килсә, ул чагында бу кием халыкка аларның тәкъвалыкларын хәбәр итү өчен кирәк. Суфи бу очракта эчкерле максатлардан азат түгел. Әгәр инде аның киеме теләк-ниятләренә бөтенләй туры килми икән, суфиның икейөзлелеге тагын да бәхәссезрәк. «Суфиларның, — ди ул, — тыйнаклыклары киемнәрендә, тәкәбберлекләре күкрәкләрендә». К. Насыйри фикеренчә, суфилар җәмгыять өчен бөтенләй файдасыз кешеләр. Теләсә нинди кеше яшәү өчен кирәкле байлыкны үз хезмәте белән — я сәүдәгәрлек итеп, я һөнәр белән шөгыльләнеп, я булмаса җир эшкәртеп табарга тиеш. Ә суфилар исә боларның берсе белән дә шөгыльләнмиләр, ә соры корт кебек башкалар хисабына туеналар.

Суфичылыкны тәнкыйть иткән кешеләрнең фикерләренә таянып, К. Насыйри тәсаувыф узган заманнарда мистик экстаз булса, ахырдан акыруга һәм шау-шуга әйләнә, хәзер исә экстазы да, шау-шуы да юк, коры хәҗлә генә калды, ди. Әлеге фикерен үстерә барып, ул татар халкының «суфи суган сөймәс, күрсә кабыгын да куймас» дигән мәкален китерә, бу мәкаль суфиларның теләсә нинди этлеккә барырга әзер булулары хакында сөйли, дип өсти.

Суфичылыкны һәм ишанлыкны тәнкыйть итеп, татар мәгърифәтчеләре халыкка дини идеологиядәге әлеге агымның чын йөзен ачып бирәләр, халык массаларын мистицизм йогынтысыннан һәм дини томаналыктан азат итү өчен җирлек хәзерлиләр.

* * *

Татар мәгърифәтчеләре кәлямне һәм суфичылыкны **рационализм** принцибына таянып тәнкыйтьлиләр. Әлеге принципны кулланма итеп алып, мәгърифәтчеләр дини-мистик доктриналарга кеше акылын, аның дөньяны танып-белүдәге чикләнмәгән мөмкинлекләрен каршы куялар, иҗтимагый тормыш мәсьәләләренә якын килгәндә, ул мәсьәләләр нинди генә характерда булмасыннар, кеше акылына һәм фәннең бәхәссез хакыйкатьләренә таянып эш итәргә чакыралар. Ф. Энгельс тарафыннан XVIII йөздәге француз мәгърифәтчеләренә бирелгән бәяне безнең мәгърифәтчеләргә карата да кулланып була. Алар фикеренчә, дип яза ул: «һәр нәрсә акыл хөкеме каршына килеп басарга һәм шул юл белән үзенең яшәргә тиешлеген акларга, яки аннан баш тартырга тиеш иде. Уйлый торган аң бөтен тереклек ияләренең бердәнбер үлчәвенә әйләнә» (К. Маркс и Ф. Энгельс. Об искусстве. Рус телендә. 1967 ел. 349 бит). Бу дини-догматик канунннарга да кагыла. Теләсә нинди тәгълимат, теләсә нинди фикер аек акылга каршы килмәслек дәлил һәм ышаныч уятырлык мәгълүматлар белән исбатланган булырга тиеш, шулай булмаса, аның бернинди әһәмияте калмый. Хәтта шәригать кануннарына үзеңнең мөнәсәбәтеңне билгеләгәндә дә акылга колак салырга һәм әйберләрнең фактик хәленнән чыгып эш итәргә кирәк. «Әгәр шәригатьтә аңа (фәнни мәгълүматларга. — Я. А.) каршылык була икән, дөреслеге ачык мәгълүм нәрсәне инкяр итүгә караганда, шәригать күрсәтмәсен үзгәртеп аңлау яхшырак», — ди. Ш. Мәрҗани (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 22 фонд. I тасвирлама. Саклау берәмлеге 20. 64 бит). Бу очракта галим кеше акылы җимешләрен — чын гыйлемне һәм фәнни мәгълүматларны — объектив төстә шәригать кануннарыннан өстен куя.

Татар мәгърифәтчеләре күренешләрне һәрьяклап өйрәнүне һәм аларга объектив бәя бирүне алга сөрәләр. Кәфер сүз дигән булып, һәр төрле яңа фикерне туган чагында ук буарга тырышкан кәлямчеләрне тәнкыйтьләп, Ш. Мәрҗани болай яза: «Бер

фикерне ачыклап, нигезенә төшенеп җитмичә кире кагу — сукыр килеш ук ату һәм наданлыктан килгән аңсызлык ул» (шунда ук, 63 бит). Ул, шәригать кануннарына таянган булып, кешенең тормышын һәм үз-үзен тотышын чикләргә тырышучыларга кискен каршы чыга. Кешенең хәрәкәтләрен теләсә нинди чикләү дини күрсәтмәләргә таянып түгел, ә акылга ятышлы дәлилләргә таянып исбат ителергә тиеш, ди.

Кәламчеләрнең аерым фикер һәм карашларын тәнкыйть иткәндә дә мәгърифәтчеләр рационализм принципларына таяналар. Әйтик, кәламчеләр арасында Мөхәммәтнең пәйгамбәрлеге ул башкарган могҗизалар белән расланa, дигән караш киң таралган була. Ш. Мәрҗани бу карашның нигезсез булуын әйтә, таякның еланга, күзсезнең күзлегә әйләнүе, ташларның телгә килүе кебек әкиятләрдән ачы көлә. Аның өчен Мөхәммәт, башкалар шикелле үк, гадәти кеше, аның пәйгамбәрлеген тикшергәндә башка гади кешеләрнең эшчәнлеген бәяләгәндә кулланыла торган принципларга таянырга кирәк, ди. «һәрбер сәнагать иясенең хәле үзенең әсәрләре илә беленә, — ди ул. — Мәсәлән, Ибн-Синаның хакимлеге аның хикмәт вә тыйбын тикшерү илә... беленә. Шул кабилдән әгәр бер рәсүлулланың сәер, әхлак вә әүсафына карасак вә аларны тикшерсәк, аның турында дөрес гыйлем хасил итәрбез. һәм дә бу гыйлем башкаларга тәкълид илә түгел, бәлки аның әхвален тикшерү вә әфгален тәҗрибә илә хасил булган чын мәгърифәт буладыр» («Мәрҗани» җыентыгы. 248 бит). Ә кәламчеләрнең бу уңай белән әйткән фикерләренә ышанып булмый, чөнки алар акылга ятышлы шундыйрак дәлилләр һәм практик мәгълүматлар белән расланмыйлар.

Дини-мистик идеяләрне тәнкыйть иткәндә, мәгърифәтчелек хәрәкәтенең икенче бер күренекле вәкиле К. Насыйри да кеше акылына таяна. Әсәрләренең берсендә ул, «Бакырган», «Фәзаилешшөһүр» кебек халык арасында киң таралган китапларда язылган хәлләрдән көлә, аларны укытып балаларның башын бутарга ярамый, ди.

Иҗтимагый күренешләрне һәм дини карашларны бәяләүдә рационалистик юл белән якын килү мәгърифәтчеләрнең мөселман диненең тәкълид, ягъни сукыр килеш башкаларга иярүне алга сөргән принцибыннан баш тартуны таләп итүләрендә дә ачык чагыла. Шушы принципка нигезләнеп, дини тәгълимат уйлап-нитеп тормый гына традицияләргә һәм борынгылар сүзенә буйсынуны алга сәрә, бүгенге кешеләрнең иҗат эшчәнлегенә булган хокукын кире кага. Мөселман дөньясында фикъһене — дини юриспруденцияне һәм аның белән бәйләнешле башка фәннәрне камилләштерү аеруча мәшһүр закон белгечләре — мөҗтәһидләр кулыннан гына килә, дигән караш киң таралган була. Кәламчеләр фикеренчә, мөселманнарның калган массасы тәкълидкә бәйле һәм сукыр килеш борынгы автопортретларга ияреpгә тиеш булып чыга. Моңа өстәп, алар мөҗтәһидләр үзләренең тырышлыклары аркасында дини иманута һәм юриспруденциягә бәйләнешле бөтен мәсьәләләрне чишеп, хәл итеп бетергәннәр, актив уйлану һәм эшчәнлек күрсәтү заманы узган икән, дип тукыйлар. Бу идея «иҗтиһад мөнкариз», ягъни иҗат гасыры үтте, дигән тәгъбирдә үзенең чагылышын таба.

Иҗтимагый идея һәм теорияләрнең үсеше иҗтимагый яшәешнең үсешенә бәйле. Әмма, чагыштырмача мөстәкыйль булганлыктан, алар үзләре дә иҗтимагый тормышның төрле якларына көчле йогынты ясыйлар. Иҗтиһад гасыры үткән дигән идея белән дә шулай килеп чыга, татарлар арасында бер тамыр җәеп алгач, ул халык тормышына шактый нык йогынты ясый, караңгылыкны, артталыкны, торгынлыкны яклап чыга. Г. Ибраһимов бик дөрес язганча, бу идеянең татарлар арасында киң таралуы аяныч нәтиҗәләргә китерә. Янәсе, «хәятта яхшылык вә изгелек намәнә ни нәрсә, нинди эш булырга мөмкин, аларның һәммәсе булып үткән, киләчәк көндә алар булырга мөмкин түгел. Үткәндә сәләф салихин бар, изге голәмәләр бар. Алар диннең, дөньяның һәммә серен аңлап, безгә ачып киткәннәр. Безгә аларныкына бер хәреф арттырырга имкән юк, иске китапларда ни бар — без мөселманлыгыбыз буенча шуларны турында-туры кабул итәргә тиешлебез... һәр яңа — бидгать вә гөнаһ, һәр искелек мөкатдәс; балигъ булып, дөньяга үз күзе белән карый башларга тиешле бер вакытта ислам угылларының фикери хәятлары менә шундый игътикад, менә шундый авыр ташлар белән бастырылган, аның фикере шундый богаулар илә богауланып, мәңгелек таш зинданга бикләнгән иде» (Г. Ибраһимов. Бөек остазыбызның кайбер тәэллифләре. «Шиһабетдин Мәрҗани» исемле китап. Казан. 1968 ел. 52—53 битләр). Шулай итеп, актив эшчәнлек гасыры үткән дигән караш фикер торгынлыгына китерә, урта гасыр-

лардан калган иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең яшәвенә булыша, халыкның икътисади һәм мәдәни үсешен тоткарлый.

Рационализм байрагын күтәргән һәм кеше акылына хөрлек даулаган татар мәгърифәтчеләре, үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, тәкълидчелек һәм борынгылар сүзенә сукырларча иярү белән килешә алмыйлар. Бу идеягә каршы башлап Курсави күтәрелә. Авторитетларга иярүне мәҗбүри дип санау, бу юлдан читкә чыгучыларны мең төрле гөнаһ кылуда гаепләү, Г. Курсави фикеренчә, хакыйкатькә күз йомудан башка нәрсә түгел. Ул сукыр килеш кеше сүзен кабатлаучылардан, уйлап-нитеп тормый кеше фикеренә иярүчеләрдән көлә, аларны хуҗасы артыннан тагылып йөргән эткә тиңли. «Мең әмир яисә гыйлем киеме белән киенеп галим күренергә тырышкан меңнәрчә әдәмнәр гамәл кылсалар да, — ди ул «Әльиршадимильгыйбад» исемле хезмәтендә, — аның белән гамәл кылырга, аңа ышанырга ярамый. Гамәл кылучыларның һәм әмирләрнең гамәлләрен дәлил итү һәм галимнәр эченнән шуларның ишек төпләрендә буталучыларның гамәлләрен таяныч ясау бу гафләт вә җәһаләт әһелләренең вәһемнәре ясап чыгарган бер нәрсә генә». (Өзек Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» буенча китерелә. 23 бит.)

Иҗтиһад гасыры үтте дигән карашка һәм тәкъдидчелеккә каршы иң көчле ударны Ш. Мәрҗани ясый. Күп кенә хезмәтләрендә ул әлеге идеяләрнең халыкка никадәр зарар китерүен күрсәтә, аларның торгынлык һәм фанатизм өчен җирлек булып хезмәт итүләрен әйтә. «Мокаддимәте...» исемле хезмәтендә ул Шәрыктагы мөселман халыкларының артта калу сәбәпләренә туктала, аны нәкъ менә әлеге идеяләрнең киң таралган булуы белән аңлата һәм бу хәлне Шәрык халыклары тормышындагы зур афәтләрнең берсе дип саный. «Бу афәтләрнең берсе,— дип яза ул,— иҗтиһад гасыры үтте, мөҗтәһидләр бетте, әдәлил китереп сүз сөйләү, фикер әйтү бары мөҗтәһидләр эше, хәзер исә мөҗтәһидлек дәрәҗәсенә ирешү юллары киселгән, китап язучылар арасында сүзләрендә һич ялгышу ихтималы булмаган пәйгамбәр дәрәҗәсендәге кешеләр юк... Әгәр кем дә булса шундый юлга керергә батырчылык итсә, ул кеше ялганчы, аның сүзләре дөрес булу ихтималы юк, шуңа күрә кире кагылырга тиеш, дип карау» киң таралган (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 106—107 битләр).

Г. Курсави башлаган эшне дәвам иттереп, Ш. Мәрҗани тәкъдидчелек идеяләренең нигезсез булуын ачып сала. «Назурательхак» исемле хезмәтендә «мөҗтәһидләр бетте, алар вакыты күптән үтте» дигән карашның тамырдан ялгыш икәнлеген күрсәтә. Аныңча, кешенең дөньяны танып-белү юлындагы актив иҗат эшчәнлегенә бернинди чик юк, кеше үзенең уйларында да, хәрәкәтләрендә дә азат булырга тиеш. Ш. Мәрҗани иске традицияләргә һәм борынгылар сүзенә, шул исәптән, мөҗтәһидләр сүзенә дә, сукырларча иярүне һәрьяклап кискен тәнкыйть итә. Мөҗтәһидләргә ул гади кешеләргә караган кебек карый һәм «мөҗтәһидләрнең дә хатасы булырга мөмкин», ди. Бу сүзләре белән дини даирәләрдә изге дәрәҗәсендә йөртелгән кешеләрнең абруен шик астына ала.

* * *

Мәгърифәтчеләр кәләмчеләрнең һәм дини культ вәкилләренең иҗтимагый тормыштагы бөтен мәсьәләләрне шәригать кануннары буенча хәл итәргә тырышуларын гына тәнкыйтьләп калмыйлар. Дини догмаларның кулланылыш дәрәҗәсен чикләү белән бергә, алар алгы рәткә фәнне һәм фәлсәфәне чыгаралар, аларның иҗтимагый тормышта зур әһәмияткә ия булуларын ачалар һәм шуның белән бер үк вакытта кәләмчеләрнең һәм дини культ әһелләренең фәнни-философик белемгә һәм аның вәкилләренә карата дошманлык позицияләрендә торуларын фаш итәләр.

Дин галимнәре — кәләмчеләр фәнни-философик мәсьәләләрне чишкәндә бары дин кануннарыннан гына чыгып эш итәләр. Ә мондый хәл белән килешмәгән, фикер хөрлеге күрсәткән, табигать һәм иҗтимагый тормыш күренешләрен фән ноктасыннан торып аңлатырга һәм фәнни-философик белемнәрне халык арасында пропагандаларга җөрьәт иткән кешеләргә кяфирлек, мөртәтлек, монафыйклык мөһере сугалар. Мөселман инквизициясенең бу үзенчәлекле формасы **тәкфир** (кяфирлектә гаепләү) дигән

исем ала. Кәламчеләр һәм дини культ хезмәтчеләре кулында тәкфир озак гасырлар буена фән һәм философия вәкилләренә каршы юнәлдерелгән коточкыч корал хезмәтен үти. Кяфирлек һәм дәһрилек мөһере сугылган кеше законнан тыш дип игълан ителә һәм һәртөрле эзәрлекләүләргә дучар була. Кыскасы, аңа мөселманнар арасында яшәргә рәт калмый. Шуңа күрә тәкфир мөселман дөньясына яңа фикер һәм фәнни белемнәр үтеп керү юлында торган иң җитди киртәләрнең берсенә әверелә.

Татар мәгърифәтчеләре тәкфирне кискен кире кагалар, фәнни-философик мәсьәләләрне хәл итүне дини тәгълиматтан аералар, галимнәрне һәм философларны кәламчеләрнең һөҗүменнән яклыйлар. Бу мәсьәләләр дә үз юлының кәламчеләр позициясеннән тамырдан аерылуын күрсәтеп, Ш. Мәрҗани болай ди: «Без хәкимнәр вә әһле мәгърифәтне, гакыл вә хикмәтне дошман күрмибез һәм аларның дәлил илә исбат ителгән нәрсәләрен шәрә фанатизм вә дошманлык белән инкяр итмибез. Әһле мәгърифәтне, гакыл вә хикмәтне дошман күрмәк, дәлил белән сабит булган нәрсәләрне шәрә фанатизм белән инкяр итмәк әһле кәлям вә ялган философлар гадәтедер. Әһле кәлям вә ялган философларның сүзләре гаять зәгыйфь вә хаклыктан ерак» («Мәрҗани» җыентыгы. 247 бит).

Тәкфирчелек практикасын тәнкыйть иткәннән соң, галим, фәннең һәм философиянең әһәмиятен инкяр итү, аларны белгән һәм аңлаган кешеләргә кимсетүле мөнәсәбәт, үз башы белән фикер йөртергә сәләтле кешеләрне кяфирләр, денсезләр дип күңелләрен кайтару соңгы гасырларда мөселман халыклары өстенә төшкән иң әшәке афәтләрнең берсенә әйләнде, ди. Әгәр кеше алланың берлеген һәм Мөхәммәтнең пәйгамбәр булуын таный икән, фәнни-философик белемнәрне яклап чыккан өчен генә аны диннән аерырга ярамый, ди. Шул караштан чыгып, Ш. Мәрҗани Шәрыкта киң билгеле булган Әбугалисина, Эль-Фараби кебек күренекле галимнәрне һәм философларны кяфирлар, монафыйклар дип сүккән дин галиме Эль-Газалины тәнкыйть итә. Эль-Газали китабындагы Аристотель, Әбугалисина, Эль-Фараби кебек галимнәрне монафыйкләр, кяфирләр дип сүккән битләрнең кырларына Ш. Мәрҗани болай дип язып куя: «Имам хөҗҗәтелисламның мондый сүзләр сөйләве, хосусан Фараби вә Иб-Сина кебек көфердән пакъ затларны тәкфир итүе аның гыйлем вә мәгърифәтенә... һич монасыйб түгелдер. Ул үзе Шәрыкта лязим булмаган эш дип, хәтта шайтанга ләгънәт кыйлудан да тыядыр. Имде аның боларны тәкфир кылуына нинди дәлил сәбәп булды икән? Әлбәттә, моңа философларга каршы тиешеннән артык фанатизмнан башка сәбәп юктыр» («Мәрҗани» җыентыгы. 266).

Фән һәм философиягә каршы көрәштә динчеләр аерым галимнәрнең хезмәтләрендә киткән хата фикерләрдән файдаланмакчы булалар. Ш. Мәрҗани мондый алымның нигезсез булуын күрсәтә. Аерым галимнәрнең хезмәтләрендә хата фикерләр чыннан да очрарга мөмкин. Ләкин бу факт фәннең көчсезлеге хакында сөйләми. «Бербер нәрсәне ясаучылар яки күзәтүчеләр ялгышалар икән, — ди Ш. Мәрҗани, — бу эле әйбернең үзенең кимчелеген, аңа бәйләнешле фәннең дөрес түгеллеген күрсәтми, бәлки эшләүчеләрнең ялгышуы дип каралып, шуларга кире кайтарыла... Барлык гыйлемнәр дә шуның кебек. Бер гыйлемне белүченең шул гыйлемгә нисбәт биреп сөйләгән сүзләрендәге яки аңа нисбәт бирүдәге хаталарын гыйлемнең үзенә сылтарга ярамаган кебек, гыйлемнең үзен дә хурларга ярамый» (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы. 62 бит). Фән, дип яза галим үзенең «Хаккылмәгърифәт» исемле хезмәтендә, гыйлемнәр эзләү чарасы, шуңа күрә аңа карата дошмани мөнәсәбәтне берничек тә аклап булмый. «Фәнне вә гыйлемне хурлау, аларның әһәмиятен инкяр итү — ул наданлык күренеше» (Ш. Мәрҗани. Хаккыл-мәгърифәт. Казан. 1880 ел. 54 бит). Ул фәннең һәм философиянең әһәмиятен инкяр итүче кеше гакылга каршы чыга һәм гыйлемнең ни икәнен, аның кеше тормышындагы әһәмиятен бөтенләй аңламый дип саный.

Алда әйтелгәнчә, дини тәгълимат иҗтимагый тормышның бөтен мәсьәләләрен, шул исәптән, фәнни-философик мәсьәләләрне дә шәригать кануннарына таянып хәл итмәкче була. Мондый караш фән һәм философиягә бөтенләй мөстәкыйльлек бирми, аларны дини тәгълиматның нәрсәненә, хезмәтчесенә әйләндерә. Шушы мәсьәләгә тукталып, мәгълүм дин галиме, Петербург мәчетенең имамы Гатаулла Баязитов болай яза: «Иң бөек, һәр җирдә бар алла — бөтен гыйлем һәм фәннәрнең чыганагы. Фәнгә

хезмәт итү аны бар иткән аллага хезмәт итү. Бөтен гыйлемнәр арасыннан иң беренчесе һәм иң бөеге — алланы танып-белү, фән — диннең кызы. Кыз бала үз әнисе алдында беркайчан да мактанырга һәм масаерга тиеш түгел» (Баязитов Атаулла. Отношение ислама к науке и к иноверцам. Спб. Рус телендә. 1887 ел. 100 бит).

Мәгърифәтчеләр дини тәгълиматның бу дәгъвасын да кире кагалар, фән һәм философия шәригать кануннарыннан азат булырга тиеш, дип чыгалар, фәнни эзләнүләр ирекен таләп итәләр. Әлеге карашны нигезләп, Ш. Мәрҗани, бер яктан, фән һәм философиянең, икенче яктан, диннең үзләренә генә хас өлкәләре, үзенчәлекле дәлилләү һәм исбатлау алымнары бар, дип чыга. Дингә бәйләнешле мәсьәләләрне хәл иткәндә, ди ул, изге чыганакларга — коръәнгә һәм пәйгамбәрнең сөннәтенә таянабыз. Инде фәнни мәсьәләләргә килгәндә, аларны исбатлау өчен гакылга таянырга һәм әйберләрнең фактик хәленнән чыгып эш итәргә кирәк. Пәйгамбәр фәнни мәсьәләләр белән шөгыльләнмәгән, шуңа күрә коръәнне һәм хәдисләрне фән өлкәсендә кулланып булмый. «Хәдис китапларында әйтелгән дәвалау ысулларын нәкъ шулай булуы мәҗбүри дип исәпләргә ярамый. Әгәр болар хөрмәт һәм иман ныклыгы йөзеннән кулланылсалар, иман сүзе булу ягыннан, аның тәэсире булырга мөмкин, әмма табигать кануннарына туры килә торган врачлык ягыннан боларның файдалары юк. Чөнки пәйгамбәрләр шәригать өйрәнү өчен җибәрелгәннәр, фәннәр өйрәнү өчен түгел» (Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты архивы, 88—89 битләр). Кәламчеләрнең китаплары да чын фәнни чыганак булып исәпләнә алмый, чөнки аларның карашлары күпчелек очракта буш хыял җимеше булудан узмый.

Фән һәм философиянең мөстәкыйль үсеш юлы белән барырга тиешлеген яклап, Ш. Мәрҗани, күренешләрнең эчке табигатеннән килә торган һәм кеше акылы белән исбатланган нәрсәләрне шәригать үзгәртә алмый, ди. «Шәригать гакыл һәм зарурлык белән исбатланган хөкемне кире какмый. Шәригать белән казыяи гакъмия вә әхкәм зарурия арасында каршылык булганда да зарурәт вә хаҗәт кадәригә дәлил сәмгыйны тәэвил тиеш буладыр» («Мәрҗани» җыентыгы. 267 бит). Димәк ки, Ш. Мәрҗани фикеренчә, мондый очракларда шәригать кануннарын гына исәпкә алу җитми, фәнни караш файдасына сөйли торган дәлилләрне дә исәпкә алырга кирәк, беренчеләрен гел кире кагу, икенчеләренә сүзсез ышану юлына басарга ярамый.

Ш. Мәрҗанинең фәннең диннән бәйсез, дин һәм фәннең һәркайсының үзләренә генә хас мәсьәләләре булуы турындагы карашын алга таба Ш. Көлтәси дәвам иттерә. Ул инде фәнни мәсьәләләрне дини мәсьәләләрдән тагын да кискенрәк төстә аера, динне фәнгә катнаштыруны катгый кире кага. Пәйгамбәрләр тарафыннан калдырылган нәрсәләр бары дингә кагыла, ди ул, «әйберләрнең хакыйкатен бәян итү аларның вазифаи шани җөмләсеннән түгелдер» (Ш. Көлтәси, һәйәте җәдидә. Казан. 1896 ел. 36 бит). Аның фикеренчә, дини мәсьәләләр, әхлак тәрбиясе һәм кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне юлга салу белән шәригать шөгыльләнергә тиеш. Инде чынбарлыкның асылын ачыклау, андагы эре вә вак кисәкләр, аларның тәртибен өйрәнү, дөньяның барлыкка килүендә бәйле мәсьәләләрне хәл итү — фән эше. Әлеге фәнни мәсьәләләр бары тик акыл көче белән хәл ителә, монда диннең катнашы юк. Әлеге фикерләрен ачыклап, икенче бер хезмәтендә Ш. Көлтәси болай яза: «Җисемнәрнең сөкүн вә хәрәкәтләрен, күләм вә зурлыкларын, шәкел вә һәйәтләрен һәм аларның араларындагы богыд вә мәсафәтләрен бәян итмәк шәригатьнең максады түгелдер... Мәсаил фәния вә мәвадди риязия кеби омур дөньявидән булган шәйләргә китап вә сөннәт вә иҗмал өммәт кеби шәригать дәлилләре белән истидмал итмәк һич урынлы түгелдер» (Ш. Көлтәси. Мөфассал һәйәте җәдидә. Казан. 1900 ел. 2—3 битләр). Коръәннәр һәм дини риваятьләрне өйрәнеп, дин галимнәре мөселман юриспруденциясен — фикъһене язган кебек үк, ди ул, галимнәр һәм философлар, табигатьне җентекләп һәм һәрьяклап өйрәнү юлы белән, аның бөек серләрен ачалар, табигый процессларның нигезендә яткан закончалыкларны ачыклыйлар, гыйлем һәм философияне тудыралар.

Дин галимнәре һөҗүменнән фәнни-философик карашларны яклау һәм гыйльми эзләнүләр ирекен саклап калу белән бергә, татар мәгърифәтчеләре фән һәм философиянең җәмгыять тормышында тоткан урынын һәм ролен ачып бирәләр. Фән һәм философия, диләр алар, белемнәрнең иң ышанычлы чыганагы, ә белем — кеше эшчәнлегенең зарури нигезе. Гыйлемгә таянып, ди К. Насыйри, кеше чынны ялганнан аерырга өйрәнә; ул, ягъни гыйлем, күңелсез чакта тынычланырга булыша, ялгыз чакта

сердәшең була, бәхет һәм шатлыкка юл ача, бәлаләрдән коткара, дусларының мәхәббәтен яуларга ярдәм итә, дошманнарга каршы көрәшерлек корал бирә. Татар мәгърифәтчеләре фән һәм философияне иҗтимагый иминлек өчен зарури булган алшарт дип, ә аларның чәчәк атуын иҗтимагый прогресс өчен кирәкле зарурият дип саныйлар. Тарихтан күп мисаллар китереп, Ш. Мәрҗани фән һәм философиянең халыклар тормышында мөһим роль уйнавын нигезли. Аның фикеренчә, бер-бер артлы грек, рим һәм иран халыкларының күтәрелүе, габассилар чорында гарәп дәүләтенең чәчәк атуы бу илләрдә фән һәм философиянең нык үскән булуы белән аңлатыла да. Бу дәүләтләрнең куәте артуда, мәдәниятләре үсүдә һәм халыкның тормыш-көнкүреше яхшыруда бу илләрдә фәнни-философик белемнәрнең киң таралган булуы мөһим роль уйнады, ди ул. Гыйлем дулкыннары аларда шәһәрләр белән генә чикләнеп калмый, илнең ерак почмакларына кадәр тарала. Кеше акылы белән табылган гыйлемнәр алар тормышында әһәмиятле урын тота һәм аларны югары күтәрә.

Мәгърифәтчеләр фән һәм философиянең җәмгыять тормышындагы гомуми урынын һәм ролен ачыклау белән генә чикләнмиләр, алар фәнни белемнәр системасында аерым фәннәрнең әһәмиятен һәм аларның иҗтимагый функцияләрен дә ачыкларга омтылыш ясыйлар. Бу өлкәдә Ш. Мәрҗанинең роле аеруча зур, ул татар иҗтимагый һәм философик фикер үсеше тарихында беренче булып фәннәргә классификация ясый. Татар мәгърифәтчелегенең икенче бер күренекле вәкиле булган К. Насыйри фәнни белемнәрне халык арасында пропагандалау буенча зур эш башкара.

* * *

Сүз дә юк, татар мәгърифәтчеләренең кәлямчеләргә һәм суфичылыкка каршы көрәше эзлекле характерда булмады һәм була да алмый иде. Алда әйтелгәнчә, алар атеистлар булмыйлар һәм динне инкяр итмиләр, үз дошманнарына каршы көрәштә еш кына коръәнгә һәм пәйгамбәрнең хәдисләренә мөрәҗәгать итәләр. Алар эшчәнлегендәге мондый чигенешләр хакында сүз йөрткәндә, мәгърифәтчеләр тормышының һәм эшчәнлегенең тарихи шартларын истән чыгармаска кирәк. Әгәр мондый эзлексезлек диннең позицияләре нык какшаган, массалар материалистик һәм атеистик идеяләрне ачыктан-ачык кабул итәргә өлгереп җиткән шартларда күрсәтелә икән, бу — бер хәл. Инде диннең позицияләре нык булган, массалар алдынгы идеяләрне үзләштерүдән ерак торган чакта күрсәтергә икән, бусы бөтенләй башка мәсьәлә. Татар мәгърифәтчеләре халык урта гасырчылык карашларыннан арынырга өлгермәгән, массалар аңында дини карашлар өстенлек иткән бер чорда дини тәгълиматны — кәлямне һәм суфичылыкны тәнкыйть итеп чыгалар. Ф. Энгельс сүзләре белән әйткәндә, узган гасырның уртасында «массаларның аңы бары тик дини азык белән туендырылган иде, шуңа күрә, давыллы хәрәкәт тудыру өчен, әлеге массаларның үз интересларын дини тышча ярдәмендә күрсәтергә кирәк иде». (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Сайланма әсәрләр. II том. 1952 ел. 79 бит.) Бу — дини тәгълиматны тәнкыйть итү өчен иң кулай тышча булды. Шундый тышчада булганда гына ул массаларны кузгата һәм аларның аңнарын уята ала иде. Моңа чал тарих үзе мисал. XVIII йөздә, мәсәлән, Франциядә хөр фикернең таралуына Гольбах түгел, ә Руссо күбрәк йогынты ясый. Ә бит беренче карашка киресенчә булырга тиеш иде. Чөнки Гольбах атеист була һәм ачыктан-ачык атеистлыкны алга сөрә, Руссо исә динне бөтенләй үк инкяр итми. Шуның кебек үк, XIX йөздәге татарлар арасында да атеизмны һәм дәһрилекне ачыктан-ачык алга сөрү әллә ни зур уңышка китермәс иде. Г. Ибраһимов дөрес күрсәткәнчә, И. Гаспринский «Тәрҗеман»ы аша, Р. Ибраһимов «Чулпан» һәм «Мират» газеталары аша, күпме тырышып та, халык аңында дингә нәфрәт тәрбияли алмыйлар. «Алар аркылы,— дип яза ул, — без Европаның шәплеген, әһле исламның бетеп барганлыгын белсәк тә, бу фактта аларга кушылсак та, бу факттан туачак нәтиҗәдә алардан аерыла идек. Борынгы китаплар исламның хур вә замин булып бетүен хәбәр бирә. Бәс алда ниндидер тәрәккый, мәдәният гаугаларына мәйдан калмаган. Үзенең алган юлында сабаты, тагассыбы чиктән тыш куәтле булган пишкадәм мәнтыйкчы, мәддагый егетләргә тәэсир итә алудан «Тәрҗеман»нар, «Чулпан»нар гаҗиз иде. Ул мәддагый вә мөтәгассыйблар-

ны үзләре утырган позициядән чыгарырга, иң элек шул үзләре дә ышанырга тиешле ислам галимнәренең сүзләре ярдәме белән аларның башындагы тәгассыбны куып чыгарырга кирәк иде. «Нәзурә...»ләр менә шул хезмәтне үтәде» («Шиһабетдин Мәрҗани». Казан. 1968 ел. 55 бит). Димәк ки, XIX йөз шартларында, дини тәгълиматка һәм схоластикага каршы көрәшү өчен, татар мәгърифәтчеләре сайлаган корал кулайрак була. Мәгърифәтчеләр сайлап алган тышчада, алар кулланган корал ярдәмендә яңа карашлар татар халкына тизрәк ишетелә, халыкның аңын уята, алар арасында материалистик һәм атеистик идеяләр таралуга җирлек әзерли.

Шуның белән бергә, татар мәгърифәтчеләре, субъектив яктан алганда да, атеистик идеяләрне кабул итәргә һәм массалар арасында пропагандаларга әзер түгелләр иде. Алар үз чорының уллары булалар, шул чорда татарлар арасында өстенлек иткән дөньяга караш аларга да йогынты ясамый калмый, аның белән араны өзү өчен әле вакыты килеп җитмәгән була[1].

Әмма шул ук вакытта мәгърифәтчеләр дини догмаларга сукырларча баш иючеләр дә түгелләр. Рационализм тарафдарлары буларак, алар кискен төстә схоластикага каршы чыгалар, дини китапларның абруен шик астына алалар, фикер хөрлеген яклап чыгалар. Динне тулаем кире какмасалар да, аның төп принципларын шик астына алалар. Алар коръәнгә таяналар, шул ук вакытта төп ударларын фанатизмга һәм мистикага каршы юнәлтәләр, изге китаплардан алынган өзекләрне дин галимнәренең тезисларын җимерү өчен файдаланалар. Ш. Мәрҗанинең карашларындагы каршылыкларга тукталып һәм аның иҗтимагый фикер үсешендәге урынын билгеләп, Г. Тукай болай дигән иде:

**Ул итсә дә аять — хәдисне күп мәкыль,**
**Булып бетми аның акылы мәкыльгә кол;**
**Инсан дигән шәрәфле бер мәхлукта ул**
**Бар дип белә хаким акыл һәм хөр акыл.**

Революцион-демократик карашларда торган бөек шагыйрьнең бу сүзләре башка мәгърифәтчеләрнең эшчәнлеген бәяләү өчен дә ярый. Кешегә, аның акыл көченә ышану, аны дини караңгылык кочагыннан араларга тырышу — мәгърифәтчеләр эшчәнлегенең иң характерлы ягы.

Дини тәгълиматны һәм суфичылыкны тәнкыйть итеп, мәгърифәтчеләр урта гасырлардан калган иҗтимагый-икътыйсади мөнәсәбәтләргә каршы чыгалар. «Дингә каршы көрәш,— дип яза К. Маркс,— читләтеп алганда, динне үзенең рухи юанычы итеп алган дөньяга каршы да көрәш. Шул рәвешчә, күкне тәнкыйтьләү җирне тәнкыйтьләүгә, динне тәнкыйтьләү законны тәнкыйтьләүгә, теологияне тәнкыйтьләү политиканы тәнкыйтьләүгә әйләнеп кала» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр. 1 том. 414—415 битләр). Алда күренгәнчә, дини тәгълимат урта гасырлардан калган тәртипләрне яклап чыга, милли тормыштагы караңгылыкны һәм торгынлыкны хуплый. Шуңа күрә татар мәгърифәтчеләренең дини тәгълиматны тәнкыйть итеп чыгуы үзенең бер очы белән котылгысыз рәвештә урта гасырчылык калдыкларына һәм аларны саклап калырга тырышучылар өстенә килеп төшә. Менә шуңа күрә дә мәгърифәтчеләрнең һәр чыгышы искелек тарафдарларының кискен каршылыгына очрый. Дини кануннарга тәнкыйть күзлеге белән караган өчен, Г. Курсави Бохара әмире тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителә, аннан ул туган иленә качып кына котыла. Искелек тарафдарлары аңа биредә дә тынгылык бирмиләр, ул, туган илен ташлап, чит җирләргә китәргә мәҗбүр була һәм шунда яшьли үлеп кала. Ш. Мәрҗаниның «Назурательхак» исемле китабы дөньяга чыккач (анда ул күп кенә дини мәсьәләләрне күтәрә һәм кәләмчеләрнең карашларын тәнкыйтьли), Казан шәһәренең 12 мулласы И. Юсуповлар акчасына «Җаруда» исемле җыентык чыгаралар. Алар анда Ш. Мәрҗанины төрлечә мәсхәрәлиләр, аны монафыйклыкта, көферлектә гаеплиләр.

---

[1] Дини тәгълиматны тәнкыйть итүдә мондый эзлексезлек бер татар мәгърифәтчеләренә генә хас түгел. Күренекле немец мәгърифәтчеләре И. Лессинг, И. Гредер, И. Гете дә дин белән араны өзә алмыйлар. Н. И. Новиков, П. Я. Чаадаев кебек мәгърифәтчеләр эшчәнлегенә күз салсак, без аның кайбер рус мәгърифәтчеләренә дә хас булуын күрербез. Динне, чиркәүне, карагруһчыларны тәнкыйть иткәндә изге китапларга таяну да иҗтимагый фикер үсеш тарихында шактый еш очрый торган күренеш.

Ләкин реакцион даирәләрнең искелекне якларга тырышулары, халык аңына мәгърифәтчелек идеяләре үтеп керүне тоткарларга маташулары барып чыкмый. Бу хакта Акмулланың Мәрҗанига багышланган бер шигырендә ифрат матур әйтелә:

Яхшыны сүккән гелән аты китмәс.
Яман сүзнең күңелдән заты китмәс;
Саф алтынны нәҗескә буяу илән
Нәҗес китәр, алтынның заты китмәс.

Кыйек ук, аткан менән, туры китмәс,
Күңелдән яман сүзнең коры китмәс,
Котырган эт һава карап өргән менән,
Асьманда торган айның нуры китмәс.

Дини тәгълиматны һәм суфичылыкны тәнкыйтьләп чыгып, татар мәгърифәтчеләре ул вакытта өстенлек иткән дини идеологиянең кимчелекләрен ачып салалар, кеше аңын үле традицияләр һәм гореф-гадәтләр коллыгыннан азат итәләр, татар халкын алдынгы культурага тарту, алар арасында фәнни материалистик карашлар тарату өчен офыклар ачалар, алга таба марксистик-ленинчыл карашларның үтеп керүе өчен җирлек хәзерлиләр. Узган ел илебез халыклары СССР төзелүнең 50 еллык бәйрәмен билгеләп уздылар. Ирекле халыкларның тату семьясында яшәп, татар халкы үзенең экономикасын, культурасын үстерү өчен киң мөмкинлекләр алды. Бүгенге казанышларыбыз югарылыгыннан без, горурланып, үткәннәргә әйләнеп карыйбыз һәм алдынгы фикер ияләренең фидакарь хезмәтенә баш иябез. Алар үзләренең кыю эшчәнлекләре белән, бер яктан, царизмның колониаль политикасы һәм тырышлыгы, икенче яктан, реакцион мөселман руханиларының тырышлыгы белән халыкларның үзара якынаю юлында корылган ясалма киртәләрне какшаттылар. Татар мәгърифәтчеләре милли чикләнүчәнлеккә кискен каршы чыктылар һәм дин догмаларына таянып аны акларга маташучыларны аяусыз фаш иттеләр. Алар халыкларның үзара якынаюга булган омтылышларын, барыннан да бигрәк, алдынгы рус культурасына якынаюны хуплап каршы алдылар. Совет строе шартларында татар халкының алдынгы улларының бу хыяллары чынга ашты һәм бүген татар халкы, Советлар илендәге башка халыклар белән бергә, якты коммунизм үрләренә атлый.

Альберт Айнетдинов

# БАТЫРЛАР ЭЗЕННӘН

Бөек Ватан сугышы елларында, илебездәге башка милләт вәкилләре белән иңгә-иң торып, татар егетләре дә зур геройлыклар күрсәттеләр. Сугыш кырларындагы батырлыклары өчен, халкыбызның ике йөзләп улына Советлар Союзы Герое исеме бирелде, йөз меңнәрчә кеше сугышчан орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде.

Үзенең батыр улларын барлау, аларның якты истәлеген мәңгеләштерү эшенә халкыбыз бик күптән — әле сугыш барган елларда ук керешкән иде. Аннан бирле узган утыз ел вакыт эчендә бу юнәлештә шактый зур эш башкарылды. Колхоз һәм совхозларга, шәһәр һәм авыл урамнарына, мәктәпләргә һәм культура сарайларына фронт каһарманнары исеме бирелде. Шәһәрләрдә, район үзәкләрендә һәм авылларда сугыш кырларыннан кайтмый калган солдатлар истәлегенә һәйкәлләр салынды. Геройларның якты истәлегенә багышлап, рәссамнарыбыз зур-зур картиналар яздылар, композиторларыбыз яңа җырлар, симфонияләр, опера әсәрләре иҗат иттеләр.

Бөек Ватан сугышы, геройлар темасы бигрәк тә матур әдәбиятта киң чагылыш тапты. Бу хакта язылган шигырь һәм поэмаларны, хикәя һәм очеркларны, истәлекләрне санап бетерерлек түгел. Прозаикларыбыз, батырлар истәлегенә багышлап, күп кенә повестьлар һәм романнар иҗат иттеләр. Кыска гына вакыт эчендә татар совет әдәбияты сугыш темасын яктырту буенча бай тәҗрибә туплады. Көн тәртибенә әлеге тәҗрибәне гомумиләштерү һәм аңа йомгак ясау бурычы килеп басты. Бу мәкалә әнә шул бурычны күздә тотып язылды. Сүз Бөек Ватан сугышы батырларына багышланган очерклар һәм публицистик мәкаләләр хакында барачак.

Советлар Союзы Геройларына багышланган беренче очерклар сугыш елларында языла. Төрле фронтларда чыккан татар газеталарында, «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») һәм «Красная Татария» (хәзерге «Советская Татария») газеталарының, шулай ук «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналының сугыш елларында чыккан саннарында батыр якташларыбыз хакында бик күп мәкаләләр, очерклар басылган. Аларны фронт газеталарында эшләүче журналистлар һәм язучылар, төрле хәрби частьларның командирлары язган. Ватан сугышының кайнар эзләре буенча язылган ул материалларның кыйммәте бәяләп бетергесез зур. Алга таба республикабыз территориясендә туып-үскән геройларны барлау, аларның батырлыгын пропагандалау эше әлеге материалларга таянып алып барыла. 1945 елда чыккан «Батырлар китабы»н укучылар хәтерлидер. Күренекле язучыбыз Кави Нәҗми аны шул еллар матбугатында басылган мәкаләләрдән һәм очерклардан төзи. «Батырлар китабы»н укучылар ифрат җылы каршылый, ул байтак еллар буена куллардан төшми укылып килә. Бу китап әле хәзер дә җитди игътибарга лаек кулланмаларның берсе санала. Шуның белән бергә, аның бераз искерә төшүен дә әйтми узып булмый. Китапка тупланган очеркларның байтагы ашыгыбрак язылган. Геройларның фронт тормышы, сугыш кырларында күрсәткән батыр-

лыклары шактый тулы һәм төпле яктыртылса да, батырлыкның алшартлары — аларның тыныч еллардагы тормыш юлы, кайда, нинди урыннарда тәрбия алулары тиешенчә ачылмый кала. «Батырлар китабы»на Татарстан җирендә туып-үскән Советлар Союзы Геройларының бик аз өлеше генә кергән. Кызганычка каршы, аның икенче китабы бөтенләй чыкмый калды. «Батырлар китабы»нда төрле характердагы төгәлсезлекләр дә очрый. Т. Шәрәфетдинов та, Г. Шакиров та Советлар Союзы Геройлары түгел. Геройлар китабында, ни өчендер, аларга да урын бирелгән. Советлар Союзы Герое К. Якупов күрсәткән батырлык турында бер җыентыкта ике тапкыр языла. Геройның исем-фамилиясен ялгыш язу аркасында, бер герой ике геройга әйләнгән...

Кави Нәҗмидән соң байтак еллар буена бу эш тукталып торды. Яңа очерк җыентыклары күренмәде, искеләре кабат басылмады диярлек. Алтмышынчы елларга кадәр бу өлкәдә ныклап эшләүче кеше булмады дияргә ярый. Ниһаять, 1966 елда тарих фәннәре кандидаты Л. Ханинның «Татарстан уллары — Советлар Союзы Геройлары» дигән китабы басылып чыкты. Тагын ике елдан шул ук китапның татарча варианты да дөнья күрде.

«Батырлар китабы» белән чагыштырганда, Л. Ханин төзегән җыентыкның күп кенә отышлы яклары күзгә ташлана. Иң элек ул тулылыгы, фәнни төгәллеге белән аерылып тора. Автор китапханәләрдә күп утырган, архивларда озак казынган. Нәтиҗәдә ул күп кенә яңа геройлар ачкан, аларның сугышчан юлларын күрсәтә алган. Шул ук вакытта китапта эчне пошырырдай төгәлсезлекләр дә киткән. Исеменә карагында, җыентыкка Татарстан җирендә туып-үскән геройлар гына кертелергә тиеш иде. Ни өчендер бу принцип төгәл сакланмаган. Сәхаб Нургаян улы Майский, мәсәлән, Башкортстанда туып-үскән герой. Л. Ханин китабында без аны да очратабыз. Татарстан геройларының кайберләре исә бөтенләй онытылып калган. Чистай районы егете Габделәхәт Вәлиев, әйтик, шундый язмышка дучар булган геройларның берсе.

Л. Ханин күбрәк хәрби архив документлары, аерым алганда, бүләкләү кәгазьләре белән генә эш иткән булса кирәк. Җыентыкта исән калган батырларыбызның сугыштан соңгы тормыш юлы бөтенләй яктыртылмый. Ә бу бик кирәк иде. Аларның күбесе тыныч хезмәт фронтында да үзләрен чын солдатлар итеп танытты. Бер дә ерак барып торасы юк, Арча районының Мирҗәм авылында туып-үскән Нәкыйп Сафинны гына алып карыйк. Башта ул озак еллар буе «Северный» совхозында директор булып эшләде, хәзер «Юдино» совхозының директоры. Авыл хуҗалыгын үстерү өлкәсендәге зур хезмәтләре өчен, хөкүмәтебез аны орденнар, медальләр белән бүләкләде. Я булмаса, Зеленодольск шәһәрендә яшәүче Советлар Союзы Герое Вәлит Хаҗиевны алыгыз. Производство алдынгысы, шуның өстенә, яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча да ул күпме эш алып бара. Л. Ханин китабында без боларның берсен дә күрмибез.

Соңгы елларда сугыш батырларының тормышы һәм көрәш юлларын өйрәнүчеләр сафына яңа авторлар өстәлде. Мин, беренче чиратта, Шамил Рәкыйпов һәм Зәки Әхмәтҗановларны күздә тотам. Кыска гына вакыт эчендә алар бер яки берничә җыентык чыгарып өлгерде. Ул җыентыклар укучылар арасында шактый зур кызыксыну уятты, матбугат битләрендә авторларның хезмәтенә уңай бәя биргән рецензияләр чыкты.

Бу авторларның очерк китаплары ни өчен шундый популярлык казанды? Моны ничек аңлатырга соң? Сәбәпләре шактый күп булса кирәк. Сүзне гомуми характердагы бер закончалыктан башлыйк. Без хәзер халкыбызның героик үткәне, Ватан сугышы кырларында күрсәткән батырлыклары белән күп тапкыр ныграк кызыксына башладык. Укучы каршында документаль әдәбиятның абруе, дәрәҗәсе күтәрелде. Ш. Рәкыйпов һәм З. Әхмәтҗанов китапларына булган гомуми игътибар күпмедер күләмдә шуның белән дә аңлатыла.

Моңарчы чыккан китапларда Советлар Союзы Геройларының фронт тормышы гына тулырак яктыртыла иде. Алардан аермалы буларак, әлеге очеркларда геройларның яшьлек елларын, тыныч тормыш шартларындагы эшчәнлекләрен сурәтләүгә дә киң урын бирелә. Аннан соң, Ш. Рәкыйпов та, З. Әхмәтҗанов та очеркларын әдәби итеп, мавыгып укырлык итеп эшләүгә зур игътибар бирәләр. Аларның әсәрләренә булган мөнәсәбәт хакында фикер йөрткәндә, мәсьәләнең бу ягын да истән чыгарырга ярамый.

Әлегә кадәр без нигездә Татарстан территориясендә үскән геройлар турында гына язып килдек. Илебезнең башка республика һәм өлкәләреннән чыккан татар

геройларын өйрәнмәдек диярлек, аларны барлау, аларның батырлыгын пропагандалау эше белән җитәрлек шөгыльләнмәдек. Ш. Рәкыйпов белән З. Әхмәтҗанов исә бер Татарстан территориясе белән генә чикләнмиләр. Аларның җыентыкларында башка өлкәләрдә туып-үскән татар геройларына да киң урын бирелә. Укучыларны алар моңарчы аз билгеле булган яки бөтенләй таныш булмаган геройлар белән таныштыралар.

Без хәзергә татар халкы арасыннан чыккан Советлар Союзы Геройларының төгәл санын белмибез. Шуның аркасында аларның саны төрле чыганакларда төрлечә йөртелә. «Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы тарихы» дигән хезмәтнең 1970 елда чыккан яңа басмасында татар геройлары 161 кеше дип күрсәтелә. Ә «Татарстан АССР тарихы»ның шул ук елда чыккан басмасында татар халкы арасыннан чыккан Советлар Союзы Геройлары 157 кеше диелгән. Соңгы елларда алып барылган эзләнүләр нәтиҗәсендә күп кенә яңа геройлар ачылды. Бүгенге көндә без Советлар Союзы Герое дигән исемгә лаек булган 171 татар егетен беләбез. Иң элек шул кадәресен билгеләп үтәргә кирәк, әлеге яңа геройларны ачу эшенә Ш. Рәкыйпов белән З. Әхмәтҗанов та шактый өлеш керттеләр. Үзенең «Геройлар эзеннән» дигән китабында Ш. Рәкыйпов безне моңарчы билгеле булмаган 4—5 яңа геройның тормыш һәм көрәш юлы белән таныштыра. Моңарчы без белмәгән геройлар З. Әхмәтҗановның «Утлар-сулар аша» исемле җыентыгында да очрый. Берьюлы 4—5 яңа герой ачу җиңел эш түгел, билгеле. Моның өчен күп белергә, күп йөрергә, эзләнергә кирәк. Бу авторларга популярлык китергән төп сәбәпләрнең берсе менә шушы иде булса кирәк. Бүгенге укучылар каршында алар күп эзләнүче, яңа геройлар ачучы әдип һәм журналист буларак танылдылар.

Шул ук вакытта һәр ике авторның иҗатына хас бер кимчелек тә торган саен ныграк сизелә барды. Аны яңа герой ачу шаукымына бирелү дип атап булыр иде. Яңа герой ачу белән мавыгып, алар электән билгеле булган геройларны икенче кат ача башладылар. Фикеребезне конкрет мисаллар белән дәлилләп китик.

«Геройлар эзеннән» дигән китабына язган кереш сүзендә Ш. Рәкыйпов башка өлкәләрдә туган 116 татар героеның сугышчан юлы бөтенләй диярлек өйрәнелмиди. Бу фикер белән килешеп бетеп булмый. Ватан сугышы геройларының сугышчан юлын өйрәнү һәр республикада, һәр өлкәдә шактый киң күләмдә алып барыла.

1965—66 елларда Уфада «Башкортстанның батыр уллары» исемле ике томнан торган китап чыккан. 1967 елда Йошкар-Ола шәһәрендә «Мари АССР Бөек Ватан сугышы елларында», 1968 елда Чебоксарда «Безнең якташлар — Советлар Союзы Геройлары» исемле китаплар дөнья күргән. Аларның һәр кайсында әлеге республикаларда туып-үскән татар геройлары турында да языла.

«Башкортстанның батыр уллары» дигән китапның икенче томында Советлар Союзы Герое Низаметдин Әхмәтҗанов хакында шактый тулы һәм матур язылган. Ш. Рәкыйпов китабының 55 битендә без бу герой белән кабат очрашабыз. Ш. Рәкыйпов китабындагы «Җилләр, җилләр, сәлам илтегез» дигән очерк турында да шул ук сүзләрне кабатларга туры килә. Советлар Союзы Герое Д. Ногманов турында «Башкортстанның батыр уллары» дигән китапта да зур гына очерк бар. Бу ике очерк эчтәлекләре белән бер-берсеннән аз аерылалар. Менә 1966 елда басылган очерктан берничә өзек:

«...В огромной бронированной лавине шел и танк старшего лейтенанта Дейлегея Нагуманова. Не обычный танк, а тральщик.

Кто был на фронте, то видел, какую опасную «военную работу» выполняли танкисты-тральщики. Мощная машина должна была проложить дорогу своим «коллегам» — танкистам, механизированной пехоте, артиллерии... Танк-тральщик был и воином-разведчиком и «медицинской сестрой», потому что на его долю падала обязанность «выносить» с поля боя раненные боевые машины...» (Башкортстанның батыр уллары. Икенче китап. 104 бит). «Все меньше остается до «пантеры». Стиснув до боли зубы, Дейлегей выжимал из мотора все, что мог. Машина неслась на полной скорости и когда расстояние до врага измерялись уже несколькими десятками метров, он вдруг увидел, что попал в засаду. Из-за кустарников на него двигались четыре тяжелых фашистских танка. Отступать было некуда, немцы окружили со всех сторон. Дейлегей при-

нял бой... Командир дал команду: «Экипажу покинуть машину!»

Хәзер Ш. Рәкыйпов китабына мөрәҗәгать итик: «Күперләр шартлатылган, юллар миналанган. Ләкин Дәүләгәй танкысы өчен мина артык куркыныч түгел. Тикмәгә генә тральщик дип аталмый ич ул. Аның «борыны»на барабан сыман нәрсә урнаштырылган. Мина шуңа эләксә һәм ярылса да танкка зыян китерә алмый. Бүтәннәргә юл салып үткән бу машина артыннан гадәти танклар, үзйөрешле орудиеләр һәм механикалаштырылган пехота шөбһәләнүсез бара. Юлда ул-бу хәлгә дучар булганда да тральщик ярдәмгә килә: трос белән эләктерә дә сөйрәп чыгара». (265—266 битләр.) «Дәүләгәй бу «тигр»ның командир машинасы икәнлеген чамалап алды һәм йөрәгендәге әлегә кадәр кайнаган нәфрәте бермә-бер артты.

— Сулга!

— Тулы газ! Алга!

Эх, машина да кеше йөрәге төсле гаҗәеп көчкә ия булса икән! Ләкин ул үз мөмкинлекләреннән уза алмый шул. Мотор соңгы чиккә җитеп кызган, әмма бер генә секундка да туктарга ярамый, һич тә ярамый... Дошман снаряды тиюдән танк чайкалып куйды...

— Экипаж, танктан чыгарга! Төтен ягына!..» (270 бит.)

Күрәсез, беренче очеркта эмоциональ киеренкелек бар, икенче очеркта коры санап чыгу гына. Өстәвенә С. Вайсманныкы алданрак язылган. Башка өлкәләрдә туган Советлар Союзы Геройларының сугышчан юлы турында язарга алынган кеше башта үзенә кадәр нинди очерклар, әдәби әсәрләр язылганын барлап чыгарга тиеш иде. Әгәр дә алар начар икән, әгәр шәбрәк, төплерәк язарыңа ышанасың икән — рәхим ит! Моның өчен берәүне дә гаеплә булмый.

Менә тагын бер характерлы мисал. Ш. Рәкыйпов «Утны безгә күчерегез» дигән очеркын Түмән өлкәсе Аслана урта мәктәбе укучыларыннан килгән хат белән башлый: «Геройның (сүз С. Кәримов турында бара — А. А.) адресын һәм аның нинди батырлыклар күрсәтүен тулырак итеп язсагыз иде...» Шуннан ул, әр-яңа герой ачкан кеше кебек, Советлар Союзы Герое Салават Кәримов турында сөйләргә тотына.

Ә бит мәсьәләгә җитдирәк карагaнда, Ш. Рәкыйповка бу очеркны язып тормаска да мөмкин иде. Аслана мәктәбе укучыларына ул С. Кәримов турында инде язылган, матбугатта басылган материалларны тәкъдим итә ала иде. Әйтик, Ә. Ерикәйнең 1943 елда ук язылган очеркын. Күренекле шагыйребез Әхмәт Ерикәйнең «Салават Кәримов» дигән ул язмасы бүген дә рәхәтләнеп укыла. Ул очерк белән танышканда, Советлар Союзы Герое Салават Кәримов безнең күз алдына ифрат колоритлы шәхес булып килеп баса. Бу яктан карагaнда, Ш. Рәкыйповныкы кайтышрак. «Утны безгә күчерегез» дигән очеркта төрле характердагы төгәлсезлекләр дә шактый очрый. Генерал Г. Сафиуллинның «Җиңү юллары буйлап» дигән мемуарлар китабы да 1962 елда ук басылды. С. Кәримов турында бу китапта да шактый күп материал бар. Димәк, Ш. Рәкыйпов һич кенә дә яңа герой ачучы булып санала алмый.

Моңарчы сүз Татарстаннан читтә чыккан китаплар хакында барды. Үзебездә басылган китапларга килгәндә дә, кызганычка каршы, шул ук нәрсә күзгә ташлана. Мәсьәләгә җитди карый белмибез, ачылган геройларны кабат ачу белән мавыгабыз. Советлар Союзы Герое Хатип Хәсәновны алыйк. Гали Хуҗиевның бу геройга багышланган очеркы беренче тапкыр «Ватан намусы өчен» дигән газетаның 1944 елгы 18 январь санында басыла. Шуннан аны башка фронт газеталары күчереп баса. Бу очерк 1945 елда чыккан «Батырлар китабы»на да кертелгән. Ниһаять, без аны 1946 елда Казанда чыккан «Җиңү юлы» исемле китапта да очратабыз. Һәм менә 1968 елда Ш. Рәкыйпов, тота да, Хатип Хәсәнов турында тагын бер очерк яза. Ике очеркны чагыштырып карагач, шул нәрсә күзгә ташлана: Ш. Рәкыйпов герой биографиясенә әллә ни яңалык өсти алмаган. Шулай булгач, аңа бер ачылган герой турында кабат язып торырга кирәк идеме икән? Мөгаен, кирәк булмагандыр.

З. Әхмәтҗановның югарыда телгә алган җыентыгында «Пулеметчы Хатип» дигән очерк бар. Ул болай башлана: «СССР Оборона министрлыгының архив документларында эзләнүләр вакытында без Татарстанда бүгенге көнгә кадәр аз билгеле булган Хатип Хәсәновның бүләкләү кәгазе белән таныштык». Күрәсез, Г. Хуҗилар, Ш. Рәкыйповлар ачкан геройны З. Әхмәтҗанов та ача, өченче тапкыр ача. Ачуын ача, тик герой биографиясенә яңалык өстәми. Аның «Пулеметчы Хатибы» Гали

Хужиев очеркының кыскача конспектын хәтерләтә. «Егерме өч елдан соң» дигән очеркны укыганда, Советлар Союзы Герое Габделәхәт Вәлиевне дә башлап З. Әхмәтҗанов ачкан икән дип уйларга мөмкин. Хәлбуки, алай ук түгел: Г. Вәлиевнең батырлыгына багышланган беренче мәкалә 1944 елда ук «Сталин байрагы» газетасында чыга. «Советская Татария» газетасындагы «Баллада о солдате» дигән мәкалә дә З. Әхмәтҗанов китабыннан күп алда басылган иде.

Зәки Әхмәтҗанов счерклары турында сүз чыккач, шул кадәресен дә әйтми узып булмый. Аның «Утлар-сулар аша» дигән китабында Г. Умеркин, З. Исхаков кебек батырларга багышланган очерклар бар. Бу геройларның һәр икесе хакында аңа кадәр Ш. Рәкыйпов язып чыкты. З. Әхмәтҗанов язган очеркларда әллә ни яңалык юк. Димәк, аңа яңа герой ачып торасы калмаган булган. Бу да эшкә җиңел карау бәласе.

Батырлар турында язу мактаулы эш, билгеле. Әмма шул ук вакытта ул бик четерекле һәм җаваплы эш тә. Без мәсьәләнең әнә шул ягын аңлап бетермибез шикелле.

Сүзне йомгаклап шуны әйтәсе килә: фронт газеталарында халкыбызның батыр улларына багышланган бай материал тупланган. Шуларны җыеп, бер җыентык чыгарасы иде. Бу, берьяктан, хәрби журналистларның һәм язучыларның зур хезмәтләрен хөрмәтләү булса, икенче яктан, яшүсмерләрне патриотик рухта тәрбияләү юлындагы файдалы бер эш булыр иде. Аннан соң бүгенге матбугатта еш очрый торган күңелсез фактлар да азая төшәр иде.

# ФРОНТТАШ ДУСТЫМ

*Рус язучылары татар әдәбияты турында*

Яшь шагыйрь сугышны илебезнең көнбатыш чигендә каршылый һәм Витебск, Смоленск, Ярцев тирәсендәге канлы бәрелешләрдә катнаша. Сугышларның берсендә, каты яраланып, госпитальгә эләгә. Госпитальдән чыккач, туган авылына кайта; колхозда эшли. Ләкин Ватаныбыз азатлыгы өчен рәхимсез көрәш барганда шагыйрь җаны тынычлана аламы соң! Озакламый Ш. Мөдәррис, врачларның киңәшләренә каршы килеп, үз теләге белән яңадан фронтка китә.

Шәрәф Хәсият улы Мөдәррисов 1919 елны ярлы крестьян семьясында Түбән Каракитә авылында дөньяга килә.

«Минем әнием әле бик яшь иде һәм, әлбәттә, аңа ике бала тәрбияләп үстерү җиңел булмады»,— дип яза ул соңыннан, үткән көннәрен искә алып.

Ш. Мөдәррис мәктәпкә йөри башлаганчы ук укырга-язарга өйрәнә. Әти кеше, семьясы янында яшәмәсә дә, балалар язмышы өчен һәр вакыт кайгырып, борчылып тора. Аларга китаплар, газета-журналлар җибәрә, аларның ничек укуы белән кызыксына. Чөнки ул үзе дә әдәбиятка гашыйк кеше була. Шигырьләр яза. Әмма ул аларны беркайда да бастыра алмый.

Әтисенең әнә шундый игелекле мөнәсәбәте тәэсирендә Шәрәф тә тирә-юнь белән бик иртә кызыксына башлый, белемгә омтыла. Башлангыч мәктәпне ул яхшы билгеләренә тәмамлый.

Шәрәф күңелендә иҗат дәрте бик иртә уяна. Сигез яше тулар-тулмас ул үзенең беренче шигырьләрен яза. Шигырьләр әле бик йомшак булсалар да, малай бөтен җаны-тәне белән шатлана, үзен чын шагыйрь итеп хис итә. Стена газетасы һәм үзешчән сәнгать түгәрәкләренә язган сатирик парчалары өчен кайчагында яшьтәшләреннән йодрык та эләккәли аңа.

Шәрәфкә унөч яшь тула. Аның беренче шигырьләре инде район газетасы битләрендә дә күренгәли башлый.

1935—36 елларда уздырылган «Уку ударнигы» газетасы конкурсында аның шигырьләре беренче урынны ала.

1937 елны Шәрәф Мөдәрриснең беренче шигырьләр җыентыгы басылып чыга. 17 яшьлек шагыйрь өчен бу, әлбәттә, куанычлы хәл!

Сугыш башлангач, ут сызыгына якын ук торган килеш, ул бик күп шигырьләр, поэмалар, очерклар, хикәяләр, мәкаләләр язып өлгерә. Солдат тормышы, сугыштагы батырлык, Ватанга мәхәббәт — авыр, утлы елларда Ш. Мөдәрриснең иҗат кредосын әнә шундый мотивлар билгели.

Без Шәрәф Мөдәррис белән 1956 елны таныштык һәм беренче сүздән үк күкрәп узган сугыш турында, утлар-сулар кичеп, бөек җиңүләргә барган шагыйрьләр турында сөйләшеп киттек.

Кызу канлы, тиз кабынып китүчән кеше булуга карамастан, бер-беребезгә бик тиз ияләштек һәм дуслашып та өлгердек.

1957 елны Казанда басылып чыккан «Яшәү хакына» дигән китапның йомгак өлешендә мондый сүзләр бар: «Соңгы елларда Ш. Мөдәррис укучыны чын-чынлап дулкынландырырлык әсәрләр иҗат итте. Бу әсәрләр хәзерге татар поэзиясендә бик хаклы рәвештә мактаулы урын алып тора».

Кызганычка каршы, әлегә рус укучысы бу искиткеч үзенчәлекле татар шагыйрен аз белә. Әле күптән түгел генә мин Татарстанда булдым. Бу юлы Казанга «Через пепел дней» дигән шигырьләр җыентыгының тәрҗемәсен эшләп бетерү нияте белән килгән идем.

Шәрәф Мөдәррис 1963 елны вафат булды. Аннан соң инде 10 ел гомер узган.

Элекке каләмдәшләре, шәкертләре шагыйрьгә карата нинди мөнәсәбәттә соң? Ш. Мөдәррисне күреп белмәгән, әле әдәбият мәйданына яңа гына аяк баскан яшь буын шагыйрьләре аның турында нинди фикердә?

Татарстанның өлкән шагыйрьләреннән берсе Сибгат Хәким Шәрәф Мөдәррис турында болай диде:

«Ул поэзиягә атлап түгел, метеор кебек атылып килеп керде. Аның табигать биргән үзенчәлекле таланты бик тиз күзгә ташлана иде... Ул лириканы, сатираны, публицистиканы бергә үреп бирә белә һәм нәтиҗәдә әсәр гаҗәп үткен, тапкыр, Мөдәррисчә ачык һәм аңлаешлы килеп чыга...

Шәрәф Мөдәррис — Муса Җәлилнең иҗаты үсеп, тәмам ныгып җиткән чорда формалашкан шагыйрьләрнең берсе. Ул чагында Муса Җәлил Мәскәүдә «Октябрь баласы» дигән журнал чыгара. Нәкъ менә шушы журнал тирәсенә Шәрәф Мөдәррис, Гали Хуҗиев, Җәүдәт Тәрҗеманов кебек сәләтле яшь әдипләр туплана да инде. Шәрәф Мөдәррис үзенең иҗат юлын шушы журналдан (балалар өчен шигырьләр язып) башлый. Хәер, ул соңыннан, фронтлардан әйләнеп кайткач, ягъни күренекле фронтовик-шагыйрь булып танылгач та, берсеннән-берсе гүзәл әсәрләре белән балаларны еш куандырды.

Поэзиясенең характеры буенча Ш. Мөдәррис татар классиклары традициясендә генә тәрбияләнмәде. Ул рус поэзиясен тирәнтен һәм җентекле өйрәнде, исемнәре бөтен дөньяга билгеле булган чит ил шагыйрьләре иҗатына искиткеч дөрес һәм төгәл бәя бирде. Ул гарәпчәдән турыдан-туры тәрҗемә итә, немец телен яхшы белә һәм немецчадан татарчага тәрҗемә итә иде.

Шулай ук ул инглиз телен ныгытып өйрәнде. Шекспир сонетларын тәрҗемә итүгә күп көч сарыф итте.

Бу тәрҗемәләр талантлы каләм иясенең зур һәм фидакарь хезмәте буларак кына түгел, акыл һәм илһам кушуы буенча эшләнгән эшнең нинди күркәм, куанычлы нәтиҗәләргә китерүен күрсәтүче бер мисал буларак та татар әдәбияты тарихында күренекле урын алды.

Ш. Мөдәррискә чит телләр гаҗәеп тиз бирелде, ул үзенә таныш булмаган нинди дә булса телне берничә ай эчендә өйрәнә ала иде.

Шәрәф Мөдәррис, шигырь төзелешен, гомумән, әдәбият теориясен яхшы белүче әдип буларак, әдәбият теориясе проблемаларына багышлап мәкаләләр язды, конференцияләрдә докладлар белән чыкты һәм һәр вакыт нинди дә булса яңалыкны, үсеп килә торган прогрессив фикерне алга сөрде. Шуңа күрә аның мәкаләләре, докладлары еш кына зур бәхәсләр кузгата торган иде.

Ш. Мөдәррис журналист буларак та тынгысыз кеше иде. Ул һич тә уйламаганда җәһәннәм артындагы берәр авылга китә дә, таныш булмаган тормышка тиз генә җайлашып, моңарчы күрмәгән-белмәгән кешеләр белән тиз генә танышып-сөйләшеп, әһәмиятле фактлар җыя һәм редакциягә кеше кичерешләренә, тормышчан эпизодларга корылган очерк язып кайта...

Ш. Мөдәррис кешелек бәхете өчен теләсә нинди авырлыкларга әзер торучы интернациональ шагыйрь иде. Аның гомере иҗатының чәчәк аткан чорында өзелде»...

Ә менә яшь шагыйрь Ренат Харис фикере.

«Кайчагында без, яшь шагыйрьләр, бергә җыелабыз да әдәбиятыбызның үткәне һәм бүгенгесе турында сөйләшәбез. Күп әсәрләр, күп исемнәр, шулар арасында

Ш. Мәдәррис исеме дә телгә алына. Башка әдипләрдән Ш. Мәдәррис нәрсәсе белән аерылып тора соң? Аның иҗатына, иҗат методына әле үсеп кенә килә торган яшь шагыйрьләр буынының көннән-көн якынрак килүе, көннән-көн ныграк тартылуы беләндер, мөгаен. Ул үз заманы өчен кискенрәк кеше булган. Кайберәүләр аны аңлап та җиткермәгәннәр. Ә без аны аңладык, яраттык һәм яратабыз. Талантлы шагыйрь булганы өчен генә түгел, хезмәтне яратуы, эрудицияле булуы, татар теленең бөтен нечкәлекләренә төшенеп иҗат итүе, чит әдәбиятларга, чит телләргә зур хөрмәт белән каравы, чит телләрне өйрәнүе, тәрҗемә өлкәсендә ат кебек эшләве өчен дә яратабыз без аны.

Шәрәф Мәдәррис безнең өчен талант һәм хезмәт, ирлек һәм гражданлык үрнәге».

Яшь шагыйрьләр Ш. Мәдәррис турында әнә шулай диләр.

Әсәрләре халык күңелендә онытылмаслык урын алган татар шагыйренең танышы һәм дусты булуым белән мин үземне бик бәхетле саныйм.

«Через пепел дней» дигән китап шушы елның азагында Мәскәүдә «Художественная литература» нәшриятында басылып чыгарга тиеш. Мин шагыйрьнең күп кенә шигырьләрен һәм поэмаларын үзе исән чакта ук тәрҗемә иткән идем инде.

Әлеге китапка кереш сүзне мин яздым. Форматын үзем сайладым. Мин аның тышлыгын әзерләдем, титул битен бизәдем, рәсемнәрен ясадым.

Безнең арабыздан бик иртә киткән талантлы татар шагыйренә, дустыма зур булмаса да матур истәлек булсын ул китап!

**ВИКТОР ГОНЧАРОВ.**

# КӨРӘШЧЕ ГЕРОЙНЫ ЯКЛАП

Гариф Ахуновның «Зәңгәр чәчәк — гашыйклар төсе» дигән китабына нигездә соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре тупланган. Җыентык «Чикләвек төше» исемле повесть белән ачыла.

Авторның бу повестен киң катлау укучылар массасы да, әдәби җәмәгатьчелек тә җылы каршылады. Газета-журналлар битендә күп кенә мәкаләләр һәм рецензияләр басылып чыкты. Әсәр соңгы еллар прозасының мөһим бер казанышы дип бәяләнде һәм хаклы рәвештә олы бүләккә — Г. Тукай исемендәге премиягә лаек дип табылды.

Минемчә, «Чикләвек төше» повестеның төп әһәмияте яңа чорның романтик героен иҗат итүендә, шушы өлкәдәге иң яхшы традицияләрне уңышлы дәвам иттерүендә. Романтиканың да төрлесе була, билгеле. Бар рыцарьлык романтикасы, революцион көрәш романтикасы, бар мәхәббәт романтикасы... Бирелә исә социалистик җәмгыятьне ныгыту өчен көрәшүче геройның романтик характеры тасвирлана. Халикъ Саматов — әлеге көрәшнең бөеклеген, изгелеген гәүдәләндерүче образ.

Әсәр баштан ахырга кадәр шул образның тормыш һәм көрәш юлын сурәтләүгә багышланган. Башка персонажлар исә повестька төп образның язмышына бәйләнешле рәвештә генә килеп керәләр. Дөрес, автор Халикъ Саматов тормышына бәйле вакыйгаларның да һәммәсенә бертигез дәрәҗәдә тукталмый, ул үз героеның тормыш юлыннан аның характерын ачарлык иң киеренке моментларын гына сайлап ала. Шуңа күрә Саматовның тормыш юлы безнең күз алдына киеренке бәрелешләр тезмәсе рәвешендә килеп баса, һәм бу хәл бөтен әсәр сюжетына үзенә бер төрле киеренкелек бирә, аны мавыктыргыч итә.

Мөстәкыйль рәвештә дөнья күтә башлаган еллардагы тәүге адымнарыннан ук автор аны тормышның каты сынаулары алдына китереп куя. 18 яшьлек егет үз язмышын партия белән бәйли. Бөек Ватан сугышының беренче көненнән үк үзе теләп фронтка китә. Каты яралана. Госпитальдән чыккач та әле, өйгә кайту ягын карамый, җиң сызганып артиллеристлар әзерләү эшенә керешә. Болары — повесть башланганчы үтелгән юл. Әсәргә ул күренешләр геройның искә төшерүе рәвешендә килеп керә.

1948 елда демобилизацияләнеп Казанга кайткач, партия райкомы аңа МВД органнарын ныгыту эшенә керешергә тәкъдим итә. Шулай итеп, Халикъ Саматов милиция органнарында эшли башлый. Сөйгән кызы аннан:

— Ә сез нигә... милициягә кердегез? — дип сорагач, ул өзеп кенә:

— Тәртип урнаштырыр өчен... (8 бит) — ди. һәм әсәрдәге вакыйгалар барышында без бу сүзгә тирән мәгънә салынганлыгын аңлыйбыз. Партия кая гына куймасын, ул һәр җирдә бөтен сәләтен һәм көчен куеп, барлык талантын җигеп эшли. һәм нинди генә урында эшләмәсен, ул һәр вакыт нык-лы, принципиаль коммунист булып кала. Әмма тәртип урнаштыру, кимчелекләрне бетерү, эшне коммунист намусы кушканча оештыру җиңел генә бармый, билгеле. Моның өчен коры тәвәккәллек кенә җитми, характер ныклыгы, ихтыяр көче дә сорала. Халикъ Саматовта тегесе дә, монысы да җитәрлек. Сез аның берьюлы ике җирдә — югары хуҗалык мәктәбендә һәм юридик институтта укып йөргән чагындагы тиңсез тырышлыгын гына искә төшерегез:

берсеннән имтихан биреп чыга да икенчесенә йөгерә. «Чыкмаган җаны да ишелмәгән сөяге генә» (26 бит) торып калган. Алга таба нинди генә җирләрдә эшләми ул: Идел — Балтик каналы төзелешендә кадрлар бүлеге начальнигы, Әлмәттә һөнәр мәктәпләре башлыгы, төрмәдә политик-тәрбия эше начальнигы... һәм һәркайда тәртип урнаштырып йөри.

Повестьта Халикъның колхоз авылын тагын да үстерү, ныгыту юлындагы эшләрен сурәтләүгә чагыштырмача күбрәк урын бирелгән. Бу очраклы хәл түгел, әлбәттә. Авыл хуҗалыгы — көрәшнең алгы сызыгы, партия иң күп кайгырткан, күп көч салган катлаулы өлкә. Бу игътибар соңгы егерме ел эчендә аеруча ачык күренде. Татар әдәбиятында, табигый, бу зур теманың аерым якларын алып сурәтләгән байтак әсәрләр иҗат ителде (А. Расихның «Язгы авазлар» романы, Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым», В. Нуруллинның «Күпер чыкканда» повестьлары һ. б.). Боларның һәммәсендә дә партия кузгаткан яңа рух, XX съезд рухы чагыла. Гариф Ахуновның Халигы да көрәш юнәлешен съезд карарларыннан ала. Биредә аның тагын бер яңа сыйфаты — җиргә, игенче хезмәтенә булган мәхәббәте ачылып китә. Дөрес, баштарак бу эшендә дә күп төрле кыенлыклар күрергә туры килә аңа. Колхозның экономикасы да, колхозчыларның материаль хәле дә ифрат начар була. Авыл кешеләре арасыннан аңа аяк чалучылар, хәтта каршы чыгучылар табыла. Ләкин Халикъ Саматов каушапюгалып калмый. Явыз ниятле бәндәләргә, колхоз милкенә кул сузучыларга карата каты чаралар куллану белән бергә, ул колхозчыларның күңелен күрүне дә истән чыгармый. Аңарда таләпчәнлек белән хөрмәт бергә яши. Иң әүвәл ул колхозның экономикасын ныгыту, колхозчыларның материаль хәлен яхшыртуны үзенә бурыч итеп куя. Ул артель хуҗалыгын тиз арада тернәкләндереп җибәрердәй доходлы статьялар таба, табыш бирердәй культуралар (җитен, клевер һ. б.) чәчтерә, олы, изге максат хакына кыю тәвәккәллекләргә бара, моңа кадәр хәл ителүне көтеп тә хәл ителмичә яткан мәсьәләләрне күтәреп чыгып конфликт тудыра, шул юлда үзен шактый кыен, катлаулы хәлләргә китереп куя. Һәм нәкъ менә шул урыннарда — колхозны һәм колхозчыларның тормышын рәтләү өчен көрәш дәвамында Халикъ Саматов характеры аеруча ачылып китә, аның гражданлык активлыгы күренә. Безнең алга ул Корчагиннар, Давыдовлар, Фәхриләр, Нәфисәләр юлын дәвам иттерүче көрәшче герой булып килеп баса.

Без биредә, әлбәттә, колхоз тормышындагы кыенлыкларны беренче булып Гариф Ахунов күтәреп чыкты, дип расларга җыенмыйбыз. Аларның хәл ителешен тормышта да, әдәбиятта да күргән идек инде. Ләкин бер нәрсә бәхәссез: автор үзенең игътибарын чорның актуаль мәсьәләләренә юнәлтә, героеның характерын иҗтимагый эчтәлекле киеренке көрәш ситуацияләре эчендә ача. Нәтиҗәдә повесть бик җитди иҗтимагый яңгыраш ала.

Бер карaганда, Халикъның шушы юнәлештәге эш-гамәлләрен, көрәш-бәрелешләрен әсәрдә әллә никадәр дәвам иттереп булыр һәм дәвам иттергән саен образ ныграк яктыра барыр төсле. Ләкин автор повестен шушы ноктада тәгаллн. Чөнки нәкъ шушы урында әсәрнең буеннан-буена сузылып килгән, әмма аның сәнгатьчә тукымасында артык чекерәеп, күзгә бәрелеп тормаган бик мөһим бер конфликт хәл ителә, дәвамлы ситуация чишелә. Һәм шушы нәрсә әсәргә тәгалләнгәнлек, бөтенлек бирә. Хикмәт шунда: әсәр сюжетында Халикъ Саматов язмышы икенче бер геройның конфликтлы мөнәсәбәте фонында, шуның бәясе, мөнәсәбәте белән үреп бирелә. Һәм шушы мөнәсәбәт әсәрдәге күренешләрне гүя ки элмәкләп ала. «Чикләвек төше» автор исеменнән түгел, персонаж теленнән хикәя ителә (мондый форма, роман жанрына караганда, повесть, хикәядә ешрак очрый). Ә хикәяләүче герой Рокыя — Халикъ Саматовка контрастлы мөнәсәбәте белән генә түгел, язмышы белән дә бәйләнгән кеше. Ул аның тормыш иптәше. Әмма бергә торсалар да, Рокыя озак вакытлар иренең карашларын уртаклашмый.

Рокыяның әтисе «Гыйбадулла — вак сәүдәгәр. НЭП заманында үз йортында кибет тоткан. Сәүдәгәрлек аның канына сеңгән» (18 бит). Ә вакыйга барган дәвердә мехо-войда эшли, тире кыйпылчыклары алып кайтып, бүрек тегә. Шактый иркен яши. Әсәрдә ул яши белүче, тормыш рәтен ярыйсы ук тирән төшенгән кеше итеп бирелә. Телендә еш очрый торган халык гыйбарәләре аның практик акылын, психологиясен һәм фикер сөрешен шактый ачык төсмерләргә мөмкинлек бирә. «Сәлам ялгыз казыкка түгел, парлы казыкка эләгеп кала» (4 бит), — ди ул булачак кияве Гапсаматка. Партия өлкә комитеты-

на барырга җыенучы кызына болай ди: «Бәк әллә ни чәпчемә, чи-чи килмә, иплэп кенә, җаен-җайга китереп кенә сөйлә, галимнәр утыра анда, башлы халык, синең белән мин белгәнне киртәгә чыгарып элгән»... (35 бит).

Рокыя әнә шул ата кулында тәрбияләнә. Төскә-биткә чибәр, буйга зифа була. Артык михнәт чикмичә үсә, шактый хәлле семьяда бердәнбер кыз булып үсә. Аның күңеленә дә менә шушы тормышның кайбер начар яклары йогып кала. Бергә тора башлагач, карашлардагы аерымлык конфликт чыганагына әйләнеп китә. Елга тамагында ике елганың суы озак кына кушыла алмый аккан шикелле, Халикъның коллективизм карашлары белән Рокыяның индивидуалистик карашлары контраст тудырып бара. Халикъның мөһим иҗтимагый эшләрен Рокыя тик шәхси тормыш, семья күзлегеннән карап кына бәяли, бу бәя белән зур эшләр ярашмагач, иренең омтылышларына (укуына, кимчелекләрне бетерү юлындагы көрәшләренә) каршы килә. Карашлар аерымлыгы, шулай итеп, реаль конфликтка әйләнә. Халикъка эшендә очраган җитешсезлекләргә генә түгел, хатынының тар караш-мөнәсәбәтләренә каршы да көрәшергә туры килә.

Татар әдәбияты өчен бу тема бөтенләй үк яңа түгел, әлбәттә. Әмирхан Еникинең «Саз чәчәге» повестенда да коммунистик принципиальлек белән обыватель-мещанлык стихиясе бәрелешкә керә. Идият Байгузин, Майпәрвaз, чибәр Наҗия кебекләр, оста хәрәкәт итеп, райком секретаре Шакир Мостафинны үз якларына аударалар. Автор Мостафинның үз позицияләрен бирен, обыватель рәхәтләкләрен кабул итә баруын сазга бату күренешенә тиңли. Мостафинга сазның суыру көченә каршы торырлык характер ныклыгы һәм коммунист принципиальлеге җитешми. Автор моны гаепли һәм коммунистик идеал яктылыгыннан карап каты тәнкыйть итә. «Чикләвек төше»ндә шул ук ситуация башкача хәл ителә. Биредә дә Халикъка йогынты ясарга тырышу, аны дөнья рәхәтләкләре белән алдарга омтылу аз булмый. Рокыя аңа, мәсәлән, зур универмагта коммерческий директор урынын табып бирә. «Менә дигән хезмәт хакы, почеты-даны, менә дигән машинасы булачак... Гыйбадулла кызы Рокыя да бер лимузинга утырып йөреп карасын әле!» (33 бит).

Ләкин мещаннарның сыналган методы Халикъ Саматовка карата көчсез булып кала. Киресенчә, бу бәрелештә Халикъ ягы куәтләрәк булып чыга. Үзенең дөрес тормышы, янып яшәве, изге омтылышлары, караш-принципларының ныклыгы белән Халикъ үзе Рокыяга йогынты ясый, аңарга индивидуалистик карашларыннан арынырга булыша. Рокыя аның принципларын кабул итә, ул принципларның бөеклеген таный. Хаксыз рәвештә Халикъны колхоз председательлегеннән алгач, элеккечә, шөкер, бу тынгысыз эштән дә котылдык, дип кул кушырып утырмый. Халикъның хаклыгын даулап, өлкә комитетына бара, колхозчылар белән бергә ул да зур хакыйкатьнең җиңеп чыгуына ярдәм итә.

Караш-принциплар көрәше, психологик эволюция үзе генә дә әсәр сюжетын киеренке-мавыктыргыч итүдә мөһим роль уйный. Моңардан тыш әле аның эстетик йогынты җәһәтеннән дә зур әһәмияте бар. Әдәбият практикасында гадәттә тискәре геройлар исеменнән хикәяләү очрамый. Вакыйга-күренешләр күбесенчә уңай персонаж карашы белән яктыртыла. Биредә исә баш герой язмышына бәйле вакыйгалар тискәре герой исеменнән хикәя ителә. Халикъ яхшы дип тапкан эш-гамәлләр хикәяләүче тарафыннан сантыйлык дип бәяләнә. Яктылык, шулай итеп, караңгы фонда бирелә һәм ул фонда тагын да ачыграк күренә.

Мәсьәләнең тагын психологик ягы да бар. Даими киеренкелек, Халикъның һәр кимчелеккә каршы аяусыз көрәшүе, карашлар уртак булган хәлдә дә, Рокыяда тирән кичерешләр тудырмый калмас иде. Көрәштә бит гел җиңү генә түгел, җиңелү ихтималы да бар. Рокыя үз язмышы, өч баласы язмышы хакында уйлана, уйланмый кала алмый. Карашлар контрасты исә кичерешләрнең кызулыгын тагын да ныграк арттыра төшә.

Аннары автор мещан карашлы кызны һич тә алай бер генә яклы итеп, кешелек сыйфатларыннан мәхрүм итеп күрсәтү юлына басмый. Киресенчә, Рокыя безнең күз алдына сизгер күңелле һәм күзәтүчән кыз булып килеп баса. Бу яктан аның мәхәббәт хисләре игътибарга лаеклы. Рокыя үз мәхәббәтенә, Әмирхан Еникинең Зөһрәсе кебек, яратмау аркылы килә. Әти-әниләре аны Гапсамат дигән егеткә ярәшәләр. Ләкин Рокыя аны яратып китә алмый. Әмма шул ук вакытта утырып калу ихтималы да уйландыра аны. «Гапсаматның кай төше кемнән ким? Кулында һөнәре бар, мал кадерен белә торган холкы бар. Ярый,

дорфарак та булсын, ди, юнылмаган бу-кән булсын, ди. Аннан кемгә зыян?.. Мин, ун класс укыган кыз, Гапсаматны тәрбия-ли алмаммыни? Аны дорфа кыланышларын-нан арындыра алмаммыни?» (11 бит) дип фикер йөртә ул.

Кызның Халикъ Саматовка мөнәсәбәте шулай ук төрле чакта төрле юнәлеш алып китә. Болай ул аны, озын зифа буйлы, же-те зәңгәр күзле яшь лейтенантны, баш-тан ук ярата. Ләкин шул ук мәлдә мили-ция лейтенантының «тәртип урнаштыру» нияте аны өркетә, ул егеткә кимсетүле дорфа сүз әйтеп ташлый.

Шул ук вакытта Рокыя Халикъ йөрәген-дә дә капма-каршы тойгылар кисешүен шактый төгәл чамалый. Алар шактый уңай-сыз шартларда очрашалар. Кызның ярә-шелгән кияве Гапсамат кулга алына. Ә Халикъ, кызны яратып йөрүче лейтенант, шуның хакында Рокыядан сорау алырга мәҗбүр. Кыз Халикъның намуслы, тактлы булуын күрмичә кала алмый. «Юк, ул миннән уч алмый, аның хәле минекеннән авыррак,— дип уйлый Рокыя.— Ул мине яратканы хәлдә, мине авыр тойгыларга салырга һәм мин бигүк өнәп бетермәгән интим мәсьәләләргә дә кагылырга мәҗбүр иде... Ул кәгазь өстенә иелеп, шатыр-шо-тыр яза башлый, озаклап, ярсынып яза, каләм сабы тоткан бармаклары артык кысудан агарып китәләр» (16 бит).

Капма-каршы хисләр бәрелеше каләм сабын кысып тоткан һәм агарып киткән бармакларга күчәләр — рухи халәт тышкы детальләр аркылы белдерелә. Күзәтүчән кешегә алар күп нәрсә турында сөйлиләр.

Инде Халикъ Саматовның теленә килсәк, без аның сөйләмендә иң әүвәл тирәндәге, күңел түрендәге олы тойгыларны аңлатыр-дай ягымлы авазлар ишетәбез.

«...Күрше Хәерниса түтәйләрнең урыс капкасыннан ялт итеп килеп чыга да ми-нем дә көянтә-чиләк күтәреп капкадан килеп чыкканымны үтә сокланып каршы ала.

— Исәнме, күрше, суга барасыңмыни?!— дип, бик тә үз иткән ягымлы тавыш белән дәшеп кала» (5 бит),— дип хикәяли аның турында Рокыя.

Икенчедән, Халикъ теленә үз эшенең дәреслегенә бик ышанган кешеләрдә була торган ачыклык, җыйнаклык, конкретлык хас. Без инде аның ни өчен милиция орган-нарында эшләгәнлеген белеп киткән идек. Колхозчыларга аванс бүлүдә электән урна-шып килгән тәртипне үзгәрткән өчен, аны райком бюросында тикшерәләр.

«— Я, турама бәгыремне, әйт, ни бул-ды?— дидем, аш җылытып китерергә дә онытып, төпченә башладым.

— Колхозчы икмәкле, мин... «строгачлы» булдым,— диде тыныч тавыш белән һәм әз генә елмаеп та куйды, әйтерсең аңа яхшы эшләгәне өчен бүләк биргәннәр» (45 бит).

Колхоз председательлегеннән төшерү турындагы хәбәрне дә Халикъ бик сабыр, җыйнак сөйли. «Халикъ теләр-теләмәс кенә әйтте. Бюро булган. Аны председательлек-тән алалар икән. Бар сөйләгәне шул бул-ды. Мин бик ялыкгач, тагын ике сүз өстәде: «Дөбердәтеп алырбыз!» — диган-нәр» (54 бит).

Теленең җыйнаклыгы, җегәрлекле, образ-лы, эмоциональ төсмерле булуы, һичшик-сез, уңай күренеш. Биредә һәр сурәт ча-расы зур эстетик функция башкарып килә, образны ачык итеп күз алдына китерергә, сюжет киеренкелеген арттырырга ярдәм итә. Башкача әйткәндә, әсәрдә сурәтләнгән мөһим иҗтимагый күренешләр дә, дина-мик сюжет та, эстетик тәэсирле тел-сурәт-ләү чаралары да бер максатка — образны мәһабәт, калку итеп сурәтләүгә, теманы образлы рәвештә ачуга хезмәт итә. Әгәр дә повестьта сүзгә саранлык белән сюжет мавыктыручанлыгы һәм характер ачыклыгы бергә кушылган икән, бу — автор әсәр стиленең ачкычын таба белгән, дигән сүз.

Озынлык-кыскалык, җыйнак яки тәфсил-ле сурәтләү мәсьәләсе — чама хисен аеру-ча төгәл тоюны сорый торган мәсьәлә. Художество әсәрендә детальләр укучыны ялыктырырлык та булмаска, шул ук вакыт-та тормышны схемалаштырмыйча тулы канлы итеп сурәтләү өчен җитәрлек тә булырга тиеш. «Чикләвек төше»н укыганда әлеге җыйнак һәм тәфсилле тасвир мәсьә-ләсендә каршылыклы хисләр дә кузгалып куйгалый, ягъни теленең эчке киеренкеле-генә соклану белән беррәттән, картиналар-ның җентеклерәк, детальлерәк, тәфсил-лерәк яктыртылуын да күрәсе килә. Болай иткәндә, киеренке вакыйгаларның аерым буыннары арасына ит куна төшәр иде, исеме генә әйтелеп кителгән кайбер күре-нешләр укучы күз алдына үзләренең реаль сурәтләре белән килеп басар иде. Югыйсә, кайбер урыннарда эскизлык, ашы-гычлык эзе сизелгәндәй булып кала. Ав-тор үзе сурәтләгән чынбарлыкның аерым өлкәләрен әллә бөтен нечкәлекләре белән белеп җиткерми микән дигән шик тә туып куя. Ләкин бу уңайдан тагын бер сорау

туа. Әсәрдә тасвирланган тормышны тагын да детальләрәк күрәсе килү — нәрсә бу? Повестьның кимчелеген раслаучы фактормы, әллә киресенчә ягын исбатлаучы дәлилме? Бу сорауга кистереп бер генә яклы җавап бирү дә мөмкин түгел.

Гомум планда алганда, укыган чакта үк китапның ялыктыра башлавына карагандa, укып чыккач та игътибарны тартып торуы, әлбәттә, әйбәтрәк. Һәрхәлдә, бу мәсьәләдә тәнкыйтькә уйланырлык нәрсәләр бар. Әдәбият тарихында тормыш картиналарын җыйнак, җегәрлекле итеп сурәтләгән әсәрләр дә, детальләп, тәфсилләп яктыртканнары да очрый.

Инде килеп хикәяләүче теле турында берничә сүз. Гадәттә хикәяләүче теле персонаж сөйләме белән автор теле арасында уртадарак тора торган күренеш. Ягъни бу тел хикәяләүче персонажның характерына яраклаштырып индивидуальләштерелә дә образлы тасвир өчен кирәк булган дәрәҗәдә автор теле мөмкинлекләрен дә үзенә җыя. Рокыя хикәяләвендә без тегесен дә, монысын да күрәбез. Ул үзенең караш-фикерләрен, уй-хыялларын, кимчелекләрен, иренә хаксызга бәйләнеп баруларын, юлына аркылы төшүләрен яшермичә, тартынмыйча сөйли.

Хикәяләүче телендә герой күңелендәге психологик эволюция дә шактый ачык төсмерләнә. Әсәрнең ахырына табарак Рокыя болайрак сөйли: «Ир бирмәк — җан бирмәк, ди, мин дә җиң сызганып тотындым, киптергән ашлыкны чүтлап кабул итәм» (53 бит). Бу сүзләрдән гомер буе иреннән аерылам дип яшәгән хатынның, ахыр килеп, шул иренең дә, эшенең дә үтә якын, кадерле икәнен аңлаганын сизү кыен түгел.

...Шулай итеп, әсәрдә, башлыча, үзәк герой Халикъ Саматов язмышына бәйләнешле хәл-вакыйгалар, чикләнгән сандагы персонажлар тасвирлана, чынбарлыкның чагыштырмача таррак бер өлкәсе дәвамлы хәрәкәттә бирелә. Автор биредә социалистик җәмгыятьнең соклангыч сыйфатларга ия булган кешесен, киң карашлы, дәүләт күләмендә фикер йөртүче коммунистны, саф күңелле көрәшчене, героик-романтик характерны тасвирлаган. Мондый типны тудыру — һәр язучының изге омтылышы. Гариф Ахунов әсәрендә ул омтылыш реальлеккә әйләнгән, әдәби яктан уңышлы хәл ителгән. Хикәяләүче образы да үзенең оригинальлеге, яңалыгы белән аерылып тора.

* * *

Китапка кергән хикәя, очерклар төрле темага карый, аларның төрлесе төрле характерда язылган. Биредә «гомерлек буйдак булып калырга, кызларның хыянәтчел кармагына беркайчан да капмаска, гомумән, кыз-кыркыннан ерак йөрергә» ант иткән штукатур егетнең күңелендә яңа хисләр бөреләнүен сурәтләгән «Зәңгәр чәчәк — гашыйклар төсе» хикәясе дә, билгеле бер тормыш ситуацияләрендә кеше характерының, холкының аерым сыйфатларын яктырткан «Фатих малае», «Сабыр табигатьле Сабирҗан» хикәяләре дә, Әгерҗе яклары, андагы хезмәт кешеләре турында язылган очерклар да бар. Ләкин, шундый төрлелек булган хәлдә дә, күпчелек хикәяләрне һәм очеркларны берләштерә торган бер уртак проблеманы да күрми үтү мөмкин түгел. Ул — сәнгать һәм хезмәт мәсьәләсе, ягъни сәнгатьнең безнең тормыштагы урыны, чынбарлыкка мөнәсәбәте мәсьәләсе. Хикәя, очерклар шушы зур һәм катлаулы теманың аерым якларын алып сурәтлиләр. «Ут эченнән чыкканда» хикәясендә, мәсәлән, режиссер Камил Фәттаховның үз кул астындагы театрны сугыш эченнән алып чыгу мәшәкатьләре тасвирлана. Әсәр шуңа күрә «Ут эченнән чыкканда» дип аталган да. «Соңарып килгән бәхет» хикәясе балетмейстер Сөбханкуловның нефть якларында, эшчеләр арасында илһам алуы турында сөйли.

Очеркларның да кайберләре сәнгать тормышын яктырталар. «Башкалада очрашулар» дигән очеркларда, мәсәлән, 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы, 1964 елда уздырылган татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы турында яза автор. Очеркларның һәммәсе дә җыйнак һәм, Г. Ахунов каләменә хас булганча, җанлы, образлы тел белән язылганнар.

Гомумән китапка кергән барлык әсәрләр, бигрәк тә «Чикләвек төше» повесте кызыксынып укырлык, гыйбрәтле-мәгънәле итеп язылган.

**ФӘРИТ ХАТИПОВ,**
**филология фәннәре кандидаты, доцент.**

# БЫЛБЫЛ ХӘБИР ЧИШМӘСЕ

Татар авылларының берсендә күп еллар элек, әле революциягә кадәр үк, бер егет яшәгән. Батыр йөрәкле, таза, матур сынлы, шук табигатьле, шул ук вакытта нечкә күңелле, моңлы егет булган ул. Сандугач булып бик оста сайраган, шуңа күрә авылдашлары аңа Былбыл Хәбир дигән кушамат биргәннәр.

Гражданнар сугышы елларында ул легендар Чапаев дивизиясенә эләккән, Колчак бандаларына каршы көрәшеп йөргән һәм шунда һәлак булган. Аннан бирле күп гомер үткән, күп сулар аккан. Кем белә, башка берәр кеше булса, күптән оныткан да булырлар иде. Ә Былбыл Хәбирне онытмыйлар. Ник дисәң, бөтен авыл Былбыл Хәбир чишмәсеннән су эчә. Заманында бу чишмәне ул үзе эзләп таба, төбен чистартып, тирәли казыклар кага, читән үрә, ике такта сузып улагын куя. Кеше үзе күптән юк, ә менә чишмәсе калган. Иртә җиттеме, авылның сылу кызлары, яшь киленнәре Былбыл Хәбир чишмәсеннән саф көмештәй салкын су ташыйлар.

Шушы бәләкәй генә хикәя Мәҗит Рафиков җыентыгының[1] бөтен яңгырашын, төп үзенчәлеген билгели. Аның хикәяләренең нигезендә шаккатарлык сюжет та, үткен проблемалар һәм матур тасвирлар да түгел, ә нәкъ менә хис, тойгы ята. Аның барлык хикәяләре, шулай ук «Илһам авазы» исемле повесте да эчке моңнары, музыкаль яңгырашлары белән хәтердә кала. Бер сүз белән әйткәндә, алар — чын мәгънәсендә лирик проза үрнәкләре.

Татар әдәбиятында лирик прозаның күптәннән килә торган бай традициясе бар. Бу төр әдәбиятның беренче үрнәкләре кайчандыр бездә бик популяр булган кечкенә-кечкенә нәсерләргә барып тоташа. Бүгенге яшь прозаиклар да бу жанрга шактый еш мөрәҗәгать итәләр. Әмма, никадәр генә җиңел күренмәсен, асылда ул — шактый авыр һәм хәтәр жанр. Лирик проза жанрына мөрәҗәгать иткән язучыны лиризмнан төчелеккә, фәлсәфи уйланулардан коры акыл сатуга, табигать күренешләрен тасвирлаудан арзан купшылыкка тәгәрү куркынычы сагалый.

М. Рафиков, бәхеткә каршы, алардан котыла алган. Аның хикәяләре буш хыялларга, коры фантазиягә түгел, ә реаль тормыш фактларына нигезләнгән. Асылда алар — ярым документаль әсәрләр. Менә авторның авылдашы Рәхмәтулла абзый («Рәхмич» исемле хикәя). Беренче карашка, гомере буе саулыкка туймаган, бөтен барлыгы, торышы-кыяфәте белән сыек кына, сырхау гына бер карт. Баксаң, читтән караганда гади генә, тыйнак кына күренгән шушы кеше батыр йөрәкле, курку белмәс солдат булган икән. Авторның Рәхмәтулла картка булган соклануы торабара безгә дә күчә. Шушы бәләкәй генә хикәя безнең әдәбиятны тагын бер үзенчәлекле милли характер, гыйбрәтле язмышлы әдәби герой белән баета. Чөнки автор тормыштагы реаль бер фактны сәнгатьчә гомумиләштерү югарылыгына күтәрелә алган.

М. Рафиков акрын яза, чагыштырмача сирәк басыла. Күрәсең, шуңа күрәдер, безнең тәнкыйть аның иҗаты хакында дәшми килде. Хәлбуки, язучының әдәбияттагы урынын ул язган әсәрләр саны түгел, ә бәлки аларның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәсе, сыйфаты билгеләргә тиеш. Аерым

[1] М. Рафиков. Родник Хабира-Соловья. Повесть и рассказы. Рус теленда, Татарстан китап нәшрияты.

очракларда, укучыларның акылына һәм күңеленә тәэсир итү ягыннан бәләкәй генә хикәя дә кайбер калын романнардан көчлерәк булырга мөмкин. М. Рафиков хикәяләре тагын бер мәртәбә әнә шул фикерне раслый. Аның күп кенә хикәяләре үзәк матбугатта басылып килә, аерым хикәяләре чит ил телләренә тәрҗемә ителгән. Арадан берсе, «Шарлама» исемлесе, мәсәлән, чит илләрдә унбиштән артык телдә басылып чыкты. Күрәсез, лирик прозаның новелла кебек бәләкәй генә төре дә теге яки бу әдәбиятны хәтта дөнья аренасына алып чыгарга сәләтле икән.

Иң ахырдан тәрҗемә хакында берничә сүз. М. Рафиков хикәяләре татар телендә музыкальрәк, образлырак яңгырый, билгеле. Шул ук вакытта рус теленә тәрҗемәләре хакында да начар сүз әйтеп булмый. Алар җиңел укыла, автор стиленең төп үзенчәлекләре төгәл сакланган, милли колорит табигый һәм дөрес бирелгән. Бу күңелле хәл, чөнки бу очракта автор да, тәрҗемәче дә — бер үк кеше. М. Рафиков ике телне дә әйбәт белә торган тәҗрибәле тәрҗемәче, ул үз әсәрләрен үзе тәрҗемә итә. Бу — сирәк очрый торган күренеш, татар әдәбиятына килгәндә исә хәзергә бердәнбер очрак.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# ШӘРЫКНЕ ӨЙРӘНҮ БУЕНЧА ЯҢА ХЕЗМӘТ

Тормыш алга киткән саен, совет галимнәре алдына куела торган таләпләр дә үскәннән-үсә һәм катлаулана бара. Бүгенге чынбарлык тарих галимнәре, шул исәптән, Шәрыкне өйрәнүчеләр каршына да күп мәсьәләләр куя. Совет власте шартларында узган илле елдан артык вакыт эчендә Шәрык тарихын өйрәнү буенча бик күп материал тупланган. Хәзер шул материалны тәнкыйть күзлеге аша уздырырга, фәнни гомумиләштерүләр ясарга кирәк. Шәрыкне өйрәнүче тарихчылар алдында фән үсешенең аерым тармаклары һәм дәверләре буенча төпле историографик хезмәтләр язу бурычы тора. Бу эшнең төп кыенлыгы шунда, бер-ике китапны исәпләмәгәндә, бездә соңгы елларга кадәр Шәрык илләрен өйрәнүгә багышланган төпле, тулы хезмәтләр юк иде.

Менә шуңа күрә дә В. Н. Никифоровның «Наука» нәшриятында чыккан «Совет тарихчылары Кытай мәсьәләләре турында» дигән монографиясе тарихчылар арасында зур кызыксыну уятты. Бу зур хезмәтнең кереш өлешендә революциягә кадәр яшәгән тарих галимнәренең Кытай турында язган китапларына төпле күзәтү ясала. Шул кадәресен дә билгеләп үтәргә кирәк, монография авторы Казан тарихчыларының Кытай турындагы историографик хезмәтләренә дә шактый киң туктала.

В. Н. Никифоров монографиясенең икенче бүлеге Владимир Ильич Ленин хезмәтләрендәге Кытай мәсьәләләрен өйрәнүгә багышланган. Билгеле булганча, бөек юлбашчыбыз Кытайдагы революцион хәрәкәт мәсьәләләренә зур игътибар биргән. Аның хезмәтләрендә Кытай халкы турында, бу илдәге иҗтимагый строй турында кызыклы күзәтүләр, искиткеч тирән фикерләр бик күп. Монография авторы аларга тулы күзәтү ясый.

Совет тарихчыларының Кытайны өйрәнүгә багышланган беренче хезмәтләре егерменче елларда чыга башлый. Н. В. Кюнер кебек, революциягә кадәр формалашкан тарихчылар белән бергә, бу эшкә М. Н. Павлович, А. Е. Ходоров, В. Д. Виленский-Сибиряков, К. А. Харивки, Г. Н. Войтинский кебек күренекле политик эшлеклеләр һәм публицистлар тартыла. В. Н. Никифоров алга таба шуларның хезмәтләренә туктала.

1925—27 еллардагы Кытай революциясе Шәрыкне өйрәнүче барлык тарихчыларның игътибарын җәлеп итә. Кытай җәмгыятенең асылын бу илдә барган милли-азатлык хәрәкәтенең үзенчәлегеннән чыгып аңлату мәсьәләсе көн тәртибенә баса. Бу елларда Кытай тарихын өйрәнү эше бик нык җанланып китә. Күп кенә галимнәр Кытайның үзендә фәнни хәзерлек узалар, башкалабыз Мәскәүдә Кытай хезмәт ияләренең коммунистик университеты һәм Кытайны өйрәнү буенча фәнни-тикшеренү институты ачыла, «Кытай мәсьәләләре» дигән җыентыклар чыга башлый. 20 еллар-

ның ахыры һәм 30 елларның башы Кытай тарихын өйрәнү юлында барган күп төрле бәхәсләр белән аерылып тора. П. А. Миф, Л. И. Мадъяр һәм Коминтернның башка күренекле эшлеклеләре катнашкан бу бәхәсләрдә Кытай тарихына бәйләнешле бик күп мөһим мәсьәләләр тикшерелә. Бәхәстә катнашучыларның күбесе буржуаз галимнәрнең Кытай турындагы ялгыш карашларын кискен тәнкыйть итеп чыгалар. Рецензияләнә торган хезмәтнең дүртенче һәм бишенче бүлекләре әлеге бәхәсләргә багышланган.

1934—1949 елларда, төрле бәхәсләрдән дә бигрәк, Кытай тарихы буенча очерклар язуга игътибар көчәя. Г. С. Кара-Морза — шундый тарихчыларның берсе. Бүгенге тарихчылар арасында аның хезмәтләренең фәнни әһәмиятен бөтенләй инкарь итүчеләр дә бар. Алардан аермалы буларак, В. Н. Никифоров аның эшчәнлегенә фәнни, объектив бәя бирә. Монографиядә Кытайны өйрәнүче совет тарихчыларының башлыгы саналган академик В. М. Алексеев хезмәтләре дә киң урын алган.

Монографиянең соңгы җиденче бүлегендә Кытайның 1917—1947 еллар арасындагы халыкара бәйләнешләре турында сүз бара. Монография авторы фикеренчә, Кытайның халыкара бәйләнешләрен өйрәнү эшенә, бу ил тарихын махсус өйрәнүче профессиональ тарихчылардан да бигрәк, А. Л. Попов, Б. А. Романов, Б. Г. Курц кебек СССР тарихын өйрәнүче галимнәр зур өлеш кертkән.

В. Н. Никифоров китабының тагын бер күркәм ягы шунда, ул матур, популяр тел белән язылган, катлаулы фәнни концепцияләрне тикшерү совет галимнәренең тормыш һәм иҗат юлларына караган кызыклы фактлар белән чиратлашып бара. Китап бик күп рәсемнәр белән бизәлгән. Кытай тарихына караган гыйльми мәсьәләләрне яктырту белән бергә, ул бик кирәкле һәм файдалы белешмә ролен дә уйнаячак. Анда Кытай халкы, бу илнең экономикасы һәм культурасы хакында бик күп мәгълүмат тупланган. Шуның белән бергә, хезмәттә фактик характердагы аерым хаталар да очрый. Әйтик, П. Е. Скачков Кытайны өйрәнү буенча фәнни-тикшерену институты китапханәсендә түгел, ә СССР Фәннәр академиясенең Ленинград Шәрык институты китапханәсендә мөдир булып эшли; Сафаровның инициаллары Г. И. түгел, ә Г. А.; академик Ф. И. Щербатский Ленинград блокадасында үлми, бәлки эвакуациядә үлә һ. б.

Югарыда күрсәтелгән кимчелекләрнең күбесен хезмәтнең икенче басмасын матбугатка чыгарганда ук төзәтергә мөмкин дип уйлыйм. Ә аның яңа басмасын чыгару бик кирәк эш. Чөнки В. Н. Никифировның бу монографиясе Шәрык илләре тарихы буенча историография курсы алып баручы укытучыларның да, Кытай тарихы, шулай ук совет фәне һәм иҗтимагый фикер тарихының үсеше белән кызыксынучы укучылар массасының да өстәл китабына әйләнәчәк.

**Н. МӘҖИТОВА,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ШӘРИФ КАМАЛНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

## Гази Кашшаф

### *Иҗат портретына штрихлар*

1939 елның азакларында без Шәриф абыйның утыз еллык хезмәт бәйрәменә әзерләнә башладык. Иптәшләр миңа аның иҗатын өйрәнергә, тулырак итеп биографиясен язарга куштылар. Иҗаты азмы-күпме билгеле булса да, аны яңача күз салып укырга кирәк иде. Чөнки биш ел элек кенә, аның 25 еллык иҗат бәйрәмен билгеләү уңае белән, матбугатта капма-каршы фикерләр күп әйтелгән иде. Ул вакыты өчен хас булган вульгар социологизм тәнкыйте революциягә чаклы булган иҗатын вак буржуа лагерена аударып калдыра, комедиясеннән уңай образлар эзли, М. Горькийча пролетариат әдәбияты тудыра алмавы өчен шактый үтемле сүзләр әйтә. Шуның белән бергә, Ш. Камалның язучылык гомере 1909 елдан исәпләнеп йөртелә, чөнки аңа чаклы газеталарда басылган публицистик характердагы әсәрләрен, янәсе, язучы «үзе серьез эшкә хисапламый».

Ләкин әдипнең хезмәт юлын күз алдына бастыру максатын куйгансың икән, аларга игътибар итмәскә мөмкин түгел иде. Карасаң... 25 еллык юбилей түгел, 1934 елда ук инде утыз еллыкка хәзерләнә башларга кирәк булган икән. Ә безнең 30 еллыкка 1939 елда җыена башлавыбыз — инерция буенча булган.

Сүз дә юк, 1905 елда «Нур» газетасында басылган шигырь, фельетоннары өйрәнчек каләме белән язылганнар. Ләкин аларның иҗтимагый яңгырашы бер дә «наивный» язучы фикерләренә охшамыйлар. Алардан Петербургта 1905 елда барган канлы көрәш исе аңкый, патша палачларына, жандармнарга үч һәм нәфрәт ялкыны беркелеп тора. Ә бу «өйрәнчек» язмалар өчен кечкенә нәрсә түгел.

«Нур» газетасының беренче санында ук (1905 ел, 2 сентябрь) Ш. Камалның милләтнең хәлен кайгыртып язган фельетоны басыла. Фельетонның ахыры икенче санда басылырга тиеш була, тик икенче санда да, аннан соң да фельетонның ахыры басылмый. Фельетон дигәч тә, ул чакта «фельетон» сатирик жанр мәгънәсендә йөртелмәгән, газетаның подвалына урнаштырылган һәрбер җитди мәкалә, публицистик язма «фельетон» дип йөртелгән.

Фельетонда язучы милләт эшен кайгыртырга тиеш булган «олылар, байлар, агалар»ның бик күп сөйләп тә берни эшләмәүләре ирония белән языла. Ш. Камал аларны «тел белән көрәшүче баһадирлар» дип атый. Фельетонның басылмый калган өлеше нәрсә турында икән? Мин Шәриф абыйның үзеннән сорыйм. Ул чыннан да тыйнак, үз әсәрләренә бәя бирүдән яки аларга нинди дә булса аңлатма ясаудан читләшә.

— Булгандыр инде... — диде ул миңа теләмичә генә.

Күп сораштыра торгач, Шәриф абый болай ди:

— Яшь чак бит, таләпләр күп булган, күрәсең... басмадылар.

Миңа шунысы ачык, Шәриф абый, чыннан да, башлангыч иҗатына өйрәнчеклек эше дип карый, шул ук вакытта үзенең шактый кискен карашларда яшәвен дә әйтә. Димәк, фельетонның икенче яртысы патша цензурасына да, редакторга да ошамаган. Шул рәвешчә, Ш. Камалның матбугатка аяк басуы кискен каршылыкка очрый.

Ул чакта Шәриф Камалга да, башкаларга да «Нур» газетасының хөкүмәт акчасына чыгарылуы һәм хөкүмәт политикасын якларга тиешлеге билгеле булмый. «Нур»ны реакцион позициядән түгел, яктылыктан атылган «нур» дип ышаналар. Моңа шулай ук сирәк-сирәк кенә булса да Ш. Камалның газета битләрендә чыгып торган шигырьләре ярдәм итә. Ә ул «өйрәнчеклек» чоры кичергәндә дә революция елларының иҗтимагый-политик атмосферасын чагылдырмый калмый. Чөнки илнең политик тормышы, революцион хәрәкәт аны бик нык кызыксындыра. Шуңа күрә дә ул Петербургка — эшчеләрнең революцион учагына килә. 1906 елда аның беренче китабы «Сада» исеме белән басылып чыга. Сада — аваз дигән сүз, яшь шагыйрь аның эчтәлеген революцион рух белән сугара, һәм ул революцион аваз булып яңгырый. Шул нәни җыентыкка тупланган шигырьләр элек «Нур»да басылалар. «Хакы бар...», «Халык тавышы» кебек шигырьләр исемнәре белән үк күп нәрсә сөйлиләр.

1906 елның 12 маенда «Нур» газетасында басылган «Хакы бар...» исемле шигырьнең баш өлеше табигать хозурлыгын сурәтли, аннан халыкның эшкә башлавын тасвир итә. Ахырдан бер крестьянның сука ясавына туктала. Крестьянның нәни улы әтисенең сука ясавын белгәч, аптырап кала, чөнки аларның сукалары бар иде.

**Әткәсе дир: китте, шымды**
**Членнәремез Думага.**
**Падишаһтан җир сорарлар,**
**Балам, сука хәзер булсын!**

Күрәсез, шигырь зәгыйфь, шигъри тел әле эшләнмәгән, язучының өйрәнчек язмаларын хәтерләтә. Шулай да анда крестьянның Думага ышанып яшәве генә әйтелми, шигырьгә бирелгән исем авторның политик позициясен чагылдыра. Соңыннан әдәби тәнкыйть аның символлар, ишарәләр белән хикәяләвен язачак. Монда шуның башлангычы, авылның идиллик күренешләре, крестьянның табышмак кебек әйтелгән «шымды» сүзе, шигырь исеме шул турыда сөйли.

Шәриф Камалның журналистлык, язучылык эше шулай башланып китә. Минем тырышлыгым уңышлы барып чыкмады, Шәриф абый миңа үзе турында да, иҗаты турында да берни сөйләмәде.

Бәлки ул миңа ышанмый булыр?! Бәлки чыннан да шулай тыйнактыр?!

Без инде аның белән күптәннән таныш, җыелышларда, теге я бу әсәрне тикшергәндә, минем чыгышларны аның бик күп тыңлаганы бар. Җае туры килгәндә, кайчак, дөрес әйттең, кебек хуплау сүзләрен дә ишеткәнем бар. Миңа аның иҗади ярдәме дә тигәне бар. Бервакыт «Совет әдәбияты» журналының редакторы Гомәр Гали белән бәхәсләшеп торганда, Шәриф абый редакциягә килеп керде. Безнең бәхәсне тыңлап торганнан соң:

— Гомәр хаклы, ул урынны төзәтергә кирәк! — дип, мине берничә сүз белән ышандырды. — Юкса, менә мондый мәгънәгә дә урын кала....

Өлкән, тәҗрибәле язучының бер сүзе әйнытып җибәрә ала.

Ләкин үз иҗаты һәм үзе турында сөйләми. Еллар узгач кына моның аның характерына хас нәрсә икәнен аңлыйсың. Татар дәүләт академия театрында «Габбас Галин», «Козгыннар оясында», «Матур туганда» кебек спектакльләрне җәмәгатьчелек катнашы белән карап-тикшерү уздырылганда, Шәриф Камал үзе дә шунда иде. Ләкин беркайчан да, бер генә тапкыр да чыгыш ясамады. Тын гына тыңлап утыра, халык беренче тәэсирләрен сөйли, кайсы артистның уенына, кайсы әсәргә карата уңай яки кире фикер әйтә. Ә Шәриф абый тып-тын.

— Без сөйлибез дә сөйлибез, автор үзе ничек карый икән?! — дигән сүзләргә дә ул борчылу-мазар күрсәтми.

— Режиссер әйтер... Уйлармын... — кебек сүзләр белән чикләнә.

Хәер, бер тапкыр ул язучылар җыелышында шактый озын чыгыш ясады. Ясамаслык та түгел иде. 1937 елның ялкынлы җыелышларында кемнең генә хәрам йоннары янмый да, канат очлары көйми. Ялкын телләре Шәриф абыйга да килеп җиткән, әле ике-өч ел гына элек 25 еллык хезмәт бәйрәмен уздырган язучыны тегесе белән аралашкан, монысы белән чәй эчкән, аңысын күреп бетермәгән өчен «либерал», хәтта «сакаллы либерал» дип тә тамгаладылар. Хәзер аңлатма бирсен, диделәр.

Бервакыт Шәриф Камал акрын гына урыныннан торды, ашыкмый гына трибунага килеп басты, яулыгын алып авыз кырыйларын сөртте, күзлеген иплэп алды һәм:

— Минем хаталарым күп, иптәшләр, — дип, тыныч кына, эчке дулкынлануын сиздермәскә тырышып сөйләп китте. — Иң элек, мин әтине сайлый белмәдем...

Соңыннан мин ул җыелышның беркетмәсен сораган идем, табылмады. Стенограмма язып алынмаган, магнитофон тасмалары исә ул чакта юк иде әле.

Шәриф Камал иҗаты буенча язылган гыйльми хезмәтләр, мәкаләләр, диссертацияләр шактый күп. Язучы хикәяче-новеллачы буларак та, драматург буларак та, повесть, романнар язучы буларак та җитәрлек тикшерелгән. Әдәбият тарихында да ул үзенә тиешле урынны алган. Реалистмы ул, критик реалист яки романтикмы, социалистик реализмга ни дәрәҗәдә өлеш керткән — бу мәсьәләләр буенча да кирәкле мәгълүмат табарга мөмкин. Ничек кенә һәм кайсы ноктадан тикшерә башласаң да, безнең каршыга оригиналь, гаять үзенчәлекле язучы килеп баса. Шунысын да әйтергә кирәк, соңгы еллардагы тикшеренүләрдә 40 нчы елларга чаклы сузылган капма-каршылык, тупас социологизм белән эш итү күзгә ташланмый. Дөрес, иҗат бәхәсе һаман да яши һәм ул яшәргә тиеш!

Ләкин 1939 елда бу хезмәтләрнең берсе дә юк, булганнары «фән әйләнешенә» кертелмәгән. Шуңа күрә мин иң элек, Шәриф Камалның үз иҗатыннан чыгып, аның иҗади биографиясен язарга тырыштым. Язып бетерүгә, әле һичкемгә күрсәтмәс борын, Шәриф абыйга укырга кирәк дип уйладым. Ул миңа 1940 елның башында (яңа елның беренче көннәре иде) үзенә килергә кушты. Мин Островский урамына киттем. Мин бик дулкынланган идем: нәрсә әйтер, болай язарга кирәкмәс, диярме, бракка чыгарырмы, әллә дөрес факт түгел дип, мине кире борып җибәрерме?! Шуңа күрә мин Шәриф абый квартирасының җиһазларына игътибар итмәдем. Зур бүлмәнең кояш белән балкып торуы хәтеремдә һәм Шәриф абыйның тыныч йөзе, күзлек пыяласы аша моңаеп та, елмаеп та караган күзләре истә.

— Шәрәф абый, бу язма — сезнең анкета һәм Сез язган әсәрләр буенча эшләнде, шуңа күрә дөрес булмаган җирләрен әйтә барыгыз! — дидем мин.

Мин укыйм, ул тын гына, һичбер хәрәкәт ясамыйча тыңлап утыра. Ара-тирә мин, тукталып:

— Шулаймы, дөресме? — дип сорыйм.

Шәриф абый, әйе, шулай, дөрес диген сүзләре белән мин язганнарны җуплап бара. Укып бетергәч, ныклап сөйләшергә исәбе бар, күрәсең, дип уйлыйм мин. Ләкин ул укып бетерүгә тора да зур имән буфет шкафыннан ике рюмка һәм коньяк алып минем алга куя.

— Яңа елны каршылаганнан калган нәрсә генә... Әйдә, Яңа ел хөрмәтенә берәр рюмка күтәрик!

Яңа ел өчен күтәргән тосттан соң да Шәриф абыйның теле ачылмады. Ул мин язган биографияне телдән раслап, рәхмәт әйтеп, үземнең ничек яшәвем турында сораша башлады.

Мин чәйгә калмадым, зур эшне башкарып чыкканнан соң була торган канәгатьләнү тойгысы белән кайтып киттем.

1940 елның мартында Шәриф Камалның юбилее матур, күңелле узды. Юбилей татар совет әдәбиятының дәрәҗәсен күтәрде, аны сөючеләрнең санын үстерде. Казандагы мәктәп, предприятиеләрдә язучыга багышланган кичәләр узганнан соң, тантана Мәскәүгә күчте.

Мәскәүдә Казан вокзалына язучыны каршы алыр өчен Константин Федин җитәкчелегендә бер төркем рус язучылары килгән иде. Федин Ш. Камал вагоннан чыгуга аны кочып алды һәм, култыклап, автомашинага юнәлде. Беренче көнне язучының иҗатына багышланган тантаналы җыелышта да председательлек итүче — шул ук — русның атаклы язучысы Константин Федин булды. Язучылар йортында оештырылган кабул итү мәҗлесе Федин җитәкчелегендә узды. Ул язучы исәнлеге өчен беренче тостны күтәргәндә дә Ш. Камалның иҗатына югары бәя биреп, аның гаҗәп тыйнак кеше булуына басым ясады.

Шәриф Камалның юбилеен Мәскәүдә билгеләү өчен без байтак кеше барган идек. Язучылар күп булмаса да, Ш. Камал драмаларында уйнаучы артистлар шактый иде.

Кемнәр кайда урнашкандыр, хәтерләмим. Ләкин без «Киев» гостиницасында Шәриф Камал, Фәйзулла Туишев, Афзал Шамов һәм мин — дүртебез бер номерга урнашкан идек. Туишев мәҗлестән бик соң кайтты, чөнки ул безнең банкетта гына кунак түгел, бәлки язучылар ресторанында гаиләләре белән шимбә кичен уздырырга килгән рус язучыларының да күктән төшкән кунаклары булды. Без гостиницага кайтып киткәндә, Фәйзулла абыйга үзенең гармуны белән мәҗлесне ташлап китү мөмкин түгел иде: виртуоз гармунчы язучыларның заказы буенча нинди генә көйләрне башкармады икән. Кыскасы, виртуоз үз стихиясендә иде.

Тик ул бик арып, авырып кайтты. Икенче көнне Шәриф абый, иркә баланы тәрбияләгән кебек, Туишев яныннан китмәде. Мәскәүдәге татар җәмәгатьчелеге өчен оештырылган кичәгә барыр вакыт җиткәнче ул аның янында, әле дару бирел, әле чәй белән кыстап, тәрбия-хөрмәт күрсәтте һәм гармунчыны аякка бастырды.

Константин Федин Шәриф Камалга багышланган кичә һәм язучы турында Александр Фадеевка сөйләгән булырга тиеш, чөнки соңыннан Фадеев белән очрашу вакытларында, ул миңа Камалның зур художник булып та шул кадәр тыйнаклыгы турында әйткәне бар.

— Алай ук кирәкмәс иде, язучыларны бүләкләүгә әзерлек алып барганда, 1939 елда, без аны белми калдык... Урыны белән өстәл җимереп дауларга кирәк! — диде Фадеев һәм ягымлы итеп көмеш тавышлар тәгәрәтеп көлеп алды.

Һәм мин ул чакта Фадеев җитәкчелегендә эшләгән СССР Язучылары союзының Шәриф Камал иҗатын Союз күләменә күтәрү өчен зур тантана оештыруын аңладым, чөнки 1940 елга кадәр автономияле республикалардан язучылар чакырып, Мәскәүдә тантаналы кичәләр уздыру гадәте юк иде дисәм, хата булмас.

Шәриф Камалның революциягә чаклы иҗатын өйрәнүче галимнәр бер нәрсәне хәтердән чыгаралар. Янәсе, ул үзе белгән тормышны язган, сезонлы эшчеләр, шахтерлар арасында йөрсә дә, революционерларны күрә алмаган, чикләнеп калган. Ләкин язучы аңлы гомере башлануга үз иҗат биографиясен үзе яза башлый, ата-ана яшәгән тормыш аңа чит, органик рәвештә ул аларга кушылып китә алмый. Аны гел хезмәт кешесе алга әйдәп бара, ул хезмәткә омтыла, матурлыкны хезмәттән, кешенең һөнәреннән эзли. Шунысы да характерлы, ул моны XIX йөзнең соңгы елларыннан ук эзли башлый һәм гомере буе шул эзләнүдән туктамый. Революциядән соң да иҗади хезмәт кешесе, завод-фабрика эшчеләре аның игътибар үзәгендә кала. Казан предприятиеләре алдынгылары, Бондюг химия заводы патриотлары, Ак диңгез — Балтик каналы төзелеше аны иҗатка илһамландыра.

Шул рәвешчә, хезмәтнең илаһи көчен башта интуитив рәвештә генә аңлаган, рухани-буржуаз тормышның «изгелеген» адым саен тукып торганда да хезмәт кешесенә омтылудан ваз кичмәгән, һаман эзләнгән, хезмәт кешесенең күңел түренә кереп казынган илһамлы бер кеше күз алдына баса. Шул сыйфатлары аны революция белән тоташтыра һәм ул революция солдаты булып, һаман югарыга күтәрелеп баручы яңа тип язучы — совет язучысы булып калкып чыга. Шуңа күрә Шәриф Камал турында, бөтен иҗатын һәм тормыш юлын күз алдына бастыра торган тулы монография язу вакыты җитте дип ышанам.

Югарыда без Шәриф Камалның иҗаты вакытлы матбугатта башланганын әйткән идек. «Нур», «Вакыт» газеталарында аның журналистлык хезмәте башлана. Революциядән соң исә соңгы сулышына кадәр ул партия-совет матбугатында эшләүдән бер вакытта да аерылып тормый.

Безнең яшь, әле яңа борынлап килә торган журналистика фәне «Эшчеләр дөньясы», «Кызыл йолдыз», «Юксыл», «Юл», «Сабан», «Кызыл Татарстан» газеталарын һәм Казанда чыккан журналларны өйрәнгәне юк. Анда салынган көч, Шәриф Камалның өлеше дә өйрәнелмәгән. Әнә шул газеталарның бүлек мөдире яки редакторы булып эшләгәндә, Шәриф Камал дистәләрчә эшче-хәбәрчеләргә чын мәгънәсендә иҗади ярдәм күрсәтә, аларның игътибарын тиешле юлга юнәлдерә белә. 1919 елда, «Кызыл йолдыз» газетасында эшләгәндә, яшь Муса Җәлилгә дә поэзия юлына аяк басарга булышучыларның берсе ул.

Хәзерге «Казан утлары» — ул исән чакта «Совет әдәбияты» журналы — редколлегиясе члены буларак эшләве минем күз алдымда узды. Гадәттәнчә, ул аз сүзле,

шау-шулардан ерак торырга тырыша торган кеше, редакция тапшырган кульязмаларны да тавыш-тынсыз гына укып чыга да:

— Журналда бастыру мәслихәт булыр,— дип, яки:

— Иптәшкә әйтергә иде, менә бу җирен яңадан эшләсен иде,— кебек фикерләрен җыйнак итеп, кыска фразалар белән әйтеп калдыра. Язма рецензия биргәндә «басарга ярый» яки «яңалык тапмадым» кебек сүзләрне кульязманың бер почмагына терки.

Гадәттә, редакция үз аппаратында әзерләнеп, басарга яраклы табылган материалларны гына редколлегия членнарына бирергә тиеш. Редколлегия члены — ул җәмәгатьчелек тәртибендә эшләүче тәҗрибәле язучы, аның үз эше өчен дә вакыты бик кысан. Ләкин Шәриф Камал редколлегия члены булган чорларда редакция аппараты бик кечкенә, кульязмалар күп, редакция үз көче белән генә материалларны эшкәртеп бетерә алмый, шуңа күрә редколлегия членнарына, өстәмә рәвештә, басарга яраксыз кульязмаларга да вакыт билгеләргә туры килә. Аннан соң шунысы да бар, һәрбер чор үзенең алдынгы әдибен күтәреп чыгарган кебек, маньякларын да онытмый. Кеше никадәр таланттан ерακта калган булса, редакция аппараты аның белән шул кадәр җәфа чигә. Югары оешмаларга язган гаризалары буенча гына да күпме эш өелә...

Шундый автор кульязмасын мин бервакыт Шәриф абыйга тәкъдим иттем. Бөек Ватан сугышы башлангач, редакциядә ике генә кеше калды. Шәриф абый, редколлегия члены буларак, редакция эшенә ярдәм итү нияте белән көн саен диярлек редакциягә кереп булыша. Шуңа күрә гаугалы «автор»дан да баш тартмады. Ләкин икенчеме, өченчеме көнне редакциягә бик рәнҗеп килде.

— Кәшшаф, — диде йомшак тавыш белән, — моннан ары миңа мондый кульязма тапшырма. Миңа син рәт чыгардайракларын бир, вакыт әрәм...

Мин аны аңладым, гафу үтенеп, «минем язучылык язмышымны үзең генә хәл итмә, Шәриф Камал кебек язучылар бәя бирсен» дигәнгә күрә генә бирүемне аңлаттым...

Озакламый миңа командировкага китәргә кирәк иде. Таҗи Гыйззәт, Шәриф Камал һәм мин столовойдан кайтып киләбез. Безне Куйбышев мәйданындагы столовойга беркеткәннәр һәм сугыш чорының тозлы помидордан пешергән шулпасы һәм песи теле чаклы котлеты белән сыйлана идек. Бауман урамы буйлап Матбугат йортына кайтканда, Шәриф абый:

— Син озак йөрмә инде, Кәшшаф, — диде. — Монда да эш җитәрлек, аннан соң без Таҗи белән берәр колхозга барып килмәкче идек...

Мин үземнең озак йөрмәскә исәпләвемне һәм кайту белән редколлегия членнары җыелып, рәсемгә төшәргә исәп тотуымны сөйләдем.

Таҗи абый да, Шәриф абый да:

— Мәслихәт булыр, — диделәр.

Ләкин командировкадан кайтканда, Бөгелмә юлы белән Рузаевкага төшкәч, анда ике тәүлек поезд көтеп утырырга туры килде. Анда бер тимер юлчы белән танышып, аның Пешлә авылыннан икәнен белгәч, Шәриф абыйның яшьлек еллары турында сөйләттем. Ул Шәриф Камалны яхшы белә икән, бигрәк тә аның хәтерендә 1905 ел вакыйгалары сакланып калган иде. Ул Ш. Камалның Рузаевка тимер юлчылар восстаниесендә актив катнашуын, бер митингтан да калмавын сөйләде. Ул Шәриф абыйның хәлен сорашты, бик күп сәлам тапшырырга кушты... һәм мин шул әманәтне тапшырырга дип шатланып Казанга кайтып төштем. Чишенеп тә тормастан, Матбугат йортына киттем, анда мине бик борчылган йөз белән Таҗи абый каршы алды.

— Исәнме, кайтуың әйбәт булды,— диде Таҗи Гыйззәт,— зур бәхетсезлек...

Ул бераз тын калды һәм:

— Әле генә Шәриф абый үлде, әйдә шунда киттек... — диде...

Туган авылыннан юлланган сәлам иясенә тапшырыла алмады. Редколлегия рәсемгә төшә алмыйча калды. Шәриф абый белән Таҗи абыйның колхозга барып, «бераз бәрәңге алып кайту» һәм очерк язу планнары һавада асылынып калды...

## Хөсәен Уразиковка 80 яшь



РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Хөсәен Уразиков — татар совет театр сәнгатен үстерүгә күп көч куйган талантлы артист, режиссер.

Ф. Шиллер әсәрләреннән «Мәкер һәм мәхәббәт»тә президент фон Вальтер, «Юлбасарлар»да Максимилиан фон Моор, В. Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» әсәрендә Капулетти, М. Горькийның «Соңгылар» пьесасында Коломийцев, Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында Колый Тархан, Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы»нда Сәмигулла һәм моннан тыш тагын сәхнәдә Х. Уразиков тудырган йөзләрчә образларны тамашачылар сокланып карадылар.

Хөсәен Ибраһим улы Уразиков 1894 елның 7 гыйнварендә Самара өлкәсе, Сафарка авылында туа.

Элек авыл мәктәбендә, аннары Уральскида рус мәктәбендә белем ала.

Беренче бөтен дөнья сугышында катнаша. Яраланып, әсир төшә. Әсирлектән котылгач, туган авылына кайта һәм Кызыл Армиягә языла.

Х. Уразиковның сәхнә эшчәнлеге дә Кызыл Армия сафларында башланып китә.

Хәрби округның политик идарәсе каршындагы театр студиясен тәмамлаганнан соң, Х. Уразиков төрле труппаларда эшли.

1923 елдан Х. Уразиков Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты, ә 1944—49 елларда шул театрның сәнгать җитәкчесе була.

Х. Уразиков хәзер пенсиядә. Ул үзенең күп еллар буе җыйган тәҗрибәсен яшь артистлар белән уртаклаша, аларга эшлекле киңәшләр бирә, сәнгатьнең олы юлына чыгарга булыша.

## Хөснул Вәлиуллинга 60 яшь



Халкыбызның яраткан композиторы Хөснул Вәлиуллин 1914 елның 28 февралендә хәзерге Саба районы, Зур Саба авылында туып үсә.

Казан музыка училищесында белем ала.

Бөек Ватан сугышына катнаша.

Сугыштан соң Казан консерваториясен тәмамлый.

Консерваториядә укыган чагында ук инде Х. Вәлиуллин халык җырларын эшкәртә, үзе дә яңа җырлар иҗат итә.

Х. Вәлиуллин бигрәк тә күренекле татар шагыйрьләренең сүзләренә язылган җырлары һәм кантаталары белән җыр сөючеләр ихтирамын казанды.

Х. Вәлиуллинның зур әсәрләреннән берсе — 1957 елда М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында куелган «Самат» операсы. Х. Вахит либреттосына язылган бу әсәр Мәскәүдә татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында зур уңыш белән барды.

Сәләтле композитор Х. Вәлиуллин «Муса Җәлил», «Миркәй белән Айсылу» (Н. Исәнбәт), «Таһир-Зөһрә» (Ф. Бурнаш), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т. Миңнуллин) һәм башка бик күп сәхнә әсәрләренә музыка язды.

Хәзер ул «Самат» операсының яңа варианты өстендә эшли; скрипка өчен лирик җырлар, тынлы оркестр өчен маршлар, баян өчен музыкаль әсәрләр иҗат итә.

## *Әнәс Тумашевка 50 яшь*



Әнәс Тумашев 1924 елның 9 февралендә Чистай шәһәрендә дөньяга килә. Аның бала чагы да шушы шәһәрдә уза.

Булачак рәссам 1938—1942 елларда Казанда художество мәктәбендә укый. 1945 елга кадәр, ягъни Бөек Ватан сугышы тәмамланганчы, заводта эшли. Сугыштан соң өметле яшь рәссамны Ленинградтагы И. Репин исемендәге скульптура-архитектура институтына укырга җибәрәләр.

1953 елда Ә. Тумашев институтны уңышлы тәмамлап, Казанга кайтты һәм Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында художник булып эшли башлады.

1958 елда К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» спектакле тамашачылар арасында зур уңыш казана. Бу әсәрне сәхнәләштерүче һәм куючыларга, шул исәптән Ә. Тумашевка да, Тукай бүләге бирелде.

«Таһир-Зөһрә» (Ф. Бурнаш), «Миркәй белән Айсылу» (Н. Исәнбәт), «Чикләвек төше» (Г. Ахунов), «Тол хатыннар, тол кызлар» (С. Шәкүров), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т. Миңнуллин) һәм тагын дистәләрчә спектакльләрне тамашачылар Ә. Тумашев оформлениесендә карадылар.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан художниклар союзы председателе урынбасары Ә. Тумашев бүгенге көндә, театрда художник булып эшләү белән беррәттән, Казан художество училищесында яшь рәссамнар укыта, төрле җәмәгать эшләренә катнаша.

## Хәкимҗан Халиков

### Җәйге яңгыр

Килә болыт, килә дулап,
Әйтерсең кыр үгезе.
Җирдән мине элəктереп
Алыр сыман мөгезе.

Яшен-камчы шул үгезгә
Суккан иде китереп,
Чылтырт итеп күкнең чите
Төште гүя кителеп.

Китте яңгыр. Иләкләп тә,
Чиләкләп тә койды ул.
Бер минутта иңкүләрдә
Күлләр ясап куйды ул.

Дөньяны су баса бит дип,
Тора идем аптырап.
Бер болытны ертып кояш
Килеп чыкты ялтырап.

### Яңгырдан соң

Җем-җем итеп тора үлән,
Энҗегә манган кебек.
Чәчәкләрдән тәмле хуш ис
Тамчылап тамган кебек.

Күккә карыйм, шундый зәңгәр,
Сабынлап юган кебек.
Шатлыгыннан бөтен дөнья
Елмаеп торган кебек.

### Өч кыз

Берсе Дилә, берсе Зилә,
Өченчесе Миңлегөл.
Берсе үлчи, берсе кисә,
Өчесе дә бик өлгер.

Әнә тагын җыелганнар
Ян тәрәзә каршына.
Алларында келтер-келтер
Җырлап тора машина.

Диләсе дә, Зиләсе дә,
Машина да ашыга:
Курчакка бит күлмәк кирәк,
Яулык кирәк башына.

Тегүче дә булмас бәлки
Бу кызларның барсы да.
Ә тормышта һөнәрнең бит
Артык түгел кайсы да.

## Канатлы музыкант

Җир өстенә кайдан болай
Бик матур көй тарала?
Әллә транзистор элеп
Куйганнармы һавага?

Уңга карыйм, сулга карыйм,
Беркем дә юк янымда:
Кайсы шулай өздерә соң
Кыңгыраулы гармунда?

Кара син ә, артисты да
Армас икән армаса!..
Үзен күргәч исем китте:
Тургай икән ләбаса!

## Язгы бакча

Бөтен бакча ап-ак бүген,
Кар явып үткән сыман.
Алмагачлар тып-тын гына
Кемнедер көткән сыман.

Өсләрендә ап-ак күлмәк,
Сабан туй җиткән сыман.
Карт алмагач әллә шуңа
Яшәреп киткән сыман.

## Гөлинә

Көзге кебек боз өстендә
Оча гына Гөлинә.
Куып җитсә җитәр аны
Бары җитез җил генә.
Өйрәткәндер кем генә,
Оча гына Гөлинә...
Тимераягым да яңа,
Нишләдем соң мин генә,
Гөлинә?

Шугалакта биегәнен
Күрсәгез лә бер генә:
Гөлинә дип белмисең дә,
Артист инде гел менә.
Кулын куеп биленә,
Тып-тып бии Гөлинә...
Бер атлыйм да егылам бит,
Нишләдем соң мин генә,
Гөлинә?

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ИҖАТ СОЮЗЛАРЫНЫҢ БЕРЛӘШТЕРЕЛГӘН ПЛЕНУМЫ

29—30 октябрьларда КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында Татарстандагы иҗат союзлары һәм иҗат оешмаларының берләштерелгән пленумы булып узды. Ул КПССның XXIV съезды карарлары яктылыгында яшь талантларны тәрбияләү буенча иҗат союзларының бурычлары турындагы мәсьәләне тикшерде.

Пленумда Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе, шагыйрь Зәки Нури, Композиторлар союзы идарәсе председателе, СССРның халык артисты Нәҗип Җиһанов, Художниклар союзы идарәсенең председатель урынбасары, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Әнәс Тумашев, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе, РСФСРның атказанган артисты Рәшидә Җиһаншина яшь алмаш тәрбияләп үстерү өлкәсендә башкарылган эшләр һәм алда торган бурычлар турында докладлар белән чыктылар.

Яшь язучылар, яшь рәссамнар, музыка һәм сәнгать осталары отрядының сан һәм сыйфат ягыннан үсешен нинди чаралар белән тәэмин итү мәсьәләсе,— диде үзенең докладында З. Нури, — барлык иҗат коллективлары өчен ифрат мөһим, беренче дәрәҗәдәге мәсьәлә булып килде һәм шулай булып калачак та.

1970 елдан 1973 елга кадәрге вакыт эчендә без 29 яшь авторны Язучылар союзына член итеп алдык. Хәзер Татарстан язучылар союзы членнарының саны 140 кешегә җитте. Союз членнарының саны ягыннан безнең оешма РСФСРда өченче урында тора. Бу — безнең язучылар коллективының күп еллар дәвамында армый-талмый алып барган тырыш хезмәт нәтиҗәсе.

Алга таба докладчы өлкән буын язучыларыбызның яшь алмаш тәрбияләп үстерү өлкәсендә башкарган хезмәтләренә тукталды. Безнең аксакалларыбыз, диде ул, үз эшләренә чын күңелдән бирелгән әдәбият фидакарьләре, партиянең турылыклы көрәшчеләре. Аларның күбесенең тормыш һәм иҗат юллары Октябрь революциясе давыллары, Бөек Ватан сугышы гөрелтеләре, удар бишьеллыкларның ашкынучан пафосы белән аваздаш. Р. Төхфәтуллин, Ю. Әминов, Ә. Маликов кебек урта буын язучыларның беренче китаплары әнә шул өлкән әдипләрнең якыннан ярдәме белән дөньяга чыкты. Алар хәзер татар совет әдәбияты тарихында ныклы урын алдылар, үзләре үк яшь алмаш тәрбияләүче укытучыларга әйләнделәр. Бераз соңрак, шундый ук даими кайгыртучанлык, игътибарлы мөнәсәбәт нәтиҗәсендә, безнең сафларга Г. Ахунов, Н. Фәттах, И. Юзеев, Ш. Галиев, А. Гыйләҗев, Б. Камалов, Э. Касыймов, Ш. Рәкыйпов, Р. Мостафиннар кушылды. Әдәби алмашыбызның сугыштан соңгы икенче буыны тагын да ишлерәк. М. Шабаев, Т. Миннуллин, Р. Гатауллин, Р. Фәйзуллин, Р. Әхмәтҗанов, Г. Рәхим кебек яшь язучылар безнең зур һәм дус коллективта тәрбияләнделәр.

Партия безнең һәммәбезне илебез тормышында барган зур вакыйгаларда актив катнашырга, замандашларыбызның тормышын һәм батыр хезмәтен бөтен тулылыгында сурәтләнгән әсәрләр иҗат итәргә чакыра. Бүгенге катлаулы тормышның төрле күренешләрен сәнгатьчә сурәтләү, ул күренешләргә коммунистлар партиясе һәм эшчеләр сыйныфы позицияләреннән карап дөрес бәя бирү өчен, һәр язучы дөньяга марксистик-ленинчыл караш белән коралланган булырга, аның тормыш күренешләре турында үз карашы булырга тиеш. Моның өчен исә иҗат кешесе үз хезмәтенең нечкәлекләрен тирәнтен үзләштергән булырга, тормыштагы яңа процессларны җентекләп өйрәнеп барырга, барыннан да бигрәк, үзе сурәтли торган геройлар тормышын яхшы белергә, үзе дә шулар арасында яшәргә тиеш. Яшь язучылар арасында, кызганычка каршы, бу эшнең җитдилеген аңлап җиткермәүчеләр дә очрый.

Соңгы дүрт ел вакыт эчендә, ди докладчы, Татарстан китап нәшрияты киләчәктә безнең сафларны тулыландырырга тиешле өметле яшьләрдән 38 авторның беренче җыентыкларын бастырып чыгарды. Алар арасында әйбәт-әйбәт шигырь китаплары бар. Әмма безне яшь прозаикларның азрак килүе, яшь драматургларның булмавы борчый. Яшьләр прозасында нигездә авыл темасы өстенлек итә. Өстәвенә, сугыш еллары һәм сугыштан соңгы авыл тормышын сурәтләгәндә, кайбер прозаиклар авыл тормышындагы кыенлыкларны һәм кимчелекле якларны күрсәтү белән артыграк мавыгалар. Шигырь җыентыкларының күбесендә бүгенге тормыш сулышы җитәрлек сизелми, яшь шагыйрьләр интим хисләрне сурәтләү, үз биографияләрен сөйләүдән ерак китмиләр. Сюжетлы шигырьләр һәм поэмалар бик аз языла. Яшь язучыларның иртә профессионаллашуы — зарарлы һәм начар күренеш, моның ахыр чиктә иҗат торгынлыгына китерү куркынычы бар, ди докладчы.

Булачак язучыларның күбесе әдәби иҗат эше белән мәктәптә укыган елларда ук шөгыльләнә башлый. «Яшь ленинчы» газетасы, «Ялкын» журналы балалар кулы белән

язылган әдәби әсәрләрне сайлап алу һәм бастырып чыгару эшенә бик житди карыйлар. Соңгы елларда Татарстан китап нәшрияты балалар язган хикәяләрдән һәм шигырьләрдән төзелгән ике китап чыгарды. Тиздән өченчесе дә чыгып житәчәк. Республика районнарында һәм шәһәрләрендә 25 әдәби түгәрәк һәм берләшмә эшләп килә. Ул түгәрәкләрдә һәм берләшмәләрдә бик күп яшь эшчеләр, игенчеләр, хезмәткәрләр үзләренең сәләтләрен һәм талантларын сынап карыйлар, белемнәрен һәм осталыкларын үстерәләр. Түгәрәк утырышларында танылган язучылар катнаша, алар башлап язучыларның беренче әсәрләре турындагы фикерләре белән уртаклашалар, киңәшләр бирәләр. Аеруча игътибарга лаеклы әсәрләрнең авторлары Казанга индивидуаль семинарларга чакырыла. «Казан утлары» журналы каршында ике ел буена яшь рецензентлар түгәрәге эшләп килә.

Язучылар союзы идарәсе һәм партия бюросының эш планнарын төзегәндә яшьләрне тәрбияләү мәсьәләләренә зур урын бирелә. Әйтик, бер 1973 елда гына да Язучылар союзы каршындагы партия оешмасының ике җыелышы шушы мәсьәләгә багышлап уздырылды. Иҗат секцияләрендә 37 авторның яңа әсәре укып тикшерелде. Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында планлы төстә яшьләрнең иҗат кичәләре булып тора, аларның радио һәм телевидение буенча чыгышлары оештырылып килә. Язучылар союзының «Идел» альманахы үзенең һәр санында диярлек унлапча яңа авторлар белән таныштырып бара. Яшь язучыларның хикәя һәм шигырьләренә республика газеталарында да киң урын бирелә.

КПССның XXIV съездында һәм бераз соңрак Үзәк Комитетның «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы махсус карарында бик дөрес күрсәтелгәнчә, әдәбият һәм сәнгатьнең уңышлары күп кенә дәрәҗәдә тәнкыйтьчеләребезнең никадәр актив эшләвенә дә бәйле. Сүз яшьләрне тәрбияләү турында барганда, тәнкыйть аеруча игътибарлы һәм сак булырга тиеш. Бездә сәләтле тәнкыйтьчеләрнең бөтен бер отряды яши, шулай да яңа чыккан китапларның, шул исәптән яшьләр язган китапларның да, зур өлеше тәнкыйть игътибарыннан бөтенләй читтә кала. Бу нормаль хәл түгел. Проблема күтәргән, әдәби хәрәкәтнең үсешен күзәткән, шулай ук аерым язучыларның әдәби осталыкларын җентекләп тикшергән мәкаләләр дә азрак басыла.

Яшь язучыларның политик белемнәрен күтәрү эшенә Союз зур игътибар бирә. Татарстан язучылар союзы каршында марксистик-ленинчыл эстетика мәсьәләләре буенча теоретик семинар эшли. Күп кенә язучылар КПССның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан иҗат интеллигенциясе өчен оештырылган семинарга йөри. Быел 10 кеше кичке марксизм-ленинизм университетында югары политик белем ала. Кызганычка каршы, арада бу эштән читтә калырга тырышучылар да бар.

Талант җәмгыять байлыгы санала. Талант иясе һәр вакыт зур тормыш ритмы белән яшәргә, даими төстә иҗади эзләнергә, үзенең талантын камилләштерү өстендә эшләргә тиеш. Шундый ук теләк һәм дәрт белән без әдәби иҗатны пропагандалаучылар буларак та эш алып барырга бурычлы. Халык һәм художникның бердәмлеге дигән төшенчәгә язучының даими төстә укучылар белән очрашып торуы да керә.

Сәнгать әсәре алдына куела торган таләпләр, бер-беребезгә булган таләпчәнлек көннән-көн үсә барырга тиеш. Чын талант бары шундый шартларда гына ныгый, өлгерә ала.

Һәм, ниһаять, язучы алдына куела торган тагын бер таләп. Сүз иң үткен гражданлык хисләре белән коралланган булуның кирәклеге, тормыштагы үзгәрешләрне вакытында күзәтеп баруның зарурлыгы турында бара.

Һәр яшь автор һәр җирдә һәм һәркайда аның үсүе, аның киләчәге өчен коллективның чын-чыннан кайгыртып торуын сизсен.

З. Нури үзенең докладын: «Әйдәгез, иҗади яшьләр белән эшлекле дуслыкны көннәнкөн ныгыта барыйк, үзебезгә алмашка киләчәк буынны бергәләп үстерик, бергәләп тәрбиялик», — дип тәмамлады.

Татар музыкасының киләчәге күп кенә дәрәҗәдә бүгенге яшь композиторларыбызның нинди булуларына бәйле, — дип башлады сүзен Н. Җиһанов.— алар ни белән яшиләр, аларны нәрсә дулкынландыра, нәрсә борчый, аларның иҗат омтылышлары һәм перспективалары нинди — музыкабызның иртәге көне әнә шул нәрсәләргә бәйле.

Бездә яшь композиторлар белән эшләүнең төрле формалары кулланыла. Боларга традицион пәнҗешәмбеләр дә, иҗат отчеты белән идарә утырышларына чакырулар да, өлкән композиторларның яшьләргә бирә торган консультацияләре дә, иҗат йортларына командировкалар бирү дә керә. Яшьләр иҗат иткән әсәрләр концерт программаларына кертелә. Бездә яшьләр иҗатына гына багышланган махсус пленум да үткәрелде.

Без һәр яшь авторны художник-гражданин итеп үстерергә тырышабыз. Иҗади яшьләребез партия мәгарифе челтәрендә идея-политик дәрәҗәләрен күтәрәләр. Аларны җәмәгать эшләренә тартабыз. Идарә членнары, съезд делегатлары арасында, кагыйдә буларак, яшь композиторлар да була. Яшьләребез КамАЗда, Татарстанның нефть районнарында һәм колхоз-совхоз эшчәннәре янында еш булалар, Казан шәһәренең һәм үзебез шефлыкка алган Әгерже районы үзешчән сәнгать коллективларына даими төстә эшлекле ярдәм күрсәтеп киләләр.

Татарстанның яшь композиторлары кемнәр? Аларның иҗади йөзләре, татар музыкасын үстерү эшенә керткән өлешләре нинди соң?

Алар арасында иҗади өлгергәнлек баскычына күтәрелгән һәм исемнәре бөтен республикага билгеле, талантлы композиторлар бар: Ф. Әхмәтов, Р. Билалов, Р. Еникеев, И. Якупов, М. Яруллин һ. б.

Билгеле, яшь композиторлардан бары шедеврлар гына көтеп утыру дөрес булмас иде. Төрлечә эзләнүләр, шатлыклы табышлар, нинди дә булса дәрәҗәдә ялгышулар да — алар өчен табигый хәл. Әмма бер нәрсә бә-

хәсеэ: яшь композиторлар халык алдындагы җаваплылыкларын яхшы анларга, бүгенге музыка сәнгате казанышларыннан иркен файдалана белергә, үзләрен бай һәм күп милләтле совет музыка сәнгатенең тулы хокуклы вәкилләре итеп сизәргә тиешләр.

Бер нәрсәне истән чыгармаска кирәк, артык акрын темп белән иҗат итү куркыныч нәрсә, бушка узган гомерне берничек тә кире кайтарып алып булмый. Композиторның иҗат мөмкинлекләре бары армый-талмый туктаусыз эшләгәндә генә тулы көченә ачылырга мөмкин. Вакыт-вакыт кына эшләү дилетантлык билгесе. Бер кешенең дә үз талантын юк-барга әрәм-шәрәм итәргә хакы юк, чөнки талант ул халык байлыгы!

Яшьләрнең игътибарын спектакльләр өчен музыка язуга, бигрәк тә милли опера өлкәсенә юнәлдерәсе килә.

Яшь композиторлар татар музыкасын һәрьяклап үстерү мәсьәләләренә дәүләт күләменнән карап якын килә белергә, бүгенге көндә беренче чиратта торган мәсьәләләрне күрә һәм чишә белергә тиешләр.

Әле күптән түгел генә сәләтле яшьләрдән өч кешене — Ш. Шәрифуллинны, Л. Хәйретдинованы һәм А. Миргородскийны без Композиторлар союзына член итеп алдык. Әмма әлеге композиторларның, шулай ук студент-композиторларның аерым әсәрләрен тынлаганда күңелдә канәгатьсезлек хисе туа. Сүз дә юк, алар заманча, бай музыкаль тел белән язалар, әмма зур, масштаблы темаларга сирәгрәк мөрәҗәгать итәләр.

Яшь музыка белгечләре газеталар битендә һәм радио аша рецензияләр, популяр мәкаләләр, яшь композиторларның иҗат портретлары белән чыгышлар ясыйлар. Ләкин бу эшне киңрәк колач белән алып барырга кирәк. Музыка тәнкыйте секциясе каршында яшьләр өчен даими эшли торган семинар оештырырга кирәктер, ихтимал. Иң яхшы тәнкыйть мәкаләләренә һәм рецензияләргә конкурс оештыру турында да уйлап карарга ярый.

Филармониядә эшләүче талантлы җырчыларыбыз һәм музыкантларыбыз Казанда да, Советлар Союзының башка шәһәрләрендә дә сольный концертлар белән чыгыш ясарга тиешләр. Андый концертларның программаларын җирле авторларның әсәрләреннән генә төзергә ярамый. Яшьләребез классик музыканың һәм бүгенге музыка сәнгатенең иң катлаулы үрнәкләрен башкарырга сәләтле кешеләр.

Без яшьләр язган әсәрләрне тагын бер кат күздән кичерәчәкбез, үзебезнең яшьләр белән ничек эшләвебез хакында тагын бер кат уйлап караячакбыз. Бу пленум әнә шуңа этәргеч бирде.

Бүгенге көндә мөстәкыйль иҗат тормышларын башлап җибәргән яшь художниклар — сәнгатебезнең киләчәге. Алар турында кайгырту Художниклар союзы эшчәнлегендәге мөһим бурычларның берсе булып килде һәм шулай булып калачак та, диде Ә. Тумашев. Әгәр моңарчы республиканың сәнгать көчләре бер Казан шәһәрендә генә тупланган булса, хәзер сәнгать коллективлары Бөгелмә, Түбән Кама, Зеленодольск, Чаллы шәһәрләрендә, берничә генә ай элек Лениногорск шәһәрендә дә барлыкка килде.

Соңгы елларда яшьләр белән эшләүнең оештыру ягына игътибар сизелерлек яхшырды. Художниклар союзы каршында яшьләр комиссиясе төзелде. Әлеге комиссия Казанда һәм республика районнарында яшәүче 70 кә якын яшь художникны исәпкә алды, шуларның 20 се югары белемле кешеләр. Бу — зур мөмкинлекләре булган иҗади көч. Комиссия үзенең төп бурычын яшьләрнең иҗат активлыгын арттыруда, аларны күргәзмә эшчәнлегендә катнашуга тартуда күрә. Шуңа күрә 1967 елдан башлап без ел саен яшьләрнең республика күргәзмәләрен оештырып киләбез.

Соңгы елларда яшь художниклар «Зур Идел» зона күргәзмәсендә, В. И. Ленинның тууына 100 ел, республикабыз төзелүгә 50 ел тулу уңае белән оештырылган күргәзмәләрдә, Мәскәүдәге 16 автономияле республика художниклары, Ленинградта үткәрелгән «Совет Татарстаны», «Сатира тынычлык өчен көрәштә» исемле халыкара күргәзмәләрдә актив катнаштылар.

Бу елларда В. Скобеев, И. Зарипов, В. Федоров, Р. Имашев, А. Абзгильдин, Л. Насыйров, А. Садыйков, В. Денисов үзләрен кызыклы һәм үзенчәлекле художниклар итеп таныттылар. Аларның кайберләре Союзга член итеп кабул ителде.

Һәр художник, яшьме ул, әллә өлкән яшьтәге, танылган кешеме, идеологик фронт эшчесе. Беренче чиратта, ул партия эшенә ышанган һәм бирелгән, марксистик-ленинчыл дөньяга караш белән коралланган кеше булырга, үзенең әсәрләрен социалистик реализмның төп агымында иҗат итәргә тиеш.

Яшь художник безнең карамакка мәктәп, училище, югары уку йортын тәмамлагач килә, әмма бу әле аларны тәрбияләү буенча безнең өскә төшә торган җаваплылыкны киметми. Союз членнарын һәм художество фонды системасында эшләүчеләрне үзебездә булган политик укуларның барлык төрләренә тартабыз. Союзга һәм Фондка тартылмаган яшьләр белән эшләү кыенрак. Киләчәктә андый яшьләр белән эшләүнең дә иңиндидер формаларын табарга туры киләчәк.

Яшь художникларның профессиональ белемнәрен күтәрү дә мөһим мәсьәләләрдән санала. Яшьләрне Художниклар союзы каршындагы квалификацияне күтәрү студиясенә чакырабыз, барлык иҗат секцияләре аларга кирәкле ярдәм күрсәтергә әзер. Ләкин без монда яшьләргә үпкә белдерергә дә хаклы: алар студияләрдә сирәк булалар, секция утырышларында тәҗрибәле художниклар белән аз киңәшәләр. Профессиональ осталыкны күтәрүнең тагын бер мөһим формасы — тормышны өйрәнү, этюдлар, натурадан рәсемнәр ясау, иҗади командировкаларга бару. Художник тормышны тирәнтен өйрәнергә, үзе сурәтли торган хәлләрне үзе күрергә, йөрәге аша кичерергә тиеш.

Сәнгать белгечләренең хезмәтләре дә яшьләребез өчен бер мәктәп ролен үти алыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, сәнгать белгечләре художниклар белән индивидуаль эшләмиләр. Матбугатта басыла торган рецензияләрнең күбесе өстән-өстән языла,

аларның тегәл адресаты булмый, алар комплиментар характерда булалар.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, күп кенә яшь художникларыбыз иҗат эшенә житди карыйлар, кызыклы темаларны чишәргә алыналар. Алар үз геройларын Казан һәм Чаллы төзелешләрендә, республика колхозларында һәм нефть районнарында табалар. Әмма бу актив белән яшьләрнең төп массасы арасында шактый зур аерма бар. Күргәзмә комитетына тәкъдим ителгән эшләрне карагач, очраклы вакыйгаларга һәм вак темаларга караган әсәрләрнең шактый булуы күзгә ташлана.

Яшьләр иҗтимагый эшләрдә азрак катнашалар, күбесе тормышта гади күзәтүче булып калырга яраталар. Алар моның белән гражданин булып өлгерүләрен тоткарлыйлар. Иҗади яшьләр гражданлык җаваплылыгын, зур эш өчен җаваплылыкны арттырырга, идеология көрәшенең алгы сызыгына чыгарга тиешләр. Тормыш белән никадәр тыгызрак элемтәдә торсалар, аларның дөньяга карашлары шул кадәр тизрәк камилләшер, талантлары шул кадәр тизрәк ныгыр.

Безне алда яңа маршрутлар һәм яңа эшләр көтә. Без, республиканың яшь художниклары совет сынлы сәнгатенең үсешенә лаеклы өлеш кертерләр, дип ышанабыз.

Яшь актер, уку йортын тәмамлагач, нинди театрга эләгә — аның алдагы язмышы шуна бәйле, диде Р. Җиһаншина. Яшь актерның язмышы репертуарга, режиссерның осталыгына һәм башка күп нәрсәләргә бәйле. Монда бөтен нәрсә театр җитәкчеләренең нихәтле сизгер булуына, театрларның үзләрендәге яшь кадрларга нихәтле игътибарлы булуларына бәйләнгән.

Яшь актерларның табигый сәләтләре һәр очракта да дөрес файдаланыламы? Аларга ашыгып төп рольләрне бирү һәр очракта да үзен аклыймы? Еш кына бит шулай да була, режиссер актер талантының бер ягын күреп ала да, аны көн-төн эшкә җигә башлый, нәтиҗәдә яшь актер үз-үзен кабатларга тотына. Минә монда инде яшь кадрларның профессиональ осталыкларын үстерүгә игътибарлы мөнәсәбәт кирәклеге ачык күренә.

Актерларның профессиональ осталык дәрәҗәсен, аларның идея-теоретик белемнәрен күтәрү мәсьәләсе театрларның һәм ВТОның игътибар үзәгендә булырга тиеш. Соңгы өч елда ВТОның Татарстан бүлеге яшьләр өчен сәхнә теле, бию, сәхнә хәрәкәте, фехтование, грим буенча меңгә якын консультация оештырды. Моннан тыш яшьләр Мәскәүдә һәм Ленинградта даими эшләүче семинарларда булалар. Без шулай ук район театрларының яшь актерларын Казанга чакыруны да практикага кертә башладык.

Кызганычка каршы, бу өлкәдәге барлык мөмкинлекләр дә тиешенчә файдаланылмый әле. Яшь тамашачылар театрында, курчак, Минзәлә театрларында яшь актерлар белән эшләү планлы төстә алып барылса, Татар дәүләт академия һәм Зур драма театрларында бу эш үз агымына куелган, ә Опера һәм балет, Республика күчмә театрларында мондый ярдәм бөтенләй оештырылмый диярлек.

Югары профессионализм чын кешелек культурасы, интеллигентлык, иҗтимагый активлык кебек сыйфатлар белән чиратлашканда гына актер үз эшенең чын остасына әйләнә. Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм Актерлар йорты советы каршында яшьләр өчен төрле секцияләр оештырылды. Алар үзләренең эшләрендә иҗади яшьләрнең төрле ихтыяҗларын исәпкә алырга тырышалар. Ул секцияләр ВЛКСМ өлкә комитеты белән тыгыз элемтәдә эшлиләр.

Яшьләр белән ВТОның Татарстан бүлеге дә, театрлар да, иҗат союзлары да эшләргә тиеш. Бары тик шул вакытта гына яшь актер үзенең бөтен сәләтен ача алыр. 1969 елдан башлап үткәрелә башлаган республика смотрларының нәтиҗәләре әнә шул хакта сөйли. Әлеге смотрлар нәтиҗәсендә яшьләр белән эшләү яхшы куелган биш театр һәм тугыз артист бөтен Союз смотрында катнашу хокукы алдылар.

Ләкин, кызганычка каршы, смотрның файдалы булуын күрә торып та, кайбер театрлар аны үткәрү буенча инициатива күрсәтмиләр, өстән күрсәтмә биргәнне көтеп яталар.

Инде ВТОның яшьләр белән эшләү өлкәсендәге кимчелекле якларына килсәк, төп кимчелек шунда, без үткәрә торган чараларда яшь актерларның барысы да катнашмый, безнең активыбыз зур түгел.

Өлкән буыннар тудырган традицияләрне иҗади үстерү һәм дәвам иттерү, халыкка идея-эстетик тәрбия бирүдә партиянең ышанычлы ярдәмчеләре булу — яшьләребез алдында торган төп бурычлар әнә шул.

Докладлардан соң фикер алышу башланды. Фикер алышуларда «Казан утлары» журналының баш редакторы Г. Ахунов, В. Качалов исемендәге театр партия оешмасының секретаре, ТАССРның атказанган артисты Е. Кузин, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, скульптор В. Маликов, яшь композитор Л. Хәйретдинова, ВЛКСМ өлкә комитетының беренче секретаре И. Рахманкулов, яшь тамашачылар театры директоры А. Кичигин, тәнкыйтьче Р. Мостафин, М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солисты, ТАССРның атказанган артисты К. Гайнуллин, музыка белгече Г. Касаткина, драматург Т. Миннуллин, Казан кинохроника студиясенең баш редакторы Р. Копосов, Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге секретаре Ә. Маликовлар катнашты.

Пленумның икенче көнендә эш секцияләрдә дәвам иттерелде.

Пленум иҗади яшьләр белән эшләүне тагын да яхшырту юнәлешендә бик күп конкрет чаралар билгеләде, эш планы кабул итте.

Пленумда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев зур речь белән чыкты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Узган елның ноябрь башларында Татарстан язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булып узды. Республикабыз язучыларының ике сайлау ара-

сындагы иҗат эшчәнлеге турындагы докладны партия бюросының секретаре, язучы Г. Минский ясады.

Доклад буенча фикер алышуларда шагыйрьләрдән М. Садри, Ш. Маннур һәм М. Мазунов, Казанда яшәүче рус язучысы Т. Журавлев, тәнкыйтьче Р. Мостафин, Татарстан язучылар союзының пропаганда бюросы директоры М. Шаймөхәммәтов, Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире Ш. Рәкыйпов, Татарстан язучылар союзы идарәсе председателе З. Нури катнашты. Алар партия бюросының эшендәге унай һәм кимчелекле якларга тукталдылар, республикабыз язучыларының иҗат эшчәнлеген тагын да активлаштыруга юнәлдерелгән кызыклы фикерләр, файдалы тәкъдимнәр әйттеләр.

Отчет-сайлау җыелышы җиде кеше составында партия оешмасының яңа бюросын сайлады. Партбюро секретаре итеп язучы Г. Ахунов сайланды.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан язучылар союзы идарәсе каршындагы драматургия секциясенең чираттагы утырышында Азат Вергазовның яңа пьесасы укып тикшерелде. Әсәр буенча фикер алышуларда М. Мостафин, Р. Ишморат, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин һәм башка иптәшләр катнашты. Алар авторга әсәрен камилләштерү юнәлешендә файдалы киңәшләр әйттеләр.

* * *

Проза секциясенең октябрь ахырларында уздырылган утырышында Ә. Гаффаровның «Тозлы прәннекләр» исемле яңа повесте тикшерелде. Фикер алышуларда Г. Бәширов, Б. Камалов, Х. Сарьян, М. Насыйбуллин һәм башкалар катнашты.

Чыгыш ясаучыларның барысы да яшь авторның беренче повестеның шактый уңышлы булуын билгеләп үттеләр, авторга әсәрен тагын да яхшырту юнәлешендә киңәшләр бирделәр.

* * *

Шул ук секциянең ноябрь аенда уздырылган утырышында А. Вергазовның юмористик хикәяләре укып тикшерелде. Фикер алышуларда Ә. Еники, Ф. Хөсни, Х. Сарьян, Г. Шәрәфетдинов, Ф. Шәфигуллин, М. Насыйбуллин, М. Хуҗин һ. б. катнашты.

* * *

Ноябрь ахырларында «Казан утлары» журналы каршындагы яшь рецензентлар түгәрәгенең чираттагы утырышы уздырылды. Утырышта түгәрәкнең эш планнары тикшерелде, оештыру мәсьәләләре каралды.

* * *

Шул ук түгәрәкнең декабрь урталарында уздырылган тагын бер утырышы вакытлы матбугат битләрендә чыгып барган рецензияләрне тикшерүгә багышланган иде. «Казан утлары» журналында, «Социалистик Татарстан» һәм «Татарстан яшьләре» газеталарында басылган рецензияләр турында фикер алышуларда уннан артык кеше катнашты.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Мәскәү шәһәренең Некрасов исемендәге китапханәсе әледән-әле милли республикаларда яшәүче әдипләр белән очрашулар үткәреп килә. Ноябрь аенда тагын бер шундый очрашу уздырылды. Ул татар шагыйрьләре Х. Туфан һәм С. Хәкимнәр иҗатына багышланган иде.

Кичәдә татар шагыйрьләре яңа шигырьләрен укыдылар, башкала укучыларын үзләренең иҗат планнары белән таныштырдылар.

Мәскәүлеләр Татарстан шагыйрьләрен ифрат җылы каршыладылар, очрашу җанлы үтте.

* * *

12 октябрьда язучы А. Гыйләҗев Казан авыл хуҗалыгы институты студентлары белән очрашты. Ул студентларга үз иҗаты һәм татар әдәбияты турында сөйләде, аларның күп санлы сорауларына җаваплар бирде.

* * *

15 октябрьдан 19 октябрьга кадәр Пермь шәһәрендә театр житәкчеләре һәм драматургларның зона киңәшмәсе уздырылды. РСФСР Культура министрлыгы, Бөтенроссия театр җәмгыяте һәм Язучылар союзы оештырган бу киңәшмә 1973—1974 елгы театр сезоны йомгакларына багышланган иде. Татарстан язучылары исеменнән киңәшмәдә Р. Ишморат, Х. Вахит, А. Гыйләҗев һәм Т. Миңнуллиннар катнашты.

* * *

Октябрь аенда Минск шәһәрендә белорус язучыларының әсәрләрен башка телләргә тәрҗемә итү һәм пропагандалау буенча симпозиум үткәрелде. Анда, Татарстаннан вәкил булып, Ш. Рәкыйпов барды. Ул, симпозиумда катнашучылар белән бергә, Минск чит телләр институты студентлары алдында чыгыш ясады.

Илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән килгән кунаклар герой шәһәр Брестта, Хатынь мемориаль комплексында булдылар, Минск шәһәренең истәлекле урыннары белән таныштылар.

* * *

Октябрь аенда язучы Г. Ахунов һәм шагыйрь И. Юзеев Башкортстанда булып кайттылар. Алар Башкортстан язучыларының VII съездында катнаштылар, күренекле башкорт шагыйре Муса Галигә 50 яшь тулу уңае белән үткәрелгән кичәдә булдылар, Башкорт дәүләт университеты студентлары белән очраштылар.

* * *

ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты әледән-әле Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясе лауреатларының иҗат кичәләрен үткәреп килә. Шундый кичәләрнең берсе 26 ноябрьда шагыйрь И. Юзеев һәм Качалов исемендәге рус драма театры артисты И. Федотовлар иҗатына багышлап уздырылды.

Лауреатлар кичәсе тамашачыларда җылы тәэсир калдырды.

* * *

27 ноябрьда «Казан утлары» журналының поэзия бүлеге мөдире, шагыйрь И. Юзеев һәм журналның тәнкыйть бүлеге мөдире Ф. Миннуллин Казан дәүләт педагогия институты студентлары белән очраштылар.

Институтның татар әдәбияты кафедрасы мөдире, тәнкыйтьче Ф. Хатипов 1973 елда «Казан утлары» журналында басылган тәнкыйть материалларына күзәтү ясады. И. Юзеев яңа шигырьләрен укыды, Ф. Миннуллин тәнкыйть бүлегенең эше турында сөйләде.

* * *

1973 елның август аенда профсоюзлар Үзәк Комитеты секретариаты, СССР Язучылар союзы идарәсе белән берлектә, «Китап һәм бишьеллык» дигән темага китап укучылар конференцияләре оештыру турында махсус карар кабул иткән иде. Аның төп максаты — эшче образын чагылдырган иң яхшы әсәрләрне пропагандалау.

Татарстан язучылар союзының пропаганда бюросы әлеге карарны тормышка ашыру йөзеннән күп төрле чаралар оештырып килә. Ноябрь ахырында татар язучыларының Н. Дәүли, М. Мәһдиев, Б. Камалов, Р. Мингалимов, К. Тимбикова һәм М. Шиһаповлар составындагы бер бригадасы Түбән Кама, Яңа Зәй, Әлмәт, Азнакай, Лениногорск, Бөгелмә районнарында булып кайтты. Алар әлеге районнарның хезмәт иялəре белән очраштылар, мәктәп һәм техникум укучылары алдында чыгыш ясадылар.

* * *

15 ноябрьда Р. Ишморатова Казан шәһәренең Вахитов исемендәге китапханәсендә укучылар белән очрашты. Очрашу вакытында ул «Милиция лейтенанты» исемле әсәрен ничек язуы турында сөйләде, укучыларның сорауларына җаваплар бирде.

Шундый ук очрашулар Казан шәһәренең Совет, Вахитов һәм Идел буе районнарындагы, республиканың Кукмара, Апас, Балтач районнарындагы милиция идарәләренең хезмәткәрләре белән дә үткәрелде.

## ӘДӘБИ-МӘДӘНИ БӘЙРӘМНӘР

Узган ел күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Мөхәммәт Гайнуллинга 70 яшь тулды. Республикабыз җәмәгатьчелеге галимнең иҗат бәйрәмен киң күләмдә билгеләп үтте. Газета-журналларда аның иҗат эшчәнлегенә багышланган мәкаләләр басылды, Татарстан радиосы һәм телевидениесе махсус тапшырулар оештырды.

Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре үзләренең октябрь аендагы бер утырышларын М. Гайнуллинның иҗат эшчәнлегенә багышлап уздырдылар. Каләмдәш дуслары галимнең хезмәтләренә югары бәя бирделәр, аңа кыйммәтле бүләкләр тапшырылды, тәбрикләү хатлары укылды.

Филология фәнен үстерүдәге хезмәтләре, нәтиҗәле җәмәгать эшчәнлеге өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән, филология фәннәре докторы, профессор, СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни сотрудникы Мөхәммәт Хәйрулла улы ГАЙНУЛЛИН КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

* * *

1973 елда дөньяның бик күп илләре молдаван халкының бөек улы, талантлы язучы, күренекле җәмәгать эшлеклесе, күп кырлы галим Дмитрий Кантемирның тууына 300 ел тулуны билгеләп үттеләр.

Безнең илебездә Дм. Кантемирның тууына 300 ел тулуга багышланган бәйрәм тантаналары башкалабыз Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясенең тарих институты оештырган фәнни конференция белән башланып китте.

Аннары бу бәйрәм Молдавиягә күчте. 15—23 октябрьда Молдавия фәннәр академиясенең төрле институтларында, югары уку йортларында галимнең тормышына һәм иҗатына багышланган фәнни конференцияләр, симпозиумнар үткәрелде. 26 октябрьда А. С. Пушкин исемендәге дәүләт театры бинасында республика күләмендәге тантаналы җыелыш булды.

Дм. Кантемирның 300 еллыгына багышланган тантаналарда катнашу өчен илебезнең төрле өлкәләреннән һәм республикаларыннан бик күп кунаклар чакырылган иде. Безнең республикадан бу бәйрәмдә Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән гыйльми сотрудникы, филология фәннәре кандидаты Ә. Кәримуллин катнашты. Ул фәнни конференциядә «Дмитрий Кантемир — Россиядә гарәп шрифтлары белән китап басуга нигез салучы» дигән темага доклад белән чыкты, Молдавия фәннәр академиясенең гомуми җыелышында «Дм. Кантемир һәм Шәрыкне өйрәнү» дигән темага информация ясады.

* * *

16 ноябрьда Язучыларның Тукай исемендәге клубында күренекле татар совет язучысы Мөхәммәт Галинең тууына 80 ел тулу уңае белән әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Бу кичәдә язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Гайнуллин эчтәлекле

доклад ясады. Язучының замандашлары истәлекләр белән чыктылар. Кичәнең тантаналы бүлегеннән соң зур концерт булды.

## КҮЧМӘ ТЕАТРГА 40 ЕЛ

Татар дәүләт республика күчмә театрының төзелүенә 40 ел тулды.

Беренче адымнарын данлы бишьеллыклар чорында атлаган театр, илебез, халкыбыз белән бергә, зур үсеш юлы узды.

Оешуның беренче көннәреннән үк Күчмә театр югары идеяле чын сәнгать әсәрләренә йөз тотты. Тамашачыны татар драматургларының, рус һәм дөнья классикларының, шулай ук тугандаш халыклар драматургиясенең иң яхшы әсәрләре үрнәгендә тәрбияләде.

Культурабыз үсешендә тирән эз калдырган күп кенә режиссерларыбызның, художникларның, композиторларның иҗат эшчәнлеге Күчмә театр белән якыннан бәйләнгән.

Оешып эшли башлаган елларда театрның иҗат көчләре нибары 10—12 кешедән тора иде. 40 ел дәвамында аның составы гел үсә, тулылана, ныгый барды. Бүген Күчмә театр үз составында утыздан артык артисты булган зур бер иҗат коллективына әйләнде. Алар арасында бөтен гомерләрен шушы театрга багышлаган фидакарь кешеләр күп. Сәхнәдә озак еллар эшләп, тамашачыларның тирән мәхәббәтен яулаган сәнгать осталарыннан М. Рәхмәтуллина, Б. Галиуллина, З. Камалова, М. Хәмзин, Г. Гыйматов, М. Шаһидуллина, С. Исмәгыйлова, Ф. Юнусов, Л. Фарсина, Ф. Фарсин, Г. Нуруллиннарга Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелде. Театрның режиссерларыннан Ә. Мәҗитов Татарстан АССРның атказанган артисты, К. Тумашева белән Р. Тумашев һәм театрның баш художнигы П. Баландин Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.

Үзенең 40 еллыгына театр һәр яктан өлгергән, житлеккән, таза иҗат коллективы буларак килде. Бәйрәмне ул зур планнар, якты өметләр белән каршылый.

Татар дәүләт республика күчмә театрының 40 еллыгына багышланган бәйрәм кичәсе ноябрь аенда Актерлар йортында үткәрелде.

## ЯҢА БЕРЛӘШМӘ

Алабуга шәһәрендә чыга торган «Яңа Кама» («Новая Кама») исемле газета редакциясе каршында әдәби берләшмә төзелде. Ул үз тирәсенә унбишләп яшь һәм башлап язучыны туплады. Алар арасында Алабуга дәүләт педагогия институты студентлары, Алабуга культура-агарту училищесы укучылары, милиция мәктәбе курсантлары, шәһәр предприятиеләренең эшчеләре һәм хезмәткәрләре, журналистлар бар.

Әдәби берләшмәгә СССР Язучылар союзы члены М. Лукин житәкчелек итә.

Күптән түгел әдәби берләшмәнең беренче утырышлары уздырылды. Анда милиция мәктәбе курсанты Ю. Изместьевның, педагогия институты студентлары С. Семин һәм В. Путятинскийның, Түбән Кама нефтехимия техникумы укучысы Н. Шәриповның, икмәк заводы шоферы В. Платоновның, тегү фабрикасы эшчесе Р. Батырованың яңа әсәрләре тикшерелде.

Берләшмә члennарының иң яхшы әсәрләре «Яңа Кама» газетасы битләрендә басылып барачак.

## ЗӘКИ НУРИ ШИГЫРЬЛӘРЕ КАЗАКЪ ТЕЛЕНДӘ

Казагыстанның «Язучы» нәшрияты, «Ак Идел» дигән исем белән, татар совет шагыйре З. Нуриның шигырьләрен аерым җыентык итеп бастырып чыгарды. Җыентык өч бүлектән тора («Күңел дәфтәреннән», «Мәхәббәт дәфтәреннән» һәм «Сатира һәм юмор дәфтәреннән»).

Шигырьләрне казакъ теленә күренекле шагыйрьләр тәрҗемә иткән. Тәрҗемәчеләр арасында Ж. Молдагалиев, С. Сәетов, А. Дуйсембиев кебек шагыйрьләр бар.

Китапның тиражы 6800 данә, бәясе 53 тиен.

## КАЗАКЪ-ТАТАР ӘДӘБИЯТЛАРЫ БӘЙЛӘНЕШЕ

Алма-Атаның «Наука» нәшрияты «Казакъ әдәбияты һәм аның интернациональ бәйләнешләре» исемле яңа китап чыгарды. Анда казакъ әдәбиятының башка тугандаш әдәбиятлар белән булган бәйләнешләрен яктыртуга багышланган мәкаләләр тупланган.

Филология фәннәре кандидаты Б. Исхаков мәкаләсе исә казакъ һәм татар әдәбиятларының үзара бәйләнеше хакында сөйли. «Казакъ-татар әдәби бәйләнешләренең үсеш этаплары» дип исемләнгән ул мәкаләдә безнең әдәбиятлар арасындагы үзара бәйләнешләрнең барлык этаплары яктыртыла.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Узган елның ноябрь аенда Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры тамашачыларга күренекле язучыбыз М. Әмирнең «Агыйдел» повесте буенча эшләнгән спектакль күрсәтә башлады. Спектакльдә театрның төп көчләре катнаша. Гаяз ролен Наил Дунаев, Ильяс ролен Хәлим Җәләлов, Артыкбикә ролен театрның яшь артисткасы Рәмзия Хисамова башкара.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты М. Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәгә куелган бу спектакльне тамашачылар җылы каршылады.

## ТАТАРЧА ФИЛЬМ

Республикабыз экраннарында «Надежда» исемле яңа нәфис фильм күрсәтелә башлады. Бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның һәм Н. К. Крупскаяның яшьлек елларын, аларның революцион көрәш юлындагы тәүге адымнарын сурәтләүгә багышланган бу фильм Казан кинохроника студиясендә татарчалаштырылган.

Фильмда В. И. Ленин ролен Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты Р. Тажетдинов, Н. К. Крупская ролен Татарстанның атказанган артисты, Г. Тукай исемендәге премия лауреаты Н. Гәрәева татарчалаштырган.

Фильмның сценарием татар теленә РСФСРның халык артисты Г. Шамуков тәржемә иткән, режиссеры — Татарстанның халык артисты Ф. Шәрәфиев.

### ТУГАН ЯК МОҢНАРЫ

Казан спорт сараенда өч көн дәвам иткән зур концертта Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең сәхнә йолдызлары катнашты. Концертны Татарстан җыр һәм бию ансамбле башлап җибәрде. Башка еллардагы берләштерелгән концертлардан аермалы буларак, бу юлы нәфис сүзгә тиешле урын бирелгән иде. Концертны танылган сүз остасы Фәйзи Юсупов һәм Нажия Минкина алып барды. Аларның юморга бай чыгышлары күңелле кичәгә тагын да ямь өстәде. Һади Такташ, Муса Җәлил кебек күренекле шагыйрьләребезнең юмористик шигырьләре концертны баетты, эчтәлеклерәк итте.

Бу концертта ТАССРның халык артистлары Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, ТАССРның атказанган артисты Габдулла Рәхимкулов, филармония солисткасы Флера Сөләйманова репертуарында күп кенә яңа җырлар бар иде. М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры артистлары Фәйтүнә Абдуллина, Ревдар Садыйковның «Су буенда очрашу», шулай ук бертуган Рәис һәм Фәрит Кәбировларның кашык белән русча бию һәм «Әтәчләр» исемле биюләрен тамашачылар җылы каршыладь.

Концерт Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Туган ягым» (Р. Яхин музыкасы, Р. Байтимеров сүзләре) исемле җыры белән тәмамланды.

### ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Узган елның октябрь аенда нефтьчеләр шәһәре Әлмәт үзенең 20 еллыгын бәйрәм итте. Шул уңай белән нефтьчеләр предприятиеләрендә, төзелеш оешмаларында, мәктәпләрдә тантаналы җыелышлар, юбилей кичәләре үткәрелде. Бу тантаналарда Әлмәттә яшәүче язучылар да актив катнашты. Ю. Әминов 14 нче мәктәп, Ә. Маликов 16 нчы мәктәп, Р. Төхфәтуллин 1-ГПТУ укучылары янында булдылар. Алар укучыларга бүгенге татар әдәбиятындагы яңалыклар турында сөйләделәр, үз әсәрләреннән өзекләр укыдылар.

* * *

Октябрь аенда Әлмәт мәктәпләрендә татар әдәбияты һәм татар теле укытучыларының семинары үткәрелде. Семинар эшендә драматург Ю. Әминов та катнашты. Ул «Казан утлары» журналының 1973 елгы саннарында басылган әсәрләргә кыскача күзәтү ясады, үзенең иҗат планнары белән уртаклашты.



Шагыйрь ХӘСӘН ТУФАН.
Ф. Әминев

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210